# Казан утлары

МАЙ № 5
1966

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ

*КЫРЫК БИШЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА*

5

МАЙ

1966

## Бу санда:

ПАРТИЯ ЧАКЫРА

А. Булгаков. Шулай булачак. . . . . . . . . 3
Г. Бакир. Канатландыргыч карар. . . . . . . 4
Г. Галиев. Быелгы яз. . . . . . . . . . 5

ПОВЕСТЬ, ХИКӘЯ ҺӘМ ШИГЪРИ ӘСӘРЛӘР

А. Гыйләҗев. Бераү. Повесть. Башы. . . . . . 9
Х. Камалов. Әнкәй истәлеге. Шигырь. . . . . . 41
Г. Мөхәммәтшин. Изге Галиәкбәр. Хикәя. . . . 48
С. Баттал. Чирмешән якларында. Шигъри роман. Ахыры. . . . . . . . . . . . . . . 59

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

М. Гаскәров. Парчалар. . . . . . . . . . 69
Р. Гатауллин, З. Шәйхулов, Е. Уткин шигырьләре. . . . . . . . . . . . . . . 71

ХАЛКЫБЫЗНЫҢ БАТЫР УЛЛАРЫ

С. Шакир. «Безне онытмасыннар иде». . . . . . 77

СӘНГАТЬ КЕШЕЛӘРЕ

Г. Рябков. Театр яшьтәше. . . . . . . . . 82

ПУБЛИЦИСТИКА

Г. Гобәй. Коръән серләре. Дәвамы. . . . . . 89
...әләре. Дәвамы

КПССның
ТАТАРСТАН ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

1965 ӘДӘБИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ МАТЕРИАЛЛАРЫ

Ф. Миннуллин. Без кичәсе үрләр . . . . . . 113
Ә. Маликов. Нәниләр өчен . . . . . . . . . 120
Н. Гыйззәтуллин. Очерк — заман юлдашы . . . 124
Заман яхшырак әсәрләр сорый . . . . . . . . 129

ГАБДУЛЛА КАРИЕВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Х. Кумысников. Якты йолдыз . . . . . . . . 133
З. Тинчурина. Безнең Кариев . . . . . . . . 140
Син безнең күңелләрдә . . . . . . . . . . . 144

ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ ТИРӘСЕНӘ

Ш. Маннур. Муса үзе сорады кебек . . . . . . 145

ТӨРЛЕСЕННӘН

Ә. Кәримуллин. Әдәби мирас һәм библиография 150

Яна китаплар . . . . . . . . . . . . . . . . 153
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . 156

*Редакциягә килгән кульязмалар кире кайтарылмый.*

---

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана 19, Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-68-21, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

# Партия чакыра

## ШУЛАЙ БУЛАЧАК!

*Заманында Маяковский илебез планнарының зурлыгын яратуы турында әйткән иде. Һәм без — бөтен совет халкы — барыбыз да аларның зур булуы белән горурланабыз. Шулай да без эшләребезнең һәм максатларыбызның бөеклегенә күнегеп тә беткәнбез инде, һәм бу безне күп вакыт таңга да калдырмый. Аннары шундый зур масштабларны, шундый зур саннарны кеше аңы тиешенчә иңләп тә бетерә алмый бит!*

*Яңа Бишьеллык планда менә шундый кыска гына бер юл бар:*

| | 1965 ел | 1970 ел |
|---|---|---|
| Электр энергиясе (миллиард киловатт-сәгать) — | 507 | 830—850 |

*Әйдәгез, шушы саннар хакында уйланып карыйк әле. Электр энергиясе җитештерүнең әһәмиятен без беләбез: «Коммунизм — Совет власте плюс бөтен илне электрлаштыру ул». (В. И. Ленин.) Яңа Бишьеллыкның никадәр зур масштаблы булуын күз алдына китерү өчен, хәзер артка әйләнеп карыйк. Патша Россиясенә түгел — ул инде күптән мәңгелеккә киткән заман — ә үзебезнең Совет власте чорына күз салыйк. Чыннан да, чагыштырырлык нәрсәләр күп монда. 1940 нчы ел. ГОЭЛРО — Советлар республикасының халык хуҗалыгын үстерүнең беренче планы — инде берничә мәртәбә арттырып тормышка ашырылган, ике бишьеллык уңышлы рәвештә үтәлгән. Ә ул чакта безнең бөтен илебез елына 48,3 миллиард киловатт-сәгать электр энергиясе җитештерә иде. Бик күп бу. Ләкин хәзер нибары биш ел эчендә генә дә электр энергиясен 333—343 миллиард киловатт-сәгатькә үстерү планлаштырылган. Кырыгынчы ел белән чагыштырганда — җиде мәртәбә артык дигән сүз!*

*Бу Бишьеллык планның безгә, Совет Татарстанында яшәүчеләргә, аеруча якын булган икенче бер юлына игътибар итик:*

| | 1965 ел | 1970 ел |
|---|---|---|
| Нефть (миллион тонна) — | 243 | 345—355 |

*Нефть турында фикер йөрткәндә, Октябрьга кадәрле чорга игътибар итәргә дә ярыйдыр. Россия ул вакытта иң күп нефть җитештерүче ил иде бит. 1913 елда ул аны 10,3 миллион тонна, ягъни безнең бишьеллык планда каралганның, якынча, йөздән өч өлешен чыгара иде. Совет власте елларында нефть чыгару туктаусыз үсеп килде. Моннан нибары унбиш ел гына элек, 1950 елда, без 37,9 миллион тонна нефть чыгар-*

*дык. Ә 1970 елда нефть чыгару 1950 елга караганда ун тапкырга якын артырга тиеш!*

*Чыннан да искиткеч, зур саннар болар. Һәм һәр сан чыклы фәнни исәпкә нигезләнгән.*

*Бишьеллык планда куелган төп бурычлар да искиткеч зур. Менә фән үсешенә багышланган бүлектәге бер пункт: «Теоретик һәм практик математика өлкәсендә математик методларны фәннең һәм техниканың төрле тармакларында киң куллануны тәэмин итәрлек тикшеренүләрне үстерергә».*

*Киң куллану. Бу — якын елларда безнең фәнебезгә һәм техникабызга яшен тизлеге белән хәрәкәт итә торган, гаҗәеп үзенчәлекләргә ия булган, күп кенә катлаулы электронлы машиналар киләчәк дигән сүз. Һәм бу хәл безнең материаль җитештерүебездә, безнең планлаштыруыбызда без моннан ун ел элек күз алдына да китерә алмаган зур мөмкинлекләр тудырачак.*

*Бишьеллык планның тагын бер пункты: «...Атом-төш физикасы методларын фәннең һәм техниканың төрле тармакларында киң файдалану, идарә ителешле атом-төш синтезы проблемаларын эшләүне дәвам иттерү, яңа конструкцион һәм башка материаллар булдыру максатында атом-төш физикасы һәм каты җисемнәр физикасы буенча тикшеренүләрне үстерергә».*

*Идарә ителешле атом-төш синтезы — хәзерге фәннең иң зур һәм катлаулы проблемаларыннан берсе. Аны хәл итү өчен, безнең галимнәребезгә монда, үзебезнең Җирдә, табигать Кояш үзәгендә тудырган температурага һәм басымга якын температура һәм басым булдырырга кирәк. Кояш үзәгендә! Ә без, күзебезне капламыйча, миллионнарча километр ераклыкта булган Җирдән торып та Кояшның хәтта тышына да карый алмыйбыз бит! Һәм безнең галимнәр менә шушы астрономик шартлар белән идарә итәчәкләр. Ә совет кешесе энергетика һәм техника өлкәсендә моннан унбиш ел элек хыялланырга да батырчылык итмәгән мөмкинлекләргә ия булачак.*

*Бу кечкенә мәкаләдә сүз яңа Бишьеллык планның нибары дүрт пункты турында гына барды. Ләкин бу пунктлар артында әле күптән түгел генә фантастлар язган эшләр тора. Хәзер ул эшләр — безнең Законыбыз. Законга язылган икән, без инде беләбез — тормышта да шулай булачак!*

А. БУЛГАКОВ.

# КАНАТЛАНДЫРГЫЧ КАРАР

*Җидееллык планның уңышлы тәмамлануы илебез халыкларын яңа казанышларга дәртләндереп җибәрде. Без алдагы Бишьеллык план буенча КПССның XXIII съезды кабул иткән карарларны зур канәгатьләнү белән каршыладык.*

*Гадәттә саннар күп кабатланганда, ялыга башлыйсың. Ләкин бу планда китерелгән саннар ялыктырмый, киресенчә, аның һәрберсе уйландыра, һәрберсе кызыксындыра.*

*Мин биредә саннар китерергә җыенмыйм. Шулай да кайберләрен искә алмыйча үтеп китә алмыйм. Әйтик, зур казанышлар яулап алган промышленностебыз алдагы бишьеллыкта 1,5 тапкыр үсәчәк. Советлар Союзының милли доходы 38—41 процентка артачак. Бу саннарга ничек сокланмыйсың! Совет кешеләренең реаль доходы җан башына 1,3 тапкыр артачак. Бу күтәрелеш кемне генә шатландырмас икән!*

*Бүтән саннар китермим, ләкин истән чыгармыйк, бу казанышлар үзеннән-үзе генә киләчәк түгел, һәр адым, күтәрелгән һәр баскыч совет*

*кешеләренең күп көч түгүен, һәркемнең намуслы хезмәт өлеше керүен таләп итәчәк!*

*Промышленность һәм авыл хуҗалыгының проектта күрсәтелгән баскычына күтәрелүе совет кешеләренең культура дәрәҗәләре үсү белән бергә барачак, әлбәттә. Бу хәл әдәбият һәм сәнгать эшчеләре алдына да зур бурычлар куя. Безнең алда торган эшләрне саннар белән күрсәтеп булмый. Ләкин шунысы ачык: зур эшләр тора алда. Бер сүз белән әйткәндә, хәзерге чор кешеләрен канәгатьләндерерлек әсәрләр бирергә кирәк. Бөек Октябрьның 50 еллыгына, В. И. Ленинның 100 еллыгына лаеклы әсәрләр иҗат итәргә кирәк.*

*Кайберәүләр, соңгы елларда киң җәелеп киткән радио-телевидение әдәбиятны кысрыклый, укучылар китаптан читләшә, дип уйлыйлар. Бу дөрес түгел. Соңгы елларда хезмәт ияләре әдәбиятка шактый якын килде. Шәһәрләрдә генә түгел, хәтта иң ерак авыл почмакларында да өй саен диярлек китап шүрлеге бар. Бу — шатландыргыч хәл. Газета-журналларыбызның тиражлары елдан-ел үсә бара. Бу шулай ук укучыларыбызда культура дәрәҗәсенең күтәрелүен, әдәби зәвыкларының үсүен ачык күрсәтә.*

*Алдагы Бишьеллыкта әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә дә зур күтәрелеш билгеләнә: мәктәпләр, китапханәләр саны артачак, авыл һәм шәһәрләребездә яңа клублар, яңа культура сарайлары салыначак, радиотелевидение челтәре тагын да киңәячәк, шәһәрләрдә генә түгел, хәтта авылларыбызда да, йорт саен диярлек тылсымлы көзгеләр — телевизорлар булачак.*

*Якын көннәрдә телестудиябезнең ике программа белән эшли башлаячагын искә алмыйча булмый. Телисең икән, спорт ярышларын карап утыр, телисең икән, рәхим ит — кино кара, тик тиешле кнопкасын гына басарга онытма!*

*Шәһәр тирәсендә үскән яңа йортларны, яки кыр уртасында яңа салынган шәһәрләрне күргәч, гадәттә: «Менә бу урыннарда, әле күптән түгел генә, тәбәнәк иске агач йортлар иде», яки «Бу шәһәр урынында шайтан таяклары гына үсеп утыра торган иде!» дип аңлатасың! Хәзерге яшь буын шулай аны күз алдына китерә ала. Ләкин революциягә кадәр булган иске тормышны димим, хәтта Ватан сугышы алдындагы көннәр не генә дә ачык күз алдына китерә алмый торган яшьләр тормыш гел шулай хәзерге кебек матур булып килгән кебегрәк уйлыйлар. Шуңа күрә кайберәүләрнең хәзерге казанышларга тиешле бәя биреп җиткермәүләре дә мөмкин. Ләкин иске тормышның бөтен авырлыкларын үз җилкәсендә татып үткәргән өлкән буын хәзерге мул, якты тормышның тәмен ачыграк сизә, аның кадерен яхшырак белә. Шуңа күрә мин, өлкән буынның бер вәкиле буларак, хәзерге казанышларга зур бәя бирәм һәм алдагы Бишьеллык план буенча билгеләнгәннәргә тагын да матуррак өметләр баглыйм. Бөтендөнья күләмендә тынычлык даулап килүче совет кешеләренең бу исткиткеч зур планны да уңышлы үтәп чыгачагына нык ышанам мин.*

Г. БАКИР.

# БЫЕЛГЫ ЯЗ

*Аеруча матур килгән быелгы яз башларында — беренче кар сулары киткән, беренче сыерчыклар килгән чакларда — мин Бөгелмә якларында командировкада идем. Үзенә бертөрле җылы һәм дымык һавалы көннәрнең берендә, кич белән, мин шактый күп гомер иткән, шулай булгач, күп нәрсәләр, күп вакыйгалар күргән олы гына яшьле бер агай белән сөйләшеп утырдым. Безнең сүзебез Совет*

*властеның беренче еллары турында, шул чорның кыенлыклары һәм шул кыенлыкларны җиңеп чыккан халкыбыз турында бара иде. Без шулай сөйләшеп утырганда, өйдәгеләрнең берсе кинәт урыныннан кузгалды һәм, репродуктор янына барып, аны уңга таба борды. Радиодан татарча концерт бирәләр иде. Менә бер вакыт диктор:*

*— Марс Макаров язган «Киек казлар» җырын тыңлагыз! Шагыйрь Хәсән Туфан сүзләре, җырлый Нәфисә Василова! — диде.*

*Искиткеч тирән фәлсәфи фикерләр, бик таныш моңнар, ашкынулы алга омтылулар, ярсу дәртләр һәм тагы әллә ниләр белән өртелгән бу көйнең бик кыска вакыт эчендә халык йөрәгенә кереп урнашканлыгын мин яхшы белә идем. Бөтен өй эче тынып калгач, әлеге көйнең матурлыгына, халыкның аны гаҗәп яратып тыңлавына тагы бер тапкыр ышандым. Әйе, кешеләрнең йөрәкләренә керә белергә кирәк шул, дидем мин үз-үземә. Әлеге агай көйне тыңлап бетергәч, миңа карап куйды:*

*— Шагыйрь Туфан җыры дидеме әле? Шулай... Моны язган кеше синең эчеңне-бавырыңны белә икән, — диде.*

*Агайның «эчеңне-бавырыңны белә икән», дигән сүзләренең төп мәгънәсе кешенең эчке уйларын өйрәнергә кирәклеккә кайтып калганлыкны монда аңлатып торуның хаҗәте юк булса кирәк.*

*Безнең партиябез гомер-гомергә нәкъ менә халыкның эчке уй, теләкләрен, аның һәм материаль, һәм рухи ихтыяҗларын өйрәнеп, аның көченә таянып эш итте.*

*Концерт тәмам булгач, агай белән безнең арада башланган сүз яңадан дәвам итте. Без яңа Бишьеллык планның авыл хуҗалыгы турында билгеләнгән гаять дәрәҗәдә зур рубежлары турында сөйләштек. Ул бу бик олы документны чын күңеле белән куанып каршы алганлыгын әйтеп:*

*— Партия башлаган эш — бөтен халык эше. Аны үтәргә бөтен халык тотына. Ә инде халык тотына икән, ул эш, һичшөбһәсез, җиңү белән тәмам була. Син революцияне алып кара, туган. Без бит аны тозсыз аш, яфрак чәй, сәләмә өс-баш белән башлаган идек. Җитмәсә тагы, безнең өстебезгә ничәмә илнең капиталистлары ябырылды. Мәгәр җиңеп чыктык бит. Чөнки халык партия ягында, партия халык ягында булды. Партия халык белән аралашты. Менә шуңа күрә җиңеп чыктык та, — диде.*

*Дөрестән дә, безнең Партиябез үзенең бөтен эшен халыкка таянып, аның ярдәменә нык ышанып башлый. Яңа Бишьеллык планны мин үзенең тамырлары белән киң халык массасы арасына керә һәм аларны тагы да матуррак, тагы да баерак яшәүгә чакыра торган бер поэма итеп карыйм. Матур әдәби әсәрләрне укыганда синең күңелеңдә бер-бер артлы ләззәтле уйлар туган кебек үк, бу планны өйрәнгәндә дә шундый ук көчле хисләр уяна, шундый ук уйланулар кузгала. Менә шуларның кайберләрен мин әйтеп узар идем. Мин монда бигрәк тә авылга кагылышлы кайбер мәсьәләләргә генә тукталып идем. Республикабыз авыл хуҗалыгы хезмәт ияләренең соңгы еллардагы уңышлары турында укучылар инде беләләр. Мин шул уңышларны тагын күбәйтергә мөмкинлек бирә торган мәсьәләләр турында, ачыграк әйткәндә, тормышның төп чыганагы булган һәм мәңгегә шулай булып калачак җир турында, аннан тиешенчә файдалана алмавыбыз хакында әйтер идем. Бездә, атап әйткәндә, үзебезнең Татарстан республикасы территориясендә, аеруча авыл араларында, ягъни ындыр артларында, елга буйларында никадәр кадерле җирләр буш ята. Без ни өчен алардан файдаланмыйбыз соң? Ачык кына итеп әйткәндә, без бу мәсьәләгә күңел куеп җиткермибез. Ә бит төптәнрәк уйлап карасаң, бер уч туфракта да нинди дә булса файдалы бер үсемлек үстереп була лабаса.*

*Яки менә бакчачылыкны алга җибәрүне алып карыйк. Инде без ничәмә еллардан бирле бакчачылыкның файдалылыгы турында сөйли-*

*без. Ничәмә еллардан бирле «Бакчачылык айлыклары» үткәреп килә- без. Шуңа да карамастан, бу эш бик акрын бара. Әгәр без республика- быз колхозларын алып карасак, алар арасында бакчачылык белән дан тоткан хуҗалыкларны бармак белән генә саный алырбыз. Ә бит моның өчен безнең республикабызда да бик уңай шартлар бар. Мәсәлән, без Ык буендагы авылларны гына алып карыйк. Аларның берсе дә бакча- чылык белән тиешенчә шөгыльләнми диярлек бит. Әйтик, Ык буендагы Чәкән, Стәрле, Сөендек, Сарлы, Сасы Күл, Күк Тәкә, Тымытык, Урсай һ. б. авылларның кайсысында бакчалар чәчкә ата? Минемчә, боларның берсендә дә бу эш тиешле юлга салынмаган. Ә шушы авылларның итәк- ләреннән агып үткән Ык буенда, ягъни аның яр буйларында табигый рәвештә үсеп утыра торган карлыган куаклары азмыни! Сүз уңаенда кызыклы гына бер фактка тукталасым килә. Мин Сасы Күл авылы, «Алга» колхозының Миргазыян Гыйләҗев фамилияле бер бик тырыш кешене белә идем. Ул моннан ике-өч ел элек кенә үлеп китте. Менә шул кеше 1960 елда Ык буеннан 125 төп карлыган куагы төпләп алып кайтып үз ишек алдына утыртты. Икенче елны ук ул шушы куаклар- дан егерме-егерме биш чиләктән артык карлыган җыеп алды. Аның бак- часындагы карлыган үзенә дә, кардәшләренә дә, дус-ишләренә дә җитте. Ә менә колхоз ни өчендер бүгенгә кадәр шушы файдалы эшкә тотына алмый. «Алга» колхозы, район күләмендә генә түгел, ә республикабыз- да мактаулы урында тора. Ләкин аның бик күп резервлары файдала- нылмыйча ята бирә әле.*

*Инде авыл җирләрен төзекләндерү, колхозчыларга, совхоз эшчелә- ренә торак йортлар салу турында берничә сүз. Бишьеллык планда ка- ралган гаять әһәмиятле бурычлар, искиткеч зур эшләр белән кызыксы- нып утырганда, мин үземнең архивымда саклана торган бер бик иске документка күз төшердем. Бу элекке Самара губернасы, Бөгелмә өязе, Чәкән волостена керә торган Яңа Урманай авылын төзүнең 1891 елда губернатор, архитектор, инженер, землемер һәм башка шундый күп ке- нә чиннар тарафыннан расланган планы. Ул планда күрсәтелгән- чә, 200 хуҗалыкны тупларга тиешле бу авылда ике мәчет, бер зират һәм бер үләксә базыннан башка берниндн дә җәмәгать каралтысы юк. Ә бит безнең хәзерге авылларыбызда төп урынны мәктәп, клуб, уку йорты, китапханә кебек аң-белем йортлары һәм балалар бакчалары, ясле, медпункт шикелле һәртөрле тәрбия, дәвалау биналары алып тора. Уйлап карасаң, аптырыйсың: элекке авыл белән хәзерге авыл арасында никадәр аерма! Ә бит безнең авылларыбызның киләчәге тагы да ма- туррак, тагы да ямьлерәк. Яңа Бишьеллыкта авылларны төзекләндерү- гә, колхозчыларны торак белән тәэмин итүгә бик зур суммалар тоты- лачак. Ләкин бу уңай белән шуны әйтәсе килә, авылда торак йортлары салганда колхозчы тормышының үзенчәлекләре искә алынсын иде. Әй- тик, колхозчы хуҗалыкны ишек алды тирәсе җиреннән, абзар-курадан, кар базыннан башка әле күз алдына китерү мөмкин түгел. Менә бу мәсьәләне кат-кат уйлап карарга һәм авылларда төзеләчәк йортларның ничә катлы булырга тиешлекләрен шулардан чыгып билгеләргә кирәк- тер. Чөнки авылның аның үзенең башка җирләрдән аерылып торган үзенчәлекләре бар бит. Югарыда әйтелгәнчә, аңа кар базы да, бәрәңге базы да, чолан да, хәтта кечкенә генә келәт тә кирәк әле.*

*Элекке авылның өлгеләре ватылган, алар урынына меңнәр тыгып ку- елган, үгез күзе кебек кечкенә тәрәзәле тәбәнәк өйләре дә бетте, аның эчендә яныл утырган сукыр лампалары да сүнде, йөзлек башлары җи- мерелгән сәкеләрен дә тимер кроватьлар алыштырды, агач бәләкләр урынына өйгә электр утюглары керде. Кыскасы, авылның яхшы якка үзгәрүе турында сөйләп кенә бетерерлек түгел. Ләкин яңа Бишьеллык планда партиябез, дөрестән дә, гаҗәп матур уйлый. Бу хакта бик озак*

*сөйләргә мөмкин булыр иде. Мәгәр бу кыска язмаларда бөтенесенә дә тукталу мөмкин түгел.*

*Шулай, партия планы — безнең план. Ул — безнең теләк һәм безнең беләк! Чөнки бу бөек планны без үзебезнең көчле беләкләребез белән тормышка ашырырга тиешбез. Аерым алганда, без язучыларның өстенә дә бик зур бурычлар төшә. Без яңа Бишьеллыкның беренче языннан ук аның геройларын әдәби әсәрләребездә тулы канлы итеп бирә башларга һәм бу иҗади эшебезне көннән-көн көчәйтергә тиешбез. Бу уңай белән Татарстан язучылары союзына минем, кечкенә генә дигәндәй, бер үпкәм барлыкны әйтмичә кала алмыйм. Соңгы елларда ярма культураларына игътибар йомшарган кебек, безнең әдәби жанрларыбыз арасында иң оператив урынны тота торган очерк жанрына да, ничектер, кимсетебрәк карау сизелә. Бу, бердән, художестволы очеркларның бик сирәк язылуында, икенчедән, игътибарга лаеклы очеркларны тәнкыйтьчеләрнең күрмәмешкә салынуларында, һәм, өченчедән, бу турыда язучылар җыелышларында булсын, яки секция утырышларында булсын, беркайчан да диярлек җитди сөйләшүнең булмавында күренә.*

*Сүзне озынга сузмыйк, беренче Бишьеллыклар чорында шушы көчле коралны нинди генә зур язучылар кулларына алмадылар. Моны без беркайчан да онытырга тиеш түгелбез. Ә менә хәзер, яңа Бишьеллык башланганда, без моңа аеруча нык тотынырга тиешбез. Әлбәттә, бу башка жанрлардан баш тартырга кирәк, дигән сүз түгел. Дөресен әйткәндә, күп кенә башка әдәби әсәрләр, минемчә, нәкъ менә очерклар аркылы туалар.*

*Мин бу мәкаләмне шагыйрь Хәсән Туфанның бик матур җырын тыңлау белән башлаган идем. Мин ул җыр турында, аның халыкка бик тиз кереп китүе турында Туфанның үзенә дә әйттем. Шуннан соң ул болай диде:*

*— Мин аны берничә вариантта язып, кешеләргә кат-кат укып карадым. Укыган саен аерым сүзләрен икенче сүзләр белән алыштыра, яки аларны элекке варианттагы урыннарыннан икенче урынга күчерә бардым. Шулай кешеләр белән бергәләп кайта-кайта эшли торгач, әнә шундый матур гына җыр туды,— диде.*

*Өлкән буын шагыйребез Хәсән Туфан әйткәнчә, безгә кешеләр белән бергәләп иҗат итәргә, бергәләп эшләргә кирәк. Чөнки бу план — безнең теләкләребез һәм безнең беләкләребез!*

**ГАРИФ ГАЛИЕВ**

Аяз Гыйләҗев



# БЕРӘҮ

*Повесть*

## I

1958 нче ел.

Җәйнең иң эссе көннәре башланып, салам түбәләр, читән чыбыгыннан үрелгән тәбәшәк абзар-куралар көйрәп китәрлек хәлгә җитеп әлсерәп утырганда, Күктау авылында янгын чыкты. Латыйплар килене самоварын соскыга каккан да көлен, уты-ние белән, лапастагы кабык колашага түккән икән.

Җиләс көн иде. Янгынчылар мыштырдап килеп җиткәләгәнче, рәттән сигезенче йортның түбәсе төтенли башлаган иде инде. Сигез каралтыдан ургылып чыккан аклы-каралы төтен тирә-як авыллардан да үзенә кешеләр чакырырга тотынды.

Тугызынчы йортны утка бирмәделәр: кырдан кайтып өлгергән трактор аны аударып, җимереп ташлады.

Ул арада күрше-тирә авыллардан атлар килеп җитте, район янгынчылары тузан туздырып килеп керделәр. Кәс һәм чыбык-чабык тутырып, малай-шалай уйнап кына буып куйган ындыр артындагы буаның лай утырган төбе һәм уйсулыкларда чапырдашкан вак балыклары күренгәнче су сиптеләр.

Һау-һулап ни тырыштылар инде, шулай да сигез хуҗалык урынында кара күмергә әйләнгән баганалар, баш-башлары янып орчык төсенә кергән бүрәнәләр, иләмсез зур җимерек мичләр генә өелешеп калды.

Бәрәңге бакчаларына ташылган, тегендә-монда ашыгыч ыргытылган тимерле яңа сандыклар, күгәргән «Зингер» машиналары һәм башка бик күп ватыкҗимерек җиһазлар тирәсендә кайнашкан кешеләр төтеннән кызарган күзләрен уа-уа: «Әле дә ярый төнлә булмады, мондый корыда, бу җилдә бала-чаган белән шырылдап үзең янып бетәрсең, ходаем. Мал-туарың калмас», дип юаныштылар.

Кич җитте. Бөтенләй үзгәргән, уннарча машиналар, атлар белән аркылы-торкылы тапталып, изелеп беткән урамны ятсынып мал-туарлар үз капкаларын тапмый йөргәндә, колхоз идарәсендә бәләкәй генә киңәшмә җыелды. Уракка-мазарга төшкәләгәнче, каза күргән хуҗалыкларны торгыза башларга кирәк иде.

Идарәгә каза күргәннәрдән сигез кеше килгән иде. Алар тәмәкедән саргайган пәрдәләрне, зур-зур кара таплары белән чуарланган кин өстәлләрне беренче тапкыр күргән сыман, оялган кыяфәтләрдә ишек янынарак елышып утырышканнар. Җиң очлары көеп чачакланган күлмәкләреннән, очкын тиеп иләкләнгән кием-салымнарыннан ыс исе, төтен исе килә иде. Әле генә булып узган хәлләрдән соң, алар һушка килеп тә бетмәгәннәр, менә син агай, диешеп бер-берсенә карарга да, сүз башларга да кыймыйлар иде. Башка вакытта авызын йомарга онытып китә торган Хифасулла карт та бүген тып-тын утыра, вакыт-вакыт башын чайкый һәм керләнгән иске фуражкасы белән чалбар тезендәге зур тишекне капларга тырыша иде.

Барысы да колхоз председателе Хөсәен Моратшинны көтәләр. Менә кепкасын салып кага-кага идарәгә Хөсәен килеп керде, бүлмәдәгеләргә күз йөртеп чыкканнан соң, карлыккан тавыш белән:

— Маһибәдәр әби кайда? — дип сорады.

Утыз биш яшьләрдәге бу кеше башыннан ахырынача янгын сүндерүдә катнашкан, сул күз кабагына бүрәнә кыйпылчыгы тиеп киткән һәм бөтен бите күмәчтәй ямьсезләнеп шешкән иде.

Ишек төбендәгеләрнең колаклары да катыланган иде ахры, алар, ә, ни әйтәсең? дигән сыман председательгә карап акаештылар. Хөсәен соравын кабатлады. Тамак кырган, авыр гына йөткергән тавышлар яңгырады.

Арада Маһибәдәр исемле тол ялгыз карчыкның да өе янган иде.

— Кайда булсын, миңгерәүләнеп йөри торгандыр әле шунда, — диде кемдер.

— Ындырда чебиләрен барлап йөргәнен күргән идем бая, — диде бер хатын.

— Идарәгә килергә тиешлеген әйттегезме соң?

— Белә ул, белә! — диде ашыгып баягы хатын. — Тик өй нәрсәгә инде аңа? Малае әллә кайчан үз янына калага чакыра ич аны.

Кешеләр сүзнең турыдан-туры үз кайгыларына барып бәрелмәвенә, аның шулай кыеклап читкә китүенә чынлап торып шатланыштылар, йөзләре бердән яктырып, ачылып китте.

— Кояштыр шулай, Хөсәен. Нәрсәгә Маһибәдәр карчыкка йорт? Малае янына барсын. Кәттә урында диләр бит. Шәһәрнең уртасында тора, имеш, машиналарда утырып кына йөри, имеш.

— Калада анда калач кына ашыйлар.

— Шулай ла, крестьян күрми инде алар күргәнне!

— Әле монда, болай да чыгып китәргә кирәкмиме дип уйланып торганда, карчык кешегә ни калган?

Хөсәеннең күзе-кашы үтереп сызлый иде. Ул урыныннан торып почмактагы бактан кулъяулыгына су агызды һәм яралы урынын сөртә башлады.

— Бергә-бергә сөйләшәсе иде, — диде ул, тегеләр белән риза түгеллеген белдереп. — Соңыннан дәгъвасы булачак.

Бүлмәдәгеләр бер мәлгә тынып калдылар.

— Сеңелем, — диде Хөсәен, хисапчы кызга эндәшеп. — Медсестра Шәфыйкага әйт, өй борынча йөреп чыксын, яралылар байтак!

— Я, авылдашлар, — диде ул, хисапчы кыз чыгып киткәч. — Ни эшлибез?

Кыр ягы дип аталган урмансыз бу якларда агач бик кадерле булып, тәвәккәлләп йорт салып керү зур егетлек санала иде. Берьюлы

тугыз йорт салу, шулар өстенә каралты-кура яңарту бик кыен, мәшәкатьле булачак иде. Бүген-иртәгә уракка төшәм дип торганда, кашлактагы борчак туеп-агарып килгәндә, тугыз йортның тугызына да берьюлы тотынырга мөмкин түгеллеген барысы да аңлыйлар иде. Инде тугыздан берсе — Мәһибәдәр карчык йорт кирәк түгел, түшәгемне тотам да улыма китәм дип әйтә икән, бусы бер дә начар булмаячак! Идарә утырышына куйганчы үзара аңлашып, мәслихәтләшеп алырга кирәк иде. Соңыннан үпкәләшеп, әчелешле булып йөрергә калмасын...

Хөсәеннең туп-туры куйган соравына берәү дә өзеп кенә җавап бирмәде. Бармаклары үз якларына ук кәкрәймәсә дә, һәркем үз хәлен аянычлырак итеп күрсәтергә тырыша иде. Күп бәхәсләшә торгач, эшне ин элек ишле гаиләле, үзе үк балта остасы Хифасулла карттан башларга булдылар. Трактор аударган тугызынчы өй аныкы иде. Әле тырышыптырмашып караганда, аңа үз бүрәнәләрен дә байтак яратырга булыр. Башкаларга бүрәнә каян юнәтергә? Тагын сигез йорт бит әле!

— Син, Хөсәен, Мәһибәдәр карчыкны юкка чутка тыгасың,— диде Гыйльми Салихы.

— Алай ярамый, — диде бераз уйланып Хөсәен. — Әйдәгез, Мәһибәдәр әбинең үзенә куябыз. Китмим ди икән, гомере буе шушы колхозда эшләгән кешене авылдан куарсыңмы әллә?

— Кортка кәефен көйләп торсаң, көйләтер ул! — диде Салих һаман киреләнеп. — Нәсел-нәсәбенең очы-тамыры калмаган. Малае карасын әнә! Жилкә симертеп ятмасын.

— Исхак эшли. Шәһәрдә җаваплы урында, — диде Хөсәен, төксе генә.

— Ни пычагыма миңа аның эше? Ипи үстерәме, май-сөт арттырамы? Аграмунлыкка укып йөрде түгелме соң?

Салихның сүзен чынга алмадылар. Аның бәрәңге жире бик әшәке кызыл балчыклы булып, ул күптәннән Мәһибәдәрнең кара туфраклы ындырына кызыгып йөри иде.

— Кабаланма, Салих, — диде Хифасулла.— Мәһибәдәрне кума син. Колхозда аннан күп эшләгән кеше бармы икән?.. Китми ул. Кан җибәрми мине, ди.

— Нинди кан? Әкият сөйләмә әле, Хифасулла абзый! Сиңа нәрсә, өйне беренче булып эләктерәсең...

Сүзнең тагын Мәһибәдәргә тартылуын яратмыйча тыңлап утырган Хөсәен, идарә члennарын җыярга кушып, кайтып китте. Башкалар аңа иярделәр.

Идарәдә үзе хакында зур сүзләр кубуын Мәһибәдәр белми дә калды. Ул һаман бәрәңге буразналары арасында йөри һәм куркышып таралган чебиләрен чакыра иде.

Бәрәңге жирендә кем тарафыннандыр чыгарылган буй-буй тышлы зур ястык ауный, бер як колагы яньчелгән җиз самовар туфракка күмелә язып ята, бер читкәрәк ертылып беткән иске кыл иләк тәгәрәгән. Мәһибәдәр ут эченнән нибарысы шул кыл иләген алып чыкты бугай...

Өе бәләкәй иде шул. Тол хатын нужада салган йорт. Каралты-курасы да утка ике-өч ялманырга гына житте. Барысы салам түбәле, утләжжалга әйбәт азык!..

Алары беткән инде, офтансаң-офтанмасаң да кире кайтара алмассың. Чебешләре кызганыч, җан иярәре бит!

Улы Исхак кайтыр дип ел саен бер оя чебеш утыртып чыгара иде ул. Менә быел да тәгәрәп кенә үсәләр иде...

— Чеп-чеп-чеп! Чебекәйләр, йомшаккайлар!..

Ызаннар буйлап төшә торгач, бакча түренә үк барып житте Мәһибәдәр. Куркышып посып ятмыйлармы дип киртә кырыенда үскән кычытканнарны аралап карады. Анда да җан иясе күренмәде. Бакча коесы чыгырында асылынып торган агач чиләкне янтайтып сап-салкын



су эчте. Аннары башы әйләнеп киткән кебек булды, ул кое янындагы соры таштан чокып ясалган ялгаш кырына килеп утырды. Чәбәләнгән чал чәчләрен яулык астына кыстырып урам якка борылып карады...

Килен булып төшеп, гомер сөргән, бала-чага үстергән, кайгысын да шатлыгын да татыган йорты инде юк... Җил капканың кара баганалары гына йөрәккә кадалырга торган шырпы кебек тырпаешып утыралар. Быел лапасларына карлыгач оялаган иде. Беренче тапкыр! Ярлы, тәбәнәк лапасларга назлы кошлар сирәк оялыйлар... Быел менә никтер ояладылар... Бала чыгарырга да утыра иде. Күкәйләре янгандыр инде. И мескен, мескен! Нишләр инде ул бичара? Кем кызганыр аны, кем юатыр?

Баласыз калган ананың хәлен Мәһибәдәр белмиме әллә?

Ә үзе?

Иң соңгы таянычы булган шушы йорты да янып беткәч, ул кая барыр?

Буразна арасыннан песи тавышы килде. Мәһибәдәр иелеп карарга да өлгермәде, дәү, йөнтәс песи аның аяк арасына килеп керде, сыенды, сырпаланды.

Карчык песине кулына алып күкрәгенә кысты:

— Кая барыйм инде мин бичара сезнең белән? — дип кат-кат кабатлады.

Песи, аны аңлаган сыман, мияулый-мияулый койрыгын селкә иде.

— Карының да ачтыр инде синең, мескенем,— диде карчык, мич алдындагы савыттагы сөтне хәтерләп. — Әйдә, синлек кенә ризык табарбыз әле!

Урамда җир җимереп аны эзлиләр иде инде. Ул як-якка авышкан бәрәңге сабакларын көч-хәл белән ера-ера үзен чакырып торучы кешеләр янына китте...

Ул кичне кем ничек: я агай-энесенә, я дус-ишенә урнашты. Мәһибәдәрне, ай-ваена да карамыйча, ахирәте Зөләйха алып китте. Ул түшәк-ястыкларын, самоварын ахирәтләренә илтеп, чәй эчеп бераз хушлангач та урынында тик кенә утыра алмады. Өй урыны яннарыннан тагын бер әйләнеп кайтты.

Эңгер-меңгердә кагаеп утырган баганалар зәһәр исләр чыгарып һа-

ман тәтиләр иде. Бер читтәрәк җыелып торган халык арасыннан кемнендер:

— Сугыш искә төште, малай. Авылга барып керәсең, гел менә шушылай була торган иде, — дип сөйләнгәне ишетелеп калды. Ындыр артларына терәлеп кенә аккан инеш өстенә әллә томан, әллә төтен сарылып яткан.

Ул ишек алдына керде. Гомеренең күпчелеге узган урында утырып ял итәсе, хәл җыясы килде аның. Тик карчык шыкланырлык почмак та, аны сыендырып, сызлаган сөякләренә ял бирерлек урын да калмаган иде монда.

Бетте, дип уйлады Маһибәдәр. Инде хәзер ябышып җыласаң да Исхакны җиңеп булмаячак. Йорт-җиреӊ беткән, каралты-кураң көлгә әйләнгән, якларлык агай-энең калмаган. Синең кадерле, газиз гомереңнең монда узуы кемгә хаҗәт? Җан тартуы, кан авазы... Боларны әйтсәң, Исхак көләчәк кенә! Таш бәгырьле бала!.. Түшәгеңне кыстырып аның янына калага китми хәлең юк. Хәзер өстенлек аның кулында...

Шәһәр турында уйлагач, карчык аның урамнарын менә шушындый ачы, зәһәр исле итеп күз алдына китерде. Аннары өметсезләнеп урамга чыкты һәм башын да күтәреп карамыйча абына-сөртенә туп-туры Зөләйхаларга кайтып китте. Маһибәдәрнең бер минут та, бер секунд та яшисе килми, чөнки алдагы көннәренең мәгънәсе, кирәклеге күренми иде. Килеп җитмәгән әҗәлне каргап, үзең теләмәгән урында җан саклап ятуда ни файда?

Башкаларның әнә улы ул төсле, кызы кыз төсле. Бергә-бергә тереклек итәләр. Сыенышып менә дигән яшәп яталар. Бала-чагалары тупырдап үсә... Уңмады Маһибәдәр балалардан, һай уңмады! Әй, Нурислам исән булса! Һай карты белән икәү булсалар, өйләреӊ-ниләреӊ яну түгел, ник дөньяларыӊ чәнчелеп китми!..

Тик Нурислам юк иде инде. Ул күптән вафат иде...

Әле ул чагында Исхакка дүрт кенә яшь тулган иде. Нурислам Кырынды өстендә сукада йөри иде. Шунда ызанда ятып йоклаган малайны кара елан чаккан. Нурислам малайны алдына салган да авылга җайдак чапкан. Тау битеннән арыш арасыннан җан-фәрман төшеп килгәндә, ат шып туктап калган. Известь яндырырга ташы алынган тирән базны ат та, хуҗасы да бик соң абайлаганнар... Малайны ничек саклап калгандыр, анысын һичничек белерлек түгел иде. Авылдашлары искәреп килеп тапканда, канга тузып чокыр төбендә Нурислам, чокыр кырында биле сынган ат ыңгырашып яталар иде...

Һай, үзе исән булса!

Нурислам өч баланың язмышын хатыны кулына тапшырып китте. Сугыш елларында күргән газапларын, нужаларын Маһибәдәр үзе генә белә... Тешен кысып тырышты ул, балаларым ятимлектән гарип күңелле булмасыннар дип соңгы көчен кызганмады, кара таңнан ярты төнгәчә эштән туктамады, өчесен тиң укытты.

Инде нужадан котылабыз, тормышыбыз җинеләя дип йөргәндә генә, бар өметләр кире сүтелделәр. Балалары кинәндермәделәр Маһибәдәрне. Олы кызы, техникум бетерүгә, бер хәрбигә кияүгә чыкты. Алар икәүләшеп җир читенә — Сахалинга күчеп киттеләр. Икенче кызы Наилә дә озак тормады. Күрше авыл егете белән башлы-күзле булып, алар да Әлмәткә, нефтькә күченделәр. Агай-энеләре моны бик хупладылар: «Кияүнең башы йомры булып чыкты, колхозда эшләп барыбер мантып булмый», дип сөйләнгәләделәр.

Карчык дәшмәде, тешен кысып колхоз эшенә чыкты, иренен тешләп өй арасында, бәрәңге бакчасында кайнашты. Аның бар өмете, өметенең дә ачысы, зурысы төпчеге Исхакта иде...

Маһибәдәр үз балаларының да төшеп калмавын авылдашларына күрсәтергә тели иде. Менә монда, үз янында алар эшләп йөрсеннәр иде!

Әтисез үскән балалар дип әйтерлек булмасын иде! Һәм ул бөтен игътибарын төпчегенә бирде. Яшьтән үк авыл ягын яратырга өйрәтте ул аны, ике сүзенең берендә кырчынын-игенченең хезмәтен олылады. Ипи бөтеннәрен зурлап, ашъяулык белән генә төреп йөртте.

Малай үсә төшкән саен, анага кыенрак була барды. Чөнки аның сүзләре белән чын тормыш арасында кайчак каршылыклар, кайбер аермалар да ишәйде. Эшләмәгән ашамый, диде ана. Тик кайсы вакытларда эшләмәгәннәрнең дә ашавын, хәтта тәмлерәген, күбрәген эләктерүләрен малай үзе күреп үсте...

Тик ана һаман өметләнде. Һәм Исхак, аның күңелен күреп, авыл хуҗалыгы институтына укырга керде. Ул көнне иң әйбәт шәлен ябынып, Маһибәдәр югары очтан түбән очка таба ике тапкыр урап кайтты...

Бала-чагалары ишәеп, гаилә мәшәкатьләрен татый башлагач, кызлар берсеннән-берсе уздырып әниләрен үз яннарына чакыра башладылар. Күрше-күлән аларның өзелеп язган хатларын укыганда:

— Бар, Маһибәдәр түти, ике дә уйлама. Кара җимеш белән чәй эчеп, шулпалы бәлеш кенә ашап торырсың. Кызларың бик игелекле ич синең, — дип үгетлиләр иде.

— Киявең ачуланса, ишек бавын тот, улың ачуланса түргәрәк менеп утыр, дигәннәр борынгылар!

Күршеләренең киңәшләренә Маһибәдәрнең җавабы шул булды.

Энеләре институтта укый башлагач, кызлар тындылар:

— Әнкәй янына кайтып эшләргә исәбе бардыр,— дип, карчыкны кыстый-кыстый чакырудан туктадылар.

Ана бик дәртләнеп, өметләнеп, күңелләнеп йөри иде. Ләкин барысы да көтмәгәндә булды да куйды...

Соңгы курска керер алдыннан Исхак авылга практикага кайтты. Хөсәен Моратшин председатель булып сайланып яңа гына эшли башлаган иде. Яшь аралары шактый гына аермалы булса да, алар бик күптәннән дус иделәр. Хөсәен үзе дә яңа кеше, ярдәмгә кайткан яшь белгечкә бик шатланды. Маһибәдәр кешелеккә саклый торган күлмәкләрен киеп йөри башлады, тәрәзәләренә яңа пәрдәләр элде.

Ләкин шатлык озакка бармады. Исхак, практикасын ташлап, шәһәргә китеп барды, укып бетерде дә шунда эшкә калды. Карчыкның инәлеп-ялынып чакыруларына колак та салмады ул. Ял вакытларында да авылга кайтмады. Киресенчә, әнисен үз янына чакырды. Йорт-җирне сатарга кушты.

Башта Маһибәдәрнең икеләнгән чаклары да булгалады. Тора-бара улының өйләнгәнен көтәргә булды. Килен нинди кеше булыр бит әле! Саз тәкәрлеге кебек бәләкәй генә болытка да чыелдап-чыелдап кычкырып йөрүче хатын эләксә, ни эшләрсең? Әле болай да булуы ихтимал ич: өйләнеп, башлы-күзле булгач, Исхак үзе дә авылның сөтен-маен сагынмасмы?..

Тик Исхак өйләнергә ашыкмады. Инде соңгы чик дип саналган егерме сигезне дә үтте ул. Маһибәдәр аптырап-йөдәп шәһәргә китте. Белербелмәс русчасы белән улының күрше-тирәләреннән сорашып йөрде.

— Бер дә хатын-кыз затын күргәнебез юк. Улыгыз бик сабыр, бик тыйнак,— дип, күршеләре аны юаттылар. Әнисенең шулай төпченеп йөрүен ишеткәч, Исхак:

— Нигә аны үземнән генә сорамадың, әнкәй? — дип үпкәләде.

— Үзеңнән дә сорарга торам, нигә өйләнмисең?

— Күңелемә ошаган кыз юк.

— Кыз юк? Хифасулла карт әйтмешли, хәзерге заманда бер каз оясы кызларның бәясе өч тиен.

— Миңа андыйлары кирәкми.

Кыз юк? Кала урамына чыккач, Маһибәдәр ах итте. Чибәр, киенгән-ясанган кызлар өерләре белән йөриләр иде.

Маһибәдәр шыпырт кына авылына кайтып төште.

Халык арасында:

— Исхакны бозганнар икән, — дигән сүз таралды.

Улының язмышы борчулы бер төер булып ана күңеленә урнашты. Институт бетереп каланың тел әйләнмәс исемле урыннарында эшләсә дә, ана өчен ул канаты ныгымаган сабый иде. Баласын очарга өйрәтеп житкермәгән килеш, ана ничек итеп үз оясын ташласын? Үз оясында аның никадәр таянычы бар: үткән гомере (ә гомере тоташтан авыр хезмәт белән узды аның), аның сүзләренә телсез шаһит булырлык истәлекләр, тарих бар, авыл бар. Ул монда хужа, бу ыгы-зыгылы тормышта аның үз урыны бар, моннан торып ул теләсә кем белән аяк тереп сөйләшә ала. Куллары җыерчыклы булса да, аның йөзе ак. Кызларның кайсысына барса да, Исхакларда тора башласа да, ул үз сүзен, горурлыгын азмы-күпме югалтачак.

Агын да, карасын да үлчәү табасына кат-кат куеп карагач, Маһибәдәр шундый акылга килде: Исхакның тормышы көйләнми торып, ул урыныннан кузгалачак түгел. Кырык тәрәүле өйдә торса торыр, ипине суга манчып ашар, әмма ана кеше ана булып калырга тиеш! Исхак өйләнсен әле, тереклек итеп карасын, аннары күз күрер...

Улының нигә өйләнмәвен дә берникадәр сизенә иде Маһибәдәр. Теге Хәерлебәнат кызын оныта алмыйдыр дип уйлый иде. Тик аңа да бик күп еллар узды бит инде... Ул чагында Исхак бала гына иде ләбаса...

Бала гына иде микән, дип тә шикләнеп куя иде ана.

Менә шундый уйлар чоңгылында бата-чума яшәгәндә янып китте аның өе...

Икенче көнне районнан ниндидер шома гына кешеләр килеп, янган йортлар тирәсендә әйләнеп-тулганып йөрделәр, кәгазьләр яздылар. Хөсәен Моратшин Маһибәдәрне чакыртып әллә ничә тапкыр кеше җибәрде. Тик карчык идарәгә бармады. Анда барыр өчен иң элек үзе уйлап куярга тиеш иде ул. Ә уйларының очына чыга алмады Маһибәдәр. Аптырагач, улына телеграмма суктырды. Шул көнне кич белән үк улыннан җавап телеграммасы китереп тоттырдылар. Исхак бик кайгыруын әйткән һәм якын араларда кайтасын хәбәр иткән иде. Хат ташучы кыз шытырдатып телеграмманы укып биргәч, Маһибәдәр яулык почмагы белән яшьле күзләрен сөртә-сөртә мич арасына атлады. Гадәтенчә «пушты кызына» бирәр уч чикләвек бирмәкче иде. Мич арасында җиз ләгәнгә абынгач кына, ул айнып китте, үзенең чит йортта, ахирәте Зөләйхаларда булуын абайлап, кычкырып ук елап җибәрде.

Хат ташучы кыз, аны уңайсызламас өчен, шыпырт кына чыгып китте.

Улы белән чит кеше өендә очрашырга туры киләчәген уйлап, Маһибәдәр куркуга төште. Үз күңелендәге өзеп кенә әйтеп бирә алырмы? Каушап калмасмы?

Сөйләшер сүзләре күп түгел иде аның. Тик ул сүз бик олы иде. Аны тизрәк тормышка ашырырга кирәк иде. Гомер үтеп бара бит, үтеп бара!..

Кояш байый...

## 2

Хөсәен белән Маһибәдәр, һич тә көтмәгәндә, су юлында очраштылар. Ахирәтләрендә торса да, Маһибәдәр һаман тынычлана алмый, таңнан ук тора, мал-туарны көтүгә куа, ишек алларын себереп чыгара, кыштыр-мыштыр килеп ян бакчага чүп-чар утарга кереп китә. Хөсәенне күргәч, ул чиләкләрен чирәмгә куйды да, яулык чите белән авызын каплап:

— Чәй суы алып кайтып киләм. Исәнме, Хөсәен, — диде.

— Үзең сау гына йөрисеңме, Мәһибәдәр түти.

Икесе дә бераз сүзсез тордылар. Тик торудан уңайсызланган Хөсәен, сүзне читкә алып китмичә:

— Бик авыр түгелме? — дип чиләкләргә ымлады.

— Түгел дә, үзебезнең оч чишмәсенә җитми инде...

— Шулайгарак китте бит, Мәһибәдәр түти, — дип авыр сулады Хөсәен.

— Гыйльми Салихы көн дә килеп йөри. Башкалар да моннан китәргә үгетлиләр. Ят кеше бусагасында су ташып интекмә... Өч балаң өч якта. Сайлап алырлыгың бар. Тот та кит, диләр. Әллә сүз берләшкәннәр инде... Әллә барысының да миннән котыласылары килә.

Хөсәен элек-электән Мәһибәдәргә бер якынлык, туганлык хисе саклап йөри иде. Аның яшь тулы күзләрен күргәч, бу хис тагын да ачыграк булып җанны авырттырды:

— Минем үгетләгәнем юк бит, Мәһибәдәр түти... Сынган җир — сызлана! Сиңа шулаерак тоела торгандыр шул, — диде.

— Кал, дигәнеңне дә ишеткән юк әле моңарчы, Хөсәен, — диде карчык, лышык-лышык борынын тартып. Аның ак ыштан балаклары җилдә җилфердиләр иде.

— Исхак кайта диләр, дөресме?

— Кем белсен аны, — диде читкә карап Мәһибәдәр. — Аныкын белмәссең!.. Язса сиңа язар инде. Иптәшең бит.

— Син аның әнисе, Мәһибәдәр түти.

— Мин барыгызга да ана. Картаймыш көнемдә генә үгәй итәсез.

— Кыен булачак, Мәһибәдәр түти, — диде Хөсәен яшермичә. — Бик кыен. Йорт торгызу ир-атлы кешегә дә бик авыр бит. Без кысасын күтәреп бирербез. Анда гына эш бетми бит әле!

— Илгә килгән каза казамыни ул? Каза булса да җәза түгел. Инде илдән аерасыз икән, ул чагында, ул чагында...

— Кем сүзе ул? Нигә аерыйк без сине?

Карчык хәленең аяныч икәнлеген Хөсәенгә теле белән әйтеп биргәч, бигрәк тә үзе ачыграк күрде. Балалары кайтып өй салышып бирмәсләр шул инде... Ул чагында, ул чагында...

— Син алай текә куйма инде, Мәһибәдәр түти, — диде Хөсәен.

— Бүрәнәләрең бармы?

— Сүбәләктән бирәләр. Идел суы басачак урманнарны кыралар, бәясе дә арзан гына. Шалкан бәясе! Тик йөз егерме чакрым! Аны кисәсе, ташыйсы, киптерәсе дә бар бит әле.

— Сарык фермаларын төзәтергә кайчан тотынасыз? — диде карчык, нидер хәтерләп.

— Урып-җыеп алыйк инде...

— Менә син тот та сарык фермасына кайтарткан бүрәнәләреңне биреп тор. Сүбәләктән китерәселәрен ферма итәрсең. Анысы өлгерә бит.

Хөсәен көлемсерәде:

— Әй-яй, ансат хәл иттең, Мәһибәдәр түти. Мин хуҗа түгел бит аларга.

— Ә кем хуҗа?

— Кем дип... Район!

— Син һаман да шул өркәк икәнсең әле!

Карчык яңадан бер сүз дә әйтмәде, иелә төшеп чиләкләрен эләктерде һәм, көянтәсен бер иңеннән икенчесенә күчерә-күчерә, ыштан балакларын яман җилфердәтеп ишек алдына кереп китте.

Ул да булмады, өй артыннан күзен ялт-йолт уйнатып Гыйльми Салихы килеп чыкты. Купшакланган борынын кашый-кашый:

— Сиңа сүз бар иде, парин, — диде.

— Ни сөйләрсең, Салих абзый?

— Өмет синдә генә, Хөсәен парин. Ексаң да син егасың, кул бирсәң дә синеке.

— Аңлап бетермим.

— Үгетлә әле шул кире беткән бәндәне! Ни пычагыма аңа өй? Нигә аңа бакча? Гүр турында уйларга вакыт аңа, менәтерәк. Җирен миңа бирсен. Иң әйбәт пужумда кычыткан үрчетеп ята.

— Ә сиңа өй нигә? Бакча нигә кирәк?

— Син парин, әкәмәт кеше. Миңа тереклек итәргә, аз-маз тырмашырга! Яшәргә...

Хөсәен көлеп җибәрде:

— Соң шулай булгач? Аның яшисе килмиме әллә? Дөньяда ул бар эшен дә башкарган диясең киләме? Маһибәдәр карчык киресен уйлый!..

Салих белән сөйләшәсе килми иде аның. Шулай да ләңгелдек көчек кебек әле бер ягыңа, әле икенче ягыңа чыгып барган кеше белән ничек бер-ике сүз алышмыйсың? Аның белән уйламыйча гына сөйләште Хөсәен, теленә очраклы сүзләр генә килде. Күңеле белән бөтенләй башка эшләр, башка кешеләр турында, үзе турында уйлый иде ул.

Хөсәен бер минутка гына үзен Маһибәдәр урынына куеп карады... Китәсе килер идеме аның үзенең?

Маһибәдәрне әнә шулай җибәреп тә булмас, ә улын, Исхакны, бау бәйләп тартсаң да авылга кайтарырмын димә. Нишләде бу яшь буын? Нигә шулай җирне, авылны сөймәс булды?..

Әйе... Моннан биш ел элек аны капылт кына председательлектән төшермәгән булсалар, бәлки, җаен табып, Исхакны авылга өндәгән дә булыр иде...

Менә ул яңадан председатель. Биш еллык тәнәфестән соң, яңадан аны сайлап куйдылар. Авыр, хурлыклы тәнәфестән соң... Нигә сайладылар әле аны? Биш ел эчендә аның рухы сынган булса, ул да әнә Исхаклар кебек җиргә җирәнеп кенә карый башлаган булса?.. Маһибәдәр карчык ничек авыз тутырып аны «өркәк» дип атады... Исхак кайтырга тиеш, ди. Ул нәрсә әйтер икән?

Аның авылга кайтмый йөрүендә Хөсәеннең дә гаебе бар түгелме соң? Әгәр шулай булмаса, иптәш итеп бер хат язар иде. Язмады бит, китте дә югалды... Хөсәен дә шәһәргә бармый тормый, ә эзләп кергәне юк...

Икесе дә сүз куешкандай күрешми-белешми тордылар-тордылар да менә хәзер күзгә-күз очрашырга мәҗбүр булачаклар.

Хөсәен яңадан председатель. Ә Исхак? Кем ул? Дәртсенеп укып йөргән агрономмы, әллә яңа кешеме?

Салих ияреп барды-барды да, Хөсәеннән игелекле сүз алып булмаслыгына тәгаен ышангач, төкеренеп артта калды.

— Тешләк хайван! — дип сүгенде ул, председатель ерагайгач. — Ни пычагыма сине казып чыгардылар соң әле, баш бәласен!.. Заманасы да киреле-морлы булып китте. Әй, тайный милиция булып йөргән чаклар булса!..

Хөсәен тау буена кадәр барды да туктады. Алачыкка кагылырга иде исәбе. Тәмәке кабызды. Авылга борылып карады.

Күктау...

Ватан диләр. Башкала диләр. Ватан кадерле диләр. Мәскәү — Ватаныбызның башкаласы диләр.

Ватан — Хөсәен өчен менә шушы басулар, елга буйлары, шушы юллар, исемсез тәбәшәк таулар. Башкала — аның өчен иң элек шушы Күктау. Ул көньякны да, төньякны да менә шушы кырлар, басулар булганы өчен ярата. Дөньяның бөтен меридианнары аның өчен шушында кисешәләр. Әгәр шушы Күктау булмаса, Мәскәү нәрсә аңа? Анда тумаган ул, тормаган да. Ул Күктау кешесе. Мәскәү дә, экватор да аның өчен географик аңлатмалар гына булып калыр иде...

Авыл урамнарының, рәсми законлаштырылмаса да, исемнәре була. Урамның гынамы әле, чүп үлән басып бетергән тар тыкрыкларга, әллә кайчан казылып, суы кибеп беткән, бурасы ишелгән коеларга, трактор-мазар үткәндә мыгырдап кала торган күперләргә кадәр, үз тарихына бәйләп, күңеленә якын исемнәрне бирә авыл халкы. Башка авыл кешеләре өчен Акбүз ат чишмәләре, Кыяр таулары, Әхми куаклыгы нәрсә ул?..

Карап торсаң, Кыяр тавы шып-шыр, ялангач бер тау. Ә аның ерымнары, җыерчыклары?.. Бөтен буеннан-буена чәчелеп яткан ап-ак ташлары... Куктау малайлары өчен изге урыннар иде бит болар...

Ә урамнар?

Гомернең кайсы буыны читләтте соң кеше күңелен туган җирләреннән?..

Шушы урынга җиткәч, Хөсәеннең уйлары өзелде. Чөнки үзен борчыган сорауга җавап таба алмый иде ул. Ул тәмәке төпчеген иренендә изә-изә, каралып яткан буш йорт урыннарына карады.

Кайгы-шатлык кешеләрне аралап, аларның чын йөзләрен күрсәтә. Моны үз башына хәсрәт төшкәндә дә сынап караган иде инде ул. Хәзер дә шул ук хәл. Салихны гына ал... Кеше кайгысы өстендә үзенә файда эзли. Юл куйсаң, бугазыңнан буып алыр, эһ тә итмәс! Юк, Хөсәен алай узынырга ирек бирмәс...

Юкка гына биш елдан соң кабат председатель итмәделәр ич аны! Элек кемгәдер ярамаган иде, хәзер авылдашлары үзләре сорадылар... Димәк, заманалар да, кешеләр дә үзгәрәләр. Биш ел күпме генә гомер әле? Шулай да үзгәрешләр сизелә...

Маһибәдәргә йорт салып бирергә кирәк, каралты-курасын торгызырга, өй җиһазлары алырга булышырга кирәк... Гомерен җир тырмап үткәргән карт колхозчы ич ул!.. Карт игенче... Хыянәтсез рәвештә җирне ярата торган изге җан... Андыйлар авылда азаеп баралар, азаеп...

Ә Исхак?

Ул нәрсә әйтер? Үпкәләмәсме? Бәлки, киресенчә булыр, ике арада булган чуалышлар чишелерләр дә китәрләр?

Хөсәен алачыкка барып җиткәнен сизми дә калды.

Тимерчеләр дә, алачык янындагы кешеләр дә аны хуплап, шау-гөр килеп каршыладылар. Аның бердән күңеле күтәрелеп китте.

## 3

Авыл башыннан машина тавышы ишетелгән саен, Маһибәдәр абынасөртенә урамга йөгерде. Ничәнче кат!

Машина дигәне бу юлы Гыйльми Салихы малаеның зур резин тәгәрмәчле, чикерткәгә охшаган килбәтсез тракторы булып чыкты. Ул тракторга тагылган вагонына солылы вика төяп өйләренә әбәдкә кайтып бара икән. Процентка вика бирә башлаганнар да инде, дип уйлады Маһибәдәр. Тракторы чаба, аның артыннан дүрт-биш малай тыр-тыр йөгерәләр.

— Тфу, кеше җилкетеп йөрисең, шыксыз,— дип сукранды карчык.

Җилкетү дигән нәрсә Салих малаеның исендә дә юк. Ул Маһибәдәрләр турына җиткәч, вак бәлеш хәтле авызын ачып елмайды да, трактор гөрләвен каплап, көчле тавыш белән:

— Исәнме, Маһибәдәрти! — дип кычкырып узды.

Ир заты күп булган семьяның авылда эше көйле. Ат җиксә дә үз өенә нидер эләктереп кайта, машина-трактор йөртсә бигрәк тә... Өч яклап ташый башласалар, Гыйльми Салихы өй түгел, пулатын салып куяр. Ата бур!

Борылып кергәндә, Маһибәдәр үзенең тәмам арганлыгын, юньләп йокы күрмәгән тәненең гадәттәгедән күп тапкырлар артык сызлануын

тойды. Иртән ипи салганда башына бераз ис тә тигән, ахры. Чигәләре сулкылдап, чымырдап тора. Ул почмак якка үтте дә ипи табаклары тезелгән киштәдән нашатырь спирте табып алып, озак кына иснәде.

Кешеләр әнә әбәдкә кайта, бу Исхак нигә бик озаклады соң әле? Телеграммасында ачык әйткән бит: «Егерме берендә кайтып житәм», дигән. Куандырды улы телеграмма белән!

Тик гомергә шул инде, китә башласаң да, кайтырга чыксаң да иза чикми калмыйсың. Тимер юлы да ерак, пароходка да алтмыш чакрым. Машина очраса, тиз кайтасың, очрамаса: «Татарстаннан да каһәрле республика юктыр инде. Күпме нефть бирәбез, икмәген тапшырабыз, юньле-башлы юллар булмады! Бу Бөгелмә — Казан тимер юлы да еки-ят итеп сөйләргә калды», дип сукрана-сукрана пристань урамының зиратка барып терәлгән очында, каен күләгәсендә берәр миһербанлырак шоферның үтеп китүен көтәсең.

Исхак та иртәнге алтыда килгән пароходтан төшеп, сәгать җидегә көч-хәл белән, шабыр тиргә батып зират коймасы янына килеп ауды. Маңгай тирен сыпырып, аз-маз хәл җыйгач, ара-тирә үтеп йөрүче машиналарны күзәтә башлады. «Эш пешәргә тиеш!» Алданрак куанган икән, бер машинага кул күтәреп карады, икенчесенә каршы ук чыкты. Аз гына тузан ойый башлаган юллардан шоферлар сәлам дә бирми уза тордылар. Ул бер кулын гына түгел, икесен дә болгап карады, йодрыкларын төйнәп кычкырды:

— Нәрсә сез, акылдан шаштыгызмы әллә?

Йөдәп беткәч, кесәсеннән «бу иптәш авыл хуҗалыгы министрлыгында эшли», дигән бәләкәй кенәгәсен чыгарып югары күтәреп торды, ярдәм итмәде. Шоферлар һаман баш чайкап үтә тордылар. Ахырда берсенең шәфкате килеп, җене чыккан Исхакка серне ачты:

— Син, агайне, безгә үпкәләмә! Безгә яңа инспектор китерделәр. Бик вак нәрсә! Шул быжгак бәндә моннан бер чакрымда гына күпер төбендә саклап утыра. Ун тәңкәгә кызыгып, правадан колак кагасы кемнең дә килми. Юкса, чүтмени, машина буш! — диде ул, әрҗәсенә ымсынып карап.

Нишләргә инде? Ике чемодан сөйрәп алтмыш чакрымлык юлга чыгаргамы? Мондагы район үзәгенә, райбашкармага хәбәр итәсе калган! Белеш малайлар да бар бит әле анда!..

Шулай уйлап торганда, Исхакның күзенә атын җай гына атлатып килүче кабык арбалы бер агай чалынды. Ул шатланып аның каршысына чыкты һәм утыртып кайтуын үтенде.

— Юк, — диде агай. — Мин хәзер борылам. Комлыкка керәм.

— Сай чокырдагы күпергә кадәр генә илтеп куегыз инде, агай, — дип ялынды егет.

— Ә аннан ары кәҗәгә атланмакчы буласыңмы?

Исхакның үтенүе ярдәм итмәде, кесәдән өчлекне чыгарырга туры килде.

Күпер төбенә килеп җиткәч, Исхак чемоданнарын бер кырыйга куйды да, як-ягына каранды. Аннары эре-эре атлап бер-ике сажин ераклыктагы куаклыкка юнәлде.

— Әй! — дип кычкырды ул. — Кайда сез?

Куак артыннан ялтырап торган күн итегенә чыбык белән суккалый-суккалый иләмсез зур фуражка кигән, карсак кына яшь милиционер килеп чыкты. Ул су кебек төссез күзләрен тәгәрәтеп Исхакка карап тора иде.

— Утырасыз шунда...— дип сүгенде Исхак.— Сезнең монда икәнлекне күрше республикаларда да беләләр инде! Тапкансыз пост!

Милиционерның исе дә китмәде, ул ботын ерыбрак Исхак каршына килеп басты да, эре генә:

— Ни йомыш, гражданин? Нигә шаулыйсыз? — дип сорады.

— Нигә шауламаска? Сезнең аркада иртәдән бирле китә алмый утырам.

— Һәм утыртмам да! Янмыйдыр бит? Бирермен мин аларга киркләрен.

— Кемнәргә?

— Шоферларга! Азынганнар. Юлга чыктылар исә, акча туныйлар. Җитәр.

— Ә без, юлчылар, нишләргә тиеш инде алайса?

— Анысы миңа не касается. Миңа аны тикшерү кушылмаган.

Исхак үзеннән дә яшьрәк бу кече лейтенантның дәү фуражкасына, ялтырап торган күн итекләренә нәфрәт белән карады. Каян килеп чыгалар диген шундый кешеләр. Шундыйларга бәләкәй булса да власть тапшырып, погон тагып чыгаралар бит! Тәртип урнаштырырга кирәк, анысы ачык, тик пристань белән район арасын ничек үтәргә? Автобус бирмиләр, тегенди машиналар утыртмыйлар. Ничек йөрергә?

Ул кызып-кызып аңлатып та, иплəп, җай белән төшендереп тә карады, кече лейтенант карышып каткан иде:

— Мине монда тәртип урнаштырырга җибәрделәр, — диде ул, сыек чыбыгы белән ромашкаларның башын кыя-кыя.

Милиционер белән очрашу Исхакка авыр тәэсир ясады. Аңа берничек тә төшендерерлек түгел, ул су кебек төссез күзләрен сиңа терәгән дә көлеп кенә тора. Машиналар туктамый, барасы юл ерак, чемоданнар авыр...

Кайчандыр шундый өметсезлек белән юлга чыкканы бар инде аның. Заманалар бер дә үзгәрмәсмени? Һаман шушындый ук җансыз йөзләр, таштай каткан чырайлар. Инструкция кушмый, закон тыя, кагыйдәләр рөхсәт итми... Каян туалар бу закон коллары? Кешелексез, мәрхәмәтсез җаннар!..

Кулыннан килсә, милиционерны кыйнап ташлар иде ул.

Ярамый...

Ике чемоданын сөйрәп, нәкъ көньякка карап юл тотты Исхак.

Кояш кыздыра. Нәкъ каршыда, баш очында ул. Кояштан түбәндәрәк тилгәннәр. Эссе. Җил юк. Юл кырларында тузанга, дегеткә манчылган эремнәр, тигәнәкләр оеп утыралар. Чокырлар, чокырлар! Ничә еллар инде шушы юлларны төзәтеп азапланалар. Тракторлар, атлылар килеп балчык дамба ясап китәләр, акча түгелә, хезмәт куела, барысы да беренче яңгырга кадәр генә... Ел саен бер километр гына юлны чынлап торып эшләгәндә дә, бу ике араны коеп куярлык вакыт узды бит! Хуҗалар юк, хуҗалар!

Шактый озак барды ул. Юл кырындагы борчакларны йолкып карады, бодай башакларын учына алып уды. Кузак саен бишәр борчак. Бодай гына ошамады аңа: вак, коңгыртсу бөртекләр. Тагын китте.

Машина берничә тапкыр кычкырткач кына, Исхак башын күтәреп борылып карады.

— Сабан туе дип беләсеңме әллә син Чаллы юлын? — диде шофер, машинасын туктатып.

— Нигә?

— Выжлап чабасың. Көтсәң ни була?

— Законнан курыкмыйсыңмы соң?

— Закон күпер төбендә калды инде. Куып җитсәң, утыртма, дип кисәтте!

Исхак чемоданнарын әрҗәгә меңгереп, үзе дә шунда үрмәләде.

— Монда утыр. Йомшаграк булыр.

— Юк, — диде Исхак. — Газдан башым авырта. Болай да кәеф китеп тора әле.

Кузовта чыннан да рәхәтрәк иде. Машина җиленә күкрәген куеп, Исхак изүен ачып җибәрде, салкынча җил шәрә тәнгә кереп, җай гына

кытыклап йөри башлады. Ул кулъяулыгы белән битен, маңгаен сөртте. Кардай кулъяулык соры тузанга манчылды. Шактый тузан йоткан икән!

Шофер сак кына алып барса да, юл тигез түгел, Исхак чемоданнары белән яртышар аршынга сикереп-сикереп ала иде.

Озын, ялыктыргыч юл артта калды. Шофер Исхакны нәкъ Күктауның ындыр артында төшереп калдырды. Шыгырдап торган унлыкны кесәсенә шудырганда, аның кысыграк күзләре хәйләкәр генә ялтыраштылар:

— Кунаккамы? — дип сорады ул.

— Шулайрак.

Шофер аның чемоданнарына күз салды да көлеп җибәрде:

— Утырттыкмы законны?! Өйгә кайткач аның саулыгына бер йөз грамм кәкмичә булмый хәзер, — диде ул.

Машина үз юлында булды, Исхак үз сукмагына борылды. Күктау өстеннән бер өер каргалар очып күтәрелде. Борынга кизәк исе, кыр ягы исе килеп бәрелде. Су буенда ике-өч хатын тирестән суккан кирпечләрне өеп маташалар иде. Шактый еракта булганга, алар Исхакны, ул аларны танымады.

Чемоданнар җиңеләеп киткәннәр иде. Исхак аларны каурый тоткан кебек кенә очырта-очырта ындыр артлатып китте. «Танышлардан беренче кем очрар икән?» Һәр кайтканда бу сорау аның күңеленә килә. Бала-чага очраса дип, элеккерәк елларны кесәсенә бер-ике конфет та тыга торган иде. Соңгы кайтуында аны балалар каршы алды. Тик Исхак аларны танымады. Балалар да борыннарын тартып, башларын бәбкә төсле кыңгырайтып ят абыйга карап торалар иде.

Бүген кемне очратыр икән?

Тик аңа берәү дә очрамады. Кукуруз арасында йөргән ике кәҗә мутланып башларын күтәреп карадылар да исләре китмичә һаман чемчекләнүләрендә булдылар. Түгәрәк каен бүрәнәләрдән тезгән бәләкәй күперне чыгып тыкрыкка кергәч, бик тәмле бал исе аңкыды. Тигәнәк, сукыр кычыткан чәчәкләрендә кортлар гөжли иде. «Табыш бар дигән сүз!»

Әнисе Зөләйха ахирәтләрендә торуын язган иде инде. Шул урамга җитәрәк, ул чемоданнарын җиргә куйды, өс-башын какты, чалбар балагына ябышкан сырланнарны сыдырып төшерде, чәчен тарады. Башы авырта, беләкләре калтырап тора, авыздан күгәргән тимер тәме килә иде... Тик бу хәлне әнисенә сиздермәскә кирәк! Ул басып торып аз гына хәл алды. Кукуруз, бәрәңге басулары өстендә тәнне изрәтә торган коры рәшә тетрәнә иде.

Корылыкка таба китмәсен тагын!

Ул тәвәккәлләп урамга керде...

Көне буе көтеп арган Маһибәдәр чоланга кереп, азрак хәл алыйм дип яткан иде. Ялы ял булмады. Капка шыгырдаса да, тычкан кыштырдаса да, йөрәге дерт-мерт итеп, сикереп торды.

Зөләйхаларның әтәче дә бик таза тавышлы. Әллә кайда тау өстендә очкан тилгәннәрне күреп ала да үкереп диярлек кычкырып җибәрә. Нәкъ менә «По-жар!», «По-жар!» дип кычкырган кебек. Шуның өстенә әтәч койма башына менә дә, канатын кага-кага, бишәр мәртәбә рәттән үзенең «киккри-күген» суза.

— Тамагыңа таш кергере, тфу-тфу, әйттем исә кайттым.

Йокыга китә алмады ул, идәнгә җәйгән толыбын каккалап стенага кадакка элде дә ишек алдына чыкты. И-и, тәмам кич булган лабаса! Күләгәләр озынаеп беткән. Бу баланың кайтмавы булгандыр инде...

Һай, бала, бала!.. Монда әнисенең ниләр уйлап ятуын белмидер шул ул!.. Идарәдән көн дә килеп сорашып торалар. «Я, Маһибәдәр түти, ни уйладың? Йортыңны тергезикме, юкмы?» диләр...

Һай, бала, бала!..

Кире борылып керәм дигәндә генә, капка ачылды.

— Улым!

— Әнкәй, исәнме.

Маһибәдәр улы кочагында бөтенләй күмелеп калды. Улы һаман да шул ук таза, чибәр. Карчык ымсынып муенын сузып урамга карады: килен күренмиме?



Бераүгә дә әйтмәсә дә, ана күңелендә җылы бер өмет бар иде: инде шушындый кайгылы көннәрендә улы килен белән кайтып аны куандыра алмасмы, дип уйлый иде. «Белмәссең, шыпырт кына кайтып шаккатырыр!»

Шуңа күрә ашны да ишлерәк салган иде. Киленне ят йортта каршыларга туры килер микәнни дип кайгырып та куйган иде. Булмады. Исхак тагын ялгыз башы кайткан иде.

Аның нинди уйлар, нинди планнар, белән кайтуын белергә теләгәндәй Маһибәдәр кат-кат улының күзенә карады. Тик еллар буе күрми торган баласының күз карашында ул аңламаган ымнар, яшерен уйлар гына чагыла иде.

Өйгә керделәр. Маһибәдәр күмерләренә көл кунган, сүнеп барган кече учакка коры чыбыклар атты:

— Ашым да кыркуланып беткәндер инде, балакаем...

Самовар яңартып җибәрде. Иске итек кунычы белән шактый өрдергәч кенә, аңа җан керде.

— Кеше самоварының җаен да белеп булмый. Пароход иртән килде дисеңме? Ачыгыплар беткәнсеңдер инде бала!

Исхак кулларын ял иттереп тезе өстенә куйган килеш ян сәкедә утыра иде, әнкәсенең ашыгуын, каушавын күреп, мөмкин кадәр көлебрәк җавап бирергә тырышты:

— Ачыктым ачыгуын, әмма түзәргә була әле.

Ул ишек алдына чыгып юынып керде һәм карчыкның күңеленә хуш килерлек беренче сүзләрне әйтте:

— Шулай да безнең очның суы йомшаграк кебек хәтердә калган.

— Әйе, улым, әйе, кая ул үзебезнең оч суларына җитәме соң,— диде ул, кинәт моңаеп.

— Бу безнең сөлге шикелле?

— Әйтмә дә инде, улым, бары янып бетте. Вак-төяк кенә, ыбырчыбыр гына чыккан шунда, — диде ана куанып. Ул сүзне шул тирәдә йөртергә ниятләп тагын янгынны искә алды, тик Исхак ләм-мим дип аңа җавап бирмәде. Ул түр стенага куелган зур рамдагы эреле-ваклы фотоларны бик җентекләп карарга кереште.

— Әхмәдулла абзый һаман чунниктәме?

— Шунда. Зөләйха апаң да бүген иртәдән үк аның янына китте. Бал суыртырга әзерләнәләр.

— Аларның Илдарлары һаман Уралдамы?

— Шунда...

Самовар кайнап чыкты, казанда шулпа гөбердәп тавыш бирде, бүлмәгә ит исе таралды.

Иң элек кара-каршы утырып чәй эчтеләр. Маһибәдәрнең күкрәге куаныч белән тулы булса да, юк-юк дигәндә дә уй-хәсрәтләр аның миен телеп уза, улының үзе кенә бер сүз дә әйтмәве аның йөрәген авырттыра иде.

Нигә сүз башламый инде?

Исхак каймакны да, төче кумәчне дә бик яратып ашады. Маһибәдәр кала күчтәнәчләреннән — мәк хәлвәсеннән, йөземле батоннан авыз итте.

Чәйдән соң да Исхак үзенең ничек-ничек пароходта кайтуын, ничек килеп төшүен, машина көтүен, атка утыруларын бәйнә-бәйнә, кайта-кайта шактый кызык тамаша итеп сөйләп утырды. Әйтерсең лә аларның ничә ел күрешмәү дәверендә шулардан да мөһимрәк, кирәгрәк эшләр, вакыйгалар булмаган!

Бер кат күрешү-сөйләшү минутлары үткәч, бер-берсенә күзләре ияләнә төшкәч, Исхак әнисенә бик матур, йомшак оринбур шәле алып бирде:

— Бу сиңа, кышка, әнкәй!

— Рәхмәт инде, улым. Болай зурлавың өчен, рәхмәт, — диде дә, Маһибәдәр шәл мамыгына битен куеп елап җибәрде.

Шәлләр алып кайткач, үзе белән китәргә кыстамас ахры бу бала!.. Чемоданда тагын шундый ук бер шәл күренде:

— Бусы кемгә? — Маһибәдәрнең тавышы калтырап, ишетелер-ишетелмәс кенә чыкты. — Киленгәме?

— Юк, әнкәй... Бусы Бәнат апага!

— Бәнатка булса ярый... Бик рәхмәт анысы өчен дә... Киленгә болай да ярар дисеңме?

Маһибәдәрнең хәле бетеп китте, йөзе агарды.

— Юк, әнкәй. Киленгә әле берни дә юк. Үзе дә юк әле киленең.

— Әй, улым, улым! Тагын шул Хәерлебәнатларга китеп олагырсыңмыни?

Исхак мамык шәлне чиста ак кәгазьгә пөхтәләп кенә урады да әнисенең күзләренә туп-туры карап:

— Барып кайтырга кирәк, әнкәй. Син үзең дә беләсең бит,— диде.

Маһибәдәр кинәт кызып китте, әллә ниләр әйтергә, үпкәләргә, рәнҗергә, ачуланырга теләде. Тик ничә еллар көттереп кайткан балаңа беренче минутларда ук ничек рәнҗисең? Ничек үпкәлисең?.. Түзәргә туры килә, тешеңне кысып түзәргә... Барысы да ачы юшкын булып һаман шул бер йөрәккә утырып кала инде.

— Нурулла абыйдан хат киләме?

— Килә дигән иде. Бу араларда гына Хәерлебәнатны да күргәнем юк. Һәркемнең үз кайгысы дигәндәй...

Исхак җыена ук башлады.

— Әллә бүгенгә өйдә генә торасыңмы, балам?

— Мин хәзер, әнкәй... Барам да кайтам... Хәзер!

Менә ул ишек алдына чыкты. Капканы ачты. Япты. Аз гына карап торды. Тәмәке кабызды. Нидер уйлап торды. Аннары түбән очка таба төшеп китте.

Маһибәдәр Исхакның Бәнатларга китүенә һаман ышанып бетми, менә капканы чыгар да, югары очка, Хөсәеннәргә таба китәр дип өметләнә иде.

Улының ерагая баруын күреп, ул йодрыклары белән тәрәзә төбен төйде...

Тагын шуларга! Тагын шул ук...

Улы һаман да үзгәрмәгән...

Биш ел түгел, ун ел кайтмый торса да, шушы ук булачак...

Ана тәрәзә төбенә капланып, үртәлеп елап җибәрде.

## 4

Бәнат, тулырак итеп әйткәндә, Хәерлебәнат, кайчандыр карты Нурулла белән авылның тимер юл станциясенә чыгып китә торган очында — Имәнле урамында яши иде. Авылда, гадәттә, «кем өе» дип сораганда, йорт башы, ир кеше исеме белән «фәләннәр йорты» дип йөртәләр. Кышын кар астыннан морҗасы гына чыгып кала торган, җәйләрен

сәрви, шомырт, балан агачларына күмелә торган бу бәләкәй йорт элек-электән «Бәнатлар өе» дип телгә кереп калган. Моңа Нурулланың күп еллар читтә йөрүе сәбәп булган булса кирәк.

Бер дә йөремсәк кеше түгел иде Нурулла.

Яшьтән үк абзар-кура, мал-туар арасында чуалырга яратты. Биш яшеннән өйрәтелмәгән бил бирмәс тайларга атлана башлады. Алты-җиде яшеннән тырмага чыкты, унда печәнгә төште. Уникедә үзбаш ат җигеп олауга йөри башлады...

Нинди генә эшкә тотынмасын, Нурулла кебек пөхтә, җиренә җиткереп эшләгән кеше юк иде. Дулап яшәде Нурулла, шаулап егет булды, гөрләтеп өйләнде, җир җимерттереп туй ясады... Тик гомерлек бәла килде: көзен ашлык сукканда барабанга кысылып, сул беләге өзелде егетнең. «Чулак крестьян буламыни?» дип әрнеп больница капкасыннан ук туры калага чыгып китте. Ахры, ару гына җиргә урнашты. Китүенә күп тә үтмәде, авылда калган хатынына акча салгалады, авыл кешесенең хаҗәтен белеп кенә ситсы-митсылар җибәргәләде. Язгы пычраклар бетеп, урам кырларына ялтырап сукмаклар төшкәндә, Хәерлебәнат кыз бала табып, аңа Сания дип исем кушты. Иренең ил гизәргә чыгып китүенә рәнҗеп калган яшь хатын, кызы тугач, чиксез шатланды, кендек әбисенә туй күлмәген бүләк итте. Бердән аның үзенә иптәш, юаныч булды, икенчедән ата җаны түзмәс, инде шәт өйгә кайтыр да, төпләнер дип уйлады.

Нурулла, кызы тууына куанып, масаеп озын бер хат язды, бәбәйгә дип күзе йомыла торган дәү курчак салды да озак кына вакыт хәбәрһәтерсез югалып торды. Хәерлебәнат бер яшьлек кызын кочаклап, елый-елый иреннән хат көтте.

Көзге караңгы кичләрнең берсендә, станциядән кайтучы күрше авыл олаучылары сул аягын тездән югарырак өздергән сыңар куллы, ябык, бетәшкән Нурулланы Бәнатлар өенә ташлап киттеләр. Бер килгән кешегә килә бит ул, Нурулла урам аркылы чыкканда таеп егылган кыз баланы коткарам дип, үзе трамвайга кысылган икән.

Электән дә ябык, курач Нурулла озын буйлы, таза бәдәнле хатыны янында көзге чебеш кебек кенә булып калган иде.

Мәҗлесләрдә булсын, җыеннарда булсын, яндырып бии, өздереп җырлый торган, әллә никадәрле җор, хикмәтле сүзләр белгән, зәңгәр сатин күлмәге өстеннән чуклы эзәр бәйләп, аягына шыгыр-шыгыр килеп торган күн итекләр генә киеп йөргән бөркет Нурулла канаты сынган мескен тавыкка әйләнгән иде. Җаны тынычсызлыгын сиздереп калын, киң кашлары астыннан утлы күмер төсле янып ике кара күз генә элеккечә карый иде.

Яшь бала өстенә гарип ир дә кайтып төшкәч, Хәерлебәнатның болай да такы-токырак барган тормышы бөтенләй чуалып китте. Вакыты җитмичә иртә картаю билгесе булып, күпереп торган кара чәчләренә беренче кырау шул чагында йөгерде.

Балыклы күл авылыннан агай-энеләре килеп, Нурулладан аерылып кайтырга өндәп тә карадылар аны. Тик хатын андый киңәшләрне ишетергә дә теләмәде...

Нурулла сыңар кулы белән кызын сөяргә, сыңар аягы белән түр сәкедән бусагага, бусагадан ава-түнә ишек алдына чыгып йөрергә, себерке тотарга, вак-төяк чыбык чабарга өйрәнде. Ләкин нужа камыты киеп тормышны алып барырга бу бик аз иде. Хатынының көне-төне эштә ватылуын күреп, Нурулла тешләрен кыса-кыса әрнеп ята иде. Ире бала карады, Хәерлебәнат тынмыйча иртә-кич эштә булды. Тирес сукты, печәнен чапты, өй эшләренә дә өлгерде. Ләкин ач та булмадылар алар, рәхәтләнеп авыз тутырып ипи дә чәйнәмәделәр.

Авылда колхоз төзелә башлагач та, Нурулла сәкедән сикереп төшеп кәнсәләргә титаклады. Сынар кулын болгый-болгый:

— Большевиклар бу нужага бер-бер чарасын табарлар дип әйтә килдемме? Рабучий халык бит алар, крестьянны аңларга тиешләр, — дип кычкырды. Тик берничә кеше этләшеп Нурулланы колхозга алмадылар:

— Гарип-горабаны тутырмагыз әле. Без эшләгәнне алар кимерен ятмасыннар әле, остарып! — дип кычкыручылар арасында Гыйльми Салихы да бар иде.

Иренең ава-түнә кайтуыннан ук эшнең ямьсез якка борылуын аңлаган Хәерлебәнат ярсып, кызып кәнсәләргә үзе китте...

Нурулла интегеп булса да, агач аяк белән йөрергә өйрәнде. Каен агачыннан ясаган аягын мамыклар, чүпрәкләр белән ботына бәйләгәндә: «Кайгы каен башында-ау!» дип җыр шыңшып куя иде. Кутырлап, кызарып сызлаган ботын кичен җылымса суга тотып утырганда, агач аягын тотып:

— Син дә кайчандыр зифа бер агач булгансыңдыр... Бер аксакка терәк булырмын дип уйламагансыңдыр,— дип сөйләнгәли иде... Ул көндезләрен, Хәерлебәнат эштә вакытта, кызы белән булашты, кичләрен яңа гына оешкан колхоз келәтләре янына каравылга барды.

Келәтләр элекке алпавыт утары урынында, авылдан бер-ике чакрым урнашсалар да, ул ераксынмады. Адәм имгәге булып ятарга күңеле риза түгел иде аның. Таза, нык келәтләрдә чәчүлек тә саклана, фураж да тора иде. Шуларның барысына да төнлә генә булса да хуҗа булып тору крестьян рухлы бу кешенең авыртуларын оныттыра, күңеленә бер җиңеллек китерә.

Караңгы, болытлы бер төн иде. Нурулла җыр шыңшып келәтләрне бер әйләнеп чыкты:

— Каен бәлләүләрдә үстем...
Шуңа кайгылы башы-ым!..

Иң кырыйдагы келәт янына атлылар туктады. Атлыларның юлдан үтеп-сүтеп йөрүенә күнеккән Нурулла аңа башта игътибар да итмәде. Толып-чикмәненә төренеп утыра бирде. Утыра торгач, башына бер шик килде: теге атлылар бик озак мыштырдыйлар, нишлиләр икән алар? Ул кәкре таягына таянып чатанлый-чатанлый шунда китте. Ватык келәт ишегеннән капчык күтәреп чыгып килүче кешеләрне күреп, ул бөтен көченә кычкырып җибәрде:

— Туктагыз, явызлар!

— Акырма, бугазың тыгылыр!

Бик таныш кебек тоелды Нуруллага бу тавыш. Ул таягын болгыйболгый тагын да якынрак атлады:

— Урлатмам, барыбер урлатмам!..

Аның тавышына кушылып ук мылтык шартлады...

Бу төннән Нурулла сыңар күзле булып калды.

Кул-аягы юклыгын ул кадәр авыр кичермәгән бу чыдам, түзем кеше, күзе юклыгына бик офтанды, бик кимсенде. Кеше арасына чыгып йөрүдән туктады. Җәен-кышын колакчынлы бүрек, сырган бишмәт киеп өй арасында гына урала башлады. Бер колакчынын маңгай турына китереп күз урынын каплап куя иде.

Келәт басучыларны эзләсәләр дә, таба алмадылар. Яман акырып үзенә ындәшкән тавышны таный да, танымый да иде Нурулла. Бер уйлаганда, Гыйльми Салихының тавышына бик охшаган иде ул. Кешене юкка батыру булмасын дип тикшерү вакытында Нурулла аны-моны әйтмәде. Терелеп, аякка баскач, җае белән үзем очына чыгармын, бәлки, дип өметләнде. Әмма ул җай тиз генә чыкмады...

Имгәк өй тавыгы булып кына яшәү тора-бара Нурулланың саруын кайната башлады. Ул Хәерлебәнатка:

— Түзәрем калмады, әнисе. Кайда, ничек булса да кысылып, тыкшынып яшисем килә, — дип инәлде.

— Каян табыйк соң син бахырга ярардай эшне? — дип өзгәләнде Хәерлебәнат. — Менә эшлисең ич, тик тормыйсың, миңа булышасың,— дип ирен юатты.

Нурулланың сыңар күзе утлы күмер төсле яна иде.

— Ю-юк, әнисе... Син минем нинди егет икәнлекне беләсең... Җанымны көйдереп, эшлисең, димә... Эшкә сусадым мин... Җитәсем килә!

— Кая?

— Күз кая караса шунда. Илдә чыпчык үлми диләр бит!

— Чыпчык хәлендә яшәргә ризамы соң син, бөркеткәем? — дип кочаклый иде Хәерлебәнат иренең ябык муенын...

Салам түбәле өйдә, Имәнле урам очында мондый сөйләшүләр һаман ешайдылар. Йоклый алмый газапланып яткан чакларында Нурулла:

— Икең бергә җигелеп эшләсәң иде дә, менә бу көзге төннәр болай ямьсез, әшәке тоелмас иде, — дип бәргәләнә иде. — Күкне-җилне, һаваны-болытны каргап озакмы яшәргә мөмкин?

Һәм менә шундый күңелсез көннәрнең берсендә Хәерлебәнат:

— Ялгыз яшәп җелегем корды, ни күрсәк бергә күрербез. Аягыңкулың гарип, сине бер үзеңне юлга ничек ышанып чыгармак кирәк. Без дә калмыйбыз, — диде ул иренә, һәм «үз куллары белән» тәрәзәләргә калын такталар кадаклады, ишеккә бәләкәй ташбака төсле күгәргән йозак элеп, ачкычын күршеләргә кертте.

Алар шулай өчәүләп сәфәр чыгып киттеләр.

Ябык кына, кечкенә генә Нурулла башын иеп уйга чумган. Арба үрәчәсеннән күккә караган аягы туп көпшәсе булып күренде. Аның янына рәттән утырган таза беләкле, эре сөякле, чигүле алъяпкычын терәп торган мул күкрәкле Хәерлебәнат шыпырт кына балавыз сыга.

Сәфәргә чыгуга иң нык сөенгән кеше Сания булды. Акрын гына шыгырдаган арба да, арбада шыплап төялгән тәмле исле салам да, арттан ялкау гына атлап килгән кара колаклы, нечкә сыйраклы колын да аның өчен искиткеч кызык һәм яңа иде.

Колын уйнаклый-уйнаклый килә дә артта кала. Хәерлебәнат, яшь, кыргый мал адашмасын тагын, дип борчыла ук башлый. Туктап колынны чакырырга тотыналар:

— Маһ-маһ-маһ!

Олаучы чакырып карый, колын килми, Нурулла кычкыра, колын аңа да колак салмый; нечкә, яңгыравыклы тавыш белән Сания маһмаһлый башлагач кына колын арт санын сикертә-сикертә чабып килеп җитә; шомыраеп иркәләп торган әнкәсенең күпергән имиләренә йомшак борынын төртә, ефәк койрыгын болгый. Кыз куанып чыркылдап көлә. Колын арба янына килә, Сания белән уйнарга, шаярырга тели...

Кайларда, нинди ризыклар тартып йөргәндер Нурулла гаиләсен. Алар авылга төгәл бер кыш хат язмадылар. Яз җитеп, җирләр кибеп, юллар төшкәндә генә күршеләренә Хәерлебәнаттан хат килде. Хатны җыелышып укыдылар. Чуклы-чуклы сәламнәрдән соң, Нурулланың тимер юл станциясендә каравылчы булып эшләвен, үзенең дә тимер юлга эшкә керүен, тамаклары тук, өсләре бөтен булуын язган иде ул. «Бакчага күз-колак булыгыз, зинһар, мал-туар йөреп, бала-чага ботарлап бетермәсен, читән-ихаталарны да урлап якмасыннар», дип тәмамланган хатны укыгач, күршеләр:

— Һи-и, җаны бар кешене җан тарта ул! Менә күрерсең, Хәерлебәнат та кайтып килер әле бер, Нурулла да чыдамас, каны каткан бәндә түгел ләбаса, — диештеләр.

Кергән, кызыксынган кешеләргә конверттагы «Белоруссия» дигән сүзләрне күрсәттеләр. Ай-һай, дип баш кактылар кешеләр, бик-бик еракларга киткәннәр икән! Загранница янында диләр бит аны Белоруссияне! Җир чите диләр!

Жир чите үк булдымы икән, булмагандыр, чөнки өченче җәйне үк кызы Санияне ияртеп Хәерлебәнат авылга кайтып төште. Кояш ягындагы тәрәзәләренең тактасын кубарып ыргытты, болдырга ук менеп житкән алабута, тигәнәкләрне йолкып-йолкып ташлады.

— Авылны бик сагындым, җәемне шушында үткәрәм, — диде.

Исхак чамадан тыш озын куллы, тез күмәчләре кабарып торган малай иде әле ул вакытта. Көтү шул очтан кайтканда, аның Имәнле урамына баргалаганы да бар иде. Хәтта бер яңгыр вакытында Хәерлебәнатларның лапасында шыкланып та торды. Киң яфраклы әрекмәннәр арасыннан яңгыр бакалары сикерешеп чыккач, тәрәзәләре кадаклanган, ишекләре бикле серле-шомлы өйгә карап бик нык курыккан да иде.

Нурулланы белеп тә бетерми иде ул, Хәерлебәнатны да, кызын да очратканы бар, әмма туктап күз салганы да булмады. Бик очраклы гына, шактый кызык таныштылар алар.

## 5

Кайчандыр шәп тегермән буасы бар иде күктаулыларның. Әле ул чагында Кыяр тавы да ул кадәр шәрә түгел иде, бәләкәй генә имәнлек иде. Җәйләрнең берсендә бик каты яңгыр-боз явып, аларның тегермән буаларын су ерды. Шул вакытта төзәтеп куярга куллары житмәде, икенче елда язгы ташу буаның субайларын, тегермәннең куласаларын, кырык чөйләре-ниләре белән алып китте.

Буасыз да, тегермәнсез дә калдылар күктаулылар. Бураларда он тулып ятканда, ваемсыз гына йөргәннәр иде, тора-бара бу эш бик читенгә китте. Ә дигәнче әйләнеп кайталар иде үз тегермәннәреннән. Хәзер барына-югына күрше авылга барырга, чират торырга, ялынырга туры килә. Колхоз да тегермән юклыктан иза чикте. Интектеләр-интектеләр дә тегермән юклыгына күнектеләр. Якын авылларда да тегермәннәр сирәгәйде. «Пар тегермәннәре корып җибәрәбез, нәрсә ул су тегермәне, капитализм калдыгы!» дип, бик күп су тегермәннәрен, яргычларны сүтеп яктылар. Күктаулылар эһ тә итмичә, шактый ерак Балтамак тегермәненә йөри башладылар. Зур су шул аларда, тегермәннәре дә дүрт ташлы!

Олылар тегермән юклыгына ризалаштылар, тик малай-шалай, егетҗиләп буа юклыктан бик интекте. Эссе җәй көннәрендә, урак өсте челләләрендә кыр ягының кайнар җилләреннән шыкланырлык бакчалар да, салкынча җиләс җил бөркеп торган урманнар да юк иде якын-тирәдә. Малайлар бер-ике җәй интектеләр дә, тәвәккәлләп, инешне үзләре буарга булдылар.

Иң элек бик бәләкәй малайлар маташты. Алар иске тегермән урыныннан бер-ике багана казып алып елга буена сөйрәп китерделәр. Аны нечкә тал казыкларга терәп инешкә аркылы салдылар. Яр буеннан кәс кисеп, тыкрыктан тирес, чүп-чар ташып буып куйдылар. Тез тиңентен су җыелгач та, коена башладылар, кичкә кадәр судан чыкмадылар. Борыннары белән буа төбен сөргәнче чумылдылар. Икенче көнне олырак малайлар җыелышты. Алар ыбыр-чыбырның дегеттәй кара суда чупырдавын яр башыннан карап-карап тордылар да бәләкәчләрне судан өреп чыгардылар. Озак көттеләр, тик су тонмады. Самайларга да күлмәк-ыштаннарын салып ыргытып, эшкә тотынырга туры килде.

Кемдер әти-әнисенә күрсәтмичә генә, өйләреннән таза-таза берничә имән казык алып төште, Әхми куаклыгыннан саллы гына ике-өч карама кисеп кайттылар, Кыяр тавыннан бәләкәй арба белән таш ташыдылар. Эш кайнады. Өченче-дүртенче көннәрдә дә буа буенда кеше өзелмәде, олырак егетләр дә кайнашып китеп, алар ат белән тирес ташыдылар. Элемтәчеләр Алмалыга телефон үткәрергә дип юл буена баганалар ташлап киткәннәр икән. Гыйльми Салихы өң-дүрт егетне ияртеп,

эңгер-меңгердә шуннан җиде-сигез багана да чәлдереп кайтты. Иртәнгә кадәр баганаларның өчесе югалган иде югалуын, әмма калганы да житте. Җыйнаулашып имән дөмбәскә белән төя-төя субай кактылар. Ерак урманнан ике-өч арба чыбык та кайтты. Бусын колхоз председателе җибәртте.

Буа күзгә күренеп күтәрелде, су акрын-акрын гына җәелә-җәелә Имәнле урам турына ук килеп җитте...

Малайлар арасында иң кызып, иң ярсып эшләгән кеше Исхак булды бугай. Буа янында әвәләнгән ыбыр-чыбыр янына самайларны ул чакырып китергән иде. Иртә таңнан шунда йөгерде, көтү каршысына барырга соңга калып апаларыннан, энисеннән әр ишетте, әмма эшен ташламады. Сикерә-сикерә тирес таптады, носилка белән туфрак ташыды...

Буа үзара дошманлашып йөргән югары оч һәм түбән оч малайларын берләштерде, кым-кырыч бала-чага онытылып эшләп йөрделәр.

Буа буышты Исхак, әмма су күтәрелеп, бәбкә үләннәре белән капланган сөзәк ярлар аста калгач, ул моңаеп чирәмлектә бер үзе басып калды: малай йөзә белми иде. Башта ук дәртсенеп кереп киткән булса, башкалар кебек ярга якынрак урында чупырдар иде әле, тик Исхакның андый хәйләгә маһирлыгы юк иде, аның йөзә белмәвен бик тиз күреп алдылар.

— Исхак, чишен, чишен, кер, кер! — дип кычкырдылар югары оч малайлары.

— Әй, карап кына торам әле, — дигән булды ул.

— Йөзә белми, йөзә белми, гарьлек! — дип такмакладылар түбән оч малайлары.

— Ние бар аның? Менә, карап тор, кулыңны алмаш-тилмәш шулай-шулай алып саласың да аягыңны чаж-чож кыймылдатасың. Су үзе күтәрә, — диештеләр малайлар.

Бөтен малай игътибар белән сиңа карап торганда, ничек базып суга керәсең?

Исхак буа койрыгынарак барып ялгызы гына чиркәнчек алырга, йөзеп карарга булды. Йөзгән кебек итеп кул хәрәкәтләре ясады, чаж-чож!.. Ул акрын-акрын гына, сиздермәскә тырышып буа алдыннан китә башлады. Чирәм араларында вак дулкыннар ясап чупылдаган су, кызыктырып аның тәпиләрен кытыклады. Ул, малайлар күзеннән котылдым дип уйлап, җинел сулады. Шул вакытта коточкыч бер хәл булды. Исхактан күз дә алмый торган олырак биш-ун малай шәрә тән судан ургылып чыктылар да, уенчак тайлар кебек кешнәшеп аны куып җиттеләр, күз ачып-йомганчы җиргә егып салдылар, тартып-йолкып күлмәк-ыштаннарын салдырдылар. Үзен күтәреп суга ыргытабыз дигәндә генә, ул ничектер ындыр читәненең юан казыгын кочаклап алды. Тешләрен кысты, күзләрен чытырдатып йомды. Малайлар аны йолыккалыйлар, төртәләр, култык асларын кытыклыйлар иде. Исхак чинап, кычкырып җибәрде. Малайлар аның саен шашыбрак аны тарткалыйлар, көләләр, сикерешәләр иде. Менә, менә йолкып алабыз дигәндә, арадан берәү:

— Әй, ташлагыз сана шуны! Киемнәрен суга ыргытыгыз, кирәк булса үзе кереп алыр! — дип кычкырды.

Әле генә үзе белән буа буышкан, иптәш-дус дип йөргән малайларның аның киемнәренә таш салып буа уртасына ыргытуларын күргәч, Исхак иреннәрен чәйнәп елап җибәрде. Тырналган тәне авырта, кулбашларыннан сызылып кына кан ага иде. Ул туфракка буялган килеш яр буенда шактый утырды. Малайлар коендылар-коендылар да астыртын елмаешып тыкрык буйлап кайтып та киттеләр. Аларның пырхпырх көлешеп, тыкрыктан үзен күзәтеп торуларын Исхак сизеп утырды...

Буа алды тынды. Яр буенда чират көтеп йөргән каз-үрдәкләр бакыл-

дашып елгага кереп тулдылар. Исхакның күлмәк-ыштаны өскә калыкмады. Ул оялып, кызарынып озын чыбык тотып яр буенда әрле-бирле йөренде. Суга керергә курыкты, тәне тартыша башлар кебек тоелды.

Шул вакыт аның күзенә таудан төшеп килүче ике хатын-кыз чалынды. Оялудан тыны бетеп, ул тыкрыкка йөгерде, як-ягына каранып торгач, калтырана-калтырана кычыткан арасына кереп качты. Шыкланырлык башка урын юк иде.

Таудан төшеп килүчеләр Хәерлебәнат белән аның кызы булып чыкты. Менә алар буа янына килделәр, аякларын чишенеп озак кына юындылар. Исхакның кычыткан көйдергән яралы урыннары түзәлмәслек әрни, кызыша башлады. Ул нишләргә белмичә, селкенергә дә куркып, кычыткanлыкта чүгәләп тора иде. Тегеләр тыкрыкка кереп, Исхак яшеренгән урынга җиттеләр. Кыз ялан аяк йөгерергә күнекмәгән иде ахры, табанына нидер кадалып, ай! дип кычкырды.

— Шырпы кергән, кызым, — дип юатты аны әнисе, кызының табанын карап. Алар туктап торган арада, Исхак куркып кыймылдап куйды, терәлеп кенә торган кычытканнар аяусыз чактылар, малай түзмәде, сулкылдап ыңгырашып алды. Хатын моны ишетте һәм күтәрелеп кычыткан арасына текәлде. Исхак шүрләп катып калды. Тик хатын ары китмәде, якынрак килде һәм кычыткан чагып бетергән анадан тума малайны күрде.

— Син нишлисең, балам, монда? — диде хатын, гаҗәпсенеп.

— Малайлар... малайлар, — диде Исхак, еламсырап.

— Нәрсә малайлар?

Исхак нидер әйтергә уйлаган иде, киселгән кап-кара чәчле, шәһәрчә киенгән кызның үзенә таба килүен күреп тагын чүгәләде. Үткен тешле кычыткан сабаклары аның тәнен көйдереп алдылар.

— Әлә-лә! — дип чырылдады малай.

— Алар сине кыйнадылармы?

— Ю-юк... Күлмәкләрне суга, буага ыргыттылар...

Хәерлебәнат мәсьәләне аңлап алды, кызын җитәкләде дә җил-җил урамга менеп китте. Бераздан Нурулланың иске күлмәк-ыштанын тотып төшеп тә җитте. Малайны көчләп диярлек кычытканлыктан алып чыкты, су буена алып төште, юындырды һәм ак күлмәк-ыштан кигертеп үзләренә алып менде. Исхак күзләрен кая куярга белмичә болдырда утырган арада, алар аналы-кызлы су буена төшеп менделәр. Икесенең дә чәчләре чыланып, йөзләре алсуланып кайтып керделәр. Хәерлебәнат малайның күлмәк-ыштаннарын сыгып, читәнгә элде һәм шунда гына:

— Кем малае соң син? — дип сорады.

— Фәтхи малае...

— Ә-ә... Әнкәң Маһибәдәр була инде алайса.

— Әйе...

Хәерлебәнат читкә карап кына бер елмайды да малайны кыстый-кыстый өйгә алып керде. Сания бер сүз дә дәшмичә, көлүен чак тыеп бабай кыяфәтле малайга карап тора иде.

Керде Исхак, өстәл янына утырды һәм гомерендә бер дә күргәне булмаган шоколод конфетны беренче мәртәбә шунда ашады...

Исхак ике-өч көн өйдән чыга алмады. Тәне вак кабырчыклар белән капланды. Ул кабырчыклар сары су белән тулдылар да тишелделәр...

Рәтләнеп өй арасында йөри башлагач, аның янына иптәш малайлары керде. Аларның күзләрен ялтыратып ишек төбендә өерелешеп торуларын күргәч үк, Исхакның бала йоннары тырпайды. Ул кече якка кереп китте дә малайлар янына чыкмады. Малайларны эштән кайткан олы апасы пешереп чыгарды.

Атна-ун көн үткәч, Исхак Имәнле урамына китте. Хәерлебәнат белән Сания аны шатланышып каршы алдылар.

Кызның әллә кайдагы Белоруссиядә торуы, әллә ничә урында төшә-төшә поезд белән кайтуы, зур-зур шәһәрләрне, киң, тирән елгаларны күргән булуы башта Исхакта ачыктан-ачык көнләшү тойгысы уятса да, ничектер ул Санияне бик тиз иптәш итте. Аның үзенең тимер юлны түгел, егерме чакрымдагы урманны да күргәне юк әле. Аталары бар малайлар этиләренә ияреп станциягә дә, урманга да баргалыйлар. Ә ул? Әнисенә ияреп Балтамак тегермәненә генә барганы бар...

Әллә кайларда булып кайткан яңа иптәше булу ятим малайның китек күңелен беркадәр юатты да, ахры. Андый иптәше авылда бер малайның да юк иде!

Санияләргә барып йөри башлаганнан бирле, Исхак әллә ничек үзгәреп китте. Тезе ямаулы чалбарын яратмый башлады ул. Төсе дә уңган, курачланган да. Аннары нигә әнисе әллә кайчан вәгъдә ителгән җиз бакалы, унике телле тальянны алып бирми инде? Апалары да ризалашканнар иде ич! Өйрәнер иде дә Саниягә уйнап күрсәтер иде...

Әнисе яңа чалбар бөтәйтергә дә, ялтыравыклы бакалы гармун алырга да өлгермәде, Санияләр китеп бардылар.

Исхак аларның китәчәген көне-сәгате белән белеп тора иде. Шулай да икенче көнне тәрәзәләре кадакланган, җил капкаларына сүс бау уралган тәбәнәк өйне күргәч, ул үзен нидер югалткан кебек сизде. Кесәләрен капшады, сөяк саплы пәкесе дә төшеп калмаган, рогаткага дигән кызыл резинка да кесәдә, нәрсәсе югалган соң аның? Малай тәки төшенмәде.

Саниянең чатан Нурулла кызы булуын һәм аларның гаилә тарихларын Исхак шул елны гына белде.

Кыз китте дә барды. Сагынуны белерлек яшьтә түгел иде әле Исхак. Шулай да Сания киткәч күңелсезләнеп, борчылып йөрде. Элекке иптәшләре белән дә артык якынаеп, үз булып китә алмады ул. Аларның буа алдындагы хыянәтләрен кичермәде...

Йөрде-йөрде дә, кызны да онытты.

Укулар башланды, кыш килде. Буа койрыгына тимераяк шуарга барганда, кар астыннан тырпаеп торган кычыткан кураларын күргәч, Исхакның күз алдына малайларның өерелешеп үзен йолыккалаулары, кыргый тавышлар белән акырулары-бакырулары килде. Ул куркып дерелдәп китте. Иң соңыннан гына аның хәтеренә мөлдерәп торган бик матур күзләр килеп төште.

Андый күзләр башка беркемдә дә юк иде.

## 6

Хәерлебанат Куктауны ташламады.

Җәйнең җәендә һәр елны кунакка кайтты. Кайтты да, я бер ай, я ай ярым торып китте.

— Карар җире дә юк шушы кыр ягының, тик шушында кайттым исә, каным тарала, сулышым киңәя,— дип сөйли иде ул.

Сания дә әнисеннән калмады. Унбер-унике яшьләрендә ул нәкъ әнисе кебек буйлы, таза булырга чамалап тартылып, үсеп китте. Ул буйлы булса да, кайбер кинәт үсеп киткән кызлар кебек котсыз сузан, юка кыз түгел иде. Матур иренле кечкенә авызында ялтырап киткән ап-ак тешләрен, алсу тырнаклы килешле бармакларын — барысын да тигез, мәкәмәл итеп биргән иде Саниягә табигать.

Баштагы елларда аларның кайту хәбәрен ишеткәч, Исхак:

— Кайтканнар икән! — дип, беркатлы гына куана иде. Хәзер яз житә башлау белән: «Кайчан кайтырлар икән?.. Ул да кайтырмы? Куктауның кайсы төшен сагынып кайтсын ди инде? Без булмаган сукмаклырлар да калмаган... Ничә карасаң да, шул камыл да таш, сыза да тузанлы юл... Әгәр ул туеп беткән булса, кайтмаса? Әтисе җибәрмәсә?» дип зурларча борчыла, хафалана иде.

Аның пошынулары тиккә булды. Сания һәр елны кайтты. Һәр елны бер яшькә олыгаеп күрешәләр иде алар. Бергә уздырган вакытлары бер-берсендә булган еллык үзгәрешләрне өйрәнеп, аңа күнегеп сизелмичә үтеп китә иде. Һәр нәрсәдән яңача ямь, башкача тәм табалар иде алар.

Әйтик, бала чакта Әхми куаклыгы чикерткәләр тоту урыны булса (ә кызыл канатлар чикерткәгә генә кабалар да инде!), соңгы елларда Исхак белән Сания бу сирәк куаклыкның яңа бер хасиятен ачтылар. Куак арасына кереп яшеренәләр дә офыклар киңәеп киткән дөньяга таудан карап озак кына хыялланалар. Офык киңәйгән саен, сүз күбәя, сөйләшүләр кызыграк, мәгънәлерәк була баралар.

Шунысы да бар: син бөтен дөньяны өстән торып күзәтәсең, сине берәү дә күрми! (Бу да аларга мөһим була башлады).

Сания Исхактан ике яшькә олырак иде. Бала чакта сизелмәгән яшь аермасы, бер елны кинәт кенә үзен сиздерде.

Моны сизү Исхак өчен бик авыр, бик аянычлы булды.

Көтү кайтырга иртәрәк булса да, Исхак Имәнле урамына китте. Күперне чыкты, тауга менә башлады (Имәнле урамы бәләкәй генә калкуга урнашкан иде), артына борылып карады. Малайлар күренми иде әле. Ул кабаланып-кабаланып авыл очына китте. Санияләрнең басу ягына чыккан нигезләренә барып утырды. Гадәттә, ул шушында көтеп утырганда, Сания үзе белеп килеп чыга иде. Шактый көтте Исхак, авыл очындагы чирәмлектә мәтәлчек атып та карады, сыерчык булып сызгырырга өйрәнеп азапланды, олы бер чикерткәне тотып аны мунчала кисәге белән үләнгә бәйләп куйды, тик Сания чыкмады. Бу якта аларның тәрәзәләре юк, өй эче күренми иде. Бүрәнә аркылы кемнәрнендер быдыр-быдыр сөйләшүләре ишетелде. Әллә кунаклар килгән инде? Булса соң, өйдә кунак булганда чыгып сызарга бигрәк уңай ич!..

Менә ипи катылары тоткан, озын чыбыклар кыстырган әби-чәбиләр, сүсләп үргән камчы шартлатып малай-шалайлар көтү каршыларга җыела башладылар. Ерак та түгел юл өстендә, тузан болыты күтәрелде. Көтү сузылып акрын гына авылга якынлаша иде.

Сания чыкмады.

Сания күренмәде.

Кәҗә-сарыклар арасында тузан йотып, аларның өй турыларыннан үтеп киткәндә, Исхак ымсынып тәрәзәгә карады. Тик пәрдә күтәрелмәде, капка шыгырдамады...

Ул сыерларын урам буе чаптырып алып кайтты. Аннан-моннан гына капкалады да тагын чыгып йөгерде. Тагын Имәнле урамына барды.

Бәнатлар өенә якынлаша башлагач, адымнары акрынайды малайның. Бераздан Исхак шып туктады: өйдән киенгән-ясанган өч кыз чыгып киләләр иде. Башта ул Санияне танымый торды. Таныгач, бөтенләй каушады, сүз әйтә алмаслык хәлгә килде. Аның шундый хәлдә урам уртасында басып торуын күргәч, кызлар дәррәү пырхылдадылар. Сания исә алгарак чыкты:

— Исхак, Исхак, мин бүген авыл уенына төшәм. Син дә безнең белән барасыңмы? — дип сорады.

Санияне уенга алырга кергән Имәнле урам кызлары бер-берсенә карашып туктаусыз көлешәләр иде. Тапканнар кызык! Ачуы килде Исхакның, күзләрен түбән төшерде һәм үзенең ялан аягын, аяк бармакларының шыксыз тырпаеп торуын, кулларының килбәтсез озын булуын, үзенең үсмер егеттән бигрәк бакча карачкысына охшаганлыгын абайлап алды.

— Юк, бармыйм, — диде ул, кырку гына һәм кырт борылып тыкрык буйлап ындыр артына йөгерде. Кызлар һаман чыркылдап көлештеләр, Сания нигәдер борчылып:

— Исхак, кая барасын? — дип кычкырып калды.

Тик малай аның борчулы тавышын ишетмәде, ул чабып өйләренә кайтты, бусага төбендә таптанып торды да җылы сулы комганны эләктереп ишек алдына чыгып китте. Аякларын, кулларын ачы сабынга ком катыштырып ышкып-ышкып юды, тиресе сыдырылып бетте, әмма аяк агармады. Малай учлап-учлап кычыткан ефәге йолкып килде, аның белән ышкыды. Апалары урамда, әнкәсе абзар-кура арасында йөри иде, аның ашык-пошык тирләп-пешеп каядыр әзерләнүен берәү дә күрмәде.

Як-ягына каранып, сандыктан яңа чалбарын тартып чыгарды. Мәктәпкә барганда гына киярсең дип әнисе чалбарны үтүкләп сандык төбенә үк салып куйган иде. Сәке астыннан ботинкаларын эзләп тапты да үйга калды. Күн итек кигәндә шәбрәк булыр иде дә бит! Буе да бераз калкурак күренер иде, егет сымаграк та булыр иде. Ул бераз кыенсынып торды да чоланнан әтисенең күн итеген эзләп алып керде. Күн итекләр шактый олы булып чыктылар. Малай аптырап тормады, аларның башларына иске оеклар, кәгазьләр шыплап тутырды да, аягына киеп, әнкәсе әйләнеп кергәнче дип, шыпырт кына чыгып сызды.

Караңгы төшеп килә иде инде.

Җылы, җәйге кич.

Буага якын гына урында аклан чирәменә яшьләр уенга җыелганнар. Шадра Василь өздереп-өздереп гармун уйный. Кызлар туктап бераз тын алалар да җыр сузалар. Моңлы итеп, озак итеп җырлыйлар. Аннары ай-һайлап егетләр биеп китә. Шадра Васильнең бармаклары тальян телләре өстендә шашынып чабалар. Егетләр, кызлар алдына килеп, тыпыр-тыпыр биеп, бармак шартлатып көдрәеп торалар да кызларны уртага тартып чыгаралар. Күмәк бию башлана. Аннары бөтенесе дә кулга кул тотаклашып, түгәрәк ясап әйләнәләр. Җырлыйлар, уртага я берәүне, я парлап чыгаралар да биетәләр.

Исхакның андый уеннарны әллә ничә күргәне бар. Апалары килмә дип кусалар да, ул уенга еш төшә. Шадра Васильгә кызыгып карап тора. Аның тальянының җиз бакаларында ялтыраган ай нурлары аңа сихерледер кебек тоелалар иде.

Унган егет Василь, шадра булса да кызларны авызына каратып тора!..

Бүген Исхак уенга якын да бармады. Һаман бер ераклыкта әйләнде-тулганды, кайсы якка гына карамасын, гел бер кешене генә күрде.

Сания олы кызлар белән рәттән басып торды, алар белән әйләнбәйләнә уйнады. Аннары югары очның Хөсәен киң балакларын җилфердәтә-җилфердәтә аның каршысына төшеп, ата каз кебек тыпырдап торды да Санияне биергә чакырды. Исхакның йөрәге дерт-мерт итә башлады, ул үзе дә сизмәстән, күн итекләрен лоштырдатып уен янынарак килде. Сания бөгелә-сыгыла тузан туздырып бии иде. Исхак шаккатып, керфек кагарга да куркып, сокланып аңа карап торды. Биюләр бетте, әйлән-бәйләнә уйнау китте. Киң балаклы Хөсәен тагын Санияне уртага чакырды. Кул чаптылар.

— Кунак кызын җырлатабыз!

— Җырласын әйдә, — дип кычкырдылар.

Сания оялган сыман бераз башын кыйгайтып торды да ялындырмый-нитми генә кычкырып җырлап җибәрде:

> Чәчәкләр куп, ләкин чәчәк өзмим,
> Табу өчен шундый ислесен,
> Мин тапканчы шундый бик ислесен,
> Җил исмәсен,
> Гөл дә үсмәсен.

Яңа көй иде бу Исхак өчен. Хәтта шадра Василь өчен дә яңа иде ахры, ул башка кызлар җырлаганда бакаларын шырылдата-шырылдата кушылып китә торган иде, бу юлы гармунын бер-ике генә кычкыртты да, башкалар белән рәттән, йотлыгып кунак кызын тынлап торды.

Тагын гөрләтеп кул чаптылар. Сания җырлап бетергәч үк оялып йөзен каплады һәм кемнедер эзләгән булып бер кырыйгарак чыкты. Исхак коты чыгып арткарак чигенде һәм нәрсәгәдер абынып егылды. Бер читтәрәк чүмәшеп тәмәке тартучы үсмер егетләр аны эләктереп кул очына күтәрделәр.

— Җибәр, бурсык!

Ул аякларын селки-селки тешен кысып кычкырды. Шулчак, аның оятына каршы, сул аягының күн итеге шуып чыкты. Күн итек эченнән иске оек кунычы, кәгазь кисәкләре бүселеп төште. Яшь егетләр, аның ай-ваена карамыйча, уртага күтәреп керттеләр һәм гармунчыга кычкырдылар:

— Уйна, Василь! Бер яшь этәч бар әле монда.

Исхакны танып, апалары малайны аралап алдылар, бер кырыйга алып чыгып, күн итеген кияргә булыштылар. Малай кызарынып-бүртенеп карап торды да үзеннән көлеп торган Хөсәенгә алагаемга китереп сукты. Таза төшерде, ахры, Хөсәен мәтәлеп үк китте. Исхак лаштыр-лоштыр чаба башлады. Хөсәеннең иптәшләре күп, кулларына эләксәң, кабырганны санап бирерләр!

Малайны куа киттеләр, Исхак хәйләгә кереште, барды-барды да иң алдан йөгереп килүчегә оста гына аяк чалды. Анысы тәкмәрләде. Күнеле күтәрелгән малай күн итекләрен салды да тауга таба элдертте. Су буе шау-гөр килеп, иһаһайлап аны озатып калды.

Тауга шактый менгәч, ул тыны бетеп җиргә утырды, мышный-мышный түбәнгә карады. Менә уенлыкны каян карарга кирәк булган икән!

Шадра Василь ярсып-ярсып бию көе сыздыра, кемнәрдер ярып сызгыралар. Ай нурына коенган буа өстендә кемнәрдер таш чәпчетәләр.

Малай кинәт тетрәнеп китте: ак күлмәкле берәү тауга менеп килә иде! Ул сикереп торды, күн итекләрен күкрәгенә кысып томырырга әзерләнде.

— Исхак, Исхак!

Сания малайның үзенме, күләгәсенме күреп алды һәм туп-туры аңа таба китте.

— Ерак чапкансың син, — диде ул, елмаеп. — Уф!

Малай сүзсез генә күн итекләрен киде. Җиргә утырды. Сания дә аның кырына ук килеп чүгәләде. Малай гарьлегеннән һаман эндәшми иде.

— Күлмәгең буяла бит,— диде ул, күз кыры белән генә кызга карап.

— Бик авыртамы? — дип сорады кыз, бераз тынычланып.

— Юк. Мин сизми калдым. Гомердә дә тоттырмый идем мин аларга...

— Ә син теге малайга ару тондырдың!

Исхак авызын ачып калды: Сания рәхәтләнеп, куанып, кулларын чәбәкли-чәбәкли көлә иде.

— Хөсәен ул... Теге вакытта, хәтереңдәме икән, минем киемнәрне суга ыргыткан егет!

Кыз буадан күзен алмый утыра. Менә алар икесе дә тынычландылар, сулышлары тигезләнде. Бергәлек әле генә булып үткән күңелсезлекне оныттырды.

— Бик матур икән ич монда, — диде кыз, бераздан.

Малай әле ни әйтергә белми иде, ул да кыз әйткәннән соң, беренче тапкыр күргәндәй, буа өстенә, төнге йокыга чумган тонык зәңгәр урамнарга, уендагы яшьләрнең кара күләгәләренә әсәренеп карап торды. Матурлыкны уртак итеп икесе дә онытылып шактый утырдылар.

— Мин яңадан уенга төшмим.

— Нигә? — диде малай, шыпырт кына.

— Шушында тауга гына киләм. Монда күңеллерәк.

— Син мине Хөсәеннән курка дип беләсеңме әллә? Тамчы да курыкмыйм. Куып җитә алмый ул мине!..

Сания акрын гына көлде.

— Ышанмыйсыңмы? Куркак дип беләсеңме? Әйдә, уенга төшәбез. Үзең күрерсең менә.

— Аны әйтмим лә, — диде кыз, бөрешеп. — Салкынайтты. Җил исә! Төшәбезме, Исхак?

Бераз төшкәч кенә, ул әйтеп куйды:

— Ничек тондырдың син аңа! Янак сөякләре шартлап киткәндер!..

Бүген ярты гына булган ай төннәр үткән саен тула барды. Сания күрше кызларына ияреп һәр кич диярлек су буена төшә, өздереп җырлый-бии дә капылт кына борылып тауга менеп китә. Үзе артыннан ияргән егетләрне ачуланып кире бора. Кыз белеп тора, ни генә булмасын, тау киртләчендә аны Исхак көтеп утыра. Олыларча тезләрен кочаклап, тынгысыз күзләре белән аны көтеп...

Алар җитәкләшеп тау киртләче буйлап бик еракка баралар. Уен тарала башлагач кына түбәнгә төшәләр. Сания Имәнле урамы кызлары белән кайтып китә, өй күләгәләренә ышыклана-ышыклана күпергә кадәр аларны Исхак озата бара...

Балаларының дуслыгына Хәерлебәнат белән Маһибәдәр дә игътибар иттеләр. Аларның якынлыгы аналарга да тәэсир итте. Элек бик үк якын булмасалар да, хәзер бер-берсенә кереп чыккалый, тәмлерәк әйберләр пешергәндә кунакка дәшә торган булып киттеләр. Маһибәдәр белән Хәерлебәнат башка авыллардан килен булып төшкәнгә, агай-энеләре күплеге белән мактана алмыйлар иде.

Хәерлебәнатның бу омтылышы авыл халкы өчен ят булып, башта Маһибәдәргә бик сәер тоелса да, бер күнеккәч, «балаларыбыз да дус, үзебез дә ахирәтләр булыйк», дип көлде. Сания Исхакның апалары белән якынайды...

Тагын ел үтте.

Кырык беренче елның язы...

Исхакка гыйнварда унөч тулды. Унөч кенә шул әле! Ә Сания быел унбишне тутырып уналтыга чыкты... Июнь башларында алар кунакка кайтырга тиешләр.

Малай Саниянең борчак кебек эре хәрефләр белән язылган хатларын җыеп, кадерләп саклый. Соңгы хатларының берсендә ул: «Сизәсеңме, язга таба минем хатларым озынрак була башлады. Бу — көннәр озынайганга гына түгел, минем Куктауны сагынуым көчәя барганга», дип язды...

Бу хатны беренче тапкыр укыганда, Исхак кызарынып китте. Аннары бик озак уйланып, хатның зәңгәр юлларыннан үз йөрәгенә тоташкан юлларны ачыкларга теләде. Башка елларда да Сания үзенең авылны сагынуын, җәйне көтеп алуын яза иде. Быел шул гади сүзләрдән Исхак яңачарак мәгънә эзләде. Эчке мәгънә, тирән мәгънә...

Мәхәббәт хакындагы китапларны йотлыгып укый башлаган, Лермонтов шигырьләре белән саташып йөргән көннәре иде аның...

«Куктауны сагынам» дип, «сине сагынам»ны әйтергә теләмәде микән ул?..

Исхакның хәтта маңгаена тир бәреп чыкты.

Үсмер йөрәгендә шуны теләү уянган иде...

Тик Саниянең тел төбендә ни барын үзе кайткач кына белеп булачак. Шуның өчен үсмер быел аны эчке бер тетрәнү, яшерен өметләр газабы белән көтте.

Сер булу яшь егетләрне, кызларны иптәшләреннән аера. Сер кешене кинәт кенә олы итә, җитдиләндерә. Сания белән язышкан серләрне Исхак үзе иптәшләреннән дә, апаларыннан да яшереп саклый иде. Аның хатларын чормада үзе ясаган сандыкта биклап тота иде. Кай-

чагында кәттә суыкларда күлмәкчән генә чормага менеп китә дә кызның хатларын рәттән барысын укып төшә. Шул ук сандыкта аның былтыр сабан туенда көрәшеп алган сөлгесе һәм шигырьләре саклана. Арада «Имән» дигән поэма да бар.

Шигырьләр дә, поэма да бер кешегә багышланганнар. С. Н. га.

Сагыну борчуы аның төсенә дә чыкты, ахрысы. Ул ябыгып, озынаеп китте. Әнкәсе аны аркасыннан еш-еш сөя иде:

— Җитепләр беткән егет булдың инде, улым! — дия иде ул, яшь аралаш куанып...

Язгы мул яңгырлар бик бәрәкәтле булды. Болыннарда гына түгел, тауның гомер-гомергә шәрә яткан, абагадан башка нәрсә үсмәгән урыннарында да ишелеп үлән үсте. Беренче эссе җилләрдә үк көеп төшә торган Әхми куаклыгында чыпчык башы-чыпчык башы җиләкләр тәгәрәп пеште. Буага уйнап кына кармак салырга төшкән кеше дә өч-дүрт куырырлык чабакларны, кушбашларны алып кайта иде. Ул игеннәрнең уңуы дисеңме, арыш арасында адашырлык, сабан ашлык арасында дуга күмелерлек иде.

Исхак инде ничә елдан бирле уку бетүгә колхоз эшенә йөри башлый. Кызлар да, Мәһибәдәр үзе дә яшелчә бригадасына йөриләр. Мәһибәдәрнең дә, Исхакның да өмет зурдан иде быел. Һич югында, җиз бакалы гармун быел базардан аларга кайтырга тиеш!

Менә шундый рәхәт, күңелле көннәрнең берсендә, Имәнле урамына елкылдап торган кара айгыр кайтып керде. Яшел печән тутырылган тарантаста Хәерлебәнат белән Сания утыралар иде.

Алар чеп-чиста өйгә кайтып төштеләр. Инде моннан бер атна элек Исхак килеп тәрәзә такталарын кубарган, Мәһибәдәр кызлары белән өмә ясап өй эчен, өй алларын, чоланны кырып юып чыгарган иде.

Сания белән Исхак кич булгач кына күрештеләр...

Көндез аларга барырга малайның көче җитмәде...

Әнә ул...

Чәчләрен үреп, килешле итеп баш түбәсенә төйнәп куйган. Киң, ачык маңгае астыннан зур кара күзләр нур сирпиләр. Матур ак йөзгә мөлаемлек өстәп, дымлы алсу иреннәр сизелер-сизелмәс кенә елмаялар. Җиңелчә зәңгәрсу күлмәк шактый калку күкрәкләрне, нечкә билне ап-ачык белдереп тора.

Менә Исхак...

Җиң эченнән чыгып уңайсыз асылынып торган куллар. Бер тырнагы кысылып кара янган. Бурлат кебек кызарынган йөз... Таракны санламыйча төрле якка чәбәләнгән каты чәчләр. Ул беренче мәртәбә быел кыш озын чәч калдырды...

Буйга алар бер чамада булсалар да, кыз аның янында олырак, өлгергәнрәк иде.

Бер ел эчендә шактый нык үзгәргәннәр, икесе дә шул үзгәрешне күреп ятсындылар. Элеккечә гадилек тә, күнегелгәнлек тә юк иде. Исәнлек-саулык сорашканнан соң да, бер-берсенә ияләшә алмадылар.

Нигә була икән мондый тартыну?

Барыбер шул ук кешеләр калган лабаса! Исхак белән Сания... Шул ук авыл... Шул ук урамнар... Нигә кыенсынып торырга? Ялган хис ич бу кыенсыну. Ничек җиңәргә аны?..

Көндезләрен очрашырга кыенсынсалар да, кичләр аларныкы иде.

Төн — бәхетлеләр оҗмахы! Тын су буйлары, ай нурына коенган көмеш таулар, озын-озын күләгәләр, томанлы, чыклы иртәләр... Яшьлек барын да аз гына бизәп күрсәтергә ярата. Үзе дә бизәлгәнне күрергә тели ул. Төн — тормышның нужасын, ыгы-зыгыларын яшерә. Төн — җирнең яшертен сихерчесе...

Үткәннәр әле матур, гөнаһсыз, киләчәк ерак, бүгенге көн сихерле бер төш кебек кенә...

— Ә буа кайда? — дип сорады беренче кичне үк Сания.
— Буа китте...
— Нигә ел саен китә инде ул?
— Хәзер елдан-ел сулар ныграк ташый.
— Нигә алай, Исхак? Елга елдан-ел саега бара, ә ташулар көчәя дип сөйлисең. Нигә болай була ул?
— Аның сере бар, Сания... Зур сере... Урманнарны кисеп бетерел киләләр. Хәзер яңгыр китергән су җиргә сеңә дә алмый кала, ашык-пошык кына җиргә төшә дә чупырдап агып та бетә. Урманнар суның тоткасы... Алар аны җыеп алалар да акрын гына аска үткәреп, чишмәләргә, елгаларга өлеш чыгарып яталар.
— Ә нигә урманнарны шулай күп кисәләр?
— Менә анысын белмим мин...
Кыз да озаклап уйлана... Ай нуры яктырткан тау киртләчендә алар кулга-кул тотышып озак-озак йөриләр. Яшь булса да, Исхак кырлар, урманнар, сулар турында ничек күп белә!
— Белоруссия урманнарын күрсәң иде син!..
— Бер барып чыгармын әле.
— Чынмы, Исхак? Әти гел сорашып тора сине.
— Каян белә ул мине?
— Ничек инде, минем дустым булып йөр дә, ул сине белмәсен.
Исхак тукталып, кызның күзләренә карады:
— Без дуслармыни синең белән?..
Егет кая басканын белешмичә йөри иде...

Аларның бәхетле көннәре һич уйламаган яктан киселде.
Иртәләрнең берсендә Маһибәдәр тыштан:
— Бик иртә төшкән әле бу томан. Үзе шундый куе, игелексез нәрсә булып ашлыкларга, бәрәңгеләргә зыяны була күрмәсен тагын, — дип шөбһәләнеп сөйләнеп керде.
Исхак таң алдыннан гына кайтып яткан иде. Ул рәтләп йокыга да китәргә өлгермәде, ахры. Уяулы-йокылы ниндидер төш күреп маташты. Бүген Сания дә алар белән печәнгә чыгарга тиеш иде. Исхак аңа шома саплы, җиңел тырма әзерләп куйды. Чөйләре шома булсын дип пыяла белән кырып чыкты...
Торырга кирәк, ә кузгаласы килми!
Күрше малае Вильданның:
— Нишләп йоклап ятасың? Сугыш башланган бит! — дигән сүзләрен ишеткәч, ул дерт итеп сикереп торды.
— Нинди сугыш? Кайда башланган?
— Ни сөйлисең син, Вильдан улым, язмаганны?
Куе томан тәрәзә пыялаларына орынып, суга манган. Өй эче ярым караңгы, моңсу. Вильданның таңкә-таңкә кызыл сипкелләре тагын да куера төшкәннәр.
Томан бераздан вак яңгырга әйләнеп ява да башлады. Мондый дымык, пычрак көндә печән турында уйларга да ярамый иде. Малайлар йөгерешеп урамга чыгалар да яңа хәбәрләрне төяп кайтып керәләр. Вильданнарның печәнлегенә менеп, шунда яталар.
Яңгыр һаман пычтыр-пычтыр сибәләп торды. Өйләргә, киртә-корталарга муртайган, ташландык иске төс биреп, авыл күренешен тагын да фәкыйрьләтте.
Вильдан:
— Без германнарны бүрек белән генә бәреп егабыз! — дип үзе җыр чыгарып, төрле көйләргә сузып гайрәтләнеп ятса да, Исхак аңа кушылмады. Ул кулларын ияк астында кушлап йөзтүбән яткан да нидер уйлый иде.
Сугыш!

Киноларда күргәннәре бар аларның сугышны. Каравыл өендә Чаптар Миннәхмәтнең сөйләгәннәрен ишеткәннәре дә бар. Тылсымлы Буденный кылычларын да яхшы беләләр... Газеталарда: «Без дошманга бер карыш җиребезне бирмәбез... Сугыш дошманның үз җирендә барачак!» дип яздылар...

Нигә елашалар соң алай ансат булгач повестка алган кешеләр?

Сафа абый әле хатынын, әле балаларын кочаклап нигә үкереп елый. Сабан туйларында батыр калган кеше ич ул! Чуер ташы кебек тракторчы... Нигә елый ул?

Исхак түзмәде, Вильданга кычкырды:

— Туктыйсыңмы син, юкмы?

— Җибәр аяктан, — дип шырылдады сипкел, җырлаудан туктап. — Менә күрерсең, бер айдан Берлинны алырбыз!

Исхак көрсенеп башын тышка сузып карады. Сирәк яңгыр һаман сибәли, көн күңелсез, ишек алдын телгәләп вак кына болганчык гөрләвекләр йөгерешәләр. Кинәт аның күзләре шар булды, ул куркып Вильданның касыгына төртте:

— Кара әле, кан!

— Кая, кая? Һей, җүләр! Тирес суы ич ул! Күрмисеңмени, абзардан агып чыккан!..

Малай чытырдатып күзләрен йомды. Күңеле төшенке, бик төшенке иде аның.

## 7

Исхак кичке караңгы иңүгә тау киртләченә китте.

Маһибәдәр апа:

— Кая барасың тагын? Мондый шомлы төндә әйдә өйдә генә утыр!— дип кычкырып калды.

Озак көтте егет Санияне. Кыз килмәде. Бик озак көтте. Туңып бетте. Ялгыз башына бик ямансу, бик кыен булды. Еламсар таллар тиятия астан инеш ыңгырашты. Буп-буш уенлыкта котсыз, серле күләгәләр селкенеп йөргән сыман булды. Күктау авылы асыл ирләрен юлга әзерләп әрни, иңри иде. Әнә, югары очта ярсып-ярсып гармун үкерә! Шадра Василь!.. Лапас-кура тирәсендә фонарьлар йөри. Сарык суялар... Бөтен авыл төн караңгылыгын санламыйча аяк өстендә, урамда, ишек алдында иде.

Утыра торгач, Исхак үзенең йөрәк тибешен ишетте.

Хуҗасына буйсынмыйча нык-нык, ярсып тибә иде ул.

Ул күңеленең кайсы почмагы беләндер сугышның җитди, хәтта бик куркыныч нәрсә икәнлеген, бүгеннән соң кичәге кебек ваемсыз яши алмаячагын, сугыш аның тормышына да кагылып китәчәген сизенде.

Ах, әтисе исән булса иде! Сөйләшер иде, киңәшер иде, сорашыр иде...

Иртән бөтен авыл тагын ду купты. Бик күпләргә чакыру килгән иде инде. Капкалар туктаусыз шыгырдады, кое сиртмәләре бер менеп, бер төшеп тордылар, урамнан арлы-бирле өзлексез кешеләр үтеп йөрде. Ишек алларында кабык арбаларда бәбәйләр елашты. Мунчалар ягылды, ипиләр пеште, коймаклар чыжлады...

Хәерлебәнатлар да китәргә җыендылар.

Хәерлебәнат:

— Абзагызны белмисезме әллә, ул бит ярты кеше икәнлеген уйлапнитеп тормый, тәвәккәл, гаяр бит ул, бахыркаем!.. Сугышына да чыгып китәр, я ничек... Тик тормас җан!.. Аннары дөнья хәлләрен кем белсен... Чуен юл бик тынгысыз урын ич ул. Алай-болай булгалаганчы кайтып элгәшә алсак кана! — дип өзгәләнеп сөйләшкән, имеш...

Бу хәбәрне көтү куарга барган җирдән Маһибәдәр алып кайтты...

Моны ишеткәч, Исхак урамга чыкты.

Салкынча дымык иртә...

Бөтен авыл тузгыган.

Менә сиңа сугыш! Әллә кайда Кама аръягында утырган бәләкәй Куктау авылына да үрелә ала икән ул. Дөньяда барлыкларын колхоз хисапчысы белән бригадир гына белә дип йөргән Нургали, Миңлевәли агайлар бер төн эчендә «кызылармеец Сөнгатов», «рядовой Булатов»-ларга әверелделәр.

Җигәргә ярау атлар җигелде, кабык арбалар, тарантаслар җитмәгәч, чытыр арбалар хутка китте. Зур җыен вакытларында да Куктау юлыннан берьюлы бу кадәр атлыларның узганнары юк иде. Акрын гына барган олаулар артыннан иңрәп-сыктап карчык-корчык, хатын-кыз, кыз-кыркын иярде.

— Минем әти германнарны кырырга бара! — дип мактаныбрак йөргән малайлар, авыл урамын чыга башлагач, әниләренә кушылып еларга тотындылар.

Исхакларның үз өйләреннән озатыр кешеләре булмаса да, ул таңнан урамда чуалды. Тегесе белән саубуллашасы, монысының атын җигешәсе, сбруен-мазарын хәстәрләшәсе бар... Барысы да китәләр. Василь абыйлар, Шәрипләр, Кәрам кодалар...

Имәнле урамында халыкка Санияләр дә кушылды. Алар, аналы-кызлы, арык алаша җигелгән, салам тутырылган иске генә кабык арбага утырганнар иде. Сания Исхакны күргәч тә арбадан сикереп төште. Алар юл кырындагы кичәге яңгыр шәбәрткән чыклы үләнне ерып янәшә бара башладылар.

— Китәсезме?

— Әйе.

Яшьрәкләр исерешеп тә алганнар иде инде. Алар атларын чаптырып әле арыш арасына кереп китәләр, әле юлга килеп чыгалар, сызгыралар, камчы шартлаталар. Олауларның әле берсендә, әле икенчесендә гармун үкерергә тотына. Куктау авылының гомер-гомергә җырлана торган аерылышу, саубуллашу, бәхилләшү җырлары бүген чын булып, шуңа күрә аяусыз булып яңгырыйлар.

Китәм инде, китәм инде,
Китәм инде, каласыз...

Әйе, китәләр...

Әйе, калалар...

Элек бу җырларны җырлап рәт-рәт ясап, кулларны иңгә салып урам иңләү бер кызык кына булган икән.

Кызык булган икән, кызык... Ә хәзер кызганыч...

Алар берни уйламыйча гамьсез генә үз кайгыларын кайгыртып, үз мәшәкатьләре белән яшәп ятканда, анда, көнбатышта, аларның күкрәкләренә төбәлергә тиешле пулялар инде коелган булган...

Юл буйларында тапталып, изелеп өлгергән арышлар егылып кала.

Юл буенда яңа чабаталарның, кыршылган күн итекләрнең табаннары астында сынып-сынып чыклы күзле чәчәкләр кала.

Моңарчы ятимлекне онытып торган ятим Исхак кала.

Сынган күңелләр, өзелгән өметләр, киселгән бәхетләр кала.

Кем кайтыр да кем күрешер...

Кем калыр да кем каршы алыр...

Кырлар, кырлар, карап калыгыз, сезнең тугры хуҗаларыгыз китә!..
Кырлар, кырлар, хушлашыгыз, нык куллы дусларыгыз китә!

— Нигә җырлыйлар инде, ичмасам, — диде Сания, ачыргаланып.

— Китәләр бит, — диде Исхак, күңеле тулып.

— Тын гына китеп булмыймыни?

— Тын гына яшә, мыштым гына йөр, шым гына сөй... Тавышсыз-тынсыз гына китеп бар! Ярамый, Сания...



Үз башына килгән уйларны Исхак ачып сала алмады, бары:
— Җырласыннар әйдә! — дип кенә куйды.
— Читен шул, бигрәк, — диде, яшьле күзләрен сөртеп, кыз.
— Мин... сине сагынырмын инде, Сания.
— Әй, — дип көлгән булды кыз. Ә үзенең күзләре тулы яшь иде.
— Әллә син калып торасыңмы?
Кыз башта сүзсез генә башын чайкады, аннары аңлатып бирде:
— Юк, Исхак, калып булмый. Әнием әйтә, без тиз генә әйләнеп кайтабыз, ди. Әтине генә барып алабыз да кире кайтабыз. Болай өчебез өч җиргә таралабыз бит. Әнкәй курка... Инде әйләнеп кайтсак, авылдан беркая да китмибез.
Малайның күзләре ялтырады, ул үзе дә сизмәстән борынын тартып куйды:
— Беркайчан дамы? — дип сорады ул.
— Әйе.
— Сез кайтсагыз, мин дә Күктаудан беркайчан да китмәс идем. Укып бетергәч тә авылда калыр идем...
Кыз дәшмәде, авыр сулап әнисенә карап куйды.
Олаулар баралар-баралар да туктыйлар. Атлар туктауга һәр арба тирәсендә бер төркем тупланып үзара гәп кузгала. Өйдә чакта еллар буе онытылып торган кадерле сүзләр хәтергә килә. Кешеләр капыл-копыл гына бер-берсен яратышуларын, якынлыкларын, аерылышыр алдыннан ояла-ояла гына булса да әйтеп, искәртеп калырга тырышалар.
Шактый җир киткәч, озатучыларның бер өлеше кайтырга борылды:
— Нихәтле барсаң да алып калырың юк! Ходай үзе сакласын да исән-сау күрешергә язсын!
Калганнар атларга төялешеп пристаньга кадәр барырга булдылар. Исхак та Саниялар арбасына елышырга ниятләгән иде дә, кемдер:
— Йөк булып йөрмә әле, синең бер кемең дә китми ич, — дип, ярым әрләп, җай гына утырган жиреннән аны куып төшерде.
— Мин олаучы булып барам, атны алып кайтам, — дип карулашты Исхак. Аңа авыз да ачтырмадылар:
— Хатыннар алып кайтыр, әйдә, барыбер заман аларга кала. Өйрәнә торсыннар, — дип кенә җибәрделәр. Ул җылытып өлгергән урынга бер апаны меңгереп утырттылар.
Хәерлебанат үзе дә:
— Бар кайт инде, Исхак улым, без сугышка китмибез ич. Кояш кебек әйләнеп тә кайтырбыз әле, — диде.

Сания әллә ничек сәер итеп елмайды, аның күперенке иреннәре калтырадылар, бераз баргач ул ап-ак яулык чыгарып болгады. Исхак арбалар буйлап йөгереп күрешеп чыкты да кырт борылып авылга таба чапты. Бераз баргач, эчен кату алып, туктап калды. Кешесез калган шып-шыр, котсыз урамга керәсе килмәде аның. Ул аръяк басуыннан язгы сыза төшә торган коры үзән буйлап инешкә кадәр төште. Элекке буа буйларын урады. Тып-тын иде, бер җирдә дә адәм заты күренмәде. Көтү чыкмаганга көне буе фермада ач яткан колхоз сарыклары шыранлап-шыранлап кычкыралар. Ул тизрәк ферма яныннан сыпыртты. Тыкрыкларда ашык-пошык кына йолкынган каз, тавык йоннары оча иде...

Күңеле һаман теге кешеләргә рәнҗи иде малайның.

«Беркемең дә юк, имеш... Әйе, этисе юк.. Исән булса, әллә бармый калыр идеме? Сыңар кулы белән тарантасны күтәрә торган ир булган ул! Ә ул авыз күтәреп, беркемең юк, дип тора. Төлке!»

Исхак өйләренә кич кырын гына кайтып керде. Мәһибәдәр ут алып, бик пошынып аны көтеп утыра иде.

— Бигрәк озак йөрдең, улым. Әллә Чаллысына кадәр үк бардыңмы?

— Юк, әнкәй.

— Алайса, аша да ят инде. Таңнан эшкә чыгасы булыр. Бригадир өч керде инде, менәтерәк, өч! Адәм заты корды Күктауда, ди.

— Бик тиз... Бригадиры кем тагын?

— Мәфтухә апаң.

— Ә-ә...

Эшкә... Адәм заты корды, ди...

Алар, Исхаклар, авылның тернәкләре булып калалар...

Урамнан нигәдер куркынып кына җырлап бер төркем кызлар узды. Йокы аралаш алар Исхакка җырламыйлардыр, күмәкләшеп бер җайга гына елыйлардыр кебек тоелды. Алар егетләрен озатканнар... Егетләрен...

Ә ул менә дустын — сөйгән кызын озатты.

Андыйлар авылда ул гына Берәү генә...

Кинәт аның йокысы ачылып китте, ул башын күтәреп карады. Кече як сәкесенә чиста сөлге җәйгән дә әнисе намаз укый. Гомердә укымаган намазын каян исенә төшергән әле ул? Намазы да әллә ничек үзенең, татарча гына. «Ходаем, үзең сакла... Явыз дошманнарның көчен таркат... Ходаем, авылыбызның ирләре исән-сау кайтсыннар... Туган җиребезне усал мимечләргә бирмә!»

Исхак мендәргә капланып колакларын томалады, күзеннән яшь атылып чыкты.

Авылда төне буе аяк эзе тынмады. Берәм-берәм Чаллыга киткән атлар кайтты. Кибет ишеге төбеннән кеше өзелмәде. Таң алдыннан гына түбән очта мунча артында мылтык тавышы яңгырады. Аксак Нуретдин этисенең ау мылтыгын алып чыгып, үзен-үзе атып үтергән иде...

Кышын ак бүрек киеп йөри торган бу тыйнак, зур соры күзле моңлы егетне ярата иде Исхак. Мәктәптә тәнәфес вакытларында ишектән чыгар иде дә гарип булуына оялып, кымшанмыйча тик басып торыр иде...

Иптәшләренең, яшьтәшләренең китүен, үзенең гарип булып ятып калуын күтәрә алмаган икән бичара...

Димәк, эшкә...

Сөя белә торган йөрәкнең әшли белә торган нык беләге дә булырга тиешлеген ул нәкъ менә шушы буталчык төнне аңлады.

Шушы төнне Исхакның үсмер чагы, бала чагы үтеп китте.

Иртән ул кашлары җыерылган ярым егет булып уянды. Бәрәңге ашарга да ул бүген олыларча, атасы урынына — түргә утырды.

*(Ахыры бар.)*

*Хисам Камалов*

## Әнкәй истәлеге

Әнкәй,
Барча балаларың арасында
Иң уңмаган бала булдым мин.
Гүя, әнкәй, сиңа бер дә бетмәс
Җәфа өчен генә тудым мин.
Дөньяны кул, авыз белән татып
Үскәндә үк белдем алай да:
Мине артык иркәләвең күреп,
Каныга иде миңа малайлар.
Ә мәктәптә — стенгазетка мин
Ясый идем рәсем күп итеп.
Күчерүче кулын — табагачтай,
«Суфлер» авызын — башмак күк итеп.
Шуңар мине беркөн кыйнадылар.
Көчкә кайттым — жалу бирмәдем.
Кәҗә сөзде, дидем...
— Үртәмәссең,
Әйбәт булган! — диеп тиргәдең.
Әкияттәге сумалага баскан
Єаескандай бик еш ялгыштым:
Борынымны тартып алуга ук
Мин койрыгым белән ябыштым...
Уку ташлап, атлы эшкә киттем.
Анда да тик бәла күрдем мин:
Шыбыр тиргә баткан атны эчереп,
Аягына су төшердем мин...
Муеныма догалыклар тактың,
Бәхет килсен диеп улыңа...
Кимсенүчән, оялчан булгангамы
Кырын килде дөнья гел миңа.
Соңрак төшендем мин: кыю булсам,
Уңар иде, бәлки, эшләрем...
Үсмер чакның юләрлеге инде,
Чын дип белә хыял, төшләрен.
Очынсам мин хисләр канатында
Үземә алам бәлаләр генә,
Акыл килә бик соң, эш узгачтын,
Бер югалту бәрабәренә.
Хис ышана, соңын уйламый ул,
Хис ташлана үзен якларга.
Акыл һич тә җирдә тапталмый ул,
Хисләр генә кайчак таптала...

...Бер язны мин тай көтүе алдым,
Китмәсме дип бездән бер кытлык:
Кулымда ат булыр — печән, утын
Әзерләрмен диеп өч кышлык.
Ләкин бәла көтеп торган гүя:
Шатун булды иң шәп таема —
Утка төшкән кебек, мескенкәем,
Бәргәләнә, башын каера...
Куе кара тутырылган нәни
Шар шикелле моңсу күзләрен
Төбәп карый да бер, тагы атыла,
Суелып, кан булды тезләре.

Күз яшьләре ага янагыннан,
Борыннары сулый күректәй.
Ыңгыраша, ләкин теле юк шул!
Нәрсә соң бу, таем, нилектән?!
...Толпар кебек унган мал иде ул,
Нечкә билле, зифа сыннары,
Ал аяклар һәрчак тетрәп тора,
Әйтерсең лә, гөслә кыллары.
Бер айгырны якын җибәрми ул,
Эре тота үзен, булдыра,
Берәр нахал килсә, авызына
Арт аягы белән кундыра.
Төнлә тайлар ялга ятып бетә,
Ә бу ятмый, чума уена,
Аннан белдем: яхшы атлар шулай
Ятмый икән гомер буе да...
...Фельдшер килде. Канлы тезгенне ул
Иелеп алды гына кулына,
Тай торды да кинәт, өермәдәй,
Чыгып чапты авыл юлына.
Таш коймага бәрелеп үлгән мескен...
Ул алынган — никрут дус иде,
Фашистларны таптап узсын диеп
Өйрәттем мин... очар кош иде...
Ә идарә мине эштән куды,
Гадел хөкем, эшли белмәгәч.
Әнкәй, сиңа тагы кайгы төште,
Нәрсә диим, бәхет килмәгәч.
Аннан — сабан, ябык атлар белән,
Алар хәлсез — бик жәл мескеннәр,
Еш утлатам, нишлим — нормам тулмый.
Ялкау диеп мине «кистеләр».
Бездә дә шул — гел бәрәңге инде.
Алып барса, алып кайталмый,
Сабандашым Сәйфук капчык чишә,
Җыр такмаклый, эшне майтармый:
«Рәхмәт инде картушкыга,
Самовар — отпускыда,
Кашыклар — транспортта,
Казан — мәҗбүри эштә!..»
Мин җир сөрдем, чәчтем,
Ә җир миңа
Әфсен өреп үзен сөйдерткән,

Җиргә булган мәхәббәттә мине
Төзәлмәслек итеп тилерткән.
Шулчак — хәбәр...
Мин сугышка алынам.
Син шулкадәр
Беттең, бөгелдең.
Мин сөендем тамак туяр бер дип.
Синең өчен, ләкин көендем.
...Киттем дә мин суга баткан кебек,
Югалганмын, хатым килмәгән.
Синең җаның, хәбәр көтә-көтә,
Зур шикләргә төшеп иңрәгән.
Эшләр белән юаныргга теләп,
Җепләр эрләп кичне көткәнсең.
Мендәреңә төшлек куеп, төшкә
Кермәсме дип, йоклап киткәнсең.
Төшеңә дә һаман кермәгәнмен,
Син тагы да шиккә таргансың.
«Артык юаш, чыдыймы соң?» диеп,
Өметеңне өзә язгансың.
Шул өметсез өмет белән янып,
Йөрәкләрең инде кан саугач,
«Күрәзәгә әллә барасыңмы?» —
Дигән әби, чара калмагач.
Ике оядан ике мая алып,
Ике күкәй сиңа төйнәгән.
«Багучыга барма, бәла алма», —
Дигән сүзләр сине тыймаган.
Син баргансың,
Ә багучы ногытын
Бер чәчкән дә тагын бер җыйган.
Язмышымны синең күз алдыңа
Ташлар тезеп сөйләп утырган:
«Кәҗүнни йорт...
Димәк, яраланган...
Ярасы авыр түгел... юл көтә...
Кемдер аңа каршы килә... ә ул —
Өйгә кайтыр өчен эш йөртә...»
Дигән ул багучы.
Ни уйларга
Белмичә син кайтып киткәнсең.
Чәнчү алган тагы йөрәгеңне,
Ук тигәндәй син хис иткәнсең.
«Үзе юаш, үзе тәҗрибәсез,
Ничек калсын шундый мәхшәрдә?..»
Уйлагансың шулай... Ә мин, әнкәй,
Сугышып йөрдем һаман яшәргә.

...Бар өметләр өзелеп барган чакта,
Ялгаган бер русча хат килеп,
Сестралар язган минем хакта —
«Ярасы авыр, өмет юк!..» — диеп.
Мурт агачны давыл аударгандай,
Син күкрәгең тотып аугансың...
Мине үлгәнгә санап, хәлеңә кереп,
Идарә он биргән, авансы...

Сестралар тагы хат язганнар,
Анга килми озак ятылган.
Үлем мине һаман сагалаган,
Алалмыйча тайган ахырдан.
Яшь булулык әллә җиңеп чыккан,
Әллә сиңа борчу булсын дип,
Үлем мине алып китмәгәнме?
Белмим, тәки исән калдым бит!
Хирурглар кискән, теккән мине...
Кайчак кайткан аңым.
Кыл өстендә үлем басып торган,
Кылдай булган — җаным...
Аңга килгәч,
Иң беренче синең
Күз алдыма килде кулларың,
Я йон язып, я бәрәңге кырып,
Яки утын кисеп торганың.
Синең куллар — яргаланып беткән,
Үлән сүле сеңгән — тимгелле,
Ә уч төбең катлы-катлы сөял,
Гүя каты панцырь шикелле.
Кул аркаңда — тимер чыбык кебек
Тик сеңерләр, күгелҗем җөйләр...
Бармакларың энә кадалуын,
Пычак кисүләрен сизмиләр!
Кояш купшаклаган борын очың,
Тир тамчысы каплый сәйләндәй.
Җилкәңә кан төшә, таңнан-таңга
Эшлисең син эссе җәйләрдә.
Ә эштән соң бәләкәй арба белән
Малга печән җыеп кайтасың,
Ачлы-туклы тәндә көчең беткән,
Көянтәдәй бөгелеп тартасың.
Ике кулың — ике тартә кебек,
Авыр йөкне сөйри юллардан...
Балаларым ди-ди тырышканга,
Тәннәреңдә ит тә калмаган.
Ә кулларың ничек армый икән?
Алар нинди утта пешмәгән?!
Нинди генә кыен татымаган? —
Тик барыбер түбән төшмәгән!
Горур куллар! Нинди талган алар...
Эх, кадерләр идем шуларны!
Мин аларга һәйкәл куяр идем, —
Кантамырлы мәрмәрдән... бары.
...Бездәге бар тискәрелекләрне,
Усал холыкларның иң каен,
Әкияттәге тылсым таягыдай
Бетерә иде кулың, әнкәем.
Үсмер чакның хыялый шук күңеле
Үчле теләк белән тулганын,
Сизгәнсең дә, безне һәлакәттән
Саклап калган синең кулларың.

...Ярам сызлап, сөюемне бүлә. —
Вакыт тойгыларын югалттым.

Төташ әрни бөтен яраларым, —
Әллә көн бу, әллә тагын төн?
Сестрадан «морфи!» — ялварам мин.
«Ярамый!» — дип коя яшемне.
Ләкин түзә алмыйм, кызгана ул,
Укол сала... тагы яшим мин!
Авыру уйлар: нигә ядь-яшь көе
Газапларга тарды бу башым?
Ирексездән уйлыйм, гафу ит син,
Төште мәллә, әнкәй, каргышың?
Искә килә: кирелегем белән
Бәгыреңне әрнетүләрем,
Берничек тә инде йола алмам
Сине кайчак рәнҗетүләрем.
Йөрәк чәнчеп торган үкенечләр,
Кайларга гына илтеп бушатыйм?
Сиңа әйткән каты сүзләремне
Ничек итеп хәзер йомшартыйм?
Мин калдырган хәтереңне, әнкәй,
Нинди хакка гына табыйм соң?
Миннән риза-бәхил хисләреңне
Нинди эшләр белән яулыйм соң?
Гарипләнеп калуым —
Сине еккан,
Чәнечкән күк фашист пычагы.
Ничек, әнкәй, шундый хәсрәттән соң,
Дөрләталдың тормыш учагың?
Син юмалап мине, хат язгансың,
«Язмыш шулдыр, балам, сабыр бул!
Бер син генә түгел, ил белән бит!
Үзеңә генә төшсә авыр ул».

...Күз алдыма килә: суырылып
Бәләкәй арба тартып кайтуың,
Тир-тузанга баткан, хәлсез көе
Салкын суны голт-голт йотуың.
Таштай авыр тормыш арбаларың
Синнән алып, тарта алмадым.
Синең ябык иңеңдәге йөкне
Үз иңемә алып салмадым.
Җиңел итәлмәдем тормышыңны,
Син гафу ит, әнкәй, итәлсаң?
Якты итәлмәдем язмышыңны,
Син гафу ит, әнкәй, итәлсаң?!
Белсәң, әнкәй, дошман тылларына
Разведкага барган чакларым,
Мин куркудан доган гел укыдым,
Җаным саклап кеше сатмадым.

...Син яшәүгә мине дәртләндердең, —
Хатлар килеп торды гел синнән,
Сестралар шәфкатьләре белән
Биздерделәр мине морфидан.
Мин аякка бастым.
Тик сыңарга...
Әй, кимсендем шулай калуга,

Мин гарьләндем дус кызлардан бигрәк,
Һәм кайтмадым туган авылга.
Әйбәт кешеләр миңа булыштылар,
Үз хәлемә йомгак ясадым.
Теләмәдем төшеп калырга мин,
Әзрәк акыл керә башлады.
«Сукбай булса...» диеп куркуларың,
Күз яшьләрең миңа көч бирде.
Ә эчемдә: дошманнарны, малай,
Сөендермә дигән үч йөрде...
Бәхетсезлекләрне җиңә-җиңә,
Яшәгәндә укып, беркөнне
Авыр хәбәр синнән... көтмәгәндә,
Кайтмавыма шундый үкендем.
Яшергәнсең хәлең... Үзең мине
Көтә-көтә күзең канаган.
Кайткач танымадым... әй, беткәнсең —
Синдә тик чыкмаган җан калган.
Мин үкседем сәке йөзлегендә:
«Нишләттегез минем әнине,
Бригадир, ник эче өзелгәнче
Эшләттегез минем әнине?
Туганнар, сез нигә якын булып,
Әниемне кызганмадыгыз?
Врачларга ник күрсәтмәдегез?
Больницага ник салмадыгыз?
Идарә, син нигә карамадың?
Җәлләмәдең аның йөрәген?
Эх, барысына үзем гаепле мин!
Әнкәй хәлен онытып йөргәнмен!»
...Гомер буе син рыясыз эшләп,
Үзеңне, әнкәй, саклый белмәдең.
Балаларың өчен җәфа чиктең,
Үзең бер дә рәхәт күрмәдең.
Бәхиллегең бирдең. Соңгы сулышың
Алган чакта, җыеп бар көчең:
«Кешеләргә игълмлы бул, дидең,
Хөкем итмә вак-төяк өчен...»
Әй, яшисең килде, әнкәй, синең
Соңгы чигең җиткән минутта!
Күзләреңдә миңа шелтә чагылып,
Көйдерде лә мине шул утта.
Шелтәләрең миңа истәлеккә!
Мәңге күңелем чәнчеп торырлар,
Һәр начардан мине, куркаклыктан,
Гамьсезлектән әрчеп торырлар...
...Син үлгәчтен,
Нидер җимерелде,
Белмим хәтта нәрсә булганын,
Зиһен бетте, бөтен төсләр сүнде,
Су кергәндәй тонды колагым.
Бар җир сары,
Күзгә сары әлпә
Эленгәндәй булып тоела...
Тукта! Кешеләр гүя шәүләләрдәй,
Кайсы төшә инеш буена?
Ничек инде шулай хәрәкәт итә?

Алар барысы исән микәнни?
Кара, кара, машиналар чаба,
Безнең тыкрык аша үтәли!
Ничек алар болай исән калган?
...Син киткәндә, әнкәй,
Мин үлемне
Тагы күрдем гүя янымда:
Кара шәүлә карачкыдай булып
Пәйда булды минем алдымда.
Ләкин аны ныклап шәйләгәнче,
Әй, курыктым, кача яздым мин.
Үзен күргәч кенә батырландым,
Куркуымны җиңә алдым мин...
Сугышта да шулай —
Атака алды
Атакадан күбрәк куркыта,
Ут эченә кереп бер сынагач
Курку бетә, куллар ут тота...
Еллар үтте...
Кабереңә инде
Сирень чәчәкләре коела...
Минем өчен һаман син кайгырып
Ятасыңдыр кебек тоела.
Кайгырма син, әнкәй, кеше төсле
Яшим, артык һәм ким җирем юк!
Бәгырем әрни сине җәлләп кенә...
Тик бәхетсез түгел алай ук!

Газиз Мөхәммәтшин

# Изге Галиәкбәр

*Хикәя*

Бердәнбер кызлары әллә кайдагы монгол якларында кияүгә чыгып төпләнеп калгач, Рәхил белән Мәфтуха башларын кая куярга урын тапмас булдылар. Матай-сатай бер-ике кыш үткәреп җибәрсәләр дә, сагыну сагышлары җинде. Рәхил белән Мәфтуха, туган-үскән илләреннән аерылып, йорт-җирләрен бетереп кызлары янына күчеп киттеләр. Шуннан соң биш-алты ел үтте. Алардан, сирәк кенә булса да, «әйбәт яшибез», дип язылган кош теледәй хәбәрләр килеп торды. Авыл халкы, үз мәшәкате артыннан чабып, аларны әкрен-әкрен оныта башлаган иде инде. Ләкин быел май ахырларында Рәхил белән Мәфтуха җитәкләшеп авылга кайтып төштеләр.

Икенче көнне иртәрәк аяк киенеп, элекке милекләрен карарга килделәр. Ярты гомерләрен үткәргән, бала үстергән нигезләренә, андагы яңа ашханәгә карап озак кына сүзсез тордылар. Яшь чакларын, тырышып-тырмашып тормыш корган елларын уйладылар. Танырлык та түгел авылны, дип, яңа мастерскойларга, ферма биналарына сокланып йөрделәр. Баш чайкадылар, тел шартлаттылар, гаҗәпләнделәр. Авыл кешеләре дә, үз чиратларында, алардан ким гаҗәпләнмәделәр. Юк, амбарларга, абзарларга карап түгел. Боларны халык күкрәк көче белән үзе төзегән һәм колхозның елдан-ел тернәкләнә, күтәрелә баруына күнеккән иде инде. Аннан соң, аларның Рәхилгә дә исләре китмәде. Ул бөртек тә үзгәрмәгән, һаман элекке Рәхил килеш калган, ни кыяфәттә китсә — шулай кайткан. Тик ак мыегының купшы очлары тәмәке төтеннәннән тагын да ныграк саргайган да, чәчләре бераз юкарган һәм алдагы ике теше төшкән.

Мәфтуха, Мәфтуха шаккатырды авылны! Читкә киткәнче ни амбар алдында булсын, ни печән чапканда булсын, толымнарын башына урап, күлмәк итәкләрен кыстырып, җиңнәрен сызганып, бөтергеч урынына бөтерелеп йөргән нечкә билле Мәфтуха әллә нишләгән иде. Печән чүмәләседәй аркылыга-буйга җәелеп, өч аяк асылындырып кайткан иде. Ул үзе май томалаган кысык күзләре белән яңа өйләргә карап тел шартлатса, хатын-кызлар аның үзенә карап тел шартлаттылар:

— И илаһым!.. Гөбе юанлыгы аяклары белән лас-лос атлап ничек йөри икән бу бичара!.. Ташка үлчим, тфү, тфү... Кара, гәүдәсен кыймылдата алмый... Җир буе җир үтмәде — шабыр тиргә батты, — дип пышылдаштылар.

Карчык-корчыклар арасында да ул кайткан көнне үк:

— Духтыр даруларының шифасы юк бу чиргә. Зәхмәт кагылган. Зәхмәт чире өшкертсәң генә чыга... Изге Галиәкбәргә күренсен иде. Колагына төшерергә кирәк Мәфтуха килененең, — дигән сүзләр китте...

Галиәкбәр хәзрәт (тирә-якта изге Галиәкбәр дигән аты да йөри) бу авылдан сигез чакрымдагы кырык-илле өйле бәләкәй генә Түтәй авы-

лында тора. Түтәй урамында ул сугыш алдыннан пәйда булды. Чабата киндерәсен тезенә чаклы урап меңгергән, йоны кыршылган мескен бүрек, терсәк турылары чигүле кулъяулык белән ямалган бишмәт кигән, йодрык кадәр төенчеген таяк башына элеп җилкәсенә күтәргән, усал күзле, мескен кыяфәтле бер адәм иде ул. Аның кем булуын, кайдан килүен, нишләп, нинди йомыш белән йөрүен башта беркем дә белмәде. Галиәкбәрнең күңеленә урманы-суы якын Түтәй авылы хуш килде. Ул шуннан китмәде. Башта ике җәй көтү көтте. Өченче яз җиткәч аңа, һич көтмәгәндә, бәхет капкалары ачылды: моңа хәтле өшкереп-төкереп, гает, никах укып, ясин чыгып тын гына, мыштым гына гомер сөргән элекке мулла, тулы гына гәүдәле яшь хатынын бу дөньяда ялгыз калдырып, җан тәслим кылды. Моңа хәтле теләсә кем өендә каңгырап йөргән Галиәкбәр абзагыз вафат мулланың ак тәнле абыстаена һәм, шуңа ияртеп, алты почмаклы таудай өенә кырпак кар яуганда хуҗа булды да куйды. Шуннан соң алашасы колынлады Галиәкбәрнең. Башыннан мескен бүреге, аягыннан ямаулы чабатасы төште. Галиәкбәр дөнья рәхәтенә чумды. Оҗмах рәхәте ахирәттә түгел икән — монда икән, дип уйланды. Шуннан соң ул авылның өч-дүрт бөртек картына сер итеп кенә үзенең дә элекке мулла икәнлеге турында шартлавык шартлатты. Әкренләп ашка-чәйгә, намаз укырга, исем куярга йөри башлады. Озак та үтмәде, карт мулланы баш-аягы белән алмаштырды да куйды.

Галиәкбәр шулай бик абыз кешегә әйләнде һәм, бүрәнә аркылы бүре куып, тыныч кына гомер сөрде. Сугышлар башланды, сугышлар бетте. Эчендә ниндидер чир табып аны сугышка алмадылар. Көннәр елга аккандай сизелми генә ага торды. Еллар үткән саен, карт-корылар, корткалар арасында Галиәкбәрнең кадере, шөһрәте үсте. Өшкерүе, сылаусыйпаулары гаҗәп шифалы, теләсә нинди сырхауны кулы белән юып алгандай итә, дигән сүзләр китте.

Әмма бер вакыйга хәзрәтнең абруен бермә-бер югары күтәрде. Даны Түтәй авылына гына сыймады — кырык-илле өйле бәләкәй авыл урамына шундый зур дан ничек сыйсын ди — күрше авылларга, тирә-як районнарга, Түтәй кешеләренең кунакка кайткан малайларына, кызларына ияреп китеп, Урал, Себер якларына, Чирәм җирләренә кадәр җәелде.

Ә ул вакыйга дигәнебез менә болай булды. Карлы-бозлы яңгыр коеп торган бер көзге кичтә Галиәкбәр хәзрәт белән аның абыстаен ашка чакырмадылар. Галиәкбәр хәзрәт нишләргә белми аптырап утырды да бисмилласын әйтеп мич башыннан бал мичкәсе сөйрәп төшерде. Эч пошуын басар өчен, чәк-чәк иснәп кенә, аллы-артлы җиде чүмеч әче бал түнтәрде. Мыжырдап торган гайрәтле җылы бал, бу адәм изге — ярамас, дип тормады — тиз арада хәзрәтнең башына типте. Каны котыруына Галиәкбәр хәзрәтнең чыдар чамасы калмады. Ул, берәүләргә яшьлектә, берәүләргә картлыкта, дип урам аркылы гына торган тол хатынга гыйшык тотып йөри иде. Шуның ян тәрәзәсен кагу нияте белән, сикереп торды да кабалана-кабалана киенергә тотынды. Кожан якасына килеп ябышкан Газимә абыстайны тукмап ташлап, салкын яңгыр астына чыгып йөгерде. Тол хатынның тәрәзәсе төбенә барып җитә алгандырмы-юкмы — анысын шушы көнгә чаклы берәү дә белми. Газимә абыстай җиде төн уртасында читән буендагы кычыткан арасыннан эзләп тапканда, аның дәрте инде шактый басылган була. Манма су эчендә сакалын болытларга тырпайтып гыр-гыр йоклап яткан хәзрәтне абыстай көч-хәл белән өстерәп өйләренә алып керә. Шушы төнне Галиәкбәр хәзрәткә салкын тия. Ул ике ай буе саташып-кызышып түшәк өстендә ята. Бер иртәдә, таң әтәчләре кычкырганда, Газимә абыстайны икенче тапкыр тол калдырырга ниятләп, сиздерми генә мәрткә китеп бара. Ләкин врачлар аңа мәрткә барып җитәргә ирек бирмиләр: ярты юлдан борып кайтаралар.

Элек тә тирә-якта исемле булган Галиәкбәрнең даны бу вакыйгадан соң бөтенләй котыра, артыграк чүпрә салынган коймак камыры шикелле күпереп китә. Күперми нишләсен! Әче бал әмере буенча якты дөньяны куеп, фәрештәләр әмере белән кире терелеп кара әле син! Буш буламыни андый кеше? Билгеле инде, — гади бәндә түгел. Ясмык бөртеге хәтле генә булса да изгелек эләкми калмый инде мәрт кадәр мәрткә сәяхәт ясап кайткан муллага!..

Рәхил белән Мәфтуха авылларына кайтып төшкән җәйдә хәзрәтнең изге уйлары да, уйлары шикелле үк изге эшләренең дә хәттин ашкан чаклары иде. Ләкин Мәфтуха җен-пәри ише нәрсәләр белән изге-мизге затларга, шикле им-томнарга ышану түгел, кыз чагында ук инде әбисенең «Бәдәвам» китабы белән Исме әгъзам, Карәнҗә һәм Сәйдергеч догасы тегелгән өч бөтиен утка тыгып яндырган чеп-чи динсез бер кеше иде. Түтәй авылына бар, хәзрәткә күрен, өшкерт, дигән сүзләргә каршы ул башта, юк белән аптыратмагыз әле, дигәндәй, кул гына селтәде. Тик киңәшләр, мулланың саваплы эшләре турындагы мисаллар бик күпкә киткәч, икеләнә калды. «Ә нигә, барып күренеп кайтсам миңа ни зыян, кешегә сан — үземә җан булып яшәгәнче, белмәссең...» — дип уйлады. Рәхилгә көчле генә ат белән тимер көпчәкле арба хәстәрләргә кушты...

Алар икенче көнне иртән иртүк Түтәйгә китеп бардылар. Чытыр арбадагы яңа чабылган хуш исле печән өстенә бөтен арбаны иңләп Мәфтуха кукыраеп утырган, Рәхил ат башындарак аякларын салындырып бара иде. Ак бәкәлле чаптар чыннан да бик шәп булып чыкты: сигез чакрым араны, ялтыр чыклар җемелдәгән болын буйлап, уйнаклый-уйнаклый бик тиз үтте.

Мәфтуха белән Рәхил, атларын урамда калдырып, ашыкмый гына Галиәкбәр капкасыннан керделәр. Алар кергәндә хуҗа үзе киң болдырларыннан төшеп килә иде. Исәнлек-саулык сорашкач, Рәхил үзләренең ни йомыш белән йөрүләрен сөйләде.

— Күлгә җылым тартышырга әйткән иде бригадир. Шунда дип чыгып барышым. Әле дә ярый уңган юлда йөрисез икән: аймыл булышмадык, — диде Галиәкбәр моңа каршы бераз саңгыраурак тавыш белән. Ишек алды уртасындагы эскәмиядә ахылдап утырган Мәфтухага озак кына карап торды да:

— Әй-әй-әй, шактый ит кунган икән шул, көрәйгән икән. Кайчан сырхауландыгыз, кайчан хәстә булдыгыз? — дип сорады.

— Бер өч ел бар инде... э-э... — Рәхил Галиәкбәргә кем дип дәшәргә аптырабрак торды, — э-э... Галиәкбәр абзый.

— Ни сәбәптән рәнҗүгә сабышты икән? Белмәдегезме?.. Ашавы ничек, тамагына тәгам җыямы? Ни белән ризыклана?

— Торган җиребездә ит бик күп. Без эшкә китәбез, Мәфтуха ялгыз башы кала. Елкы итен чуен чүлмәк белән мичкә утырта да көн буе ит ашый, чүмечләп шулпасын эчә. Бару белән шуңа салынды. Бүтән продуктаны авызына да алмый.

— Һм, алай икән, — диде Галиәкбәр. — Нәсел-нәсәп, кардәш-ыру арасында, зат-кавемегездә мондаен чир элек очрамагандыр бит?

— Юк, абзый, юк. Токымыбызда күренгән нәрсә түгел иде...

— Авырлыгын үлчәп карамадыгызмы? Күпме тарта икән? Ничә пот чамасы?

— Шушы елның яңа ел тирәләрендә йөз егерме дүрт килодан артыграк иде.

Галиәкбәр, Мәфтухага җансыз әйберләргә карагандай карап торды да килограммнарны тиз генә үзе яраткан кадакларга әйләндерде:

— Өч йөз дә ун кадак икән, алла боерса. Азрак симерергә туры килгән икән. Тазарган, тазарган... Ярый, нишлисең бит, ябыктыру чарасына керешеп карарбыз. Һәр мөэмин-мөселман үз мөселманын кыен хәлдә очратса, кулыннан килгән хәтле ярдәм итсен, ди китап... Арык-

ланыр, әлхәмделиллаһ, күңеле теләгән кадәр арыкланыр Мәфтуха сеңел. Бер ай эчендә көянтә белән иелә-бөгелә су ташучы чап-чандыр гына яшь киленчәккә әйләнер дә куяр... Хи-ыхи-хи-ыхи-ыхи!..

Галиәкбәр күзләрен кысып, ялкау эт өргән тавышкарак охшатып, көлеп җибәрде. Аның артыннан май баскан тамак төбе белән нечкә генә итеп Мәфтуха да кеткелдәп куйды.

— Өйгә керик. Хак турында сөйләшик! — диде Галиәкбәр һәм тегеләргә карап тормыйча кырт борылып ишеккә юнәлде. Мәфтуха белән Рәхил аңа иярделәр.

Өйгә килеп кергәч, алар бераз аптырап калдылар, Рәхил дә, Мәфтуха да изге хәзрәтнең өе чыннан да хәзрәт өе кебек булырга тиеш, дип уйлаганнар иде. Ул бүтән гади бәндәләр торган йортка охшамаска — төрле төстәге йон җебеннән өйдә суккан палас җәелгән һәм түрдәге сандык өстенә таудай түшәк-ястык өелгән озын сәкеле, стенасы шамаильләр, киштәсе иске китаплар белән тулган, мич арасында җиз комган белән цинковой таз торган йорт булырга тиеш иде. Ә алар әйбәтләп җыештырылган, идәненә яхшы келәмнәр җәелгән, тәрәзәләренә ап-ак челтәр корылган чиста һәм якты бүлмәгә килеп керделәр. Рәхил стенадагы картиналарга күз йөртеп чыккач:

«Хәер, заман мулласы заманча яшәми ничек яшәсен соң! Үзе гап-гади бер карт икән, төсе әзрәк эткәйгә тарткан... Әллә ни кырмас кыруын да, шулай да танышып китү ярый, Мәфтуханың күңелендә калмас... Мәшәкате өчен берәр тәңкә бирмәсәң килешмәс...» — дип уйлап куйды.

Галиәкбәр аларны диванга утыртты. Үзе урындык белән каршыларына килеп утырды. Мәфтухага карый-карый үзенең әлеге дә баягы саңгырау тавышы белән:

— Бу зәхмәткә акча-фәлән күрсәтергә кушмаган. Әҗеренә эре хайван, вак җәнлек-җанвар, кош-корт, ягъни дә, тояклы терлек һәм канатлы үрдәк-күркә китерсәләр, шифасы күп булыр, тиз савыгыр, дип өйрәтә китап, — диде.

Мәфтуха бөтен гәүдәсен дерелдәтеп сулый-сулый баш селекте. Рәхил, бер тәңкә җитмәс, пожалуй, икене бирергә туры килер, дип уйлап куйды.

— Бу чиргә өч дога килешә. Сезгә шуларның кайсысы кирәк? — дип сорады Галиәкбәр хәзрәт. — Кур-Кур догасымы, Йөр-Йөр догасымы, әллә гадие генәме?

— Ә иң әйбәте кайсысы соң? — диде Мәфтуха гаҗәпләнеп.

— Иң шифалысы Йөр-Йөр догасы инде, — диде Галиәкбәр, — әмма шунысы бар: бу доганың хакы тегеләренә караганда артыграк.

«Өч сумынны каермыйча ычкындырмас бу», — дип уйлады Рәхил тагын.

— Ә шулай да Йөр-Йөр дигәне күпмегә төшәр икән?

Галиәкбәр, Рәхилнең шушы соравын гына көтеп торгандай, бармагын бөгә-бөгә санап бирде:

— Мал-туардан бер сарык җитәр, бүтәнен изаланып китереп йөрмәгез. Шул сарыкка өстәп тагын бер ана каз, бер баш быелгы күркә, кышлаган ата үрдәк, тавык белән әтәч... Һәмдә ки, аллаһе боерса, пар күгәрчен белән сыңар чыпчык бирерсез... Чын изге күңелегез белән теләп, бисмиллагызны әйтеп... Янә дә шунысын хәтерегездән чыгармагыз: әтәчнең кикрик шәрифе бөтенләй булмасын, чыпчыкның да бик нык кәкре томшыклысы кирәк...

Рәхил шаккатты. Үзе дә сизмичә, диваннан күтәрелә башлады. Исенә килеп тагын утырды. Ни кылана бу мулла? Нәрсәләр даулый?.. Тиле кызның туена дигәндәй... Үлчәүсез кием кисеп азаплана түгелме?.. Үзенең бер шаригы әбиләренә кунакка киткәнме, әллә Рәхилләрне әлефне таяк дип белмәүче, акылларына зыян килгән томана башлар дип уйлыймы? Бармагын бөгә-бөгә тавык-күркә санаганда ап-ак калын каш-

лы, какча яңаклы бу кешенең үткен күзләрендә Рәхил ниндидер яшерен көлемсерәү шәйләп алды. Ник көлемсери ул? Мыскыл итәме? Шаярамы? Ник шаяра? Мәфтуханың хәле шаярырлыкмы әллә? Тирләп-пешеп ничек утырганын күрә бит...

Мәфтуха үзе дә хәзрәт әйткән малларның чамадан тыш күплегенә гаҗәпләнеп утыра иде. Ул, күзләрен түгәрәкләндереп, әле иренә, әле Галиәкбәргә карады.

— Ә шәрифле кикрик дигән нәрсәсен кайдан табарбыз икән соң?

Рәхил аңа каршы:

— Юк, кикриксез шәриф дип әйтә ул, — дип куйды.

Ә Галиәкбәр аларның икесенең дә сүзләрен төзәтте:

— Кикрик шәрифе, ягъни, гади халык теле белән әйтсәк, просто кикрик була.

— Ә-ә-ә! — диделәр Мәфтуха белән Рәхил икесе дә бергә. Сарыкның һәм кош-кортларның бәясен чутлап чыгарганнан соң икеле-микеләрәк утырсалар да, Галиәкбәр, аларның ник кинәт пошаманга калуларын төшенеп, хакны, әгәр догаларымның вә һәм дәвалавымның шифасы тисә, соныннан түләрсез, инде дә килеп алла кабул итмичә файдасы күренмәсә, мыскал әйбер дә китермәссез, шулай да бәхилләрмен, дигәч, эчләренә җылы керде. Һәм, икесе дә күңелләнеп китеп, Галиәкбәргә, әгәр иртәнге тәһарәте бозылырга өлгермәсә, өшкерү белән дарулауны хәзер үк башларга мөмкинлеген, моңа Мәфтуханың әзер икәнен әйттеләр.

Зур бәхетләренә каршы, Галиәкбәр хәзрәтнең мөбәрәк тәһарәте әлегә бөтен булып чыкты. Галиәкбәр хәзрәт, эшне озакка сузмыйча, келәтләреннән бер ак төенчек алып керде. Аны өшкереп Мәфтухага бирде.

— Киленчәк, менә сиңа ике кадак ярым борчак. Бу, әлхәмделиллаһ, прастуй борчак түгел, Сөләйман тавындагы Зәйнулла хаҗи зираты янында чәчмәенчә үзеннән үзе үскән изге борчак. Ходайның һәр бирмеш көнендә өч тапкыр, ягъни иртән, көндез вә кич, караңгы чоланга кереп, кара песи өстеннән өч мәртәбә сикереп чыгарсың. Сикереп чыгарсың да, аллаһе боерса, шушы борчакларны, аяз көн торса, ишек алдыгызның такыр җиренә, явым-чәчем булса, өй идәнегезгә чәчепсибеп җибәрерсең. Аннан соң һәр бөртеген бисмилла әйтеп берәм-берәм чүпләп савытыңа тутырырсың. Аяк өсте басып чүпләргә, ягъни изге борчакның һәр бөртеген иелеп алырга куша китап. Ятып яки дә утырып һич ярамый. Ул чакта тылсымы бетә, чиреңә файдасы тими... Аңладыгызмы минем сүзләремне, колагыгызга яхшылап сеңдердегезме, киленчәк? Вә син дә, Рәхил туган?

Рәхил аның сүзләрен, «борчак-борчак дигәләп ну сибә борчакны карт төлке», дип, ә Мәфтуха, «әллә чынлап та изгеме соң бу, ышанма — терелтеп тә куяр, ышанган тауда киек бар», дип, бераз икеләнә башлап тыңлый иде. Уйларыннан айнып:

— Аңлыйбыз, хәзрәт, бик нык аңлап торабыз синең сүзләреңне!..

— Колакка да яхшылап сеңдердек, — диделәр.

— Сеңдерсәгез — рәхмәт! Бусы бер булды, ягъни. Инде икенчесенә күчик!..

Галиәкбәр чаршау эченнән кечкенә бер кәгазь пакет алып чыгып, аны Мәфтуханың учына салды.

— Менә монда, Мәфтуха киленчәк, — диде серле тавыш белән, — аерым-аерым утыз көнгә атап өшкерелгән утыз кыяр төше. Сиңа ит зәхмәте кагылган. Бүгеннән алып бер ай дәверендә нәфсеңә баш булалмый сыңар калҗа ит капсаң да, минем өшкерүләрнең, кем әйтмешли, сукыр тиенлек тә файдасы калмас... Я хода, үзең ярлыка!.. Инде дә... Һәр бирмеш көнне иртән йокыдан уянып тышка чыгып кергәннән соң, юынып-чистарынып алгач, бисмилланы әйтеп кыяр төше йотарсың. Йоткач бер алма, алма артыннан бер кыяр, кыяр артыннан бер фәми-

дур, фәмидур артыннан янә дә бер алма ашарсың. Иртә өчен күнел канәгатьләндерергә шул житәр. Төшлектә бер тәлинкә сөтле аш, катыкфәлән, чәй белән тәгамләнерсең. Кич эремчек, балыкише нәрсәләр әзерләтерсең. Бу зәхмәткә, чамасын чамалап әз-мәз ашаганда, солы кесәле, борчак, борай, янә дә дөге, манный боткалары да килешә. Тәлинкә тояклы, аеры тояклы, тырнак тәпиле хайван-җанварларның, йөгерүче, тырманучы, суда йөзүче, һавада очучы кош затының итен ай буена күрмәгәч, эчендәге зәхмәтең ачыргаланып «ит!», «ит!» дип кычкырыр. Тора-бара хәлсезләнер. Шунда инде изге кыяр төшләре һәм алма, фәмидур, кыярише яшелчәләр аны бөтенләй дөмектереп синең эчеңнән куып чыгарыр. Инша алла! Эчең чирдән котылгач, күзгә күренеп арыкланырсың. Китап шулай күрсәтә: кайгырмасын, җөгәнер, ди... Боларны да аңлап калдыгызмы? Ничек-ничек итәргә икәнен белдегезме? Балачага шикелле башыгыз болганмасмы?

— Аңлап калдык!..

— Белдек!..

— Болганмас, хәзрәт, — дигән көр җавапларны ишеткәч, Галиәкбәр: «Инша алла, алайсаң каршы сүзем юк», — диде. Аннан соң Мәфтуха белән Рәхилгә тәрәзә төбендәге гөлләр арасыннан дүрт кырлы зәңгәр шешә алып күрсәтте.

— Инде дә өченче шөгыльгә күчәбез. Мин алабуга балыгы эченнән чыккан чурагайны төеп, жиде төн уртасында бисмиллалап алынган таң суында эретеп, шуны мунча чыккач — тәнем кердән, җаным фани дөньяның уйларыннан чиста чагында — догалап куярмын. Ул дару менә шушы шешәдә торыр. Син, Мәфтуха киленчәк, аны көн саен килеп, көн саен нәкъ кояш чыкканда кашыклап эчеп китәрсең. Кара аны — эчеңдәге зәхмәтең рәхәтләнеп, тешен ыржайтып атка утырып йөрмәсен. Аңа тынгылык бирмәс өчен тәпи-тәпи килерсең, тәпи-тәпи китәрсең, аллаһы боерса... Абаем булмаган җөремтәк кешедә мантый алмас андый нәрсә. Мин Түтәйдә, син анда икәүләп тотынсак, ул ялгыз зәхмәт-мәлгуньне, шәт иншалла, аста калдырырбыз... Бу соңгы нәсихәт тә башыгызга барып життеме?

— Житте, хәзрәт, бик житте! — диде Рәхил, икеле-микеле уйлар эчендә калып.

Мәфтуха, эшләпә-эшләпә күкрәкләрен калкытып, «пуфф!» дип сулап куйды.

— Галиәкбәр абзый... хәзрәт, ыхх... Ник син ул шүкә даруын, ыхх... үземә генә биреп җибәрмисең?.. Үзем... уфф... генә эчәрмен. Килеп дим йөргәнче!.. Ыхх!..

— Бик шулай да, бик бирер идем дә, Мәфтуха киленчәк, — диде Галиәкбәр хәзрәт кара кайгыга төшеп, — мөмкин түгел ул эш. Һәр таң атканда, җен-пәри, шайтан затлары көннән өркеп жиде кат җир астына кереп качып беткәч, мин ул таң суының догасын яңартам. Шулай итмәсәң, искерә, көче бетә. Мин картлыктан кәкрәеп беткән аякларым белән чалыш-чолыш атлап көн саен сезгә барып йөри алмам. Андый эш өчен колхоздан ат сорап булмый. Мондаен эшне, гәрчә бик изге, бик савапны алла эше булса да, хәзерге заманда качып-посып кына эшләргә туры килә. Бик шауларга тырышмыйсың. Урамга чыгып кычкырып йөрмисең... Әкрен кирәк, иплән кирәк ишетергә сандугач сайрауларын, дип җырлыймы әле радиу?.. Хи-ыхи-хи-ыхи-ыхи... Сәламәтләнергә, сихәтлек алырга теләсәң, үзең килерсең инде, Мәфтуха киленчәк. Исәнлек-саулыктан да, тазалыктан да зур байлык юк бит... Әлхәмделиллаһ!..

Мәфтуха белән Рәхил киңәшү өчен ишек алдына чыктылар.

— Мин бу картка ышаныргамы-ышанмаскамы дип аптырап торам әле. Кыяр төшләре, тавыклар шунда, әллә нәрсәләр. Сәдакасын да җилле генә каера: бер айлык зарплата... Имчегә барсаң — яңа авыру табарсың, шул булыр, — диде Рәхил.

— Бөтенебез дә алганда «Бисмилла!», биргәндә «Әстәгъфирулла!» инде дә... Әмма кулыннан эш килмәсә, шул хәтле сорарга оялып иде. Хәлемне күреп торасың бит — авыру газабы үлемнән әшәкерәк, — диде Мәфтуха аңа каршы. — Файдасы тисә тияр, тимәсә юк, безгә ни зыян! Әллә, мин әйтәм, бер кизәнгәч сугабызмы?

— Мин синнән әйбер кызганып әйтәмме әллә. Белеп торасың бит. Авыруы җиңел булса да, терелүе кыен икәнен бик яхшы аңлыйм мин. Әйдә, тәвәккәлләдек, анасы!..

Алар Галиәкбәр хәзрәт янына яңадан керделәр. Борчак төенчеген һәм кыяр төшләрен алдылар да, иртәгә караңгылы-яктылыда ук килеп җитәргә вәгъдә биреп, авылларына кайтып киттеләр.

Мәфтуха белән Рәхил чыннан да әйткән сүзләрендә тордылар. Икенче көнне таң сызылганда болын юлында «алла, алла, үләм» дип ыңгырашып атлаучы Мәфтуха һәм аннан биш адым артта атын әкрен генә атлатып килүче Рәхил күренде.

Галиәкбәр аларны, иртә булуына карамастан, баскычның нәкъ кичәге урынында кичәге кыяфәтендә каршылады. Бөтенләй эштән чыккан, кеше төсе калмаган Мәфтухага карап:

— Бәрәкалла-машалла! Ничава, киленчәк, әйбәт! — дип кычкырды. Атлы Рәхилне күргәч кашларын җыерырга итсә дә — җыермады.

— Саклый килүеңә кул куям. Нинди хәл-әхвәлләргә юлыкмассың бу җиһанда... Кайтканда утыртып кайтсаң да ярар. Бик җончыган. Һәм дә ки янә дә өч көн буе җәяү килер, ат белән кайтыр. Шуннан соң мескен хайванны интектереп йөртмәссең. Үзең дә күзгә-башка чалынмассың, — диде.

Көнчыгыш инде тәмам яктырган, кояш менә-менә чыгам дип тора иде. Галиәкбәр, ашыга башлап:

— Мәфтуха киленчәк, җәһәтрәк кыйлан, алла бәндәсе! Даруны йотып өлгерергә кирәк! — диде.

Мәфтуха аны тыңлап ашыккандай итте. Ләкин баскыч төбенә җитәрәк дахаты бетеп, дөпелдәп җиргә ауды. Тиз генә тимер күчәрле бәләкәй арба алып килделәр. Мәфтуханы шуның белән тартып келәткә илттеләр. Ике чигәсенә бозлы чүпрәк куйдылар. Ярты сәгатьтән Мәфтуха хәлләнде, кешеләргә тотынмыйча үзе атлар дәрәҗәгә килде. Галиәкбәр хәзрәт аңа дару эчерде. Мәфтуханың кояш нурлары сузылып кергән тәрәзәгә кат-кат каравын күргәч, кулын селтәде:

— Шундый-шундый хәлләр чыккач нишләмәк кирәк. Гаеп юлда йөреп соңармаган. Бүгенгесен аллаһе тәгалә хәзрәтләре үзе разый кылсын, — диде.

Бераздан Мәфтуха белән Рәхил атларын юрттырып кайтып киттеләр. Галиәкбәр хәзрәт балыкчылар янына юнәлде. Газимә абыстай ишек алдына чыгып тавык-чебеш туйдырырга тотынды.

Шул чагында урам ягындагы тәрәзә төбенә көтүдән качып калган шаян кәҗә бәтие сикереп менде. Ул өй эченә күзләрен йөртеп чыкты да, кызык тапмагач, тәрәзә төбендәге гөлләр белән таныша башлады. Иренен сузып ясмин гөленең хуш исле ак чәчәкләрен татып карады. Ошатмады — борынын җыерып төчкерде. Бүлмә өрәңгесенең аклы-чуарлы чөй сыман яфраклары белән кыңгырау сыман салынкы чәчәкләре дә аның күңеленә хуш килмәде. Ә менә тал гөлен ни өчендер яратты бәти. Күп уйлап тормыйча, аның кызыл, сары, ак һәм ал төстәге катмарлы чәчәкләрен чүпләп чыкты. Аннан идәнгә төште. Почмак саен иснәнеп йөри башлады. Кызыксынып, мич арасындагы буяулы чиләккә борынын тыкты. Аннан зәңгәр борынын гарьләнеп чайкый-чайкый кире чыкты. Кергән юлына «борчак» коя-коя, төчкерә-төчкерә тәрәзәдән кире урамга сикерде. Тәрәзә төбендәге дүрт кырлы зәңгәр шешә шакылдап идәнгә төште. Эчендәге кызгылт «таң суы» былт-былт итеп ярыкка ага да башлады. Ләкин гөнаһсыз кәҗә бәтие боларны күрмәде.

Боларны Газимә абыстай күрде. Күрде дә «ах!» итте. Йөгереп барып шешәне күтәрде. Тик шешә буш иде инде. Газимә абыстай уйга калды. Әгәр карты моны сизсә, абыстайның якты көне караңгы төнгә әйләнәчәк. Юк кына нәрсә өчен дә атна буе сукранып йөрүче метер хәзрәт аның башын ашаячак. Мин тутырам — син түгәсең, мин табам — син туздырасың, тәмуг кисәве, фиргавен токымы, дип җәнҗал куптарачак.

Дөрес, Газимә абыстаң Галиәкбәр хәзрәткә элгәрге шикелле олтырак булып тормый соңгы елларда. Хәзрәт әче бал чөмереп җан тәслим кыла язгач, аның кадере әзрәк артты. Газимә абыстай, исереп егылганынны мир халкына әйтәм, дип, хәләл җефетенең котын алды. Галиәкбәр хәзрәт, әйтмә инде, дип бик ялынды. Моннан соң пьянчуклыкны ташлыйм, дип кат-кат ант итте. Газимә абыстайны, гадәттәгечә аркасын куймыйча, өч төн рәттән кочаклап ятты. Газимә абыстайның җаны эреде. Картының абруен төшермәскә булды. Тик ул хәзер дә картының бик котырган чакларында җаен табып шул эшне телгә ала. Галиәкбәр теләсә-теләмәсә дә авызына су каба.

Монысы җитмәсә, абыстай кулында икенче корал да бар. Бер елны аларга Нижний Тагилдан кайткан чибәр генә яшь хатын килде. Оялаояла гына:

— Кияүгә чыкканыма биш ел инде, мулла абзый. Һаман бәбиебез юк, — дип киңәш сорады.

Галиәкбәр аның кояшта пешкән шоп-шома тулы аякларына кирәгеннән артык текәлеп карый-карый:

— Рәхәтләнеп яшә әле... яшь чакта. Бала — бәла. Я хода! Балага тарсаң җәфаланырсың... Балалы хатынның балагы чыга, — диде.

— И мулла абзый, чәчәкле гөл кадерле була ич!

— Бәрәкалла, чибәр киленчәк, хак сүз. Ул тапкан — уңган хатын, кыз тапкан — изге хатын, ә кысыр хатын — бүсер хатын, ди изге китап. Э-э, э-э... Күршегә кер... чибәр киленчәк. Һм-һм... күршегезгә кереп кара, алла боерса!..

— Күршеләребез белән бик тату торабыз, Галиәкбәр абзый, — диде яшь хатын. — Керешеп-чыгышып, кунакка чакырышып йөрибез.

Хәзрәт үзенең сүзен ачыграк әйтергә мәҗбүр булды:

— Керү белән керүнең аермасы зур, чибәр киленчәк... Һм-һм... Күрше йорттагы ир затлары, ягъни, үзләре генә калган чакта керергә кирәк.

Яшь хатын, аның ишарәсен аңлагач, чыгып килгән кояш шикелле кызарды.

— Карт азгын!.. Судка бирермен!.. — дип, Галиәкбәр хәзрәтнең йөзенә төкереп, чыгып йөгерде.

Син шулай да син болай, дип карты бик бәйләнә башласа, Газимә абыстай:

— Безнеңише кара халыкка болай да ярый, шулай да ярый. Картлык көнебездә битебезгә төкергән кеше юк әле, аллага шөкер! — дип шуны искә ала, һәм Галиәкбәр тагын телен тешләргә мәҗбүр була.

Менә шул ике хәлне кирәк чагында бик оста файдалана Газимә абыстай. Балыктан кайтып кереп: «Изге дару, өшкергән дару кая?» — дип дуларга итсә, бу юлы да бик җебеп төшмәс Газимәң. Әмма өйдә тавыш чыгарудан кемгә файда?! Тыныч яшәүгә ни җитә?! Берәр хәйлә уйлап табарга кирәк!..

Газимә абыстай чыннан да җаен тапты. Чиләктән су тутырды да, бераз уйланып торганнан соң, аның өстенә чөгендер суы тамызып, дүрт кырлы зәңгәр шешәне тәрәзә төбенә — элекке урынына утыртып куйды.

— Файдасы тияме — юкмы, — анысын, бер ходайдан башка, бәндә белми. Әмма кое суы белән ачыган чөгендер суының берәүгә дә зыяны тигәне юк әле! — диде.

Мәфтуха икенче көнне келәттә егерме минутлап кына ятты. Бозлы чүпрәкне дә табан асларына гына куйдырды. Тагын бер көннән келәт идәнендәге палас өстендә яту вакыты ун минуттан артмады. Ә инде килеп йөри башлавының дүртенче көнендә Мәфтуха келәткә бөтенләй кермәде — башын югары тотып, тантаналы кыяфәт белән турыдан-туры өйгә үтте.

— Я, хәлләр ничек? Аруга таба барамы? Нихәл, Мәфтуга киленчәк? — диде Галиәкбәр, тимер кашыкка зәңгәр шешәдән таң суы тамыза-тамыза.

— Әйбәт, мулла абзый, уфф! — диде Мәфтуха. — Ыхх... Уфф!..

— Файдасы тиячәк бу изге даруның, инша алла! Көн саен таң сызылганда тәмле йокымнан уянып догасын яңартып куям бит.

Газимә абыстай табак-савыт юган жиреннән башын борып аңа карады. Көләсе килүен көчкә тыеп: «Яңартасың, илла да мәгәр бик нык яңартасың. Сусыз юып, жилсез киптерәсең, карт төлке. Таң сызылганда матча күтәреп гырлап ятасың. Ул гырлауга өйдә чикерткә заты калмады инде: куркып качып бетте», — дип уйлады.

— Ит ничек, ит? — диде Галиәкбәр хәзрәт, Мәфтуха даруны эчеп жибәргәч. — Ашыйсы киләме, алла бәндәсе?

— Дөресен әйткән чакта — килә! Төшкә кереп аптырата. Кичә төшемдә табак тутырып симез сарык ите пешердем, Галиәкбәр абзый... Э-эһ... Муен сөяген алып кимерергә генә иткәнием, уяндым да киттем бит, агай... Ыхх... И кызганыч та булды инде...

— Ничава, ничава, киленчәк. Теге мәлгунь шайтан котырта сине, шул ләгънәт кыстый. Түз, бирешмә! — диде Галиәкбәр, Мәфтуханы озатканда...

Мәфтуха шулай һәр иртәне Түтәй юлын таптады. Көн үткән саен, аның күңеле күтәрелә барды. Тәне жиңеләйгәннән жиңеләйде. Ят әйбер таккандай көч-хәл белән сөйрәп йөргән аяклары ныгыды, корсагы күзгә күренеп шиңде. Унбиш-егерме көннән Мәфтуха пар ияк белән генә калды, иягенең иң түбәнге каты эреп беткәндәй юкка чыкты. Егерме бишенче көнне Түтәйгә килгәндә, Мәфтуха, Чытыр ерганагын әйләнеп үтмичә, йөгереп барып турыдан гына сикерде. Дөрес, ул теге як чирәмгә үк барып житә алмады. Чытыр ерганагының нәкъ уртасына килеп төште. Шулай да үзен кош тоткандай бәхетле тойды. Тездән кара ләпек ярып коры жиргә үрмәләгәндә жүләр кешедәй кет-кет көлеп үрмәләде. Шатлыктан телен югалта язып: «Кайтканда да сикерәм. Кызу гына йөгереп киләм дә сикерәм», — дип үзенә сүз бирде.

Мәфтухага карап шаккатмаган адәм калмады. Өйләреннән кеше өзелмәде. Карчык-корчык, карт-корылар Галиәкбәр хәзрәтнең ни әйтүен, ничек-ничек өшкерүен, дәвалавын кабат-кабат сөйләтеп Мәфтуханы хәлдән тайдырдылар. Бәхетең бар икән, кызым, тирә-якта бер изгегә туры килдең, диделәр. Сүз сүзне тартты. Утыз теш арасыннан чыккан сүз, колактан-колакка, авыздан-авызга күчеп, утыз кешегә житте. Галиәкбәр хәзрәтнең яңа могжизасы турындагы хәбәр, өсте-өстенә өелеп, хәзрәт үзе дә белмәгән искиткеч уйдырмаларга уралып, еракларга жәелде. Түтәй авылына карап юлга чыгучы төрле сырхауларның саны ишәйде...

Менә соңгы — утызынчы көннең таңы беленде. Галиәкбәрнең олы хезмәтләре өчен вәгъдә ителгән сарыкны, кош-кортларны кайчан, ничек китерергә икәнен сөйләшү һәм рәхмәтләр әйтү өчен, Рәхил дә Мәфтухага ияреп Түтәйгә килде.

Түтәй мулласының яңа могжизасына — Мәфтуханы тылсым көче белән дигәндәй тиз арада рәтләп аякка бастыруына — тирә-якның таң калуын әйткән идек инде. Ләкин хәйләкәр хәзрәт үз «һөнәренең» серләрен әле һаман да тулысынча ачып бетермәгән, соңгы көннәр өчен дә

сандыгында саклап яткырган икән. Ул үзенең шушы соңгы сере белән Газимә абыстайның ике күзен дүрт итте.

Галиәкбәр Мәфтухаларны бүген ачык чырай, кайнар чәй белән каршылады.

— Гел дару булмас, соңгы тапкыр күрешү көнендә бал белән сыйланып китегез, — диде. Аннан көлеп: — Борчылмагыз, бал да, чәй дә өшкерелмәгән — менә дигән грузин чәе! — дип өстәде.

Мәфтуха, өстәл янынннан кузгалып, бераз тын алгач:

— Галиәкбәр абзый, вәгъдә ителгәннәрне иртәгә иртүк китереп житкерербез. Тик менә чыпчык мәсьәләсендә генә бер ни эшли алмыйбыз. Кулны тотып тора. Малайлар инде әллә ничә дистә тотып китерде, ләкин берсенең дә борыны сез әйткән рәвешле үк кәкре түгел, — диде.

Галиәкбәр куе ак кашларын күтәреп:

— Мәфтуха киленчәк, юк өчен хафаланмагыз, алла боерса. Бер нәрсә дә кирәк түгел. Даже чыпчык та. Акча гына бирерсез, — диде.

Тегеләр гажәпләнебрәк:

— Нишләп, хәзрәт абзый? — диделәр.

— Шулай, туганнар, — диде Галиәкбәр, — кичә кич мунча кереп намаз укып яткан идем. Бер изге төш күрдем. Жәбраил фәрештә яныма иңеп сездән акча гына алырга кушты. Сәвабы тагы да күбрәк булыр, диде.

Мәфтуха белән Рәхил Җабраил кадәр Җабраил фәрештәнең боерыгына каршы килергә батырчылык итмәделәр. Галиәкбәрнең кулына, сарыклар, төрле үрдәкләр белән мәшәкатьләнеп йөрүдән котылдык, дип сөенә-сөенә шактый күп акча тоттырдылар да, үзләренең монгол якларына кунакка чакырып, саубуллашып китеп бардылар...

Аларны озатып кергәч, Газимә абыстай:

— Ник кош-корт алмадың, симертеп суяр идек? — дип сорады.

— Хәзерге заман өчен акча әйбәтрәк, — диде Галиәкбәр. — Тыныч та, ашарга да сорамый.

— Әзрәк булды түгелме соң?

— Монысы да күп әле, чөнки мин Мәфтуга киленчәк өчен кыл да кыймылдатмадым бит.

— Ничек инде кыймылдатмадың?! — дип кычкырды Газимә абыстай. — Мәфтуханы шайтан килеп терелттеме әллә? Син бит!..

Галиәкбәр кашларын жыерып куйды:

— Мәфтуха киленчәк үзен-үзе терелтте!

— Ә?.. Ничек инде?

— Сүзне төптән башлыйк алайсаң, — диде Галиәкбәр. — Колакларыңны торгызып тыңла, икенче миннән сорап йөдәтмә. — Һәм ул абыстайга түбәндәгеләрне сөйләп бирде: — Сезнең Түтәйдә, рәхмәт төшкере, элек Рәбәрттин исемле карт яшәгән. Беләсең бит инде. Заманнар үткәч, үлем түшәгендә әйтә ди бу: «Дөньялыкта бер генә үкенечем кала — Минзәләне күрми үләм. Бүтән үкенечем юк!» — дип әйтә ди. Ә бит Түтәйгә Минзәлә жәй көне унбиш, кыш көне турыдан унике чакрым. Вәт әй, яшәгән элеккe кешеләр. Шуның сымак былтыр ютәл төшкәч мин дә әйтәм үземә: «Ни гомер мулла исемен күтәреп йөрдем, ә Казан мәчетен, андагы жомга намазларын күргәнем юк. Урап кайтыйм әле, ютәлне дә өшкертермен», — дим. Син дә ишеттең бит... Киттем. Самолет белән какраз жомгага. Илле биш минут дигәндә чыжт итеп килеп тә төштек. Намазга, урыс әйтмешли, самый время житештем. Намаздан соң мөтәвәллигәме-кемгәме әйтәм: ютәл, мин әйтәм, өшкертәсе иде, мин әйтәм. Ә теге әйтә, син туган, ди, тизрәк, ди, духтырларга чап, ди, алла сакласын, сарык ютәле булмасын, ди...

Чаптым. Газраил якаңа ябышса, нибуч, син дә чабарсың. Бәхеткә каршы, безнең Ибрай малае анда би-ик олы урында эшли. Үзең беләсең бит. Шул мине ятьрәк генераллар белән министрлар гына карала

торган бүлнискә җилтерәтеп алып китте. Осубый прпускы белән, биш көнлек. Әле боларны сиңа сөйләмәгән идем. Барыбер аңламас, дип... Көтеп кенә торганнар икән. Әй карарга тотындылар берсеннән-берсе олы профессорлар мине, әй карарга тотындылар, агай. Бүлмәдән бүлмәгә йөртәләр. Берсеннән чыгуга икенчесенә кереп китәсең. Нәкәнис, биш көн буе йөри торгач, әллә нәмәдәй чирләр табып бетерделәр. Үзем дә белмәгәнне, бөтенләй уйламаганны. Бер кочак рисиптә яздылар, чумадан тутырып дару бирделәр. Әнә бит әле, яртысы һаман тора. Шушыларны, ашардаен ашап, эчәрдәен эчеп бетерсәң, кызлар күзе төшәрлек булырсың, дедушка, диләр. Көләләр...

Тәки терелттеләр. Ютәл дә бетте, хәл дә аруланды... Менә шуннан синең яныңа кайткач үз алдыма уйланып, план корып йөри башладым. Мин бит электән дә аллага бик үк ышанып җитми идем, чыннан да, була-нитә калса нишләрсең, дип бераз шөлләп кенә йөри идем.

Газимә абыстай, сискәнеп: «Тәүбә әстәгъфирулла!» — дип куйды.

— Ие шул, — дип дәвам итте Галиәкбәр. — Әллә мин синең сымак бер җүләрме? Үләсең дә бетәсең инде. Күмәләр дә куялар. Туфракка әйләнәсең. Ни җәһәннәм анда, ни оҗмах!.. Намаз укыйсың. Булса, значит, намазың бушка китми, булмый икән — анысыннан да әллә ни зыян юк.

— Я ходай, сиңайтәм, нинди исәр сүзләр сөйлисең? Җир йотар!

— Ирләр сүзен бүлдереп утырсаң, башта үзеңне йотар...

Газимә абыстайның пешекләргә генә дип казанга салган тавыгы инде әллә кайчаннан бирле быгыр-быгыр кайнап утыра иде. Ә ул үзе, яшен суккан кебек, картының авызына карады да катты. Галиәкбәрнең соңгы сүзенә каршы берни әйтә алмады: әзрәк селкенеп, коры иреннәрен ялап кына куйды.

— Ә бит дөнья алга бара, — диде Галиәкбәр, аңа текәлеп карап. — Һәр җирдә эш гөрләп тора. Сөләйман пәйгамбәрнең кулыннан килмәгәннәрне кулыннан китерә хәзерге кеше. Синең изгелегең аңа бармыюкмы! Исәпкә-санга алу ел саен кими бара. Какуй монда разный дога белән баш ватып торырга!.. Менә шулайрак уйлап, ары бәрелеп, бире сугылып яшәргә калды хәзер. Алар түгел, үзең дә алласына да, мулласына да ышанмый башлыйсың. Дөньясы үзгәргәч, син генә үзгәрми калмассың инде... Менә шулай. Менә сиңа изге, хәзерге заман изгесе! Аңладыңмы?..

— Аңладым да, аңламадым да... Мәфтуханы ничек терелттең соң?.. Изге булмагач, аллага да бик үк ышанып җитмәгәч... Ничек инде?..

— Мәфтуха киленчәк көне-төне симез ит күшәп кырын ятсын да, симерми нишләсен! Симермим дисең икән, чәй-суны әз эчәргә, ит, бал, шикәр, камыр-комырны әз ашарга кирәк. Йөрергә, хәрәкәтләнергә, эшләргә кирәк.

— Алайса, син...

— Әйе, шулай, физкультура ясасын дип, Түтәйгә тәпи-тәпи йөрттем. Борчаклар — гап-гади прастуй борчак. Таң суы — үзебезнең кое суы, әзрәк даруга охшасын дип, чөгендер суы гына кушылган. Төйгән чурагый да, чурт та юк. Ә бүтән серләр-мерләр аны ышандыру өчен инде. Сырхау кеше үзенең терелүенә аллага ышангандай ышанырга тиешле. Шул чакта гына даруның файдасы тия. Ә болай, сәламәтлекнең атасы да, анасы да — эш, ди китап.

— Корьәнме?

— Нинди корьән булсын — «Медицина белешмәсе». 65 нче битендә Мәфтуха киленнең сырхавы турында язылган. Симерү авыруы, адипоситас ягъни, белдеңме?..

Газимә абыстай шаккатып тамагын кырып куйды. Казан капкачын барып ачты, андагы пешкән тавыкны күреп, ирексездән икенче мәртәбә тамак кырды.

*1965 ел.*

Салих Баттал

# ЧИРМЕШӘН ЯКЛАРЫНДА[1]

Роман

## ДҮРТЕНЧЕ КИСӘК[1]

### I

Тарих мең дә тугыз йөз дә
ун җиденче ел башы.
Җепшек кар астында ага
Чирмешәннең елгасы.

Бер ташыр ул ярларыннан —
хәзер инде яз алды.
Кешелек язына кадәр
вакыт инде аз калды.

Язгы Чирмешән аркылы
волостька шуа чана.
Тирән уйга баткан Хәмит
кабатлый һаман: «На, на!»

Патша төшерелгәнгә өч көн.
Тик авыл белми әле.
Тик байлар, атларга утырып,
волостька йөри әле.

Киңәшәләр: «Ни кылырга?
Халыкны булмас алдап...»
Прокламацияләр төяп
кайтты волостька солдат.

Керде киңәшмә залына.
Карады дикъкать белән, —
Николай патша рәсемен
Тондырды приклад белән.

Һушы китеп ауды шунда
киңәшмәдәге кемдер.
Солдат үкчәсе астында
ертылып калды киндер.

Таныды Хәмит солдатны —
Мәгъзия уртанчысы. —
Шуңар охшап, тулып тамган
ничәдән бер тамчысы.

Прикладны сиңа да җитәр,
шул уйдан интегә тор,
үз авылың күләмендә
син, Хәмит — император!

Сараның ачы кулыннан
әле дә яңак кыза. —
Мылтык түтәсеннән алда
суккан ул задаткага.

Кайта Хәмит. Аты арган.
Ләкин моны сизми ул.
Инкыйлабның прикладыннан
котылырга эзли юл.

Үз хезмәтчеләре белән,
кемнәр әле? — мәлгуньнәр,
килешү юлын тапканнар, —
Сен-Симоннар, Оуэннар...

---

[1] Ахыры. Башы 1965 елның 10 һәм 1966 елның 3, 4 саннарында.

Тегe чакны алар исемен
ишетте Антоннан ул.
Астыртын гына тарихтан
өйрәнде барысын да ул.

Борынгы руслар алган күк
француз тәрбиясен,
Хәмит тә куллана хәзер
аларның тәҗрибәсен:

Тәрбияче итеп асрый
күрше авыл марҗасын.
Күпне белүче ул ханым
тәрбияли Алмасын.

Оуэннар да, Сен-Симоннар
кемнәр алар? Нәрсә? — дип,
күптән сорашып, белеште
менә шуңардан Хәмит.

Нык карарга килде менә.
Авыл инде бик якын.
Керде ук кебек атылып
ул чыбыркылап атын.

Шыелдап барган чанада
кулын болгап, кычкыра
беренче хәбәрче булып:
— Патша мәтәлгән! Ура!..

■

Керде кайтып йортына ул
беренче кергән кебек.
Тукталды Сәлим каршында
беренче күргән кебек.

— Карачы! — диде бот чабып, —
ничек үсә бит әдәм! —
Үткән ел — кендектән идең,
хәзер — минем җилкәдән!

Өйләндерәм! — Ятка китеп,
әрәм булмасын балам.
Юк, иртәрәк... Әле сиңа
иң әлек гармун алам!

Һәм сүзендә торды Хәмит —
Сәлим гармунлы хәзер.
Уйный да, кочаклап йоклый, —
дөньясы тулды хәзер.

Менә Алма кызлар җыйды
хөррият хөрмәтенә.
— Уйна! Уйна! — дип, Сәлимнең
тиделәр теңкәсенә.

Һәм уйнады, сер бирмәде
шаяннар каршында ул:
уйнарга кечкенәдән үк
өйрәнде Антоннан ул.

Ни бәхет! — аңар кагылды
Алма биегән чакта
чабулары гына түгел,
толымнары да хәтта!

«Берегезнеке дә түгел, —
минем Сәлимем генә!» —
Шундый хис Алма йөзендә
балкый самими генә. —

«Ул минем уенчыгым бит,
минем песи... Минем эт!» —
дип, бер-беренә балалар
мактангандагы кебек.

Әлбәттә, байларда кичә
гади түгел, башкарак.
Алманың тәрбиячесе
оештырды маскарад.

Һәм озаткандай итте дә
Сәлимне өенә ул,
киендереп кертте аны
кызлар киеменә ул.

Бар әкәмәтләрне язмыйм,
тик шуны әйтеп үтәм —
кызлар киеме кешене
гаҗәп үстерә икән!

Алма биш яшькә олырак,
буйга тиң икәве дә.
Качынган бер «кунак кызы»,
әйтми кем икәнен дә.

Йоклар вакыт җиткәч, Алма
марҗа белән киңәшеп,
«кунак кызын» алып керде
үз бүлмәсенә дәшеп.

Һәм кунып та калды шунда
уникe яшьлек егет,
солтан кәнизәге белән
Дон Жуан кунган кебек [1].

Иртән, Сәлим киткәч, Алма
сөйләде төшен менә.
Корт чакмаган ләкин аны,
тешләгән чебен генә.

[1] Байронның «Дон Жуан»ында сурәтләнгән эпизод күздә тотыла. *С. Б.*

Юатты аны марҗасы.
һәм тынычланды Алма:
чебен генә тешләгәнгә
шешенмәс, инша алла!

II

Антоныбыз кайда? Аны
күздән югалтмыйк әле.
Юлга чыккан ул җәяүләп,
Казанга атлый әле.

Революция офыгын
шушыннан карарга ул
манарага менгән кебек
үрмәли Казанга ул.

Конкрет максат билгеләп
кайтасы килә аның —
кемнәр белән, кая таба
ясарга хәзер адым?

Кулында большевикларның
«Рабочий» газитәсе —
аны кирәкле урынына
тыйпылдырмый илтәсе.

Рыбнорядский урамда —
начар гына бер кибет.
Шунда моны кем каршылый? —
Гирш Ольkеницкий бит!

Антонның үзе кебек үк
сөргендә яткан кеше.
Әле генә шуннан, ягъни
Чистайдан кайткан кеше.

Антонны димли:
— Тау-тау эш...
Казанга күч син дә, — ди.
— Юк, — ди Антон, — мин төпләндем —
анда минем семья, — ди.

һәм уйлап куя эченнән:
«Авылда да тау-тау эш.
Мин дә кадрларны анда
шулай тупларга тиеш...»

Наборщиклар полосалар
күрсәтәләр шунда ук.
Гирш Шмулевичның хәтта
сөйләргә вакыты да юк.

Большевикларның штабы
нәкъ шул кибеттә икән;
барлык яңа юллар хәзер
шул өйгә илтә икән.

Кайтып керә мылтык асып
көпшәсе белән аска —
— Чанышев!
— Назар Ежов! — дип,
күрешә алар башта
һәм:
— Солдатлар комитеты
оешты! — дип өстиләр.—
Чираттагы «Рабочий»га
моны кертегез! — диләр.

Бу хәбәр дә якты булып
төшә Антон аңына:
«Ник ярлылар комитетын
оештырмаска миңа?!»

Кичкә чаклы шунда булып,
чыкты кабынып шул йорттан —
Казанны һәм губернасын
кайната торган уттан.

Кайткан чакта күрә юлда:
кәҗүнни бүрәнәләр
үрәчәсез чаналарда
авылга сөйрәләләр.

Менә ат белән Мәгъзия
бергә җигелгән чана,
хатын ашыктыра атын:
«Юллар өзелгәнче, на!»

Алдарак — бүтән олаучы,
«Күсәкләр» нәселе ул,
нәселдән нәселгә килгән
ачу белән сөйли ул:

— Баржа тарттык. Сал агыздык. —
Гомер-гомергә — бурлак.
Патша сарайлар салдырды
безнең салларны урлап.

Мәтәлде. Кычкырыналар
хәзер: «Ирек тә ирек!»
Ирекнең ни мәгънәсе бар
нигезең булгач черек.

«Тугыз кыз» атасы кайта
«Күсәк»ләрдән алдарак.
Атын әйди. Ә ирекка
карашлары башкарак:

— «Сукыр елаганы — күз», — ди, —
җир — авыл елаганы.
Җирне кашык исәбеннән
бүләргә кирәк аны...

Кызлары тоткан кашыкны
ул җиргә санап кайта.
Һәр олаучы белән бергә
фронттан солдат кайта.

Олауларны узып, Антон
шуларны тыңлап үтте.
Үткәч, арттан берничә сүз
йөрәгеп тырнап үтте:

«Антон эше — ал да гөл», дип
ишетелде чак кына.
Һәм моның мәгънәсен Антон
аңлады кайткач кына.

III

БӘЕТ

«Әтекәемнең
гуринчасында
йөри идем лә
читекчән генә.
Унике яшьлек
сабый киявем
килеп керде лә
чүплектән генә...» —

Җырлыйлар. Төшенми Антон
мәгънәсе ни икәнен —
«унике яшьлек кияү»нең
белми Сәлим икәнен.

Белми, чөнки бу эшләрне
көтмәде Хәмиттән ул:
авыл революциясен
үзенчә хәл иткән ул!

Белми ул — Сәлим өйләнгән!
Гәрчә ул — сабый бала,
никах укыттырган Хәмит —
кияү дип саный ала!

Һәм моның өчен мулладан
дин юлын таптырган ул.
Бар байлыгын мирас итеп,
Сәлимгә тапшыра ул...

Җыен булган. Төшерелгән
иске староста да.
Мәчеткә юнәлгән хәзер
халыкның барысы да.

Хәмит ияртқән аларны, —
агым башында бара.
«Ни булыр?» дип, кызыксынып
Антон да шунда бара.

Карый — керделәр мәчеткә.
Кемне алар өстери?
Мәгъзиянең ире икән —
чыкмаска аяк тери.

Изге җаннардан түгел ул,
тик мәчеткә йөргәли:
Өйдә утын юк — мәчеткә
елынырга кергәли.

Куркудан агарынган ул.
Сөйрәүчеләр әрлиләр:
— Суярга илтмибез сине,
я, кәҗәләнмә! — диләр. —

Сине — ярлыны сайладык,
кайгырт ярлылар хәлен! —
Көчләп тагалар муенына
староста «медален».

Калтыраган кулы белән
башмакларын эзли ул,
көләргәме, еларгамы? —
нишләргә да белми ул.

Алып кайтты Хәмит аны
үзенең хаҗәтенә,
кул куйдырды Сәлимгә дип
яздырган васыятенә.

Аннары сыйлап озатты:
— Бар, укы намаз, — диде, —
Староста булдың. Инде
хатының кыйнамас, — диде.

«Антон абый! Син белеп тор —
Алма — минем каләшем!
Сәлим аңар тия калса,
үзенә үпкәләсен!»

Шулай искәртте Антонны
Мәгъзияләр кечесе.
Кечесе, тик егетләрнең
авылда беренчесе.

Иптәшләре моның өчен
итмәде гаеп, әнә,
Мәгъзия малаен яклап
җырлана бәет әнә:

БӘЕТ

«Таулар башында
карларга җәеп,
авыл кызлары
киндер ашлыйдыр.

Унике яшьлек
сабый киявем
кочаклагачтан
елый башлыйдыр...»

Торагына кайтты Антон,
йөри тирәли урап. —
Кайда Сара? Кайда Сәлим? —
Караңгы, бикле торак.

Шомланып куйды уйлап ул
Сараның йөклелеген:
бер-бер хәл булганмы? Торак
шуңар бикләмә бүген?

Янәшәдә балкый байның
яңарак салган өе.
(Шул өйне бит ул мулладан
акыртып алган иде.)

Чү! Сара тавышымы бу,
чакырамы шушында? —
Аның килгәне күренә
тәрәзә яктысында.

Һәм бу шулай булып чыкты:
алар хезмәтен түләп,
Антон кайтканчы, аларга
шул өйне иткән бүләк!

Димәк, аның юлдашлары —
бүрәнә ташучылар
«Антон эше — ал да гөл», дип
әйткәннәр төбәп шуңар!

Бүләк өйгә кайтты Антон.
Исемлек төзеде дә,
Сәлимгә бирде:
— Шуларны
чакыр әле тиз генә!

Сәлим Антонның йомышын
үти иде «ялт!» итеп.
Хәзер йомшак кәнәфидә
утыра мәрткә китеп.

Сара шунда әйтеп куйды
яклаган кебек аны:
— Урамда дошманнары бит,
чыкса кыйныйлар аны. —

Урам якка колак салып,
әйтте:
— Әнә, тыңлачы...
Анда —
бәет куплетлары —
берсеннән-берсе ачы:

«Мин кочаклагач
нигә елыйсың? —
белмисеңмени
сагынып көтүем.

Унике яшьлек
сабый киявем,
син дә көттең бит
сарык көтүен...»

— Бар! — диде Антон. — Ичмасам
курыкмавыңны белгерт!
Сәлим, исемлекне алып,
бакча ягыннан — әлдерт!

Хәмит кычкырды урамга:
— Таралыгыз, этләр! — дип.
Антон кычкырды:
— Сез монда
кирәгез, егетләр! — дип.

IV

Шул төнне урам буенда
йокысыз йөрде Хәмит.
Тик бер ут калды авылда —
ул — Антон өендә бит!

Дөресрәген әйткәндә —
Антонга бүләк өйдә.
Ниләр бар анда, нишлиләр? —
Белергә кирәк, әйдә!..

«Рөхсәт сорарга мы?» дип ул
ишек төбендә тора...
Үз өе! —
Рөхсәт сорамый,
тамагын гына кыра.

Ачып кера —
халык шыгрым!
Төрле
ярлы-ыргыйлар.
Хәмит сәламен алыйммы,
юкмы? — дип аптырыйлар.

Һәм Антонга карыйлар да,
нәкъ аныңча, сак кына
сәламгә җавап итеп тик
кыралар тамак кына.

Карый Хәмит — кем генә юк! —
Башмакчы Бәшир дә бар,
Австрия киемендә
бер унлап әсир дә бар.

Мәгъзиянең олы улы
алар белән сөйләшә:
— Их бин — бедняк. Ду бист — бедняк, —
һәм Хәмиткә курсәтә:

— Эр ист — буржуй! — Унзер буржуй.
Ду хабст тоже буржуй.
Шуле, кайт Австриягә,
буржуй муенын бор да жуй! [1]

Хәмит муенына карап,
әсирләр баш кагалар.
Хәмит кереп өзгән сүзне
башлап китә башкалар:

— Я. Безне патша талады,
талады Столыпин.
Алар дөмекте. Тик һаман
ярлы бит без. Талый кем?

Әңгәмә болайга киткәч,
чыраен сытты Хәмит.
Яңакланган кеше кебек
урамга чыкты Хәмит:

Столыпин урнаштырган
тәртипләр нигезендә
ничәмә ярлы җиренә
хуҗа бит ул бүген дә!

Димәк, юкка маташкан ул
старосталар сайлап.
Кая гына атламасын —
хәле юк. Юлы — тайгак.

Кыланасыларын күптән
Хәмит кыланган инде.
Революция бу. Хәзер
халык уянган инде.

Ярлыларга үз хокукын
Антон аңлата торсын,
йокы алмаса да, Хәмит
түшәккә ята торсын.

Без хәзер аның кызына,
ягъни Алмага килик.
Катлаулы кичерешләрен
аның аңларга телик.

Нәкъ атасыча — дөньяга
карашы җәдит аның.
Дингә дә ышанмый. Чөнки
әтисе — Хәмит аның.

Ышанмый гына да түгел,
дингә тирән нәфрәте.
Аны үстерде күптәнге
коры еллар дәһшәте.

Әнисенең җилкәсенә
таудай гөнаһ йөкләнеп,
Авылга алла юнәлткән
афәттә гаепләнеп,

нахакка рисвай кылынып
йөртелгән елдан бирле,
кызы Алма йөрәгендә
шул нәфрәт үсә килде.

Алма да үсте.
һәм җитте
ул шундый хәлгә хәзер —
нахак бәлане
хак гөнаһ
белән түләргә әзер!

Динчеләр өстенә мәгърур
карый күңел күзләре —
хатын-кыздан куркыр өчен
бар икән нигезләре! —

Сизеп тора йөрәгендә
мәхәббәтнең яшь көчен, —
иблис көчен —
игеннәрне
яндырган кояш көчен!

Бәет чыгаручыларны
үзе яклы дип саный.
һәм чыннан да, — нәрсә аңар
унике яшьлек сабый!

Ул бары әкияттәге
гарәп малае кебек,
эчендә җен көче яткан
шешәне ачты килеп.

Әкиятләрдәге кебек үк
шул ук шешәгә тагын
ул җенне кире бикләргә,
юк, көче җитми аның!

Уянды, кайный Алмада,
тыныч куймый һич аны
әнисенең нәселеннән
аңар күчкән һинд каны.

Йозакларын шаңгырдатып,
мәһәр сандыгын ачты,
киенде, ясанды, аннан
көзге каршына басты.

Каләм алды.
Аның шаян
йөрәк тибеше инде
шул минутта бәет булып,
ап-ак кәгазьгә иңде:

---

[1] «Мин дә ярлы, син дә ярлы. Ә ул — буржуй. Безнең буржуй, Сездә дә буржуйлар бар. Бездән өйрәнеп, Австриягә кайтыгыз да, буржуйның муенын борып, чәйнәгез», димәкче була.

«Әтекәемнең
гуринчасында
йөрим төренеп
атласка гына.

Унике яшьлек
сабый киявне
эти үстерде
запаска гына...»

Тәрбиячесен уятты:
— Вставай-ка, карале!
Ник тыңдылар, җырласыннар,
илтеп бирче, бар әле

менә шушы бәетне... — дип,
бирә кәгазен аңар.
Тегесе, йокы аралаш:
«Илтермен. Ярар. Ярар...»

дип, әйләнеп кенә ята.
Уяталмый марҗаны,
аптырагач, үзе шунда
ята кочаклап аны.

V

Сизгер Хәмит,
урам якка
карый аякка басып.
Тәрәзә пыяласында —
камчы сабы — «шык» та «шык».

Ул чыкканда Сәлим керде.
Кияү булса да гәрчә,
каенатасыннан ул күзен
яшерде хаиннәрчә.

Елмайды Хәмит.
Юл биреп,
җибәрде кертеп аны.
Казаклар төркемен күрде
чыгып ачкач капканы.

Шулай дезертирлар аулап,
коралллы отряд йөри. —
Генерал Сандецкийның
әмерен үтәп йөри.

Һәм кем дә кем буржуйларның
җирләренә суза кул,
җәза бирергә хокуклы
«Кара телле» отряд ул [1].

Аңлаштылар. Акрын гына
сөйләшеп, пышын-пышын.
Җыелыштагылар сиздe,
тик эш үткән инде... — Соң.

Ишек, тәрәзәләр — сакта —
яктырганчыга кадәр.
«Дезертирлар» атылачак,
чыгарга теләсәләр.

■

Сәлим керде дә, Алмага:
— Торма, торма... Ят! — диде.
— Ят шул! — диде Алма аңар, —
эх, ят булмасаң иде!

Ут кабызды бүлмәсендә, —
кандилле, асылмалы.
Нурлы йөзен күрде Сәлим, —
йөрәге басылмады.

Таң калды ят булуына —
Алманың үскәненә.
Һәм ят булуына гүя
масая өстәвенә! —

Сәлимгә шундый үтергеч
бер караш ташлап үтте,
гүя карлыгач чебенне
очышлый ашап үтте!

Нәкъ шул минутта бүлмәнең
тышында дөбер-дөбер
коридор буйлап, зал якка
төркем үтте ниндидер.

Уй үтте Сәлим башыннан:
«Мөгаен, Хәмиткә, — дип, —
ярлылар ашка керәләр,
тотарга тәрилкә», дип.

Мин моны аңлатып тормыйм,
укучым минем зирәк, —
ярлылар түгел, казаклар
кергәнен белсә кирәк.

Ике сакчы куйдылар да
теге өй ягасына,
калганнары чәйгә кера
Хәмит гурничасына...

VI

Ә теге өй — сак астында.
Чыгар юллар инде юк.
Ярлыларда сүнә өмет.
Мае бетеп, сүнде ут.

[1] 1917 елда карательный отрядларны татар авылларында «кара телле» отряд дип йөртәләр иде. С. Б.

Корал да юк. — Тик бер мылтык,
ул да патронсыз икән,
соңгы патронын хуҗасы
эт атып әрәм иткән.

Кайсыдыр кадак суыра
стенада капшанып.
Сөйләнә: «Кергән берсенең
күзен чыгарам казып!»

Нәкъ бала тудыру өчен
шартлары да, вакыты да:
почмак ягында — ыңгыраш, —
Сараны тулгак тота.

Һәм ыңгырашты шыгырдап
уртада имән өстәл:
— Тирә-яктан чыгып булмый, —
юл эзләп карыйк өстән! —

Шулай Мәгъзия олысы
басты менеп өстәлгә.
— Безгә, — ди, — кирәк Ленинннан
үрнәк алып эшләргә.

Ул бит — патша строен
каерып аткан Ленин.
Неужели көчем җитмәс
шул түшәмгә дә минем! —

Көчәнде җилкәсен терәп...
Күккә ашкандай булып,
юкка чыкты, ышкылды да...
Калды туфрак коелып.

Өстәлгә басып, таянып,
көчле терсәкләренә,
абыйлары салган эздән
чыкты энекәшләре дә.

Нинди им-том иткәннәрдер —
өнсез калды сакчылар.
. . . . . . . . . . .
— Чыгыгыз! — дип, өч баһадир
ишекне шар ачтылар.

## VII

Чыгучылар караналар
өй алды, өй артына.
Аларның кайбере инде
таярга тайяр тора.

— Кем кача, менә аңар — җир, —
тоттырам, кайда кулы! —
Шулай диде караңгыда
Мәгъзиянең бер улы.

Шунда караңгы булса да,
күргәндәй булды дус-иш:
җир кирәкме — хәзер күраш,
юкса алырсың — кукиш!

— Башың алтын, саклан! — диеп,
бары Антонны гына
борып керттеләр ярдәмгә
авыру хатынына.

Хәмит өе — чолганышта.
Хәерле, таңгы сәгать.
Ике трофей винтовка,
калганнарда — лом, сәнәк...

Операция уңышлы,
атышсыз үтте, кансыз.
Сәлим ярдәм итте моңа,
эш чыкмас иде ансыз.

Алманың кире кагуын,
шуның ачысын татып,
чыкты аннан, эчке яктан
тимер ыргакны ачып...

Була кайчак — бирәү өчен
шундый хурлыклы качыш —
башкалар өчен — кирәкле
һәм иң көтелгән ачыш!

Килеп керде, якынайды —
Алманың нәкъ алдында —
зур кайгылы, зур шатлыклы
пешкән, җитешкән дөнья.

Әтисенең дөньясына —
казаклар тулы залга
басып кере шыпырт ташкын,
Мәгъзиялеләр — алда.

Кечесе беренче кабат
Алмага туры карап,
тынлык таләп итеп үтте,
аңарга бармак янап.

Елмайды Алма. Янәсе —
«Кемгә саныйсың мине!» —
Тып-тын торды: бу — беренче
мәхәббәт сере иде.

Залда сәгатьләр буена
мәҗлес кызган иде;
һәм казаклар эшне уйлап
эшләүдән узган иде.

Үзен аклау өчен Хәмит
шунда да тапты юлын:
ясавыл, атарга диеп
күтәргән иде кулын

Мәгъзиянең залга башлап
килеп кергән улына, —
сукты Хәмит аскы яктан
ясавылның кулына.

Маңгайга төбәлгән наган
төшәмгә атты шунда.
— Безнең гореф-гадәт шул, — дип
Хәмит аңлатты шунда, —

Сез мидә кунак идегез,
алар да кунак миңа.
Бездә кунаклар атышмый,
кунак ул тыйнак була...

Шулай ярлылар нәфрәтен
коралсызландырды ул;
төбәлгән ачу наганын
үзеннән алдырды ул.

Җазачылар китте кайтып,
атсыз, коралсызланып,
кыйналып теше коелган
бүреләрдәй сызланып,

Әйдә, алар әзли торсын
Казандагы өннәрен, —
Без Чирмешән якларында
тыңлыйк авыл өннәрен.

Казаклар атына менеп,
ярлылар — антонлылар
волостька староста дип,
Хәмитне илтеп куйдылар!

Һәм әйттеләр:
— Әмереңне
үтәр өчен без — әзер.
Алпавыт җире — безнеке! —
Сукаларга бир әмер!

Антонның тактикасына
Хәмит таң кала ничек:
алпавытка һөҗүм итә
Хәмитне калкан итеп!

Кечерәк милекчеләргә
әле тимәгәч алар,
Хәмит кебек башка байлар
инде тынычланалар!

Җиңәр Антон. Һәм Хәмитнең
киләге инде калмас.
Үзен мәтәлдерер Антон,
Ай-ваена карамас...

Калай таккан иде Хәмит
Мәгъзиянең иренә;
нәкъ шундый роль тапшырылды
менә аның үзенә!

Әйдә, башкар үз ролеңне!
Хәмит әйтте баш иеп:
— Языгыз әмерегезне,
мин кул куярмын... — диеп.

Мәгъзиянең олы улы
Каләмне ун кат манып,
алтмыш ялгышлы алты сүз
«приказ» дип, бирде язып.

— Моны акка күчерәлмим,
һәр сүзе, — диде, — шифр, —
исерек баш һәм ришвәтче
Вася — волостной писарь.

— Ах син, контр! Менә каләм!
Менә — кәгазең! — дигәч,
каләм дигән штык очы
корсакка барып тигәч,

чакырды писарь киңәшмә:
— Кем укый — яза белә,
зинһар шуларны танырга
ярдәм итегез, менә!

Киңәшмә кызды. Бәхәсләр
чигеннән ашып китте.
Мәгъзиянең улы үзе
шуңар катнашып китте:

«З» хәрефе бармы башында? —
Танылды: «Земля» димәк.
Әйе! Аны язудан да
сөрүе җиңелрәк!

«Сөрергә алпавыт җирен» —
яз шуны! — Бетте-китте!
Бәрәңгедән пичәт ясап
бирәве тәкъдим итте.

Сукыр лампада корымлап,
бастылар җәһәт кенә.
Урак-чүкеч юк аңарда,
әлегә — сәнәк кенә.

Бу — кисәтү эмблемасы:
карышып кына кара, —
җир сөрергә сабан белән
сәнәк тә бергә бара!

Ләкин төп корал ул елны
бер япьле сәнәк иде —
штык иде. Җиңүгә дә
менә шул сәбәп иде.

Армиядән сабанга дип
кайта калса бер солдат,
тагын да бер штык арта
кемнеңдер күзен алдап.

Йондай җиңел «винтовкалар»...
Асып йөри һәр кеше —
юкә агачтан ясалган,
башмакчы Бәшир эше!

■

Ныгып керәш походында,
Антоннар мәктәбендә
узды Чирмешән яклары
Февральдән Октябрьга.

Декрет булып, ил өстенә
бәйрәм кояшы чыкты:
«Җир!», «Тынычлык!» —
Урамнарга
бар карты-яше чыкты.

«Җиде гүзәл» балетының
авторы Кара-Карай,
көнләшер иде шул чакта
тугыз гүзәлне карап:

Әтиләре бара әнә
урамда гармун уйнап.
Чолгаган аны кызлары,
баралар биеп, җырлап.

Аларның кичерешләрен
бәян итсә итәчәк
үз җырлары, үз сүзләре:
«Аллы-гөлле гөлчәчәк!..»

«Фани дөнья үтәчәк», дип
җырласалар да моны,
димәк, яңа дөнья туа, —
иске дөньяның соңы!

Һәм хәзер дә,
нинди генә
җимеш турында язма, —
чәчәге аткан аның, —
шул
Октябрьдагы язда!

*1965.*

## *Халык мәзәкләре*

### НИК ӨСТЕРӘП ЙӨРЕРГӘ

Элекке заманда бер картның улы читтән кайткан. Чәй эчкән вакытта хәл-әхвәлләрне сорашып бетергәннән соң, әтисе:

— Я, улым, акча ягы ничегрәк соң? Бераз алып кайта алдыңмы? — ди икән.

— Алып кайткан да булыр идем, ләкин файдасы юк бит, — дигән малае.

— Ничек инде файдасы юк?

— Монда бер сум күпмегә йөри?

— Бер сум күпмегә йөрсен, бер сумга йөри инде ул.

Шулай булгач, андагы бер сумны монда кадәр ник өстерәп йөрергә! — дип җавап биргән ди, малае.

### КЕМНЕҢ ӘТИСЕ НИНДИ?

Ике малай үзара сөйләшәләр икән:

Берсе әйтә, ди:

— Минем әти авырганда доктор килгән иде, әти телен күрсәтте дә, аннан соң, доктор апа аңа белешмә язып бирде.

Икенчесе әйтә, ди:

— Ә минем әти алай итмәде. Ул башта белешмә алды, доктор апа чыгып киткәч кенә телен чыгарып күрсәтте.

### ШАЛКАН

Колхозның яшелчә бакчасына Шәрифулла бабай шалкан утырткан булган. Шундый уңган, зурайган бу шалкан. Менә уңыш җыю вакыты җиткән. Тарткан бабай, тарткан шалканны — тартып чыгара алмаган. Карчыгын чакырган. Икәүләп тартырга ябышканнар. Тартканнар, тартканнар, чыгара алмаганнар. Ярдәмгә оныкларын чакырганнар.

— Гафу итегез, күз нурларым, кулымда дипломым була торып, шалкан тартыр хәлем юк, — дип җавап биргән оныклары.



## *М. Гаскәров*

●

*Әйтерсең, узган 23 елны Минзәлә буеның хуш исле болыннарында мәтәлчек атына-атына гына үткәнмен. Бигрәк тә сизелмәде. Әле күптәнме Нөркәй урта мәктәбендә укып йөргән чаклар, инде педагогия институтын тәмамлау алдында торам. Әмма җан һич олыгаюны белми. Әчкелтем хуш ис таратып борын төртүче тополь бөреләрен әле дә малай кебек сокланып күзәтәм. Һәр яфракны күзем белән саргайтам. Сары көз җитә. Яфраклар коела. Аерылу гел сагыш алып килә, юкса. Тик гаҗәп, туган туфракка мәхәббәтең никадәр олы икәнен нәкъ менә шушы вакытта аңлыйсың.*

*Кошлар китә. Ә мәхәббәт аерылгысыз, яшьлек кебек мәңге синдә кала.*

*...Мәхәббәттән һәрчак җыр туа.*

# ПАРЧАЛАР

## Чәчәкләр

*Бер көтү бала килеп чыкты. Меңләгән көмеш кыңгырау бер-беренә бәрелеп зеңгелдәштемени: бакчаны чың күмде.*

*Бераздан, түгәрәккә тезелеп, әйлән-бәйлән уйный башладылар. Ирennәре — чәчәк, күзләре — чәчәк, бит очлары — чәчәк, үзләре — чәчәк.*

*Көн яктырып киткәндәй булды.*

*Агачларның ботаклары шәрә, күк көлсу, җирдә сарылык, шиңгән гөлләрдә кырау иде.*

*Йөрәктәге кырау эреде, күңелгә аязлыгы, нурлы яктысы, хушбуй исләре белән яз тулды.*

## Җир турында җыр

*Җирнең күкрәге корылыктан чатнап яргаланган. Бәбкә үләннәре көйгән. Кайнар һава кайнар тузаннан күктә өермә куа.*

*Тереклекнең күзе зәңгәр һавадагы ак болытларда.*

*Җир суга сусаган.*

*Җир су көтә иде.*

■

*Коры кантарның беренче тамчыны нинди комсызлык белән үзенә сеңдергәнен үз күзем белән күрдем.*

*Җир белән күкне су баганалары тоташтырды.*

*Сөрүлектән җылы пар күтәрелгәнен үз күзем белән күрдем.*

*Гөрләвекләрнең балчыкка орынуыннан туган җирдәге иң беренче мәхәббәт җырының инде меңенче мәртәбә өр-яңа булып яңгыраганын үз колагым белән ишеттем.*

■

*Ике атна буе бөресен ача алмый утырган карабодай кыры чәчәккә күмелде. Умарта ояларыннан берьюлы «яшибез-з-з!» көе гөжләде. Алланып ачылып киткән роза чәчәге түтәл арасына җыелган суга иелеп үз матурлыгына үзе сокланды.*

## Күк-кү

*Җылы яңгыр явып, әле генә егылып яткан үләннәр, дәррәү үрә басып, күккә үрелделәр.*

*Җирдән пар бәреп тора. Шул пар белән бергә бәбкә үләннәренең яшеллеге, җитен чәчәгенең зәңгәрлеге, роза гөлләренең алсулыгы, тагын әллә нинди төсләр тарттырып бөккәндәй дугаланып торган салават күперенә күтәрелә кебек.*

*Урман аланында күке тавышын тыңлыйм.*

*Күк-кү.*

*Бер... өч... биш!*

*Күк-кү.*

*Өч... биш... ун!*

*Күкеләр кычкыра. Кычкыра да туктый. Күкеләр туктаган саен, тагын бер генә кычкырсагыз ла, диясе килә.*

## Язгы су

*Борылмада юлымны язгы су бүлде. Челтер-челтер агып ята. Шулкадәр чиста, шулкадәр саф — чишмәләрең бер якта торсын. Матурлык алдында күзем бәйләнгәндәй тукталып калдым. Озак тордым. Ахырда, шушы сафлыкның кайдан башланганын күрәсем килде. Язгы су мине калкулыкның башына меңгерде. Киңлеккә карадым. Калкулыкның ясуланып торган өлешендәге өч аршын җир киртәләп алынган, урталыкта — язулары ашалган соры таш. Су, коймалар арасыннан үтеп, ташны әйләнә дә бөтерелә-бөтерелә алга ургый. Су монда озак тукталмый. Ул белә: коймалар барыбер яфракка бөреләнмәс, баганалар барыбер шаулы имән булып үсмәс.*

*Су, чәчри-чәчри, кояшта матур ялтырап, түбәнгә ыргыла. Ярага яба торган бака яфраклары үсәчәк кырларга ашыга.*

## *Рәшит Гатауллин*



•

*Туган елым 1938. Туган җирем Башкортстан, Кушнаренко районы, Марс авылы.*

*1953 елда җидееллык мәктәпне тәмамлагач, озак еллар колхозда төрле эшләр башкардым. 1961 елда читтән торып урта мәктәп бетердем дә, Уфадагы Башкорт дәүләт университетының татар бүлегенә укырга кердем. Быел университетны тәмамлыйм.*

*Поэзиягә мәхәббәтем бала чактан ук зур. Университетта укыган дәвердә «Кызыл таң» (Уфа) газетасында, яшьләр альманахында шигырьләрем басылып чыкты.*

*Язасы килә. Яраткан шагыйрьләрем Такташ кебек, Назар Нәҗми кебек зур хисләрне гади сүзләрдә халыкка җиткерәсе иде...*

•

Кояш көлеп-көлеп карады да
Ак тамчыга кунды.
И сөенде тамчы, и сөенде,
Алсуланды, тулды.
Нурга чумган тамчы түзәлмады,
Сузылды да... тамды.
Очты кояш. Якты нуры гына
Җиргә төшеп янды.
Мин дә сине якты тамчы итеп
Күргән идем.
Югалмамын, мәңге янармын дип
Белгән идем...

## Кошлар кебек очып килмәдем мин

Күл читендә үскән ак каеннар
Яфракларын коя сагыштан.
Зәңгәр күлдән
Зәңгәр дулкын кагып
Күтәрелеп китте аккошлар.
Әй, аккошлар,
Кая кузгалдыгыз?
Бик еракмы барыр юлыгыз.
Урман-күлнең яме беткәч кенә
Нигә инде китмәк булдыгыз?!
Башка җирдә күлләр башкадыр ул,
Язлар башка анда, башка ямь.
Әй, аккошлар,
Юлыгызга карап
Беркайчан да сездән көнләшмәм.
...Күл читенә басып карап калдым
Аккошларның очып киткәнен.
Кошлар кебек очып килмәдем мин,
Кошлар кебек очып китмәмен.

Һәр яфракның,
чәчкә,
үләннәрнең
Телен белсәң —
күпме сере бар,
Һәрберсенең үзе генә тапкан,
Үзе генә җырлар җыры бар.
Мин сөйләшәм,
җирем,
синең белән

Яфрак,
үлән,
чәчкә,
нур аша.
Алар бар да тамырлары белән
Йөрәгенә синең тоташа.
Тамырлары туфрагында торса,
Чәчкә шиңмәс,
якты нур сүнмәс.
Һәм минем дә
кешеләргә әйтер
Сүзем бетмәс,
җырым сүрелмәс.

## Бир, әнкәй, кулларыңны

Әнкәем җәйге иртәдә
Уята килер микән?
Куллары белән иркәләп:
— Тор, улым, диер микән?
Сабый кулларымнан алып
Бастырдың мине юлга.
Тоттырдың тормыш юлыннан
Дилбегә ясап кулга.
Тыймадым микән атымны,
Ашкынып киткән булдым.
Туктарга кирәк урында
Чаптырып үткән булдым.

Адаштым китеп еракка,
Язмышым бармак яный.
Буй җитмәс җиргә үрелдем, —
Мин әле һаман сабый...
Әй, тиле чак, мин яңадан
Эзеңнән китәр идем.
Юлларга төшкән томанны
Таратып үтәр идем.
Яшьлектә ялгышып киткән
Бормалы юлларымны
Тәпиләп яңадан үтим,
Бир, әнкәй, кулларыңны!

## Бер чәчкә өзәр идем

Яшьлегем тартты еракка,
Ашкынып чаптым ары.
Юлымда калды ал-кызыл
Чәчкәле тугайлары.
Алмадым өзеп берсен дә,
Бөгелеп калды гөлләр.
Ни күреп алга ашыктым,
Мин җуләр инде, җуләр!!!
Мин менә ерак далада,
Тирә-як көйгән үлән.

Ә алдымда — о, син гомер!
Бер зәгыйфь чәчкә күрәм.
Яшьлекнең янар чәчкәсе, —
Еракмы әле бүген!?
Бу коелган, сулган чәчкә —
Юк, юк, минеке түгел!!
Яшьлектә калган эзләрдән
Үтәргә житсә көчем:
Китәр идем, сиңа бары
Бер чәчкә өзәр өчен.

## *Зәвил Шәйхулов*



*Мин 1939 елда, Башкортстанның Кушнаренко районы Солтанай авылында, укытучы гаиләсендә туганмын. Җидееллык мәктәптә укыганнан соң, Бәләбәй педагогия училищесын тәмамладым. 1958 елда армиягә алынып, хәрби диңгез флотында 4 ел хезмәт иттем. Хәзер Башкорт дәүләт университетының татар бүлегендә укыйм.*

### Диңгездә

Айкалдыра диңгез — чайкалдыра,
Төшмәгәнмен гүя бишектән —
Ачы җилләр аша әниемнең
Әлли-бәлли көен ишетәм.

Туган якта шушы сәгатьләрдә
Күпме малай моряк булам, дип,
Хисләр канатында оча-оча,
Йокламыйча уйлап ята бит!..

Кеше шулай яралгандыр инде, —
Коры җирдә диңгез сагына,
Ә диңгездә,
Дулкын көчен тоймый,
Җәяү йөри туган ягында.

### Җилкәй

Җилкәй, җилкәй,
Җылы көньяк җиле,
Тагын миңа җырлар китердең.
Сагындырып кына искәнгәме,
Син кунагы монда һәркемнең.

Әйдә түрдән, әнә туп өстенә
Сарыл да син, сөйлә, җил генәм,
Без утырган тирәк төпләрендә
Кем утыра хәзер кем белән?

Сөйлә, ничек язгы ташу үтте,
Дымга тукмы иген кырлары?
Һаман шулай кичен яңгырыймы
Эштән кайткан яшьләр җырлары?

Туган авыл аша үткән булсаң,
Күргәнсеңдер анам карчыкны,
Кече энем быел укучы бит,
Ничек әйтә «Р»ны, ачыкмы?

Әйдә сөйлә, җилкәй, җырлап күрсәт
Нинди яңа җырлар Уралда?
Минем өчен диңгез дулкыннары
Кул чабышып сорап торганда,
Көйлә әле, миңа үпкәләмә,
Күрәсең бит
Куллар... коралда.

## Кунакта

Моряклар, дилəр, безне,
Чиксез, дилəр, диңгезне.
Ничек анда, сөйлə, дип
Ачырмыйлар да күзне.

Каншларыгыз, һай кыйгач!
Сөйлимче алай булгач:
Ник чиксез булсын диңгез,
Безнең йөрəккə сыйгач?!

Дөрес, суы бозлана,
Безнең тирдəн тозлана;
Ни өчендер, кояш та
Анда нурын кызгана.

Хезмəтме?
Авыр түгел,
Егетлəр камыр түгел:
Эремилəр, батмыйлар,
Сезне сөеп саклыйлар.

●

Чайкалудан туктый алмыйм
Диңгезлəрдəн чыгып кына,
Дулкынланган йөрəгемə
Акчарлаклар килеп куна.

Йөзеп йөрилəр кораблар,
Дөп-дөп басалар моряклар...
Инде күптəн даладамын,
Көшегез, көш, акчарлаклар!

Нигə генə алар һаман
Китми икəн күңелемнəн?
Əйтерсең лə мин бер дулкын
Океаннар киңлегеннəн...

Чайкаламын.
Сүнəр идем
Җилсез урында, рəхəттə;
Кайна, тормыш,
Давыл китер! —
Яшəү телим хəрəкəттə.

## Казанда

Агыйделдə туган дулкын булып
Килеп җиттем Идел ярына —
Казан утларына сөенешеп
Зур дулкыннар йөри янымда.

— Киңлеклəрдə үскəн зур дулкыннар,
Иəртегез олы диңгезгə!..
— Киттек, — диде алар, — мондаш булгач,
Юлдаш та бул, əйдə, син безгə.

# Егор Уткин



●

*Туган елым 1932.*

*Туган җирем — Алабуга районы Бөрешле авылы. Бала чагым Бөек Ватан сугышы елларына туры килгәнлектән, сигез-ун яшьләрдә ук инде ат җигеп, җирне «аз-маз тырмаларга» һәм көту көтәргә туры килде.*

*1951—1955 елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт иттем. 1955—1957 елларда Бондюг химия заводында моторист-компрессорчы булып эшләдем һәм шушы чорда эшче яшьләрнең кичке урта мәктәбен тәмамладым.*

*1957—1963 елларда Алабуга педагогия институтын читтән торып тәмамладым. 1958—1963 елларда район газетасында авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире булып эшләдем. Хәзер Алабуга районы Сәйтәк авылында сигезьеллык мәктәп директоры. Шул авылда пропагандист һәм партоешма секретаре вазифаларын да үтим.*

*Шигырьләрне 1958 елларда яза башладым. Авылда туып үскән һәм авылда яшәүче кеше буларак, төп темам бүгенге авыл тормышы һәм аның кешеләре.*

## Диңгездән дә тирән мәхәббәт

Ачык, якты йөзләр каршылады,
Читтән — димәк, кунак син безгә.
Хәйран калып йөрдең, бодай кырын
Чагыштырып шаулы диңгезгә.

Өстәп-ялгап кем дә тел какмады,
Шапырыну ул монда чит гадәт...
Кырда дулкын уйнатырга кирәк
Диңгездән дә тирән мәхәббәт.

## Яз иртәсе...

Таң алдыннан яңгыр үткәнгәме,
Үләннәрдә көмеш алкалар...
Кырны иңләп, яшел хәтфә сыман
Чәчкән игеннәрем калкалар.

Анам күңеле кебек юмарт кырым,
Беләм: хисем таныш күпләргә,
Ужымнарым күммәс тургайны да,
Ә башкаем тиде күкләргә.

Бер кузгалса, күңел дулкынлана,
Ташкын, дәрьяларга иш икән.
Ужым җирдән яңа калыкканда
Мин башаклар шавын ишетәм.

●

Кинәт килде дә
Кырлар өстенә
Коя чиләкләп,
Күгелҗем болыт.

Ана күкрәген
Тапкан баладай,
Шаулап утырган
Игеннәр тынып,
Җирдән дым эчә
Йотылып-йотлыгып.

●

Хәл кергәндәй була,
Сусаганда
Иренеңә тисә бер тамчы.
Кирәк чакта, җырым,
Кешеләргә
Шул бер тамчы су күк
Булсаңчы.

## Шофер җыры

Үзенә тарта ерак, кыен юллар,
Бер урында таш та мүкләнә.
Ак юл теләп, иркәм, һич югында
Гадәтеңчә, тот та үпкәлә.

Шофер түгел, һич тә тынгы белмәс,
Юлдан туймас чегән булды яр
Дия күрмә. Сагынып көтеп алгач,
Очрашудан татлы нәрсә бар!

## Адымнар яңыйлар...

Хәтердә бомбалар шартлыймы,
Сискәнеп уянам йокыдан.
Кулларым бишеккә үрелә,
Ирексез бишеккә тотынам.

Ятимлек ачысын татыган
Күңелләр тынычлык тапмыйлар...
Боннда бит палачлар яңадан,
Яңадан маршта атлыйлар.

Аларның адымы күңелдә
Туплардай ярыла ухылдап.
Һәр баскан адымда яңгырый:
Майданек,
            Освенцим,
                        Бухенвальд.
Юк, аяк тавышы түгел ул,
Иңри күк аналар, сабыйлар...
Кешеләр!
        Сак,
            уяу булыгыз!
Адымнар
        яңыйлар,
                яңыйлар.

*Самат Шакир*

# «БЕЗНЕ ОНЫТМАСЫННАР ИДЕ»

Соңгы елларда «Дружба народов», «Новый мир», «Совет әдәбияты» журналларында һәм рус, татар, башкорт, украин, мари, чуваш, казакъ телләрендә чыга торган газеталарда патриот шагыйрь Х. Мөҗәй турында материаллар басылды. Эзләнү, материаллар туплау дәвам итә. Нәтиҗәдә, Х. Мөҗәйнең немец тоткынлыгындагы көрәше турындагы мәгълүматларыбыз да торган саен тулылана, байый бара. Күптән түгел Мәскәү өлкәсенең Серпухов шәһәре янындагы Шахлово авылында яшәүче элекке хәрби әсир Шахов Василий Михайловичтан хат килде. Ул үзенең хатында Х. Мөҗәйне якыннан белүен, аның белән Моосбургта һәм Дахауда очрашуларын язган. Хатын ул түбәндәгечә дәвам итә:

«Мөҗәһит Хәйретдиновны мин Дахау концентрацион лагеренда бергә булган вакыттан бирле яхшы беләм. Безне бу лагерьга 1944 елның апрелендә Моосбургтагы хәрби әсирләр лагереннан китерделәр. Без Мөҗәһит белән бергә «Кибель команда»да эшләдек. Бу команда баракларга кара бурда (берникадәр кофе салынган) һәм чөгендер салып пешерелгән апара — баланда ташый иде. Безнең киемнәрнең аркасына зур кызыл хәреф белән «R» (рус) дип язылган. «R» хәрефе язылган тоткыннарны лагерьдан читкә чыгарып эшләтмәскә һәм башка бараклардагы тоткыннар белән аралаштырмаска, гомумән, каты күзәтү астында тотарга, дип Мюнхен гестапо начальнигы боерык биргән иде.

Мөҗәһит Хәйретдинов подполковник Михаил Шихерт белән бик дус булды, алар безне гитлерчы палачлар алдында куркып калмаска, тез чүкмәскә, соңгы сулышта да Ватанга турылыклы булырга өндәделәр һәм рухландырдылар. Бу ике офицер кызыклы, тарихи вакыйгалар сөйләделәр. Мөҗәһит берникадәр акцент белән сөйли, ләкин аның сөйләгәннәре безгә көчле тәэсир итә иде.

Бер көнне милләте буенча чех булган бер тоткын, лагерь режимына чыдый алмыйча, электр тогы җибәрелгән чәнечкеле тимер чыбыкка ташланып үлгән. Мөҗәһит моны күргәннән соң баш киемен салып, бераз сүзсез торды да:


— Мондый үлем белән һәркем үлә ала. Ә менә дошманга каршы көрәшеп үлү — моны бары тик көчле кешеләр һәм үзләренең эшләренә ышанган кешеләр генә булдыра ала! — диде.

Владимир Тельманов дигән политик тоткын Сергей Есенин шигырьләрен күңелдән белә иде һәм ул аны Мөҗәһит Хәйретдиновның соравы буенча бик еш сөйләде. Владимир шагыйрь Есенин шигырен сөйләгәндә Мөҗәһитнең бик дикъкать белән тыңлап торганы әле дә хәтеремдә...

Мөҗәһит Ватанны җаны-тәне белән ярата, шуның өчен һәрвакыт Ватан турында сөйли һәм горурлана иде.

Гестапо яңадан тикшерү эшләре башлагач, Мөҗәһитне ике тапкыр сорау алуга чакырдылар. Аннан ул бик каты кыйналып кайтты. Без барыбыз да көрәштәш дустыбызга ярдәм күрсәтергә тырыштык. Гестапочыларның ерткычларча җәзалауларына карамастан, ул рухын төшермәде, һәрвакыт үзен көчле һәм нык тотты...»

Менә икенче конверт. Ул Х. Мөҗәйнең туган авылы — Башкортстан АССР, Туймазы районы, Төрекмәннән килгән — Х. Мөҗәйнең туганы Хажуафа апа Мәскәүдәге Ватан сугышы ветераннары комитетыннан үз адресына килгән бер хатны җибәргән.



М. Хәйретдинов концлагерьда.

Анда «БСВ» җитәкчеләренең һәм членнарының үлемсез эшләре, Ватан алдындагы бурычларын намус белән үтәүләре һәм фашист ерткычлар тарафыннан җәзаланулары әйтелә.

«Ватаныбызның даны һәм бәхете өчен гомерен биргән Мөҗәһит Хәйретдиновны без бервакытта да онытмабыз!» — дип язганнар һәм сугыш ветераннары комитетының тапшыруы буенча Вихорев, Левин, Серов, Егоров, Секрета, Артамонцевлар кул куйган.

Шушы хәбәрләр-хатлардан соң, мин яңадан Мәскәүгә киттем. Поездлан төшү белән, туп-туры Ефим Аронович Бродский квартирасына юл тоттым. Ул миңа Мюнхен концлагеренда фашизмга каршы төзелгән яшерен оешманың киң колач белән эш алып баруын яңа табылган документлар һәм фоторәсемнәр белән тулыландырды.

Мөҗәһит Хәйретдиновның 1942—1943 елларда Мюнхендагы офицерлар лагеренда интегүе безгә билгеле иде. Мюнхен зурлыгы ягыннан Германиядә өченче урында торган промышленность шәһәре була. Сугыш кораллары эшли торган заводлар, хәрби полигоннар һәм җир асты аэродромнары күп монда. Гитлерчылар оккупацияләгән зонадагы Совет гражданнарын Мюнхенга куып китергәннәр һәм авыр эшләрне башкарырга мәҗбүр иткәннәр. Хәрби заводлардан читтәрәк, Штадельгейм төрмәсе һәм иске зират арасындагы Шванзеештрассе урамында хәрби әсирләр өчен лагерь төзелгән. 1941—42 елларда әсир ителгән рус офицерларын лагерьга китереп япканнар. Фашистлар лагерь урнашкан урамны «Аккош күле» (Шванзеештрассе — Аккош күле) дип атасалар да, чынында, бу мәет иске аңкып торган күңелсез, пычрак урамнарның берсе булган. Лагерьда көн саен дистәләрчә әсирләр ачтан үлгәннәр.

Коточкыч авыр шартларда яшәсәләр дә, әсирләр үзләренең Ватан алдындагы бурычларын намус белән үтәгәннәр. Немецларга эшләүдән баш тартканнар, фашистик плакатларны ерткаинар, гестапочыларга сатылучыларны үтергәннәр... Совет офицерлары кайбер көннәрне гитлерчыларның котын алып, кумәк рәвештә «Изге сугыш» җырын җырлаганнар. Фашистлар үзләре өчен үлем маршы булган бу җырны кемнәр җырлавын белергә теләп, лагерьда берничә тапкыр тикшерү ясыйлар, ләкин «гаепле» кешеләрне таба алмыйлар.

Журналыбызның 1965 елгы 2 санында Мюнхенда совет офицерларының «БСВ» дигән коммунистик оешма төзүләре һәм фашизмга каршы көрәшүләре әйтелгән иде. Шулай ук тарих фәннәре кандидаты Ефим Аронович Бродскийның Берлин һәм Мюнхен архивларыннан «БСВ» оешмасы турындагы кайбер материалларны табуы һәм копияләрен алуы турында да язылган иде. Бу документ «Б С В»ны ф а ш и т у» дип атала. Ул Мюнхен шәһәренең гестапо начальнигы штандартенфюрер СС Освальд Шефер тарафыннан язылып, Германия империясе куркынычсызлык саклау баш идарәсе начальнигы Эрнст Кальтенбруннерга адресланган. Материал шактый калын, ул немец телендә булып, машинкада басылган һәм яшерен рәвештә Берлинга җибәрелгән.

Яшерен «БСВ» оешмасы җитәкчеләре кушаматлар белән йөргәннәр. Гестапочылар бу кушаматлар астында кемнәр яшеренеп ятканын белергә тырышканнар. Соңга таба, бик күп эзләнүләр аркасында, кайбер мәгълүматларны алуга да ирешкәннәр.

Гестапо эш кәгазьләрендә бу турыда болай дип язылган:

«Оешманы полиция ача алмасын яки эшне кыенлаштыру өчен, Корбуков һәм Винниченко тәкъдиме белән, «БСВ» членнары барысы тик алдан билгеләнгән подпольный кушаматлардан файдаланганнар. Шушы кушамат исемнәр оешманың рядовой членнарына билгеле булырга тиеш табылган. «БСВ» членнары түбәндә күрсәтелгән подпольный кушаматлар белән йөргәннәр:

1. Роман Петрушель: Федотов, Мученик, Знаменов, Саша.
2. Иван Коненко: Николай Костров, Минин.
3. Мөҗәһит Хәйретдинов: Самсон.
4. Мария Кузькина: Чайка.
5. Константин Яров: Захаров, Костриков.
6. Константин Моисеенко: Константинов, Советов.
7. Алексей Мартыненко: Шахов, Май.
8. Иван Корбуков: Кречет, Иван Семенович.
9. Савелий Батовский: Буревестник.
10. Алексей Кириленко. Музыкант.
11. Борис Яжемский: Борис Келесов.
12. Симон Перцов: Софийский...» [1]

Мөҗәһит Хәйретдинов, Михаил Шихерт һәм Константин Моисеенколар Гитлер режимын җимерү өчен төзелгән конспиратив оешмага Ватанга чын күңелдән бирелгән, Коммунистлар партиясе өчен үзенең җанын-тәнен кызганмаган кешеләрне член итеп алганнар һәм, аларның кайберләренә махсус задание биреп, лагерьдан качуны оештырганнар. Моның өчен алар немец антифашистларыннан файдаланганнар.

Бу турыда гестапочылар болай язганнар:

«Кастелянша Мария Герман, 1890 елның 26 мартында Глонда туган, үзенең ире Стефан Герман белән берлектә 1941 елның январеннан бирле Лондоннан бирелә торган радиотапшыруларны даими рәвештә тыңлаган. 1943 елның язында ул көнчыгышта эшләүче Мария Заброда белән танышкан һәм аңа системалы рәвештә Англия радиосы тапшыруларын җиткереп торган. Яров һәм Корбуковның кушуы буенча Заброда исә Виктор Басковның һәм 1920 елның 21 сентябрендә Винницада туган Павел Гладковның качуын тәэмин иткән. Бу әсирләр Шванзеештрасседагы хәрби әсирләр лагерьенда Михаил Шихерт һәм Мөҗәһит Хәйретдинов тарафыннан «БСВ»га член итеп алынганнар. Шул максат белән Мария Заброда Корбуковтан алган штатский киемнәрне базда саклаган. Әсирләрне уңышлы качырганнан соң, Заброда аларга акча һәм азык товарлары карточкасы биргән һәм Корбуковка китергән. Берничә көннән соң, Дахау шәһәрендәге чит ил эшчеләре өчен булган лагерьның вәкиле Константин Моисеенко аларны эшкә урнаштырган» [2].

Совет патриотлары белән турыдан-туры элемтәгә кереп эш итүчеләрдән берничәсе Карл Циммет, Ганс Гутцельман, Эмма Гутцельман, Георг Ярес һәм Карл Мервварт була. Бу антифашист көрәшчеләр Гитлер режимына каршы халык фронтының (АНФ) Мюнхен үзәген оештыралар. Шулай итеп БСВ һәм АНФ бергәләп фашизмга каршы кискен көрәш башлый. АНФ һәм БСВ исеменнән чыккан листовкалар гестапо кулына да килеп керә.

Фашизмга каршы көрәшкә чакырган листовкаларның, прокламацияләрнең кемнәр тарафыннан язылуын һәм халыкка таралуын белү өчен, гестапо палачлары әсирләрдән төрле методлар белән сорау алганнар. Рейхсфюрер Гиммлер һәм куркынычсызлык баш идарәсе начальнигы Кальтенбруннер конспиратив рәвештә төзелгән коммунистик оешма белән кызыксынганнар һәм аның эзенә төшү өчен бөтен чараларны кулланырга боерык биргәннәр.

Конспиратив оешманың яшерен эшләрен фаш итү, җитәкчеләрен һәм членнарын юкка чыгару өчен Мюнхен һәм Берлин гестапосында махсус бүлекләр төзелә. Шымчылар һәм провокаторлар биш ай буена казыналар... Ниһаять, шымчыларның күрсәтүе буенча гитлерчылар Иван Корбуковны кулга алалар һәм Мюнхен төрмәсенә утырталар. 23 декабрьда Гофманштрассе һәм Фюрстенридерштрасседа янадан 24 «БСВ»

---

[1] «Новый мир» журналы, 1964 ел, 6 сан.
[2] Шунда ук.

житәкчесе кулга алына. 12 январьда «БСВ»ның актив житәкчесе Константин Яровны төрмәгә утырталар. Озакламый коммунистик оешманың башка әшлекләре дә кулга алына. Алар арасында Карл Озолин, Иван Бугорчиков, Михаил Тарасов, Мөжәһит Хәйретдинов, Николай Баранов һәм башкалар була. Бу политик тоткыннарны, сорау алу өчен, Дахауга озаталар.

Дахау концентрацион лагереның элекке политик тоткыны, хәзер Германия Демократик Республикасында укытучы булып эшләүче Рудольф Зенф совет патриотларыннан сорау алу вакытында анда булган. Аның Германиядән Е. А. Бродскийга язган хаты буенча түбәндәгеләр билгеле:

Ин элек сорау алу өчен гестапочылар майор Озолинны, капитан Зингерны һәм лейтенант Моисеевны чакырганнар. Кыйнап сорау алганнан соң, аларны ярым үлек хәлләрендә баракка китереп ташлаганнар.

Рудольф Зенф 92 совет патриотының корычтай нык ихтыярлы һәм иң соңгы сулышларында да Ватанга турылыклы булуларына сокланып болай ди:

«Бу кешеләр башларын югары күтәргән хәлдә, чын кешеләрчә һәлак булдылар!»

Хәзерге вакытта исән калган хәрби әсирләр Вәли Бикташев, Сәгыйть Тажетдинов, Василий Шаховлар Мөжәһит Хәйретдиновның каты кыйналудан балтыр һәм беләк итләренең яргаланып бетүен, каш-керфекләренең утка өтелүен, кулының сынуын һәм тырнакларының кләшчә белән суырылган булуын әйтәләр. Ләкин ул, әнә шундый коточкыч җәзалар кичерсә дә, физик яктан бөтенләй гарипләндерелсә дә, йөрәге белән, жаны-тәне белән Коммунистлар партиясенә, Туган илгә турылыклы булып кала.

— Без Ватан өчен барысын да эшләдек. Үлгәндә дә партия һәм халык алдында йөзебез ак булачак... Безне онытмасыннар иде,— ди ул очрашуларның берсендә Сәгыйть Тажетдиновка.

Мөжәһит Хәйретдиновның дусты Владимир Тельмановны фашистлар бер генә кешелек тимер тартма эчендә, салкында тоталар, сорау алганда кулларын каерып сындыралар, башын стенага бәреп жәрәхәтлиләр. Ләкин ул сорауларга жавап бирү түгел, үзенең чын исем-фамилиясен дә әйтми (ул оешманың яшерен кушаматы белән йөргән).

Ачудан кызарган-бүртенгән палач резина таяк белән тоткынның аркасына суга һәм әче тавыш белән кычкыра:

— Фамилияң?!

— Исемең?!

Тоткын жавап бирми. Офицер зажигалкасын яндыра, папиросына ут кабызып ишекле-түрле йөри һәм тагын да гайрәтләнә төшеп, тоткынның яңагына сугып жибәрә.

— Әйт, исем-фамилияң кем?! — дип жикеренә палач, пистолетын селти-селти.

Тоткын соңгы көчен жыеп таш идәннән тора да:

— Минем исемем — Владимир! Фамилиям — Тельманов! — ди.

Сорау алучы эсэс офицерлары куркышып бер-берсенә карашалар һәм өерләре белән тоткынга ташланалар.

Яшерен оешма члены иң соңгы сулышында да Октябрь Социалистик революциясенең бөек юлбашчысы Владимир Ильич Ленин һәм Германия Коммунистлар партиясе житәкчесе Эрнест Тельман идеяләренә турылыклы була. Ул иң кыен вакытта да, каршына кырык үлем килгәндә дә үзен Володя дип, фамилиясен Тельманов дип атый һәм һәлак була. Фашистларның сорау алу кәгазьләрендә дә бу тоткын «Владимир Тельманов» дип язылган. Хәзергә кадәр аның чын исеме һәм фамилиясе ачылганы юк.

1944 елның 28 августында Дахау концентрацион лагерендагы меңнәрчә тоткыннарны зур мәйданга, кичке барлауга дип тезәләр. Башка тоткыннарны үз баракларына жибәргәннән соң, «БСВ» члennарын тимер рәшәткә белән әйләндерелгән 27 блокның 4 нче камерасына ябып куялар. Бу камера чын мәгънәсендә «таш капчык» була. Аның янына бер генә кеше дә якын килә алмаган. Бу камераны эсэс солдатлары һәм бүре токымыннан булган ун-унбишләп эт саклаган.

Гестапочылар 3 сентябрьдә 4 нче камерада утыручы тоткыннарга: «Иртәгә сезне икенче лагерьга күчерәбез»,— дип белдергәннәр. 4 сентябрьдә политик тоткыннарны лагерьның плацына тезеп куйганнар һәм көчле каравыл астында капкага таба алып




Дахау лагеренда 92 совет әсире атылган урынга куелган истәлек тактасы.

**киткәннәр. Политик тоткыннарның күпчелеге юл капчыкларын һәм иске-москы әйберләрен, ашамлыкларын үзләре белән алган булганнар. Алар лагерь мәйданында басып торган меңләгән тоткын иптәшләре белән төрле ишарәләр ясап хушлашканнар, кул изәгәннәр һәм якындарак булганнарга:**

**— Туганнар, безне онытмагыз... Без Ватанга турылыклы хәлдә үләбез,— дигәннәр.**

**Яралы һәм хәлсез тоткыннарны эсэсчылар автомат белән төрткәләп ашыктырганнар. Ин беренче сафта полковник Тарасов, комиссар Серебряков, подполковник Баранов, подполковник Хәйретдинов, подполковник Шихерт, майор Громов, майор Озолин һәм башкалар барган. Бу беренче төркем политик тоткыннар барысы 30 кеше булып, лагерь капкасыннан чыгу белән аларны крематорий һәм полигонга таба борганнар...**

**Кинәт автоматтан ату тавышлары яңгыраган. Ахырдан аларны крематорийда яндырганнар.**

**Данко йөрәкле бу баһадирларның үлемсез эшләре, мактаулы исемнәре калды. Аларны халык бервакытта да онытмас! Советлар Союзында һәм чит илләрдә яшәүче Мюнхен һәм Дахау лагерьларындагы элекке хәрби әсирләр бу үлемсез кешеләр турында истәлекләр сөйлиләр, хатлар язалар.**

**Менә Карл Редерның Е. А. Бродскийга язган хатыннан бер өзек:**

**«Мин 92 кешенең куркусыз рәвештә үлемгә баруын үзем күреп тордым.**

**Бу турыда мин бүген дә уйлыйм һәм минем күз алдыма кыю, батыр кешеләр килеп баса. Алар крематорийга тыныч һәм туры карап атладылар, ә тирә-якларында эсэс офицерлары өреп торучы этләр кебек, акырып-бакырып бардылар. Шунысы ачык, алар бу кешеләрдән куркалар иде... Бу көнне бер кеше дә эшләмәде. Бу батырларча һәлак булганнарны тавышсыз гына искә алу демонстрациясе иде».**

**Фашизмга каршы көрәштә үзләренең башларын салган патриотларның исемнәре, соңга калып булса да, ачыкланды һәм ачыклана бара. Ләкин кайбер фактлар һаман әле сер булып торалар. Чөнки Совет Армиясенең җиңүле рәвештә Германия территориясенә керә баруын күргән фашист җитәкчеләре үзләренең көннәре санаулы гына калганын сизгәннәр һәм Мюнхен, Дахау лагерьлары турындагы документларның күбесен яндырганнар.**

**Сугыштан соңгы еллардагы эзләнүләрдән соң табылган документлар һәм исән калган элекке хәрби әсирләр Мюнхен һәм Дахау лагерьларындагы совет офицерларының фашизмга каршы бик зур эш алып баруларын раслыйлар.**

# Сәнгать кешеләре

*Галим Рябков*

# ТЕАТР ЯШЬТӘШЕ

1921 ел.

Ашлыклар гына түгел, хәтта кыргый үләннәр дә көеп-янып беттеләр, эссе һавада өргән җан алгыч җилләр туфракны коргаксытып-киптереп бетерде ул елны. Кешеләргә, терлекләргә, кош-кортларга аз гына да ризыкланырлык әмәл калмады. Тәрәзәләренә такталар кадаклап, йорт-җирләрен ташлап, бик күпләр илнең төрле якларына, икмәклерәк җирләргә киттеләр. Фатих абзый Булатов та, семьясын ияртеп, Себер якларына юл тотты. Ләкин яшүсмер кызы Галиянең туган яклардан китәсе килмәде, Казанда партия мәктәбендә укучы апасы Зәйтүнә янында калды. Соңрак язмыш аларны Уральск шәһәренә китерде. Бу тукталыш Галия өчен шактый уңай туры килде. Ул Уральскида татар культура тормышында шактый зур роль уйнаган, яхшы җырчы булып танылган Камил Мотыйгый белән танышты.

Профессиональ театр белән дә ул беренче тапкыр Уральск шәһәрендә танышты. Ә шушы шәһәрдәге татар балалары йортына урнашуы аңа укуын дәвам иттерергә мөмкинлек бирде. Анда яхшы тәрбиячеләр, яхшы укытучылар бар, барысын да белергә омтылучы, матур хыяллар йөртүче романтиклар бар иде. Булачак композитор Нәҗип һәм булачак дирижер Садриҗәлал Җиһановлар белән тәрбияләнде ул. Галия Булатовага Уральск балалар йортында тәрбияләнүе киләчәктә артистка булып формалашу өчен зур этәргеч булды дисәк, ялгышмыйбыздыр...

Галия менә Казан шәһәрендә. Биредә ул Булатовлар семьясына электән таныш бер кешене очратты. Бу кеше соңрак «Шәмсекамәр» исемле гүзәл пьесаны язган Мөхәммәт Әблиев иде.

— Укырга керергә телисеңмени, Галия сеңелем?

— Артистка буласым килә.

— Быел театр техникумы ачыла. Студентлар җыя башладылар инде, — диде Әблиев, — иртәгә үк техникум директоры иптәш Баязитский янына кил, мин сине аның белән таныштырырмын. Театрның кайда икәнен беләсеңме? Бауман урамында. Рус драма театры бинасында булыр.

Мөхәммәт Әблиев биргән киңәшкә Галия бик шатланды. Ләкин имтихан бирүләре ничек булыр? Техникумга керергә аның белеме дә җитми торгандыр әле?

Галиянең төн йокылары качты, төрле уйлар белән буталып бетте ул: техникумны бетереп артистка да булып алды, сәхнәдә уйнады, кул чаптылар, чәчәк букетлары бүләк иттеләр, кулларын кыстылар, тәбрикләделәр. Шикләнүләрнең дә иге-чиге юк иде: ничек ул имтихан тотар, нинди сораулар биреп йөдәтерләр?



Галия техникумга директор белән очрашу өчен билгеләнгән вакыттан шактый элек килде. Көтәргә булса, вакыты да бит аның үтми — Галиягә дә бик озак көткәндәй тоелды. Ниһаять, кешеләр эшкә җыела башлады. Шау-шу, ыгы-зыгы китте. Директор да кабинетына таба узды кебек. Әнә, Мөхәммәт Әблиев та сүзендә торган: аның коридордан килгәне күренде.

Галияне кабинетка чакырдылар. Сүзне Әблиев башлады:

— Менә, иптәш Баязитский, таныш булыгыз, мин сезгә сөйләгән кыз шушы инде, — дип, Галияне директор белән таныштырды.

— Утырыгыз, Галия сеңелем,— диде директор, ягымлы тавыш белән.— Укырга теләгегез бар икән. Бик яхшы. Ләкин артист булу бик кыен нәрсә бит, сез моны беләсезме? Бу профессиягә теләсә кем лаек була алмый...

Галия Зәки Баязитскийның сөйләгәнен игътибар белән тыңлап утырды, аннары каушый-каушый җавап бирде:

— Тырышып карар идем, иптәш директор, әгәр дә укырга алсагыз...

— Алай булса, Галия сеңелем, — диде директор, сүзен дәвам итеп. — Техникумга алуны сорап гариза язгыз.

Мөхәммәт Әблиевның булышлыгы белән язылган гаризасын дирекциягә кертүе булды, Галияне имтиханнар бүлмәсенә чакыра да килделәр. Рус теленнән, математикадан имтихан алучылар аңардан канәгать була алмадылар. Ләкин бөтенләй өметне өзәргә иртәрәк иде әле. Актерлык осталыгы дигән фәннән дә сынау үтәргә тиеш иде ул. Нинди фән икән соң бу? Ул бу сүзне әле беренче тапкыр гына ишетә. Ә бактың исә, бу артист булу өчен төп фән икән. Бүтән фәннәрдән үтә алмаганны моннан ничек үтәсең ди!

Бик чибәр, бик мөлаем йөзле укытучы Зинаида Михайловна Славянова аңа шигырь укырга тәкъдим итте.

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул.
Авылыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңа күрә сөям җаным, тәнем белән...

Булачак укучының салмак чыккан көмеш тавышы, тирән мәгънә аңлаткан мимикалары һәм хәрәкәтләре, дикциясе имтихан алучыга ошады булса кирәк. Моны укытучының ачык йөзеннән, эчке дулкынлану белән хуплап утыруыннан күрергә мөмкин иде. Бу хәл Галиянең күңелен күтәреп җибәрде.

Аннары Славянова Галия Булатовага көзге янында бизәнеп утырган кызны пантомима ярдәмендә күрсәтеп карарга кушты. Моны эшләгәч, укытучы тагын бер тема бирде:

— Бер хатын-кыз көянтә-чиләкләрен асып килде дә коедан су алып китте, ди. Бу тема нинди хәрәкәтләр таләп итәр — шуны эшләп күрсәтегез, — диде ул.

Галия моны да шактый осталык белән башкарды кебек. Славянова тыйнак адымнар белән Галия янына килде һәм булачак укучының маңгаеннан үбеп алды.

— Актриса булырга сәләтең бар, сеңелем.

Галия музыкадан имтиханны ул чакта ук инде танылып өлгергән композитор Салих Сәйдәшевка бирде, танецлар буенча Юлий Муко дигән укытучы алды. Әлбәттә, Галия өчен бу фәннәрдән дә имтихан бирүләре җиңел булмады. Ләкин табигый сәләт барлыгын, талантның ачылырга тиешлеген тоеп, бу укытучылар да аның техникумга алынуына ярдәм иттеләр.

Әнә шулай, 1923 елның мартыннан башлап, Галия Булатова театр техникумының студенты итеп алынды.

Тырышып укыды ул: уку программасыннан тыш, махсус әдәбиятны күзәтеп барды, сәхнә осталары турындагы мемуар әдәбият белән кызыксынды. Өлгерлеге, кешеләргә мөнәсәбәттә игътибарлы булганы өчен аны иптәшләре ихтирам иттеләр. Халыкка сәнгать хезмәте күрсәтү эшләрендә актив катнашты, предприятиеләргә барып, эшчеләр арасында концертлар белән чыгучы артистлар исемлегендә аның фамилиясен дә еш кына күрергә мөмкин иде. 1923 елның Сабан туенда үткәрелгән бер концертта яхшы биегәне өчен аңа бүләк тә бирделәр.

1923 елның март аенда Галия тормышында бер зур вакыйга булды. Татар академия театрында Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр палас» исемле пьесасын куярга әзерләнәләр иде. Репетиция бара. Практикант студентлар сәхнәдә берсен-берсе алыштырган күренешләр, вакыйгалар белән кызыксынып, тикшеренеп утыралар. Режиссер Тинчурин студентлар янына килде: әсәрдә Зәнҗәфиль ролен башкару өчен кеше кирәк икән. Кәрим ага иң элек Галиягә мөрәҗәгать итте:

— Миңа сезгә, сеңелем, бик шәп роль бирәм. Өеңә кайтып, текстны яхшылап өйрән. Аннары образның детальләре турында бергәләшеп уйларбыз. Рольгә керә алсаң, бүтән чакларда да рольләр бирербез.

Шатлыгыннан өенә кайтып җиткәнен сизми дә калды Галия. Бии-бии кайтты ул. Театрның художество җитәкчесе үзе шундый ышаныч белдергәч, ничек шатланмыйсың ди!

Булачак актрисаның «Зәңгәр палас» спектаклендә башкарган роле Кәрим Тинчуринга ошады һәм ул үз вәгъдәсендә торды: Галияне еш кына кечерәк-кечерәк рольләр уйнарга чакыра торган булып китте. Бу исә чынында Галия Булатованың атаклы драматург, зур актер һәм режиссер белән җитди дуслыгының башланып китүе иде. Соңыннан ул Татар дәүләт академия театрында берничә еллар буе Кәрим ага Тинчурин белән бергә эшләде.

Бер уйлаганда актриса булып формалашу процессы бик җиңел бара кебек: уку да практика үтү. Ләкин җиңү бер вакытта да җиңел генә булмый бит, кыенлыклар, мәшәкатьләр чыгып кына тора. Футурист яшьләрнең сару кайнатулары гына ни тора бит! Әле дә күз алдында: тимерче күрәгенә охшашлы ала-кола зур кепка кигән, чүмәлә кебек чәчләре иңбашларына кадәр салынып төшкән, шакмаклы күлмәген нечкә каеш белән буган, муенына ефәк кашнә ураган, тездән аз гына түбән төшеп торган кыска һәм тар штанлы бу егетне кем дип белерсез? Футуризмның тышкы ягын гәүдәләндерүче булыр бу, ә эчке ягына килгәндә исә, ул — делетант.

Тарих бик яхшы белә: революциянең беренче елларында буржуаз культураның совет сәнгатенә зарарлы йогынтысы үзен шактый сиздерә иде әле. «Сәнгать — сәнгать өчен» теориясе белән исереп, чын тормышны чагылдыру идеясеннән читкә тайпылган декадентларны, формалистларны оешу ягыннан да, идея ягыннан да фаш итәргә һәм тар-мар китерергә кирәк иде. Безнең партиябезгә бу юнәлештә дә гаять зур эш башкарырга туры килде.

Татар театр техникумында укучы яшьләр арасында да эчтәлекне инкарь итеп, форма артыннан гына куучылар юк түгел иде. Алар укырга, сәнгатьне дөрес аңларга комачаулый иде. Әлбәттә, андый шарлатанлык Галия Булатовага да ошамый иде.

— Ничек инде бу болай? Ясалма күренешләр, кирәкса-кирәкмәсә дә югары интонацияләр, абстракт геройлар, символик образлар... Тормыштан читләшү була түгелме соң бу?

Әйе, сәнгать чын тормыштан аерылганны һич яратмый, шунлыктан художник иң элек безнең социалистик чынбарлыгыбызны иҗади өйрәнергә, үз замандашларын белеп яшәргә тиеш. Станиславский әйтмешли, чорны аңларга, алай гына да түгел, шул чорның актив кешесе булырга кирәк. Бу хакыйкатьне Галия бик яхшы аңлады. Иҗади эзләнүләр, үз чорының кешеләре белән иң актив аралашу, тормыш тәҗрибәсенә, сәхнәдәш мастерларның киңәшләренә мөрәҗәгать итү — яшь актрисаның эшчәнлеге шул нигездә иде. Сәнгать мәсьәләләре буенча коммунистлар партиясе карарларында бирелгән күрсәтмәләрдән, реализм мәктәбенең өйрәтүләреннән ул рух күтәренкелеге, идея азыгы алды. «Совет актеры үзенең кешелек сыйфатлары ягыннан сәхнәгә күтәрелгән яңа герой белән тиңдәш булырга тиеш. Бары тик шул чакта гына

ул совет кешесенең матурлыгын, характер гүзәллеген, мораль сыйфатларын, дәүләтчә фикер йөртә белгәнлеген дөрес һәм тулы чагылдыра алыр», — болар Галия өчен буш фразалар түгел, бәлки иҗат таләбе иде.

■

Булатова — драматик пландагы актриса, зур талант иясе. Кырык ел буена бер өзлексез сәхнәдә уйнавы белән ул үзен халкына лаеклы актриса итеп танытты, хәтердә озак саклана торган гүзәл образлар иҗат итте.

Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә 1929—30 елларда Гадел Кутуйның «Җавап» исемле пьесасы күрсәтелде. Анда Фатиха ролен яшь артистка Галия Булатова башкарды. Постановканың премьерасын караганнан соң, атаклы шагыйрь Һади Такташ шундый юлларны язды:

«Йөрәк хисләренә бай Фатиха ролендә уйнаган Булатованың йөрәге аркылы үткән хисләр белән тышкы хәрәкәтләренең кушыла баруы, бу көнгә кадәр иң күренекле артистларыбыз бирә алмаган табигыйлекне, осталыкны күрсәтте. Быелгы сезонда Булатова картларга алмашка килгән көчле бер талант булып күренә...»

Художникның яше еллар белән түгел, бәлки аның кешелек дөньясына биргән иҗат хәзинәләре белән билгеләнә. Моны безнең Галия Булатова үткән иҗат юлындагы бик күп факторлар да ачык раслыйлар. Вакыт узган саен Галия ханым иҗат иткән образлар саны да арта барды. Ул совет тамашачысын берсен берсе кабатламый торган төрле характерлар, төрле заман кешеләре белән таныштырды. Яшь актриса — үзе дә совет сәнгате белән бергә үсте, хаклы рәвештә үз замандашларының мәхәббәтен һәм ихтирамын казанды, ә Шәмсекамәр образы тугач, аңа инде Татарстанның атказанган артисткасы дигән мактаулы исем бирелде.

Әйе, Шәмсекамәрне без яхшы беләбез, чөнки ул безнең арабызга кереп, бик тиз иялəшеп алды, хәтта аны «Шәмсекамәр апа» дип йөртә башладылар.

Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә драматург Мөхәммәт Әблиевнең «Шәмсекамәр» исемле пьесасының беренче спектакле 1937 елда куелды. Бу драма тамашачы тарафыннан бик тиз танылды һәм бер ел вакыт эчендә сәхнәдә 50 тапкыр уйналды. Шул ук елларда бу драма Башкортстан сәхнәләрендә дә зур уңыш белән барды.

«Шәмсекамәр» драмасы революциягә чаклы татар авылында тормыш упкынындагы хәлләрне күрсәтүгә, тамашачыны зур социаль каршылыклы авыл күренешләре белән таныштыруга багышланган. Элекке авыл турында тарихи дөреслекне исбат итәргә кирәк булса — һич тә икеләнеп тормыйча «Шәмсекамәр» пьесасындагы вакыйгаларны телгә алырга мөмкин: кулаклар, мулла-мунтагайлар кылган кабахәтлекләрне, дин, шаригать дигән булып, хатын-кызларны мыскыллауларны, урядниклар, стражниклар, старосталар тарафыннан эшләнгән гаделсезлекләрне санап та бетерә алмассың. Авыл сыкрана, авыл ыңгыраша...

Спектакльне караганнан соң алган тәэсирләре турында «Кызыл Татарстан» газетасының 1938 ел, декабрь аенда чыккан номерында бер эшче хатынның мәкаләсе урнаштырылган. Анда түбәндәге юллар бар:

«Бу спектакль миңа күп нәрсәне, барысыннан да элек патша вакытында хезмәт иясе татар хатын-кызының мәсхәрәле тормышын күз алдына китереп бастырды. Татар байлары, дин һәм иске гореф-гадәтләрне, халыкның караңгылыкта яшәвен үзләренә корал итеп алып, хезмәт иясе хатын-кызлар өстеннән теләгәнчә мыскыл иткәннәр... Спектакль миңа әнә шуларны күрсәтте.

...Бу спектакльне караганнан соң, мин үземнең бүгенге тормышымны, революциягә чаклы яшәгән хатын-кыз тормышы белән чагыштырып карадым да, үземнең иректә һәм бәхетле тормышым өчен тагын бер кат сөендем...»

Галия ханым башкаруындагы Шәмсекамәр безнең алга искиткеч тыйнак, эчкерсез, турылыклы, киң күңелле, эш сөючән хатын-кыз булып килеп басты. Шәмсекамәрнең поэтик образын, аның кичерешләрен, саф мәхәббәтен, дошманына ачы нәфрәтен Булатова кебек чагылдыра алган мастерлар әлегә бик аз. Шәмсекамәрнең яшәүгә сәләтлелеге артистка Булатова исеме белән дә бәйле.



Г. Булатова — Шәмсекамәр ролендә.

Актриса талантының отышлы яклары тагын шунда: ул үзе башкара торган геройның чорын яхшы өйрәнә, аның әсәрдә тоткан урынын дөрес билгели белә, социаль һәм политик якларына дөрес трактовка бирә һәм шулай ук колоритны, милли буяуларны саклый.

«Мин, — ди Галия Булатова 1938 елда матбугатта чыккан мәкаләләренең берсендә үзе иҗат иткән образ турында, — Шәмсекамәр образы аша, революциягә кадәр изелгән татар хатынының тормышын гәүдәләндердем. Хәзер бүгенге бәхетле чорыбызның бәхетле тормышында яшәүче ирекле хатын-кызларның героик образларын иҗат итәсем килә...»

Һәм Галия ханым бу теләген тормышка ашырды да. Бөек Ватан сугышы барган көннәрдә, 1944 елда, Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә драматург Мирсәй Әмирнең «Миңлекамал» драмасы күрсәтелә башлады. Үз вакытында бу әсәр һәм аның постановкасы Казан җәмәгатьчелегендә бик зур резонанс тудырган иде. Спектакльнең максаты бик ачык: илебез авыр сынаулар кичергән бер вакытта колхоз производствосында хатын-кызлар тоткан урынны күрсәтү, фронт белән тылның бердәмлеген, совет патриотизмының какшамас куәтен тагын бер мәртәбә исбат итү.

Бик күпләрнең хәтерендә, ул вакытларда авылдагы төп эшләрне нигездә хатын-кызлар башкардылар, җитәкче эшләрнең дә күбесе алар кулында булды. Шул елларда республикабызда 300 дән артык хатын-кызның колхоз председателе булып эшләгәнен искә төшерү дә Бөек Ватан сугышы елларында аларның тоткан урыннарын ачык күрсәтә.

Пьесаның төп герое — Миңлекамал Сәфәргалиева «Яшел алан» колхозында председатель булып эшли. Миңлекамал сугыш нәтиҗәсендә хуҗалык ягыннан шактый какшаган бу колхоздагы хәлләрне белеп, җитәкчелек эшенә үз теләге белән килә. Эш көчләре җитешми, хезмәт дисциплинасы бик йомшарган, кыскасы, кая карама, шунда — өзеклек. Ләкин Миңлекамал үз көченә нык ышана: колхозны авыр хәлдән чыгарачак ул, моның өчен аңарда энергия дә, түземлек тә җитәрлек.

Галия Булатова Миңлекамалның авыр кичерешләрен сәнгать осталыгы белән, тамашачының хәтерендә озак саклана торган итеп чагылдырды. Аның башкаруындагы Миңлекамал чын-чыннан колхоз вожагы, таләпчән, ләкин бик гадел җитәкче, эчке дөньясы бай кеше булып гәүдәләнә. Сүзне Миңлекамал ролен башкаручының үзенә бирик. «Азат хатын» журналында чыккан бер мәкаләсендә ул болай дип язды:



Г. Булатова — Миңлекамал ролендә.

«Образны тудырырга бер вакыйга ярдәм итте. Авылдан сеңелем кунакка килде. Ул балалар укыта. Чәй алдында ул авылда ничек итеп ирләр эшен башкарганын..., дәүләткә икмәк бирү өчен колхозчылар арасында ничек итеп эш алып баруларын сөйләп китте... Колхозда хезмәт дисциплинасы урнаштыру аңа ничек авыр булган: вакыты белән аңа бик ягымлы да, вакыты белән бик усал да булырга туры килгән... Ул, чалгы күтәреп, басуга — иген җыярга китә. Кышларын утын кисә, халык арасында ел буе аңлату эше алып бара...

Мин аны кочып алдым:

— Син — Миңлекамал, туганым! Әйе, коммунист Миңлекамал!

Менә шуннан соң икенче көнне үк мин героемны репетициядә ачык итеп күрсәтеп бирдем... Спектакльне колхозчыларга күрсәткәндә, тәнәфес вакытында бер төркем колхозчылар йөгереп килделәр дә:

— Бу безнең председатель ич! — дип упладылар».

Татарстанның атказанган артисткасы Галия ханым Булатова иҗатында Миңлекамал образы бер баскычка югары күтәрелү булды. Нәкъ менә шуннан соң, Миңлекамал образы безнең белән бергә яши башлады. Галия Булатовага, шул образны уңышлы башкаргач, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Указы белән республиканың халык артисткасы дигән мактаулы исем бирелде.

Татар совет театры сәхнәсендә Галия Булатова иҗат иткән образлар аз түгел дигән идек. Ләкин эш азлыкта да, күплектә дә түгел, бәлки образларның калку итеп чын сәнгатьчә башкарылуында, аларның бер-берсен кабатламауларында — сәхнә мастерына шуннан чыгып бәя бирелә.

Н. Исәнбәтнең «Зифа» һәм «Рәйхан» әсәрләрендә төп геройлар ролендә Галия ханым Булатова уйнаганын тамашачылар әле дә хәтерлиләрдер.

Булатова башкаруындагы Зифа образы гүзәл совет хатын-кызларының берсе буларак хәтердә кала, ул — мораль яктан югары, принципиаль кеше, намусына тап төшермәс һәм һәрвакыт дәреслек ягында торучы итеп бирелә.

Зифа һәм Рәйхан. Охшыйлармы алар берсе берсенә? Юк. Рәйхан белән Зифа язмышларында күп кенә уртак яклар булуга да карамастан, алар барыбер төрле характердагы, төрле юнәлештәге совет кешеләре.

«Рәйхан» драмасы сәхнәдә барган көннәрдә язучы Әмирхан Еники Булатованың уены турында болай дип язган иде:

«Әйе, Галия Булатова Рәйхан ролен тирән, эчке эмоциональ көч белән башкара. Ихтыяр көче, акыл һәм йөрәк җылысы сизелеп тора аның Рәйханында... Әмма бу соңгысын сиздерүдә ул артык юмартланмый һәм бу бик табигый да. Чөнки кыска гына вакытка булса да ике ир арасына баскан хатын бик зур такт күрсәтә белергә тиеш. Булатова, чыннан да, менә шул тактны күрсәтә белә, ул акылы белән генә түгел, йөрәге белән дә Гәрәй ягында...»

Кырык ел буена дәвам иткән иҗат юлында Галия Булатова бик күп образлар иҗат итте. Рус һәм чит ил драматургиясе үрнәкләре белән татар тамашачысын таныштыруда да аның роле зур. Мәсәлән, А. Островскийның «Бүреләр һәм сарыклар» пьесасыннан Глафира, «Соңга калган мәхәббәт»тән Людмила һәм «Гаепсездән гаеплеләр»дән Кручинина, В. Сотконың «Тормыш яңадан башлана» спектаклендәге Грета Норман образларын тамашачы әле дә хәтерли торгандыр. Алар һәммәсе дә актрисаның иҗат эшчәнлегендә лаеклы урын алдылар.

Шекспирның «Король Лир» трагедиясеннән Регана, Мона Брэндның «Килен кайтты» дигән пьесасыннан Лола, Назыйм Хикмәтнең «Мәхәббәт хикәясе» исемле әсәреннән патша Мөһминә-Бану рольләрен башкарганда да артистка Булатованы сәхнәдә күреп дулкынланмау мөмкин түгел иде.

Галия Булатова Г. Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театрының иң талантлы актерларыннан берсе. Ул театр белән бергә талантлы сәхнә мастерлары семьясында тәрбияләнеп үсте, сәнгатьнең югары үрләренә күтәрелде, татар театр сәнгатен үстерү юлында үзеннән лаеклы өлеш керткән һәм әле дә гүзәл хезмәтен дәвам итә торган талант иясе булып танылды. Татар әдәбиятының һәм сәнгатенең Мәскәүдәге декадасы вакытында Совет хөкүмәте, совет сәнгатен үстерүдәге гүзәл хезмәтләрен исәпкә алып, аңа Россия Федерациясенең халык артисткасы дигән мактаулы исем бирде. Ә 1950 елда ул Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнгән иде.

Актриса әле дә зур иҗади планнар белән яши, театр сәнгатенең үткәннәре, бүгенгесе һәм киләчәге турында уйлана. Аңа, театр ветеранына, бу юнәлештә эш муеннан. Сәхнә аның туган йорты кебек. Быел татар театры үзенең 60 еллык юбилеен билгеләп үтә — бу актриса өчен икеләтә бәйрәм, чөнки быел аның үзенә дә 60 яшь тула бит.

Күп санлы тамашачылар, барлык культура җәмәгатьчелеге һәр ике бәйрәм белән дә аны чын күңелдән котлыйлар һәм яңа, зур иҗат уңышлары телиләр.

Халыкара эшчеләр хәрәкәтенең гүзәл эшлеклесе Клара Цеткин белән әңгәмәсе вакытында бөек Ленин болай дигән иде: «Сәнгать — халыкныкы. Аның тамырлары бик тирәнгә, хезмәт иясе халкының киң массаларының калын катлавына үтеп керергә тиеш. Ул шушы массалар аңларлык һәм яратырлык булырга тиеш. Ул шушы массаларның хисләрен, фикерләрен һәм ихтыярын берләштерергә, аларны югары күтәрергә тиеш». Халык артисткасы Галия ханым Булатова үзенең бөтен тормышын, талантын, бөтен йөрәк җылысын әнә шуңа, дәһи юлбашчыбызның әнә шул идеяләрен тормышка ашыру өчен көрәшкә багышлады, һәм ул хәзер дә шул идеяләр белән яши, иҗат итә.

*Гариф Гобәй*

# Коръән серләре

5

### АЛЛА АЛДАДЫМЫ, СИНМЕ?[1]
### «БЕЗ СЫНАР ӨЧЕН ГЕНӘ СЕЗНЕ ҖИҢЕЛҮГӘ ДУЧАР ИТТЕК».
### КҮГӘРЧЕНЕҢ БУЛСА...
### САДАКАҢНЫ САЛЫП СӨЙЛӘШ.

Мөхәммәт тирә-юньдәге вак кабиләләрне шул рәвешчә дингә «өндәп», иман китермәгәнен кылычтан үткәреп, йорт-җирләрен талап йөргән арада Бәдер сугышында хурлыклы җиңелеп кайткан Мәккә канлы үч алуга әзерләнә. Үч — бер хәл, әле тагын ул явызның ныгып китеп, Сирия юлын бөтенләй бикләп куюы бар бит... Шуңа күрә бу сугышка бае-ярлысы, бөтен Мәккә, хәтта ирләре Бәдердә һәлак булган 15 хатын, шул җөмләдән Әбү-Суфьян хатыны Хенда да катнаша. Әбү-Суфьян өч мең кеше туплап, барабаннар кагып, быргы уйнатып килә Мәдинә өстенә. Мөхәммәтнең гаскәре бу вакытта әле нибары меңгә якын.

Ислам лагере куркуга төшә.

Ә пәйгамбәр нык. Кыю. Тәвәккәл. Оборона чараларына керешә. Сәхәбәләрне дәртләндерү теләге белән алласы исеменнән тиешле вәхи дә әвәләргә өлгерә:

«Әгәр сезнең арагызда 20 чыдам бәндә булса, 200 не җиңеп чыгар. 100 чыдам меңне җиңәр».

(*Коръән, «Табыш» сурәсе, 66—67 аятьләр.*)

Булыр микән?.. Ислам гаскәре сугышка керергә ашыкмый. Менә шунда инде Мөхәммәт тиз генә мондый вәхи игълан итә:

«Алла сезгә ярдәмгә 5 мең фәрештә җибәрер. Аларга таныклык билгеләре тагылган булыр».

(*Коръән, «Гыймран» сурәсе, 121 аять.*)

Юк, күрәсең, кайберәүләр монысына да ышанып бетми.

— Бәдер сугышында да шулай диган идең син, фәрештәләр ярдәм итәр диган идең, берсе дә күренмәде.

Яңа вәхи:

«Алла беркайчан да (хәтерләп калыгыз: беркайчан да) мөэминнәргә каршы килгән кяферләрнең юлын уңышлы итмәячәк».

(*Коръән, «Хатын-кызлар» сурәсе, 140 аять.*)

Ләкин, күрәсең, күктә башка мәшәкатьләр килеп чыга, алла вәгъдәсен оныта, ислам гаскәренә ярдәмгә 5 мең түгел, әчмухе фәрештә дә җибәрми. Мәккә кяферләре бу юлы пәйгамбәр гаскәрен тар-мар итеп кайтып китәләр.

Мөселманнарның гайрәте кайта. Һәркемнең күңеле төшенкә. Кыюраклар Мөхәммәтнең күзенә терәп әйтә:

---

[1] Башы 1, 2, 3, 4 саннарда.

— Әйт, пәйгамбәр, алла алдадымы, синме? Ярдәмгә 5 мең фәрештә килә дигән идең бит син...

— Алла, беркайчан да кяферләрдән җиңдертмәм, дип әйтте дигән булдың әле тагын...

Мөхәммәтнең акланыр әмәле юк, шулай да ул алла исеменнән иреннәрен бер лепелдәтеп куя:

«Җиңелүегезгә кайгырмагыз. Әгәр бүген җиңелгәнсез икән, алар элек җиңелде. Без вакыйгаларны үзебез шулай үзгәртеп торабыз. Без моны кяферләрне һәлак итү, ә сезне сынау өчен эшлибез... Сезнең чыдаммы-түгелме икәнне белми торып, без сезне ничек җәннәткә кертик ди инде... Без сезне сынар өчен генә җиңелүгә дучар иттек».

*(Коръән, «Гыйимран» сурәсе, 133—136, 146 аятьләр.)*

Сабый балаларны юатамыни!.. Төшенеп бетмәгәннәрдер, югыйсә, нинди сынау инде ул тагын? — диярләр иде.— Шул хәтле кеше суештырып сынамаса, бөтәнчә белми мени ул? — диярләр иде.— Сынамыйча белми торган булгач, нигә син аны кырмыска күңелендәген дә белә дип, мактыйсың соң? — диярләр иде. Тагын менә нәрсә әйтер иде алар. «Вакыйгаларны үзгәртеп торабыз» булгач, бу суелышның очы-кырые булмас бит, агаене,— диярләр иде... Күрәсең, мөселманнар төшенеп бетмәгәннәр.

Бу сугышта Мөхәммәт үзе ансат котыла, берничә бөртек сакал шәрифен йолкып өзәләр дә, бер ярым мөбарәк тешен сугып сындыралар... Ә сәхәбәләр яман күп кырыла. Үлек белән тулы Мәдинә кырында ятим калган хатыннар, бала-чагалар арадан әтиләрен эзләп йөриләр. Күз яше, чәч йолкып үкереш. Сыкрашып яткан яралыларга ярдәм күрсәтеп өлгерү мөмкин түгел... Мөхәммәтнең әтисе белән бертуган Хәмзә батыр, мәшһүр сугыш чукмары, соңгы сулышын биреп ята... Хатыны, балалары елашып аның өстенә капланган. Менә аның баш очына Мөхәммәт килеп тезләнә. Иреннәрен тешләгән. Бөтен гәүдәсе дер-дер килә.

Хәмзә җиденче кат күктә хәзер, ул хәзер алланың арысланы, — ди пәйгамбәр һәм тирә-ягында үлеп ятканнарга күз йөртеп чыга да, дәвам итә.— Шәһадәтлек кылам: бу үлекләр, шулай ук алла юлында һәлак булдылар. Алла юлында һәлак булучы һәркем кыямәт көн алла хозурына дан белән килер. Аларның тән яралары, патшалар киеме кебек ялтырап, мускус кебек хуш ис аңкытып торыр...

Ахыр чиктә дулкынланган, үз чире кузгалырга торган минутларында Мөхәммәтнең илһамы әнә шулай аеруча көчле чәчәк ата. Менә ул торып баса...

«Әй мөселманнар! — ди ул үзенең көр тавышы белән.— Алла юлында үлгәннәрне үлгән санамагыз. Юк, алар тере. Алар инде алла хозурында. Үзләренә тиешле бүләкне алды инде алар. Алар өчен курку, хәсрәт чигү бетте. Алар хәзер җәннәттә!»

*(Коръән, «Гыйимран» сурәсе, 163—165 аятьләр.)*

Беравыктан тагын болай ди пәйгамбәр:

«Алла юлында үлүчеләрнең гамәлләре югалып калачак түгел... Алла аларның йөрәкләрен тынычландырачак. Җәннәткә кертәчәк ул аларны».

*(Коръән, «Мөхәммәт» сурәсе, 5—7 аятьләр.)*

Хәтта менә нәрсә ди пәйгамбәр:

«Синең сугыштагы дошманың синең өчен файдадан гайри эш кыйлмас. Чөнки син аны үтерсәң, саваплы буласың. Инде ул сине үтерсә (тагын да яхшырак — Г. Г.), шәһит китеп, җәннәткә керәсең».

*(684 нче хәдис.)*

Бу ике аять, бер хәдис — Мөхәммәтнең ифрат зур уңышы... Алар Мөхәммәт өчен генә түгел, гасырлар буена дәвам иткән ислам хәрәкәте, дин сугышлары өчен тиңдәшсез зур хезмәт итә. Фани дөньяда җәфа чигеп, гөнаһ җыеп ятканчы шәһит китәсең дә, тау чаклы гөнаһың булуга карамастан, турыдан-туры җәннәткә барып керәсең... Мона ышанган ислам гаскәренең үлемнән әз генә дә курыкмыйча, хәтта үлемне теләп сугышуы гаҗәп хәлме? Чыннан да шулай була. Персия белән сугышырга барганда ислам гаскәренең башлыгы Халид Персия шаһына юлдан шундый хат җибәрә:

«Мин үзем белән шундый гаскәр алып барам, кайсыдыр ки үлемне сез тормышны яраткан кебек үк ярата».

Пәйгамбәр, шәһит аятенә өстәп, тагын шундый чүпрә сала.

«Кылыч — күкләрнең ачкычы. Дин өчен кылыч күтәреп чыккан кешенең һәр тамчы каны, һәр сыкрануы күкләргә язылачак, аның савабы намаз, уразалардан зур. Алла юлында сугышып үлсәң, бөтен гөнаһларың гафу ителер, үзең җәннәткә кереп, мәңге шатлык-рәхәт эчендә йөзәрсең, хур кызлары кочагында рәхәт чигәрсең...»

Алай гына да түгел:

«Һәрбер шәһит үзенең якыннарыннан җитмеш кешене җәһәннәм утыннан имин булуда ярдәм итә алыр».

*(297 нче хәдис.)*

Шәһит турындагы аятьләрнең алда булачак тәэсирен хис итеп рухланганы хәлдә, Мөхәммәт тагын бер мөгез чыгара. Ләкин монысы инде ике башлы таяк. Бер

башы дин ислам өчен, ислам илләре өчен киләчәк заманда коточкыч зарарлы булачак. Хәзер әле Мөхәммәт таякның ул башын күрми. Ул икенче башын гына күрә. Ә анысы аның үз заманы өчен искиткеч файдалы. Шул башын шәһит уйдырмасы белән бергә кушкач, алдагы сугышларда җиңүне хәл итүче көч хасил була. Монысының исеме — тәкъдир яки язмыш, күрәчәк дип тә йөриләр.

Әйтергә кирәк, тәкъдиргә ышану яңа хорафат түгел, гарәптә борын-борыннан бар. Мөхәммәт үзе исә аңа бик ышанып бетми. Мәккәдә чагында ул аны хәтта бөтенләй инкарь итә. «Юныс» сүрәсенең 108 аятендә алла исеменнән тәкъдир турында менә нәрсә ди:

«Туры юлга кергән кеше шул юл белән барып, бәхеткә ирешер, ялгыш юлдан киткән кеше, шул юлда калып, бәхетсез булыр. Мин сезнең өчен өстемә җаваплылык алмыйм».

Ягъни, кеше үзенә юл сайлауда ирекле. Бер ниткән язмыш юк... Хәзер исә, Мөхәммәт үзенең бу аятенә каршы килеп, кешенең язмышы тулысынча алла кулында ди.

Нигә? Бу экият пәйгамбәргә нигә кирәк булды икән соң? Җавабы бик дәлилле: әһле ислам арасында сугышка каршы кешеләр күренә башлый, үлемнән куркучылар күренә башлый.

«Әй алла, нигә дип син безгә сугыш йөклисең?» — диләр алар. «Бу сугыштан безгә мәгънә чыгар микән?» — диләр. «Алла юлында сугышка чакыргач, авырган булып өйләрендә ятып калалар».

*(Коръән, «Хатын-кызлар» сүрәсе, 79 аять. «Гыймран» сүрәсе, 148 аять. «Тәүбә» сүрәсе, 38 аять.)*

Тәкъдир хорафаты менә шушындыйларны юмалар өчен, алдап ут эченә кертер өчен кирәк була. Һәм пәйгамбәр язмыштан узмыш булмау турында аять арты аять яудырырга керешә.

«Алла шулдыр ки... кайсы сезнең өчен дөньяда яшәү мөддәтен (срогын) төгәл билгеләп куйды».

*(Коръән, «Хайван» сүрәсе, 2 аять.)*

Ягъни сугыш кырында үтермиләр икән, син болай да шул ук сәгатьтә үләчәксең. Иң яхшысы: сугышта үл дә шәһит кит, тиле!.. Алай гына да түгел әле, кешенең нинди үлем белән үләсенә кадәр язылып куелган.

«Һәрбер җан иясе алла ихтыяры буенча, язмыш дәфтәренә язылып куелган буенча үләргә тиеш».

*(Коръән, «Гыймран» сүрәсе, 139 аять.)*

Мөхәммәт язмыш мәсьәләсе белән шулкадәр мавыга, ниһаять, ул менә нәрсә ди: Ә «...озын гомерне без кяфер кешене гөнаһка батырыр өчен генә бирәбез, аларга соңыннан интектергеч газап булачак».

*(Коръән, «Гыймран» сүрәсе, 172 аять.)*

Кяферне гөнаһка батырыр өчен...

Хәзер без бу урында, ходай тәгалә фиргавен явызның гомерен бик белеп 400 ел иткән инде, алайса, шул кирәк ул мөртәткә, диярге тиеш булабыз. Ә Метүшләк дигән икенче бер мәҗүси патша 929 ел яшәгән, аңа да шул кирәк: аның Ләмәк исемле улы 777 ел... Ләкин медальнең икенче ягы да бар бит. Кяфер мөртәт озак яшәгән саен, усаллана төшә түгелме, ишәя, дин дошманы арта түгелме соң?.. Әй Мөхәммәт, Мөхәммәт, мәзәк тә бәндә булгансың син.

Тәкъдир мәсьәләсенә кайтыйк. Бу уйдырманы дәвам итеп, Мөхәммәт:

«Үлмәктән калмак юк,— ди.— Биек манарага менеп яшеренсәгез дә, үлем сезне эзләп табачак».

*(Коръән, «Хатын-кызлар» сүрәсе, 80 аять.)*

Бу аятькә ияреп, безнең мулла абзыйлар соңыннан мондый экият уйлап чыгаралар. Имештер, үлемең судан дигәч, берәү гомер буена мич башыннан төшми яткан икән дә, әҗәле җиткәч, тагарактагы суга егылып төшеп үлгән...

Тәкъдир, язмыш... Алла әйткәнемчә, бер башының тәэсире көчле була. Ләкин бу «сугыштан безгә файда булырмы икән?» диючеләр, «авырган булып ятып калучылар» бетми. Бетмәве бер хәл, аларның «авыруы» бүтәннәргә дә йогу ихтимал бит... Бу хәлне күреп, алла үзе дә хафага төшә. Шундый бөек зат, җир-күкләрне «ә» дигәнче юктан бар итеп куйган бөек зат, хәзер мәмләкәте кыл өстендә калган бер өтек патшага әверелә дә кала.

«Ярдәм итә күрегез,— ди ул мөселманнарга.— Миңа ярдәм итсәгез, мин дә сезгә ярдәм итәрмен, аяк табаннарыгызны ныгытырмын».

*(Коръән, «Мөхәммәт» сүрәсе, 8 аять.)*

Алла (чыны — Мөхәммәт) моны физик ярдәм, сугышка өндәү мәгънәсендә генә түгел, үзенә һәм сугышка мадди ярдәм мәгънәсендә дә әйтә. Ул тиз көндә бу ярдәмнең төрле формаларын уйлап чыгара... һәм алла (чыны — Мөхәммәт) ярдәмне бөтенләйгә түгел, әҗәт итеп кенә сораганын әйтә:

«Аллага бурыч бирегез. Ул сезгә икеләтә кайтарыр һәм гөнаһларыгызны гафу итәр».

«Садака бирү — аллага бурычка бирү белән бер, алла аларның садакаларын икеләтә кайтарачак».

*(Коръән, «Алдашу» сүрәсе, 17 аять, «Тимер» сүрәсе, 17 аять.)*

— Икеләтә. Бу бик әйбәт. Ләкин кайчан кайтарыр икән соң ул алла бурычны?

— Теге дөньяда...

— Уһу-у... озаграк икән шул, пәйгамбәр...

Акча җимеше — бакча җимеше түгел, янчыклар, күрәсең, алай тиз генә чишелми. Пәйгамбәр андыйларны хурларга, куркытырга керешә:

«Сез алла юлына садака бирергә чакырыласыз. Ә сезнең арагызда саран кешеләр бар, ләкин саран кеше үзенең саранлыгы белән үзенә зыян гына итә. Алла бай, сез ярлы. Әгәр сез тыңламасагыз (ягъни тизрәк янчыкларыгызны чишмәсәгез — Г. Г.), ул чакта алла сезне бүтән халык белән алмаштырыр (ягъни сезне дә Фиргавен, Нух, Лут кавемнәрен һәлак иткән кебек һәлак итәр дә, дөньяга бүтән халыклар китерер — Г. Г.), алар инде сезнең кебек саран булмаслар».

*(Коръән, «Мөхәммәт» сүрәсе, 40 аять.)*

Күрәсең, гарәпләрнең янчыклары һәмишә чишелми. Хәзер алла юлына садака бирмәүчеләрне пәйгамбәр бөтенләй бетереп ташлый. Күзен дә йоммыйча, аларны кяферләргә тиңләп, җәһәннәм газабы белән куркытырга керешә:

«Андый кяферләр өчен без интектергеч җәза әзерләп куйдык»,— ди.

*(Коръән, «Хатын-кызлар» сүрәсе, 41 аять.)*

Күрәсең, бу җимгә әзме-күпме чиртүче табыла. Алла шат. Ул бу турыда хәбәр итеп, шундый бер аять иңдерә:

«Чынлыкта,— ди ул,— алла җәннәт бәрабәренә мөселманнарның җаннарын һәм мал-мөлкәтләрен сатып алды. Алар алла юлында сугышалар... Алланың вәгъдәсе буенча кеше үтерәләр, үзләре дә үләләр... Алла белән договор төзеп сату итүегезгә сөенегез! Бу зур уңыш бит!»

*(Коръән, «Тәүбә» сүрәсе, 112 аять.)*

Мин чиксез бай, минем кулымнан теләсә нәрсә килә, дигән алла хәзер әнә шундый түбәнлеккә төшәргә мәҗбүр. Болай да еллар буена барган сугышта интеккән, бөлгән гарәптән ул хәзер мәчет алдында басып торган бер өтек саилче кебек кулын сузып, садака сорый!.. Кыен ла сине аңлавы, алла агай!..

Кайберәүләрнең китап ярлыга, ятимнәргә, толларга, гарип-горабага да бирергә кушкан, нигә анысын әйтмисең, диюләре мөмкин. Әйтәм. Әйе, садака турындагы аятьләрнең андыйлары да бар һәм беренче карашта алары белән Коръән безне бик тә изге, бик тә игелекле эшкә өнди кебек... Ләкин бик беләсегез килсә, бу изгелекнең төбенә шулай ук бик нечкә сәясәт яшеренгән.

Беренчедән, Мөхәммәт заманында ятим, тол, фәкыйрь-фәкора кем? Бөтенесе алла юлында, ягъни талау, басып алу сугышларында этиләре, ирләре, уллары «шәһит киткән» сабыйлар, тол хатыннар, карт-корылар. Шул сугышларда аягын, кулын, күзен калдырып кайткан гарип-гораба. Алар хисапсыз күп. Сугыш кыры киңәйгән саен, аларның саны ишәя тора. Аларны тиешенчә тәэмин итсәң, иртәгә «шәһит китәчәк» мөселманнар, хатын, бала-чагалары, ата-аналары өчен тыныч булган хәлдә, гайрәтлерәк, кыюрак, аяусызрак сугышачаклар. Икенчедән, бу мохтаҗларга мөселман үзе ярдәм итмәгән тәкъдирдә, алар яһүд, христиан авылларына хаер өстәргә чыгачак. Монысы тагын зуррак сәяси оттырыш булыр иде... Ә халык? — Мин аны тагын бер тапкыр зирәк булган, тапкыр сүзле булган, курку белмәгән дияр идем, халык пәйгамбәр әйтә дип, алла куша дип, изрәп төшми. «Алла биргән малларыгыздан садака рәхим итегез» дигәч, Мөхәммәткә:

«Нишләп соң аларны без ашатып ятыйк, әгәр теләсә, алла аларны үзе дә ашата алыр иде»,— дип җавап кайтара.

*(Коръән, «Ясин» сүрәсе, 47 аять.)*

Чыннан да, мөселман алла өчен сугыша, алла үзе әйтмешли, «аллага ярдәм итә», алла өчен аяксыз, кулсыз кала. Ә аны, ни сәбәптәндер, алла үзе түгел, халык ашатырга тиеш!..

Шәригатькә төрле форма садакалар кертүдә өченче һәм төп сәбәп моңардан гыйбарәт. Халыкны ятимнәргә, толларга, гарип-горабага ярдәм итәргә өндәмәсә, пәйгамбәрнең үзенә садака алып яту уңайсыз була бит.

Кайберәүләрнең: «Пәйгамбәр — алланың иң якын дусты, шул байлыгы өстенә садака алып ятканмы?» — диюләре мөмкин. Яткан һәм ничек кенә әле!.. Мужик артын кашыса, мулла акча бирә дип белә, ди халык мәкале. Бу бик тапкыр мәкаль. Ләкин, гөнаһсына кермик, мулланың иң тыйнаксызы да давайлап сорау кадәр түбәнлеккә төшми. Ә пәйгамбәр төшә менә. Кибән-кибән игене, йөзләгән дөяләре, меңләгән сарыклары, йорт тулы малы. Ә күзе туймый, һаман сорый. Һәм шуны Коръәненә кертеп законлаштыра:

«Иа иманлы бәндәләр! Пәйгамбәр белән икәүдән икәү калып сөйләшкәндә, әүвәл башлап, садакагызны чыгарып салыгыз...»

*(Коръән, «Сүз көрәштерү» сүрәсе, 13 аять.)*

Мөхәммәт вафат булганнан соң, дин башлыклары садакаларның әһәмиятен үстергәннән үстерә барып, яңа формаларын уйлап чыгаралар: зәкәт, гошер, фытыр... Халык бирә, мескен, бае да, ярлысы да. Авызын ачса, үпкәсе күренә, өе кырык колһуалла белән генә тора, ә бирә. Чөнки хәдис әнә нәрсә ди:

«Әй адәм баласы!.. Ашадың — бетердең, киден — туздырдың, садака бирдең — кыямәт көн өчен сакладың».

*(«Җәвамигыль кәлим», 342 нче хәдис.)*

Чөнки (тагын бер чөнки) намаз, ураза, хаҗлар белән генә аллә кая китеп булмый әле; Мөхәммәтнең иң якын дүрт юлдашының берсе, Госман хәлифә, әнә нәрсә дип әйтеп калдырган:

«Намаз, ураза безне җәннәтнең ярты юлына китереп җиткерә, ә садака безгә җәннәт ишекләрен ачып куя».

Пәйгамбәр һәм хәлифәләрнең тырышлык нәтиҗәсе буларак, дин ислам илләрендә чыннан да хәер сорау көненә калган кешеләр белән рәттән хәерчелекне яшьтән үк үзләренә кәсеп итеп алган суфилар, дәрвишләр, төрле исемдәге соры кортлар, әрәм тамаклар армиясе яшәп килде. Хәтта безнең илдә дә калдыклары очрый әле. Шуңар күрә без бу армиянең «эшчәнлеген» зарарлы күрәбез, садаканы зарарлы күрәбез.

6

## АЛЛА ҮЗЕ ДӘ СУГЫШКА КАТНАША. ӘБҮ-СУФЬЯН ЯЗМЫШЫ. АЧУЫҢ КИЛМӘСЕН, ПӘЙГАМБӘР, СИН — ХАИН.

Менә инде яһүдләрнең «җимеш» җыяр көннәре килеп житте. Тирә-юньдәге тагын берничә кабиләне кылыч ярдәмендә иман китертеп, китермәгәнен талап, позициясен ныгытканнан соң, пәйгамбәр Мәдинә еврейләренә каршы ачыктан-ачык һөҗүмгә күчә. Ул хәзер элеккеге кебек төче телләнеп тормый, кылычын бугазларына куеп сөйләшә. Әлбәттә, үз белдеге белән түгел, биредә дә алла кушуы буенча:

«...Без һәрбер илчене аңа буйсыныр өчен җибәрдек...» ди хәзер алла.

*(Коръән, «Хатын-кызлар» сүрәсе, 62 аять.)*

Тегеләр һәмишә буйсынмагач, ачыктан-ачык шәһәрләреннән куу белән өркетә башлый. Еврейләр, хаклы рәвештә, баш күтәрә. Риваятьнамәләрдә шул вакыйга язылып калган: Әсма исемле еврей шагыйрәсе һәм Әбү-Афак исемле 120 яшьлек карт шагыйрь пәйгамбәргә үзләренең үткен телле шигъри укларын яудыралар. Өченче бер шагыйрь, Каһаб ибне Әшраф, үзенең шигырьләрендә Бәдер сугышында батырларча һәлак булган Мәккә егетләренә дан җырлый, Мәккәне Мөхәммәттән үч алырга чакыра. Өчесен дә газаплап үтерәләр.

— Моннан соң да акылга килмәсәгез!..

— «Ә без син уйлаганча акылсыз түгел. Безнең калебебез гыйлем савытыдыр. Синең гыйлемеңә ихтыяҗыбыз юктыр».

*(«Тәфсир Ногмани», 1 җөзьә, 20 бит.)*

— Үкенерсез...

— Юк, акылыбыз үз динебездә калырга куша, Мөхәммәт.

— Сезгә акылыгыз аны кушса, безгә алла менә нәрсә куша:

«Әй мөселман! Үзеңә якын кяферләр белән сугыш...» «Әй пәйгамбәр! Кяферләргә юл куйма, алар белән аяусыз сугыш... кяферләр һәм икейөзлеләр белән сугыш, аларның урыны — җәһәннәм төбендә».

*(Коръән, «Тәүбә» сүрәсе, 124 аять, «Форкан» сүрәсе, 54 аять, «Тыю» сүрәсе, 9 аять.)*

Ә бераздан алла турыдан-туры сәхәбәләргә мөрәҗәгать итеп, болай ди:

«Кяферләр белән дус булмагыз, аларны күргән бер җирдә бәреп үтерегез».

*(Коръән, «Хатын-кызлар» сүрәсе, 91 аять.)*

Алла хәтта ничек үтерү тиеш идеке турында да күрсәтмәләр бирергә онытмый:
«Имансызларны очратсагыз, муеннарын кылыч белән чабып өзегез». «Муеннарын чабып өзегез. Бөтен бармакларын чабып өзегез».

*(Коръән, «Мөхәммәт» сүрәсе, 4 аять,*
*«Табыш» сүрәсе, 12 аять.)*

Бернича вак бәрелештән, урам сугышларыннан соң килмешәк Мөхәммәт еврейләрне, анадан тума калдырып, шәһәрләреннән куалап чыгара.

Гомуми нәфрәт. Мөхәммәт үзе дә бөгебрәк җибәрүен төшенә, лакин: — Мин мени!.. Яһүдләрне шәһәрдән куарга миңа алла үзе кушты, — ди ул. — Беләсегез килсә, бу сугышка алла үзе дә катнашты әле, ди. Ышанмыйсыз? Әйтми тора идем әле, тыңлагыз, алайса:

«...Я һ ү д л ә р н е й о р т л а р ы н н а н к у у ч ы — а л л а ү з е. А л а р ү з л ә р е н к р е п о с т ь л а р ы с а к л а п к а л ы р д и п у й л а д ы л а р. А л л а и с ә, а л а р к ө т м ә г ә н я к т а н к и л е п ч ы г ы п, а л а р н ы ң й ө р ә к л ә р е н ә к у р к у с а л д ы...»

*(Коръән, «Җыелыш» сүрәсе, 2 аять.)*

...Җирләрен, малларын, мал-туарларын үзләштерүче шулай ук мин үзем түгел, аларны безгә алла үзе алып бирде,— ди Мөхәммәт.— Тагын ышанмыйсың? Алайса, менә сезгә әле генә Җәбраил фәрештә китереп киткән аять:

«...һәм ул (алла — Г. Г.) сезгә мирас итеп, аларның йортларын, байлыкларын, җир-суларын бирде. Алланың һәр нәрсәгә кодрәте җитә аның».

*(Коръән, «Төркемнәр» — «Әхзаб» сүрәсе, 27 аять.)*

Бу Мөхәммәтнең хәттин ашкан оятсызлыгы булу белән бергә, бик зур ялгышы. Качаклар Хәйбәр дигән еврей шәһәренә барып сыенгач, милләттәшләреннән, шулай ук Кораеш һәм башка кабиләләрдән Мөхәммәткә каршы союз төзеп, Хәбәштән оста сугышчы наемщиклар китереп, Мәдинәгә һөҗүм әзерлиләр. Бу юлы да гаскәр башлыгы — Әбү-Суфьян. Пәйгамбәр Мәдинә әйләнәли тирән канау казытып, бераз бәрелешеп алганнан соң, гаскәре белән бергә шәһәргә кереп бикләнә. Әбү-Суфьян гаскәре Мәдинәне өч атна камалышта тотканнан соң, ниһаять, бер эш чыгара алмыйча, кайтып китәргә мәҗбүр була. Әбү-Суфьян Мөхәммәтне гарәп дөньясында ишетелгәне-күренгәне булмаган бу куркаклыгы өчен хур итеп, иң әшәке сүзләр белән бизәп хат яза. Кайчан да бер очратып үч алырга вәгъдә итә. Мөхәммәт аңар җибәргән җавап хатында: тиз көндә, тиз сәгатьтә аның үзенең җанын җәһәннәмгә җибәрергә, Кәгъбәсендәге бөтен сыннарын җимереп ташларга алла белән ант итә. Ләкин икесенең дә антлары үтәлми. Тормыш икенче нәрсә китереп чыгара. Бу ике дин дошманы — ислам пәйгамбәре һәм иң явыз Мәккә кяфере — көтмәгәндә кардәш булып китәләр. Анысы турында әз генә алдарак.

Хәзергә Мөхәммәт алдагы ун ел эчендә Мәккәнең кәрваннарын таламаска, үзара сугышмаска дигән договор белән Мәккәнең кул-аягын бәйләп куя да үзенә каршы һөҗүм оештырган Мәдинә качаклары белән, бер очтан аларны химая кылган Хәйбәр яһүдләре белән исәп-хисапны өзәргә ашыга. 12.000 җәяүле гаскәр, 200 атлы. Кулда берсе кояш, берсе кара бөркет рәсемле ике байрак... Ләкин Хәйбәр бирелергә ашыкмый. Моңарчы этле-мәчелерәк яшәгән яһүд кабиләләрен дәһшәтле куркыныч берләштергән... Яһүдләр пәйгамбәр гаскәренә батырларча каршы торалар. Тәмам хәлдән тайгач кына үзләренең крепостьларына кереп бикләнәләр. Бары тик аяусыз ачлык интектергәч кенә, ак әләм күтәреп чыгарга мәҗбүр булалар.

Мөхәммәтнең бу илбасарлыгын да мулла абзыйлар, изге эш күреп, авыз суларын корытып сөйлиләр. Әйтергә кирәк, Мөхәммәтнең талау сугышлары дини китапларда гомумән сугыш дип аталмый. Газәвәт була аның исеме — ягъни изге сугыш. Ә сугышчысы: гази, ягъни изге сугышчы. Бара-тора сугыш сүзе дини әдәбияттан бөтенләй төшеп кала. Аны «җиһад» сүзе алмаштыра. Ягъни — тырышу, омтылу.

Ә түбәндә бәян ителәчәк вакыйганы мулла абзыйлар аеруча гыйбрәтле «омтылу» дип аңлаталар. Ә безнеңчә... Менә үзегез бәя бирегез. Әсир төшкән 700 яһүд чылбырлар белән богауланган хәлдә пәйгамбәр хозурына китерелә. Мөхәммәт аларны Канау сугышында яраланып, әле һаман ишәгенә атлана алмас хәлдә булган Саад ибне Моад исемле бер сәхәбә хөкеменә тапшыра.

— Минем карардан риза булырсыз микән соң? — ди Саад ибне Моад, каһкаһә белән көлеп.

Яһүдләр, уза китсә, малларыбызны алыр, йортыбыздан куар дип белеп:

— Бәли, риза булырбыз, — диләр.

— Риза булсагыз, әйдәгез, алайса...

Бу хаким карары буенча шәһәр мәйданына әсирләрнең үзләреннән бер тирән чокыр казытып, бөтенесен шунда кумеп үтерәләр; хатын, бала-чагаларын кол итеп Мәдинәгә алып китәләр. Әлбәттә, малларын да дөяләренә төяп китәргә онытмыйлар. Ә мал, күрәсең, әз булмый. Бу уңай белән алла хәтта мактанып куя:

«Алла сезгә күп итеп төшем вәгъдә иткән идеме? Күрәсез, ул үзенең вәгъдәсен тизләтте дә инде».

*(Коръән, «Жиңү» сүрәсе, 20 аять.)*

Менә инде хәзер пәйгамбәрнең Әбү-Суфьян белән кардәшләшеп китүе һәм башкалар турында. Ун елга төзелгән договор Мәккә белән Мәдинә арасындагы дошманлыкны йомшата гына түгел, бу ике шәһәрне дуслаштыра. Договорны камилләштерү буенча Мәккә Мәдинәгә, Мәдинә Мәккәгә барып йөри, бер-берсенең базарларында булалар. Алдагы елда Мөхәммәткә бөтен сәхәбәләре белән өч көн буена Мәккәдә йөрергә, Кәгъбәгә кереп хаҗ кылырга рөхсәт ителә. Шул көннәрдә Әбү-Суфьянның Хәбәшкә качкан Зәйнәп исемле кызы кайтып төшә. Ире үлеп калган. Пәйгамбәр бу чибәргә бер күрүдә гашыйк була. Бәлки, бу бер сәяси максат белән эшләнгәндер, — ничек кенә булмасын, алла изге эшне тиз тотарга кушкан, — әле кичә генә кылычка кылыч килгән, шундый усал хатлар язышкан дин дошманы кызының куенына пәйгамбәребезнең кияү булып кереп киткәнен халык сизми дә кала. Ә иртә торгач:

— Синнән яшерен эшем юк, кайнатай, Мәккә дин ислам мәркәзе булырга тиеш.

Әбү-Суфьян бер яктан дошман гаскәре башлыгы, икенче яктан хәзер пәйгамбәргә кайнатай тия. Нишләсен? Ул барыннан да бигрәк эш кешесе, сәясәт кешесе, сыйныф кешесе. ...Кораешлар Бәдер сугышында җиңелгәч, әһле исламнан үч алмый торып, битен юмаска, хатыны белән ятмаска ант иткән Әбү-Суфьян, күрәсең, хәзер эшнең кая барып чыгасын сизгән, — пәйгамбәр ягына ава. Яшерен рәвештә иман китерә һәм Мөхәммәт килүгә капитуляция әзерләп, Мәккәнең капкаларын ачып куярга вәгъдә итә. Ә Мөхәммәт, нишләвең бу, сугышмаска договор төзедең бит, ант иттең бит, димәсеннәр өчен, тиз генә күктән яңа вәхи төшертеп җиткерә:

«Алла һәртөрле антны бозарга рөхсәт итте».

*(Коръән, «Тыю» сүрәсе, 2 аять.)*

Аяте кечкенә булса да төш кенә, әйе бит?..

Шулай да сак булырга кирәк. Мәккә бер Суфьяннан гына тормый... Мөхәммәт һөҗүм өчен бу юлы да сугышлар тыелган айны көтеп ала. Һәм, бер яктан сугыш тыелган ай дип, икенче яктан, солых договорыбыз бар дип, гамьсез йоклап яктан Мәккәгә атылып килеп керә.

Ун мең җәяүле гаскәр, меңгә якын атлы...

Сигез ел элек мәсхәрә итеп көлгән, ниһаять, куып чыгарган мәҗүсиләр алдыннан пәйгамбәр, атын әкрен атлатып, башын горур күтәреп үтә. Шат, канәгать... Бар да кул баглап, баш иеп калалар.

«Әй алла, әй алла, вәгъдәңдә тордың, мәҗүсиләрне җиңәрлек көч бирдең!..» — дип кычкыра пәйгамбәр. Ул атыннан төшеп тормый, Кәгъбәгә атылып кереп, андагы 360 сынны чәлпәрәмә китерә. Хәтта Ибраһим белән Исмәгыйл сыннарының да кулларен күккә очыра. Кәгъбәдәгеләр белән генә калмый, бер очтан тирә-як авыл-шәһәрләрдәге сыннарны да пыран-заран китереп ташлый.

Шундый бер вакыйга сөйлиләр. Гузза гыйбадәтханәсендәге Гузза сынын җимереп ятканда, акырып-бакырып, урманнан бер кортка килеп чыга. Шәп-шәрә, чал чәчләре тузган, битләрен тырнап бетергән. Карчык, дөньядагын калдырмый сүгенеп, бәддога укып, фетнәчеләргә ташлана. Гаскәр башлыгы Халид аны эһ иткәнче кылычы белән урталай чабып өзә.

— Адәми зат түгелдер, җен карчыгы булгандыр ул, — ди гаскәр башлыгы.

— Түгел, Гузза шул үзе инде, — ди пәйгамбәр.

Гыйбадәтханәдә бик оста итеп эшләнгән бер мисыр күгәрчене сыны була, пәйгамбәр аны стенадан үз куллары белән алып ташлый, һәм нәкъ менә шушы вакыйга барлык җанлы нәрсәнең сыны дин ислам әһеле өчен дөрес түгел икәнлеккә ишарә була. Сыннарның, рәсемнәрнең мөселманга гөнаһ булуы турында берсеннән-берсе оста язылган, берсеннән-берсе куркыныч риваятьләр дөньяга килә. Мөселман кеше рәсеменнән, шайтан бисмилладан качкан кебек, кача торган була... Өлкәнрәкләрегезнең хәтерендә булса кирәк. Элек чәй тартмасында кытай сурәте була иде. Мөселман мондый чәйне сатып алуына, сурәтен пычак белән кырып ташламый торып, өенә кертмәс иде. Бу хәл революция елларына кадәр килде... Риваятьләр әкренләп онытылды... Хәзер иң тәкъвә мәчет картлары, намазлык өстеннән тормаган әбиләр сурәткә үзләре төшә, киногә барып, телевизорның күзенә кереп, сурәтләрнең үбешкән-кочышканнарын, ярым шәрә кызларның бот күтәреп биегәннәрен рәхәтләнеп карап утыра. «Тфү, хәсис!», дигән була. Ә торып китми, утыра бирә...

Мөхәммәтнең соңгы 13 ел гомере кяферләр белән сугышып үтә. Ләкин дин флагы астында барган бу сугыш — басып алу сугышларының башы гына була әле. Моннан соң ислам гаскәре Иран, Ирак, Сирия, Ямән кебек илләргә басып кереп, югарыда бәян кылынган ерткычлыкларны киңрәк масштабта, яманрак сурәттә дәвам итә. Шул рәвештә ислам дине Идел буена, Себергә, Монгол иленә, Кытайга килеп җитә, Европага бәреп керә. Боларында инде Мөхәммәтнең Коръәне дә васыяте генә бар, үзенең катнашы юк. Бу «изге» эшне Мөхәммәт үлгәннән соң иң якын юлдашлары — дини китапларда чәһреяр дип аталган Әбүбәкер, Гомәр, Госман, Галиләр һәм алардан соң хакимлек иткән бүтән патшалар дәвам иттерә. Бу китапта мин аларына тукталмаска булдым.

# Бишенче бүлек

«Үземнән соң ирләр өчен калдырган фетнәләрнең иң зарарлысы — хатыннар».

*Мөхәммәт пәйгамбәр.*

I

## РӘХӘТЕН КҮР, АГАЕНЕ! ДӨНЬЯ БУЛГАЧ, ШУНДЫЙ ХӘЛЛӘР ДӘ БУЛА. МЕНӘ БУ АССОРТИМЕНТ ИЧМАСА!

**Коръәндә пәйгамбәрне яхшы аты белән искә төшерерлек бер урын бар. Бу хатын-кыз мәсьәләсенә карый. Мәҗүси гарәпләр, гаиләдә беренче бала кыз булып туса, аны тереләй күмә булганнар. Мөхәммәт үзенең Коръәнендә бу кыргый йоланы ташларга өндәп, гарәпләргә берничә мәртәбә ачынып мөрәҗәгать итә. Әлбәттә, бу Мөхәммәт хезмәте генә түгел. Андый шигарны хәнифләр күптән инде алга сөреп килә, әрминкәләрдә шагыйрьләрнең бу хакта ялкынлы шигырьләре яңгырый. Ләкин бик борыннан килгән ата-баба йоласын ташлату өчен алла сүзе кирәк була. Ул кадәресен Мөхәммәт эшли. Һәм хатын-кыз мәсьәләсендә без Мөхәммәт пәйгамбәрне башкача яхшы аты белән телгә ала алмыйбыз. Хатын-кызга карата Мөхәммәт башаягы белән кыргый мөнәсәбәттә була. Бу хакта сүзне туп-туры менә нәрсәдән башлыйк: Коръән һәр мөселманга берьюлы 4 хатын белән тору хокукын бирә.**

**Хәзер күп кеше моңа ышанмый. Коръән андый сүз әйтмәс, аны мут ишаннар белән азгын муллалар үз мәнфәгатьләре өчен уйлап чыгарган, диләр. Ләкин чыны шул. Коръән мөэмин мөселманга 4 хатын белән тору хокукын биреп кенә калмый, барчабызга шуны киңәш итә һәм, онытып куя күрмәгез тагын дигән кебек, әледән-әле безнең исләребезгә төшереп тора:**

**«Күңелләрегезгә ошый икән, ике хатынга, өчкә, дүрткә өйләнегез», ди Коръән.**

*(Коръән, «Хатын-кызлар» сүрәсе, 3 аять.)* [1]

**Һәр мөселман өчен норма шундый. Дүрт. Бу норманың үзенә караганда да әһәмиятлерәк искәрмәсе бар. Шәригатьчә яшик дисәгез, сез аны, изге күреп, үтәргә тиеш. Күңелләрегезгә сеңеп калсын өчен игътибар белән укыгыз, кайта-кайта укыгыз:**

**«Әтиләрегез өйләнгән хатыннарга (үги әниләрегезгә диюе булса кирәк — Г. Г.) өйләнмәгез. Чөнки бу — күңел кайтаргыч эшәке, кабахәт юл. Үз әниләрегезгә дә, сөт әниләрегезгә дә өйләнергә ярамый. Сөт әниләрегезнең кызларына да ярамый. Шулай ук үз кызларыгызга, апаларыгызга, сеңелләрегезгә, әтиләрегез ягыннан булган тутәйләрегезгә, абыйларыгызның, апаларыгызның кызларына өйләнергә рөхсәт юк. Тагын хатыннарыгызның әниләренә өйләнергә рөхсәт юк. Үги кызларыгызга да өйләнү тиеш түгел, ә инде әниләре белән тора башларга өлгермәгән булсагыз, рөхсәт (ягъни, бүген кызын, иртәгә әнисен алырга рөхсәт — Г. Г.), уллары-гызның хатыннарына өйләнергә ярамый. Туталы-сеңелле ике кызга ярый, шуннан артыкка ярамый. Ә инде өйләнеп өлгергән булсагыз, тора бирегез!! Чынлыкта алла гафу итүче бит ул, алла шәфкатьле бит ул... Кияүдәге хатыннарга өйләнергә ярамый, инде кул салып өлгергән булсагыз, сүзем юк».**

*(Коръән, «Хатын-кызлар» сүрәсе, 3, 26—28 аятьләр.)*

**Бер сүз белән әйткәндә, полный хөррият!.. Дөрес, пәйгамбәребез «Мең дә бер хәдис»нең 46 нчысында бу мәсьәләдә ирләрне бераз тезгенли төшеп, ике төрле итеп аңларга урын калдырмаслык итеп, үтә образлы итеп:**

**«Ике яңак арасындагы телеңне вә һәм дә ике бот арасындагы нәмәстәңне сакла», ди.**

**Нәрсәдән? Кемнән?**

---

[1] Китапның бу бүлеге «Азат хатын» журналында басылып чыкканның соңында, бер нәмәгълүм кешедән мин шундый аноним хат алдым.

«...Бу мәсьәләдә хатыннарыгызга тигез карагыз, тигез шартларда яшәтегез, шулай булмаган тәкъдирдә бергә генә өйләнегез, дигән җире дә бар бит аның, нигә анысын яшерәсез...», диелгән иде ул хатта.

Әйе, Коръәндә андый искәрмә бар. Ләкин ул бер генә дә Мөхәммәт өстендәге кара тапны сыегайтмый, киресенчә, куерта төшә. Кем хатыннарына тигез карый алмый, тигез шартлар тудыра алмый, пардан киендерә алмый, пар читек, пар күлмәк, пар яулык алып бирә алмый, барысына бертөрле затлы ризыклар ашата алмый? — Эшче, крестьян, кол. Ә менә мал-мөлкәтле кеше өчен бу чүп тә түгел. Ул дүрткә түгел, артыгына да тигез шартлар тудыра ала. Аллаһ тәгалә сәламәтлектән аермасын да, җегәрне генә киметмәсен...

Моның җавабын сез шул ук китапның 47 нче хәдисеннән эзләп таба аласыз. Бередә пәйгамбәр:

«Үзеннең хатыннарыңнан һәм кәнизәкләреңнән гайри хатын-кыздан сакла син ул ике бот арасындагы нәмәстәңне, әй мөэмин мөселман!» дип катгый рәвештә кисәтү ясый.

Ләкин, чү! Бу бер биргән сөякне кире тартып алу була түгелме соң? Сәхәбәләрем нәүмизләнмәсме соң?.. Мөхәммәт тезгенне бөтенләй бушата:

«Сезгә тагын кол хатыннарыгыз белән дә дәртләрегезне баскалап алырга рөхсәт ителә, — ди ул «Хатын-кызлар» сүрәсенең 28—29 аятендә. — Тик моның өчен сез аларга шушы күрсәтмә нигезендә (??) бүләк бирергә тиеш буласыз».

Кысылды дип торганда, тагын да өстәлде түгелме!.. Ассортимент артты! Меню тәрлеләнде!.. Аллабызның бу кадәр шәфкать-мәрхәмәт, юмартлыгын күреп, кайсы таш йөрәкнең генә күңеле эремәс икән дә кайсының гына күзеннән шатлык яшьләре бәреп чыкмас икән!.. Дөрес, аллаһ тәгалә тагын бер урында:

«Инсаф белән яшәргә, гыйффәтле килеш яшәргә теләгән кол кызларыгызны бозык эшкә көчләмәгез», дип, әһеле исламны нәүмизләндерергә итә. Ләкин шул ук аятьтә, әйттем исә кайттым дигәндәй, агаенене тизрәк тынычландырырга ашыга:

...«Инде тотып алып көчлисез икән, чынлыкта, алла көчләүчеләрне гафу итүче, шәфкатьле бит ул алла», ди.

*(Коръән, «Нур» сүрәсе, 33 аять.)*

Кыйссадан хисса: сиңа дүрткә өйләнергә ярый, өстәвенә, кол хатыннарың белән дә аулакта шаяргалап алырга ярый, кол кызларыңны теләсә кайда тотып көчләргә ярый... Инде моннан соң да алланы бер, пәйгамбәрне хак дип белмәсәгез!..

Күп кенә мөселман илләрендә тагын вакытлы никах дигән бер никах яшәп килә. Бу берничә сәгатьлек никах һәм мөэмин мөселман өчен аның саны чикләнмәгән. Никах укыган өчен садакаң гына төтсен. Мулла абзаң аны хәзер шатырдатып укып бирә. Тик шунысы: бу төстәге никах, үзебезчәләтеп әйтсәк, законлаштырылган фәхешлек, ничектер, безнең Идел буена, Урал, Себер илләренә килеп җитмәгән,— анда яшәүче мөселман байлары шәригатьнең шундый зур хөрмәтеннән мәхрүм калганнар. Хәер, безнең бай абзыйлар, аның каравы, башкасын үкенечкә калырлык итмәгәннәр. Махсус мөселман фәхешханәләре ачып, кяферләрне бусагасыннан да атлатмыйча, хак мөселманнар гына җыелып, хак мөселманча гына итеп зина кылып ята булганнар. Моны исбат итү өчен революция алды елларында нибары 50—60 мең татар яшәгән бер Казан шәһәрендә генә 40—50 «кызлы» мөселман фәхешханәсе, тагын бик күп яшерен фәхешханәләр булганны әйтү дә җитсә кирәк.

Шәригатьнең никах турындагы кануннарын хак мөселманның барлы-көрлесе төгәл үтәп барырга онытмаган. Онытып җибәрмәсеннәр өчен, мулла абзыйлар никах укыган саен бу турыда хәзер дә әле һәр мөселманның исләренә төшерә торалар.

Никах димәктән, күптән түгел булган бер җәнҗаллы вакыйга искә төште. Мәгълүм булганча, халыкның бер өлеше, диннең көндәлек йолаларыннан — намаз, ураза кебекләрдән — әллә кайчан ваз кичкән булса да, гомергә бер килә торганнарын: исем куштыру, сөннәткә утырту кебекләрен үтәп килә әле. Үзе ансат, көндә биш тапкыр тәһарәт аласы, утыз тапкыр бил бөгәсе юк, ай буе ач торасы юк. Ә савабы!.. Никах та шундыйлар җөмләсеннән булып, шәригатьтә аеруча зур урын тота. Чөнки хөтбәдә әйтелгәнчә:

«Никах — юктан бар итүче тәңренең мәңгелек фәрманыдыр. Никах — пәйгамбәр сөннәтедер, пәйгамбәр сөннәтеннән баш тарткан кеше — аның өммәтеннән түгелдер». Ягъни, нәҗеси бер кяфердер. Алла сакласын...

Вакыйганың каһарманнарын, авылының исемен әйтеп язарга ни кыҗрасам да, борынгы китаплардагыча: «К» илендә, фәлән комсомол егет белән фәлән комсомол кыз туенда булды бу хәл, дип кенә башлап китәргә мәҗбүрмен. Исемнәрен фаш итмәвемне зинһарлап үтенделәр.

...Туй көне билгеләнә, өндәү таратыла. Мич башында әче бал, мичкәне бәреп чыгарга җитеп, дулап утыра.

Ә никах?

Туган-тумача, кода-кодача, кардәш-ыру арасында: укытыйк, диючеләр бар, миңа димәгәе, диючеләр бар, кирәкми лә, диючеләр бар, башаяклары белән каршылары да юк түгел. Болары — баш кодалар. Кияү күптән шундый. Аның каравы кодагыйлар, бигрәк тә кыз әнисе: «Юк, юк, авызыгызны да ачасы булмагыз, газиз баламны гомергомергә үз нигеземдә зина кылдырып яткырганчы, үлгәне артык, әлгаязе биллаһи!..»

Кыз, әнисен кызганып, елый: «Укытыйк!» Кияү: «Әйдә, черт с ним, ябышып калмас әле...»

Мәҗлес җыйнала. Табын борынгыча, идәндә. Никах укытырга сугышка кадәр үк муллалыктан ваз кичеп, күрше авылга укытучы булып киткән Борһан агайны күздә тотканнар икән дә, килмәгән; кодагыйлар ерак авылдан бер хәзрәт кисәге табып кайтканнар. Каешланып, кыршылып беткән фәскә саргаеп беткән чалма ураган. Аягында киндер мае белән бераз рәткә китерелгән читек. Кәвеше дә шундый — анысын салып, артына куйган. Өстендә нафталины аңкып торуга карамастан, көя тишеп бетергән, эт өрде исә таралып төшәргә торган бохар чапаны. Тавышы да чапаны кук... Кодагый-

лар шуна да мөкиббән. Чаршау артына кереп поскан кодачалар, тәңре сүзен ишетеп калырга дип кенә кергән күрше карчыклар, тыныш саен авыз эчләреннән нидер укып, хәзрәткә куәт биреп торалар. Кыз әнисе тәмам эреп төшкән. Күзендә шатлык яше, үзе бертуктаусыз: амин хәзрәт, амин хәзрәт...

Менә хәзрәт, хөтбәнең алыш-биреш өлешенә җитеп, кызның атасына мөрәҗәгать итә. (Алгы өлеше гарәпчә иде, монысы үзебезнең телдә):

— Я фәлән угылы фәлән! Фәлән микъдар мәһәр бәрабәренә кызыңны фәлән угылы фәләнгә хәләл җефетлеккә бирдеңме?

— Бирдек, хәзрәт.

Инде хәзрәт егет атасына мөрәҗәгать итә:

— Фәлән угылы фәлән! Фәлән угылы фәлән кызын фәлән микъдар мәһәр бәрабәренә угылың фәләнгә хәләл җефетлеккә кабул итеп алдыңмы?

— Алдык, хәзрәт.

— Ягез, бер фатиха.

Мәҗлес бердәм рәвештә амин күтәрә.

Ниһаять, кыз анасы чаршау артыннан сузылып мискене алып, тирән тәлинкәләргә, суганлы-борычлы, күкәй тәбәле шакмак токмач сосарга керешә.

Дөнья сүзе китә.

— Алла юк дип йөрсә дә, монысына килгән әле, — дип пышылдый хәзрәт кемнедер күздә тотып.

Үз авылларының клуб мөдире икән. Күзләр очраша.

— Әйе, — ди клуб мөдире, — ләкин монысы өчен түгел, тегесе өчен килдем мин. Изге хөтбәнең никадәр изге икәнен әйтеп бирер өчен килдем, авылдаш.

«Әллә инде тел чишүем гөнаһ шомлыгына каршы булды?..» — Хәзрәт сагая. Бәгъзеләре, шул җөмләдән кыз атасы, кызыксына кала:

— Ә син аны каян беләсең, энем?

— Сүзгә сүз беләм. Борһан абый әйтеп бирде.

— Җәле, җә...

Клуб мөдире, кесәсеннән бер кәгазь алып, хөтбәнең бер гарәпчәсен, бер тәрҗемәсен укырга керешә. Гарәпчәсен укый да аеруча басым ясап тәрҗемә итә:

«Никах тәңренең фәрманыдыр. Әгүзе биллаһи минәшшайтан ирраҗим... Күңелегезгә хуш килгән хатыннардан бергә, икегә, өчкә, дүрткә өйләнегез», ди. Һәм гөжләшү башланганчы тизрәк дәвам итә:

«Никах пәйгамбәр сөннәтедер, пәйгамбәр сөннәтеннән баш тарткан кеше — аның өммәтеннән түгелдер... Күңелегезгә хуш килгән хатыннардан икегә, өчкә, дүрткә...»

— Стоп, егет! Дөрес лыгырдыймы ул, хәзрәт?

Кыршылган фәс тагын да яньчелә төшкән кебек була, хәзрәтебез үзе дә йолкынган әрекмәндәй шиңеп китә:

— Кем... ни... мин...

— Дөрес лыгырдыймы, дим?

— Кем... ни... мин... шәригать язганны... 50 ел укып йөрибез... Никах — мәңге юктан бар итүченең фәрманыдыр...

— Фәрманыңны куеп тор! Син кияүгә минем кыз өстенә тагын өчне алып кайтырга киңәш биргәнсең бит! Ә без монда шуңа амин күтәреп утырганбыз, шулаймы?!

— Мин... ни... кем... мин шәригать...

— Бар, шәригатең белән бергә ычкын моннан!

Хәзрәт табан ялтыратырга уйлап, артындагы кәвешләрен капшый... Ә чаршау артында күз яше... Әти кеше йомшый кала. Туйганчы бер көлә ул зур корсагын тотып. Аннан хәзрәтне җиңеннән тартып туктата:

— Әйдә ярар, утыр, алла бәндәсе...

— Мин... кем... ни...

— Ишеттек... Җитеш әйдә... катык катасыңмы?.. Мужет бераз мич башындагын...

Менә нинди вакыйганың шаһите булдым мин К. карьясендә.

Гади мөселманнарга карата шундый шәфкатьле, шундый юмарт алла пәйгамбәребезнең үзен (дөресрәге Мөхәммәт үзен) дүрт хатын, кол хатыннар, кол кызлар белән генә дә чикләми. Юмартлыгын өч өлеш арттырып, ассортиментны икеләтә киңәйтеп, менә нәрсә ди:

«Әй, пәйгамбәр! Туй бүләгеннән мәхрүм итмәс булсаң, без сиңа әтиең ягыннан булган агаңның кызларына, әниең ягыннан булган агаңның кызларына, әниең ягыннан булган түтәңнең кызларына да өйләнергә рөхсәт итәрбез. Тагын мөһаҗир кызларына, сугыштан әсир итеп алып кайткан хатын-кызларга, вә һәм дә үзе теләп килгән, шулай ук үзең теләп алган хатыннарның бөтенесенә өйләнергә рөхсәт итәбез. Бу бездән бер сиңа гына бирелгән хокук. Алла гафу итүче бит ул, алла шәфкатьле бит ул, алла юмарт бит ул...»

*(Коръән, «Төркемнәр» — «Әхзаб» сүрәсе, 49—50 аятьләр.)*

әйтерең бармы!.. Бик юмарт икән шул, шәфкатенең чиге юк икән... Төрлесеннән берәрне генә алса да, уһу, нихәтле җыйнала!..

Һәм җыйный Мөхәммәт. Төрлесеннән җыйный. 99 хатыны өстенә, агасының бердәнбер хатынын тартып алган Сөләйман пәйгамбәрне хәтерлисезме? Тагын бер төндә 70 хатынга куәте җиткән Давыт пәйгамбәрне?.. Моннан соң Мөхәммәтнең аталы-уллы бу ике үгез турындагы әкиятне уйлап чыгаруы — үзенең азгынлыгын, җенеси тотнаксызлыгын аклау өчен идекенә төшенү кыен булмастыр.

Диннәрнең берсен яманлап, берсен мактый торган түгел. Шулай да хатын-кызга ислам динендәгечә кыргый караш бер диндә дә юк. Мәсәлән, христианнарда, шәригать буенча, дин башлыгы ул кадәр хатынга түгел, беренчесе үлгәч, икенчегә дә өйләнә алмый. Даһи Толстойның «Тере мәет»ен генә хәтерләгез... Ә Мөхәммәт?.. Никахлы хатыннарының саны турында бездә төгәл мәгълүмат юк. Тарих битләренә кереп калганнары — 14. Алтынчы дистә белән барганда берьюлы 9 белән торган. Бу — никахлылары гына. Кол хатыннар, кол кызлар, җарияләр, кәнизәкләр, сөяркәләр бу санга керми. Юк сүз, язучы үзе уйлап чыгарган дииоләргә урын калдырмас өчен, хәзер мин а н и л ә р е б е з н е ң һәркайсы белән сезне бераз таныштырып үтәм. Юк, ялгышмадым — а н и л ә р е б е з н е ң. Руслар поп хатыннарын матушка дигән кебек, без дә, шәригать буенча, пәйгамбәр хатыннарын әни дип йөрергә тиешбез. Бу хәтта Коръән аяте белән законлаштырылган:

«Пәйгамбәр мөселманнарга аларның үзләреннән якынрак (?). П ә й г а м б ә р н е ң х а т ы н н а р ы — м ө с е л м а н н а р н ы ң а н и л ә р е».

*(Коръән, «Төркемнәр» — «Әхзаб» сүрәсе, 6 аять.)*

Сәер?— Әйе, сәер. Ләкин Коръәнчә булсын дисәң, ундүртесен дә әни дисең.

Беренче әниебезне хәтерлисездер?.. Хәдичәне? Гөнаһысына кермик, ул әнкәбез исән чакта Мөхәммәт тыйнак була әле, бүтәнгә өйләнми, ә инде аны җирләп кайткач, тиз көндә Мәдинәнең патшасы да булып киткәч!..

Башта пәйгамбәребезнең бер хосусиятен әйтеп китү кирәк. Ул, карт дими, яшь дими... толмы-кызмы, — анысы да барыбер. Хәдичәдән кала бөтен ислам дөньясында да иң мәшһүр хатыны, пәйгамбәребезнең иң сөеклесе — Гайшә. Нәрсәсе белән мәшһүр, нилектән иң сөеклесе — мәгълүм түгел. Хәер, анысының хаҗәте дә юк. Безгә мәгълүме, безгә хаҗәте, безне хәйраннар калдырганы, ниһаять, безнең нәфрәтебезне кузгатканы — бүтән: Мөхәммәт пәйгамбәр кияү булып кергәндә, Гайшәбикә әнкәбез, артык та түгел, ким дә түгел: тугыз яшьлек бер сабый була.

Борынгы дин китаплары бу хәлне бик хуп күреп, мактаулы эш күреп, изге күреп язган. Хәзерге муллалар исә бу хәлгә үзләре дә уңайсызланалар. Тик бәгъзе берләре генә, пәйгамбәрне акларга маташып (мин әйтер идем: саламга ябышып), ул якларда кызлар иртә өлгерә шул, диләр. Әйе, моңарда чыпчык борыны хәтле генә хакыйкать бар. Ләкин фәкать чыпчык борыны хәтле генә. 9 яшьлек гарәп кызы безнең яклардагы 11, уза китсә, 12 яшьлек кызларыбызга тиң булуы мөмкин. Ләкин ул бит әле һаман сабый!.. Ә Мөхәммәт бу вакытта инде 52 яшьлек бабай!.. Зөфаф кичәсенең бичара кыз өчен никадәр «күңелле» булганын язып тормасак та аңлашылса кирәк... Моның өчен, хәзер бездә, пәйгамбәр идекенә карамастан, бик әйбәтләп, бер унбиш елны чәпәрләр иде. Ә Мөхәммәт үзе хаким, үзе патша, күктә — алла, кулда — Коръән...

Пәйгамбәр үрнәгендә мондый кыргый хәлләр Көнчыгыш илләрдә хәзерге көндә дә очрый әле. Ана күңеле сизә, баласы харап булачак, рәхәт тормыш, мәхәббәт турында сүз дә булу мөмкин түгел. Газиз баласы 20—30 яшендә итәк тулы бала белән калачак. Ләкин бердән кызга ана түгел, ата хуҗа, дөресрәге бай кияүнең алтыны хуҗа, икенчедән, бу — пәйгамбәребез йоласы бит! Шәригать законы!.. Бар, кызым, чәчләрегез бәйләнгәндер...

2

## АЛЛАҢ ҮЗ КЕШЕ БУЛГАЧ, НИЧЕК РӘХӘТ!.. ЯЗУЧЫ КАРЧЫК. «ӘДӘПНЕ АЛЛА МИҢА ҮЗЕ ӨЙРӘТТЕ».

Әнкәбез Гайшә — пәйгамбәрнең кызлата алган ике хатынының берсе. Калганнары бар да тол хатыннар. Ләкин аларның да күбесенә пәйгамбәребез баба булырлык. Шундыйлардан берсе әнкәбез Хәфаса. Ул Мөхәммәтнең иң якын дүрт юлдашының (чәһреярларының) берсе булган Гомәрнең кызы. Хәбәштанга качкан булып, ире үлгәч кайтып төшә. Гомәр аны икенче бер чәһреярга — Госманга бирмәкче. Госман алмый. Эти кеше бу хәлгә гарьләнгәнен Мөхәммәткә килеп сөйли.

— Ә син бер дә борчылма, — ди Мөхәммәт аны тынычландырып, — Госманга алла синең кызыңнан әйбәтрәк кыз билгеләп куйган, бер үк вакытта синең кызыңа Госманнан әйбәтрәк, дәрәҗәлерәк кияү билгеләгән...

— Ничек?

— Шулай...

Һәм чыннан да шулай булып чыга... Мөхәммәт Госманга үзенең Өммегөлсем исемле кызын бирә, үзе әлеге Хәфасага өйләнә. Тол дигәч тә, 24 яше белән генә бара әле, үзе бай: иреннән дөнья хәтле мал калган. Әтисе илдә беренче байлардан.

Мөхәммәт бу әнкәбезгә исәп белән өйләнгән булса кирәк. Әйтергә кирәк, күп кенә риваятьләр пәйгамбәребезнең Гайшәгә дә шундый исәп белән өйләнүе турында сөйлиләр. Гайшәнең әтисе — Мәккәнең зур дәрәҗәле бае бит, бара-тора зур полководец. Мөхәммәт үлгәннән соң хәлифә булып кала.

Пәйгамбәрнең Өммехәбибә белән һәм Әбү-Суфьянның тол кызы белән булган никахларны да, әлбәттә, исәпле никах түгел дип әйтеп булмый. Хәер, моны пәйгамбәр үзе дә яшерми. Хәтта шуны үзенең хәдисләре белән канунлаштыра.

«Хатын яки дине, яки матурлыгы, яки малы өчен никах кылыныр», ди.

*(225 нче хәдис.)*

Пәйгамбәрнең мондый никахлары арасында иң күзгә бәрелгәне — әнкәбез Мәймүнәгә өйләнүе. Мөхәммәт куенына кергәндә, ул инде беренче иренә 38 ел хезмәт иткән 51 яшьлек әби була. Аның каравы, Мәймүнә әби (әйттем исә кайттым — әнкәчебез Мәймүнә) гаять зур дәрәҗәле ике мәҗүси гарәпкә туләй тиешле. Мөхәммәт шул никах аша бу ике адәм белән якын мөнәсәбәткә керүне күздә тота. Шулай булып чыга да. Боларның берсе — бөтен илгә мәшһүр оста сугышчы, Мөхәммәтнең котын алып торган Халид ибне Вәлид. Кардәшләшеп алгач, иман китерә, ислам гаскәренең бөек полководецы булып китә. Легендар батырлыклары өчен аңар әһеле ислам «Ходай кылычы» дигән кушамат тага. Икенчесе — үзенең сатирик шигырьләре белән Мөхәммәтнең тенкәсенә тиеп беткән атаклы шагыйрь. Анысы да иман китерә һәм үзенең ялкынлы шигырьләре белән үлгәнче ислам диненә хезмәт итә.

Тәртип буенча Хәдичәдән соңгы беренче хатыны — әнкәбез Сөвәдә дә шундыйлардан. Мөхәммәт кияү булып кергәндә, ул инде 52 яшьлек әби, ләкин яман да бай, дәрәҗәле, кардәш-ыруы күп. Әнкәбез Сөвәдә арты алар да иман китерә һәм дин исламга кылычы белән дә, малы белән дә хезмәт итә...

Хатын-кызга килгәндә Мөхәммәт дин, милләт мәсьәләсендә дә талымлы түгел. Пәйгамбәребез яһүдләр белән, алда күренгәнчә, алыш-бирешне күптән өзгән булса да, хатын-кыз мәсьәләсендә үзенең нәфесенә турылыклы булып кала. Әнкәләребездән Сәлимә, Һиндә, Рәйханә — еврей кызлары. Бу өч хатын, сугышларда әсир төшеп, ганимәт мал тәртибендә жирәбә буенча Мөхәммәткә чыгалар, яки башка берәүгә чыгалар да, Мөхәммәт шулардан сатып ала.

Әнкәбез Барра да шундыйлардан. Монысы мәҗүси гарәп кызы. Ире сугышта үлгән. Жирәбә буенча Сабит ибне Рәис исемле сәхәбәгә чыга. Сабит ибне Рәис Баррадан зур йолым сорый. Барраның ул кадәргә чамасы юк:

— Кимет.

Мөхәммәт бөтен җире килгән бу яшь чибәргә сокланып карап тора да:

— Мин синең өчен йолымыңны киметүдән дә күркәмрәк яхшылык эшләргә хәзермен, — ди. — Мина хатын буласың. Ә Сабитны мин үзем бәхилләтермен...

Барра риза. Пәйгамбәр Мәдинәгә кайтып җиткәнче дә көтми, ялга туктаган бер җирдә никах укыла, ефәк чатыр корылып, пәйгамбәребез яшь бикәч куенына керә.

Тагын бер кыз белән бер хатынның безгә әни булып китү вакыйгалары аеруча мавыктыргыч. Боларның берсе — Мария. Мысыр патшасы бүләге. Кол кыз. (Төрлесеннән алуны дөресләгән аятьнең нигә кирәк булганын шәйләдеңме инде, укучым?) Мысыр патшасы аны пәйгамбәребезгә үзенең мөселманга чыгу билгесе буларак, бер ишәге белән бергә бүләк итеп җибәргән була. Пәйгамбәребез башта аны сөяркә итеп тота, соңыннан, әнкәбез булып киткәч, пәйгамбәргә бер ир бала табып бирә.

Мария туташның ничек-ничек әниебез булып китүе турында сөйләшүдән алда, әйдәгез бер тыныш ясап алыйк. Пәйгамбәребезнең хатын-кызга мондый кыргый карашын, үзенең 14 кә өйләнүен, һәр мөселманга дүрткә өйләнергә әйтүен Коръән яки шәригать ничек аклый? — Берничек тә акламый. Хәер, аларга аклап торуның хаҗәте юк. Коръәнчә бу нормаль хәл. Ә хәзерге муллалар исә, моның бик үк нормаль түгел икәненә төшенеп, бу кыргый законны акларга итенәләр. Ләкин аларның аклаулары — батучының саламга ябышуы гына. Мәсәлән, Казанның заманында атаклы динчесе Сөнгатулла Бикбулат үзенең 1914 елда басылып чыккан «Хәзрәте Мөхәммәт» исемле китабында (347 нче бит), «Мөхәммәт бозык уй белән түгел, кызларның ата-аналарының күңелләрен күрү теләге белән, тагын кызларны мөшрикләрдән саклап калу теләге белән шулай күпкә өйләнгән», — ди. Ә без? Коръән безнең заман өчен дә бит, татарлар өчен дә.

Бәгъзе бер муллалар болай акламакчы: «Хатын-кызның төрле чагы була бит, — диләр алар. — Күреме-фәләне, бала табу чаклары... Ә ирләргә көн дә кирәк...» Ә бит ирләрнең дә төрле чаклары була, мулла абзыйлар, командировкасы-фәләне, тагын солдат хезмәте... Бу исәптән шәригать хатынны 4 белән генә дә чикләмәскә тиеш булып чыга түгелме соң дисәң, мулла абзыйлар телләрен тешлиләр. Өченче бертөрлеләре күп хатын белән торуны аеруча савапле эш күрә, аны мөселман үрчетү өчен зарур гамәл, ди.

Бу рәвешле аклануга пәйгамбәрнең хәдисләре дә куәт бирә.

Мин, — ди Мөхәммәт, — кыямәт көн башка милләтләр арасында өммәтемнең зур булуы белән мактанырмын... Никахланыгыз, үрчегез...

Мөхәммәт мөселманнарны хәтта менә нинди сүзләр белән дәртләндерә... «Күп бала таба торган хатын бала тапмый торган матурдан алла каршында сөеклерәктер».

*(«Мең дә бер хәдис», 343, 118, 439, 910 хәдисләр.)*

Ләкин мөселманнарның, пәйгамбәрнең бу тырышлыгы тормышта берничек тә акланмый. Җәмгы мөселманнарның 1300 еллык тырыш хезмәтләренә карамастан, хәзерге көндә 9 кяфергә нибары бер мөселман туры килә. Әйтергә кирәк, мөселман үрчетүдә пәйгамбәр үзе дә әллә ни мөгез чыгара алмый. Аның 14 хатынга нибары өч кызы була, алары да бер Хәдичә абыстайдан булып, яшьли үлеп бетәләр. Тагын бер улы булып, анысын, алда әйткәнемчә, әнкәбез Мария табып бирә. Бу урында без бер төндә 70 хатын белән йоклап, җыенысыннан бер чирләшкә баласы булган Давыт пәйгамбәрне хәтерләсәк, урынлы булыр. Чөнки Мөхәммәтнең дә 14 хатыннан ир баласы шул бер генә, әнкәбез Мариядән генә булып, ул да шулай ук чирләшкә туа һәм сабый чакта ук җан тәслим кыла.

Инде Мария туташның ничек-ничек әниебез булып китүенә килик. Ул бик кызыклы һәм үтә гыйбрәтле. Әш шунда ки, дин китапларының раславына караганда, гөнаһысына кермик, пәйгамбәр хатыннарын тигез күрә. Мәчет бакчасында һәр хатынының үз гүрнәчәсе. Мөхәммәт — «Зәңгәр шәл» ишаны түгел, алар янына кереп куну нәүбәтен намус белән саклый. Бу хакта Сөнгатулла Бикбулат, әнкәбез Гайшәнең күп кенә дини китапларда урын алган түбәндәге сүзләрен китерә:

«Рәсүлулла нәүбәт мәсьәләсендә безне тигез күрә иде, беребезнең өендә икенчеләребезнекеннән артык юанмый иде. Һәр көн диярлек барчабызның да хәлен белеп чыга, кич булгач, нәүбәте җиткән хатыны янында куна иде. Сөвдә үзе картайгачтын, нәүбәтен миңа һиба кылмыш иде»[1].

*(«Хәзрәте Мөхәммәт», 347—348 бит.)*

Бу урында әнкәбез Сөвдә өчен көенеп, әнкәбез Гайшә өчен сөенеп, бераз тынып торыйк та, әнкәбез Мария турындагы юлларга күз атыйк.

Шулай бер көнне, әнкәбез Хәфаса чираты булып, ул каядыр чыгып киткән арада әниебез булачак Мария килеп керә. Белеп кергәнгә охшый, күзләре майланган... Пәйгамбәребез үзе дә, тик торганчы — тиген эш, дигәндәй, бераз шаярып алырга каршы түгел... Ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы диикме, безнең бәхеткә каршы диикме, шул чак әнекәчебез Хәфаса кайтып кермәсенме! Керә керүгә, мәче төсле атылып килеп, «өстерәлчек»нең чәченә ябышмасынмы!

«Өстерәлчек» булу өстенә, кол да бит әле!.. Кая ул әрепләшеп тору, Мария тиз генә чыгып сыза. Хәзер әнкәбез Хәфаса пәйгамбәр өстенә очып килә. Пәйгамбәребез, ул Мариягә моннан болай кутәрелеп тә карыйсым юк, дип ант иткәч кенә тына Хәфаса. Тына һәм пәйгамбәрнең гайбәте турында беркемгә тишмәскә сүз бирә. Ләкин, — хатын-кыз авызында сүз торамы соң! — әнкәбез Гайшәгә әйтә. Утыз теш арасыннан чыккан сүз бише белән бөтен галәмгә тарала... Пәйгамбәр, ачудан, әнкәбез Хәфасаны аерып җибәрә, бер очтан, кызып китеп, моннан болай бүтән әниләребез белән дә йокламаска ант итә. (Әйтергә кирәк, хатыннарына ачуы килгән чакта, Мөхәммәт гомумән аларны яннарына ятмау белән җәзалый торган була. Дин китаплары, хосусән «Хәзрәте Мөхәммәт» үзенең 331 битендә безгә бу турыда бик тасвирлы итеп язып калдырган: «Бер тапкыр ниндидер яңа кием даулаганнары өчен Мөхәммәт тулы бер ай дәвамында һичбер хатынының янына ятмады.) Ә кызуы басылгач, үкенә пәйгамбәр. Хәфасаны аерганына аеруча өзгәләнә. Ләкин алла үз кеше булгач ничек рәхәт!.. Беләсезме нишли алла? Без бу урында аның пәйгамбәребезгә күрсәткән мәрхәмәт-шәфкате өчен жылый-җылый зекер әйтергә тиешбез.

«Әй Мөхәммәт! — ди ул «Җиңү» сүрәсенең 2 нче аятендә, пәйгамбәребезнең хәленә кереп, — без синең элекке гөнаһларыңны, шулай ук моннан соң булачак гөнаһларыңны гафу итеп куйдык».— ди, (күрдегезме — булачак гөнаһларын да — Г. Г.) һәм, шәфкатьле алла, ак эт бәласе кара эткә дигәндәй, пәйгамбәрнең түгел, әниләребезнең тетмәләрен тетә. Ә пәйгамбәргә үзенең нәфесен тыеп азапланмаска, антын бозарга, әнкәбез Хәфасаны яңадан хатынлыкка алырга рөхсәт итә. Бер очтан Мария белән йоклауны, аны үзенә хәләл җефет, безгә әни итүне дөресли торган аять төшереп җиткерә:

«Әй пәйгамбәр! Нигә син шулай үзеңнең хатыннарыңа ярар өчен алла тыймаган эшләрдән нәфесеңне тыясың? Алла гафу итүче бит ул, алла рәхимле бит ул. Алла сиңа антыңны бозарга рөхсәт итте. Алла — синең яклаучың, алла белүче, алла бөек акыл иясе. Хатыннарыңа (Гайшә белән Хәфасага — Г. Г.) әйт: сезнең йөрәгегез мәкерле диген, хәзер үк тәүбәгә килегез, диген. Инде киреләнер булсагыз, үзегезгә үпкәләгез, алла пәйгамбәрне яклаучы, диген, Җәбраил дә, бүтән фәрештәләр дә пәйгамбәр яклы, диген. Алланың пәйгамбәргә, сезне аертып җибәреп, әйбәтрәк, күндәмрәк, иманлырак, тәкъвәрәк кызлар алырга кушуы мөмкин бит, диген».

*(Коръән, «Тыю» сүрәсе, 1—5 аятьләр.)*

[1] Һиба кылу — бүләк итү.

Тукта. Нигә «мөмкин» генә? Юк, алай аллача булмый. Алла шундук күктән «мөмкин» сезне төшереп җиткерә:

Менә нәрсә, пәйгамбәр. «Син үзең теләмәгән хатыннарны аерып җибәрә аласың, теләгәннәргә өйләнә аласың. Аерганнарыңны янәдән ала аласың. Моның өчен сиңа бернинди гөнаһ булмый».

*(Коръән, «Төркемнәр» — «Әхзаб» сүрәсе, 51 аять.)*

Кәҗә, сарыкларың белән ничек эш итсәң, хатын-кызлар белән дә шулай эш итә бир генә диясе калган!.. Бу аятьне ишеткән әнкәбез Хәфаса белән әнкәбез Гайшә шундук койрыкларын кысалар. Әә без әниләребез 8 дән 7 гә кала дип куркышып торганда, 9 әниле булып китәбез!.. Шундук мәчет ишек алдында яңа гүрнәчә җиткерелә. 9 нчы гүрнәчә... Әнкәбез Мариягә дә, пәйгамбәребезгә дә шәп булды. Берүк, алла сакласын, пәйгамбәребез генә картаю сәбәпле нәүбәтне уздырып җибәрә күрмәсен инде...

Әә пәйгамбәрнең уздыру кайда әле! Аның күзе Зәйнәпкә, үзенең асрамага алган улы Зәетнең бердәнбер хатынына төшә... Иснәнеп керүе булганмы, йомышы төшепме, — өйләренә килеп керсә, Зәет каядыр чыгып киткән, Зәйнәп яңа мунчадан чыккан, ярым ялангач хәлендә ял итеп ята.

Менә нинди икән син чишенгәч, киленкәй!.. Һәм пәйгамбәр, киленнән күзен ала алмаган хәлдә, үзенең аңар акылдан язар дәрәҗәдә гашыйк булганын әйтә дә бирә.

Үзенә әйтеп оялтсын дипме, ничекме, — Зәйнәп бу хакта иренә җиткерә. Ир нишли дип беләсез? Зәйнәбен өзелеп сөюенә карамастан, аны пәйгамбәребезгә үзе үк тәкъдим итә.

Ник?

Һәркемдә туачак бу сорауга дин китапларында бертөрле дә җавап юк. Безнеңчә, җавап мондый булырга мөмкин. Бу вакытта Мөхәммәт инде күпләр өчен тәмам культка әйләнеп җиткән була. Дөресрәге, чәһреярлары, бүтән якыннары, дәрәҗәле байлар аны шуңар китереп җиткерә. Мөхәммәт хәзер алланың нинди дер бер илчесе генә түгел, әңгәмә вакытларында, хәтта Коръән аятьләрендә ул инде «алла белән мин» дип кенә җибәрә. Төрле илләрдән килгән илчеләр, сәхәбәләрнең аңар булган ихтирам вә хөрмәтләрен күреп, хәйран калалар. Иран илчеләре булса кирәк, илләренә кайткач, аның турында менә нәрсә сөйлиләр: «Тәһарәт суы да изге икән аның. Кырылган чәчсакалын, кискән тырнагын кыйммәтле савытларда саклыйлар, әңгәмә вакытында ялгыш кына сакалына орынып киткән идем, шәкертләреннән берсе төртеп җибәрде...»

Мөхәммәтнең культка әйләнүе хакында тагын шундый бер риваять бар. Кәгапь ибне Зөһаир исемле бер шагыйрь, әле Мәккә кяферләр кулында чакта, Мөхәммәтне мәсхәрә итеп шигырь язган була. Мәккәне алгач, Мөхәммәт кешеләре аны эзләп табып, зинданга ябалар. Әә ул, качып чыгып, Мөхәммәт хозурына килә һәм аны күкләргә ашырып мәдхия җырлый. Шигырь Мөхәммәткә шулкадәр ошый, — ибне Зөһаирне гафу итә һәм өстендәге җиләнен аның иңнәренә сала... Кыйссаның хикмәтле җире менә кайда: бу җиләнгә бай сәхәбәләр янчык-янчык алтын тәкъдим итәләр. Шагыйрь баш тарта. Әә ул үлгәннән соң, Могавия исемле хәлифә бу җиләнне аның варисларыннан ун мең дирхәм алтынга сатып ала. Хәлифәдән хәлифәгә күчеп, 35 буынга җитә бу җилән!.. Безнеңчә, «нигә?» нең җавабы шул: Зәет өчен дә Мөхәммәт бу вакытта инде бөек- культ булган...

Мөхәммәт улының тәкъдимен рәхәтләнеп кабул итә. Туй. Җабраил инде әллә кайчан күктән төшеп, яшьләрне тәбрикләп, алланың бу мөбарәк никахны күкләргә язып куйганын әйтеп менеп киткән. Мөхәммәт бу тәбрикне башта әнекәбез Зәйнәп куенында кияүләп ятканда укый.

Башка берәүнеке булса, без ул тәбрик белән ак кәгазьне пычратырга уңайсызланыр идек, ләкин алла сүзләре бит! (Әле тагын, бәлкем, безнең күзгә генә шулай күренә торгандыр, асылда менә дигән изге сүзләрдер?..) Һәрхәлдә, без аны укучыга җиткерергә булдык:

«Менә син алла шәфәгать кылган вә үзең шәфәгать кылган кешегә (Зәеткә — Г. Г.) әйттең: хатыныңны өйдән чыгарып йөртмә, алладан курык дидең. Ләкин син аңар йөрәгеңдәге әйтмәдең, кеше сүзеннән курыктың. Әә сиңа кешедән түгел, алладан курку кирәк иде. З ә е т у л х а т ы н б е л ә н ү з е н е ң н ә ф е с е н б а с т ы б и т и н д е. Х ә з е р б е з а ң а р с и н е ө й л ә н д е р д е к».

*(Коръән, «Изге төркемнәр» — «Әхзаб» сүрәсе, 37 аять.)*

Аятьтәге астына сызылган сүзләрне тагын бер кабат укы, укучым, укы һәм уйла. Сүрә исеменең эчтәлегенә никадәр хас булуы турында уйла. Элек заманда бай бәтчәләрне кызлар белән кавыштырып йөрүче яучы карчыклар Мөхәммәт алласы тикле үк әдәпсез булдылар микән? Мондый явыз мәзәк алладан гайри (чыны Мөхәммәттән гайри) иң кыргый патшаларның да башына килмәгәндер.

Пәйгамбәр үзе дә бу никахы белән хәттин ашканын сизә. Хәтерегездәдер, житмәсә бер сүрәсендә, гөнаһ шомлыгына каршы, алласы аңа киленнәренә өйләнүне тыйган иде бит... Мөхәммәт соңга калып булса да, хәйлән шаргый ясый. Нишли? — Зәетнең әтисе булудан ваз кичә. Пәйгамбәр угылы Зәед ибне Мөхәммәт хәзер гап-гади бер Зәед ибне Хөррәт була да кала! Билгеле, Мөхәммәт күңелләрне йомшатырлык бу изге эшне үз ихтыяры белән түгел, алла боерыгына таянып эшли:

«Аллага таян, Мөхәммәт! — ди аның алласы. — Алла химая кылучы ул. Алла кешене ике йөрәкле итеп яратмады. Сезнең асрамага алган угылларыгызны сезгә угыл итмәде».

*(Коръән, «Төркемнәр» — «Әхзаб» сүрәсе, 4 аять.)*

Һәм шул ук сүрәнең 40 нчы аятендә:

«Мөхәммәт бер ирнең дә атасы булганы юк», — дип өсти.

Мәккәдә чагында суфиланып кына, башын түбән иеп кенә, тәсбих тартып, зекер әйтеп кенә йөргән пәйгамбәребез, патша булып алгач, шул рәвешчә, кешелек тарихында иң тәүфикъсыз, иң тотнаксыз кешегә әйләнә! Аятьләреннән күренгәнчә, ул моны үзе дә яшерми.

Каенатасы Әбү-Суфьян, Мөхәммәтнең хәрам сарайга өсте-өстенә хатын-кыз ияртеп кайтканын күреп:

— Бернинди авызлык белән җинеп булмый торган дөя икән бу, — ди.

Мөхәммәтнең җенеси тотнаксызлыгын (үз сүзләре белән әйтсәк, якынлык кылу сәләтен) бер риваять бик ачык раслый. Мөхәммәт тәмам беткәшкән, сәлперәйгән. Тотып кына йөртәләр. Иң сөекле Гайшәсе янына килеп керә. Ә Гайшә, башының бик каты сызлавын әйтеп, моңардан дару сорый.

— Дару нигә сиңа? — ди пәйгамбәр. — Синә миннән алда үлү хәерле. Мин синең күзләреңне йомдырырмын, мәет киемнәре киертермен, үз кулларым белән каберге төшереп куярмын да озаклап торып дога кылырмын.

Гайшәдә, күрәсең, юмор сәләте була:

— Әйе, — ди ул иренә җавабында. — Аннары минем өемә тагын берәр яшь хатын алып кайтып тора башларсың. Шулай бит, пәйгамбәр?

Пәйгамбәрнең хатын-кызга хиреслеген Гарәбстанда гына түгел, чит илләрдә дә беләләр. Тарихка шундый вакыйга билгеле: Киндиләр башлыгы моңар, бүләк итеп, Кайтала исемле бер яшь кыз җибәрә. Ләкин, никадәр үкенеч!.. Бу вакытта пәйгамбәребез инде Гайшә кулында җан биреп ята.

Мөхәммәт үзенең шундый әхлаксыз, шундый бозык кеше булуына, ичмаса, соңгы гомерендә бераз уңайсызлана белде микән? Шулай да була бит: бер төрле кеше, гомер-гомергә азып-тузып йөри дә, комы коела башлагач, үкенә, ояла... Юк, Мөхәммәт үкенми, оялмый, киресенчә, һәрдәм үзен әдәп вә әхлак үрнәге итеп, хәтта үзенең шул «әдәплелекләре» турында масаеп сөйли:

«Әдәпне миңа алла үзе өйрәтте, — ди ул, — минем әдәбемне алла әнә ничек матур кылды». (58 нче хәдис.)

Әйтерең бармы, искиткеч матур!.. Ләкин мондый «матур әдәпләрең» өчен, бездә димим, хәтта шул ук Мәккә яки Мәдинә кешеләре бүген сине, әлбәттә, хөкемгә тарттырырлар иде.

Пәйгамбәрләребезнең үз мәнфәгатен күздә тотып, үз теләкләренә, үз хаҗәтләренә яраклаштырып, ниһаять, үз азгынлыгын аклап язган аятьләренең хезмәте мулла, ишан, ахун, мөфтиләр һ. б. соры кортлар өчен дә гаять зур була. Моның тәэсире ислам дине үтеп кергән көнчыгыш илләрнең ханнарына да зур була. Алар, берсенберсе уздырып, хәрам сарайларындагы уйнашчы кызларның санын ишәйтәләр. Иран шаһы Фатали Хан Каджар үзенең хәрам сараенда 400 кыз асрый. 20 нче гасыр башында яшәгән төрек солтаны Габделхәмиднең уйнашчы кызлары бер меңгә җитә. Соңгы Бохар әмире Сәед Әлим үзенең нәфесен 112 кыз белән чикли.

Ә фәкыйрь-фөкара? Коллар? Алар, мескеннәр, дүрт хатын турында Коръән шәриф битләрендә уку белән канәгатьләнергә тиеш булалар, дүрткә дүрт калым кирәк, дүртесенә дүрт йорт кирәк, дүртесенә дә тигез шартлар тудырырга кирәк. Ә аның, мескеннең, дүрт түгел, бер өе дә юк. Күбесенчә (бу бигрәк тә көнчыгыш илләрдә шулай иде), гомеренә хатын чырае күрми яшәгәннәре күп була иде. Хәер, көнчыгыш илләрдә хәзер дә андыйлар еш очрый әле.

3

## «ОЯТ ҖИРЛӘРЕГЕЗНЕ САКЛАГЫЗ». ПӘЙГАМБӘРНЕҢ КҮЗЕ ШАР БУЛДЫ. «ДҮРТ ШАҺИТ ТАПМАСАГЫЗ, ЫШАНМЫЙМ».

Мөхәммәт пәйгамбәр әдәп вә хәя үрнәге булудан ерак торса да (китап күтәрә алмаслык әдәпсез мисалларны без әле монда кертмәдек), әйтеп бетергесез көнче була. Үз хатыннарын, бер очтан бөтен мөслимәләрне ят ирләр күзеннән яшерү теләге белән нишләп кенә бетми ул! Һәр мөслимәгә үзләрен танытмаслык итеп, шулай ук үзләре ят ирләрне күрә алмаслык итеп баштанаяк төренеп йөрергә боера. Хатыннарның беләзектән ары, тубыктан югары җирләре хәрам, шуннан гайри җирләрен күрсәтү хәрам эш кылу белән бәрабәр, ди. (Дини китаплар исә зина кылу белән бер дәрәҗәгә кадәр барып җитәләр.)

«Әй, пәйгамбәр! — ди Мөхәммәт үзенең алласы исеменнән, — хатыннарыңа, кызларыңа, барлык мөслимәләргә әйтә күр: йөзләренә бер үк пәрдә корып йөрсеннәр».

*(Коръән, «Төркемнәр» — «Әхзаб» сүрәсе, 59 аять.)*[1]

Юк, йөзләренә пәрдә кордырту белән генә дә чикләнми пәйгамбәр, хатын-кызга иң яхшысы: өйләрендә утыру. Чөнки:

«Хатын иренең рөхсәтеннән башка чыгып йөрсә, өенә кайтып кергәнче, алланың һәм фәрештәләрнең ачуында булыр. Хәтта ире залим кеше булса да».

*(391 нче хәдис.)*

Ә ул залим ир бер вакытта да рөхсәт итмәсә, ә хатынга чыгып керү зарур булса? — Булмагае!.. Алла белән фәрештәләр ачуына дучар буласы килмәсә, чыкмаска тиеш, бетте китте!

«Тагын мөслимәләргә шуны әйт, — ди алла, — күзләрен бик уйнатмасыннар, гаурәтләрен сакласыннар. (!) Зиннәтләре (!) күренерлек булмасын... Күкрәк авызларына күкрәкчә кисеннәр, зиннәтләрен күрсәтсәләр дә, әнә ирләренә, әтиләренә, каен аталарына, үзләренең һәм ирләренең улларына, абыйларына, энеләренә, абыйларының улларына, җенеси дәрте беткән хезмәтчеләренә, вә һәм дә җенеси дәрте кузгалып өлгермәгән улларына күрсәтсеннәр».

*(Коръән, «Нур» сүрәсе, 31 аять.)*

Йә, ничек зирәк димисең инде бу алланы! Бөтенесен, бөтенесен күздә тоткан бит!.. Тик, игътибар иттегез микән, биредә алла бер нәрсәне исәпкә алып җиткермәгән: бизәкләрен абыйларының һәм ирләренең улларына күрсәтергә ярый ди, ул. Ә бит алар арасында инде җенеси дәртне бик әйбәт белә торган айгыр егетләр булу да мөмкин иң! Ә каенатай?! Бу мәсьәләдә каенатайларны чуттан чыгарып ташлау — сизгерлекне җую булыр иде. Мисал өчен пәйгамбәребезнең үзен генә искә төшереп үтү дә җитә. Киленкәе Зәйнәпнең башын-күзен ни рәвештә әйләндерүен әйтүем...

Берәр мут художникка әйтсәң, ул, мөгаен, мондый рәсем ясар иде. Яңа гына өлгереп җиткән мөслимә күрсәтергә язык җирләрен ачкан, кием магазиннарындагы манекеншалар кебек, әрле-бирле йөреп тора... югарыда телгә алынган категория ирләр төрлесе төрле күз белән; дәрте сүнгәне — дәртсез итеп, дәртлесе — дәртле итеп, дәртнең нәрсә икәнен белеп җиткермәгән сабыйлар хәйран калып карап торалар... Әйтерен бармы, пәйгамбәребез бу мәсьәләдә җитәрлек тырышкан. Хәтта менә нинди киңәш биреп калдырырга онытмаган ул.

«Хатыннарыгыз йөргән чакта кием эчендәге зиннәтләре селкенеп торырлык каты басып йөрмәсеннәр».

*(Коръән, «Нур» сүрәсе, 31 аять.)*

Шулай да пәйгамбәр шул ук «Нур» сүрәсенең 59 нчы аятендә, кияүгә чыгу өметләре калмаган әбиләрне, шәфәгать кылып, бу кагыйдәдән азат иткән. Андый әбиләргә чикләнмәгән хөррият:

«Кияүгә чыгу өметләре калмаган әбиләргә, — ди ул, — әгәр дә мәгәр эчке бизәкләре белән мактанып йөрергә уйламасалар, бөтенләй чишенеп ташлау да гөнаһ эш түгелдер...»

Ләкин пәйгамбәр биредә дә бер нәрсәне исәпкә алып җиткермәгән, бизәкләре белән мактаныр хәлләре булган әбиләрне, ай-һай, әби дип, кияүгә чыгу өметләре калмаган дип, әйтеп була микән соң әле!?

Бу аятьләрнең көнчелек нәтиҗәсендә туган дуамаллык, хатыннарны кимсетү икәнен әйтү белән бергә, аларның фәкать гарәпләргә, аның да өстен катлавына, фәкать өстен катлавына, бер эшсез селкенеп йөрүчеләргә яраклаштырып язылган идекен күзлексез дә күреп була. Бергәләшеп уйлап карыйк: кеше танымаслык рәвештә пәрәнҗә, чадра корып, күкрәкчә, хәситә ябып, зиннәтләреңнең селкенгәне беленеп тормаслык итеп киенеп, ирләр танымас хәлдә киенеп, чиллә кояш астында урак уру яки заводта эшләү мөмкинме?! Ә бит җәһәннәм газабыннан котлары алынып беткән бичара аналарыбыз, әбиләребез Коръәннең бу кануннарын безнең гасыр башларына кадәр төгәл үтәп килгәннәр. Үтәмәүгә җөрьәт итүче шайтан арбасына утырган хатын-кызларга мәчетләрдә бәддога укылган. Тарих битләрен актарырга кирәк, әллә ниләр бардыр, хәтта әнә революция елларында муллалар һәм аларның иярченнәре бер Үзбәкстанда гына да пәрәнҗәләрен салырга җөрьәт иткән 300 хатын-кызны газаплап үтерделәр.

[1] Бу кыргый йоланы Мөхәммәт пәйгамбәр Иранда киң таралган борынгы Зороастри диненнән алган булса кирәк. Ләкин анда бу йоланың тоткан урыны бүтән. Кыргый халыкларның күбесендәге кебек, боларда да ут изге санала. Ә хатын-кыз, билгеле инде, шакшының шакшысы. Шул сәбәпле, учак янында кайнашканда сулышы кереп утны арусызламасын өчен, хатын-кыз авызын томалап йөрергә тиеш була.

Хәзер алай түгел, дисезме? Дөрес. Ә ник? Чөнки, бер сүз белән әйткәндә, хәзер иман дигәнең алай түгел. Югыйсә, Коръән, ислам дине, шәригать законнары борынгылар өчен бертөрле булып, безнең заман өчен икенче төрле диган аять тә, хәдис тә, тәфсир дә юк. Моңа хәтта ишарә генә дә юк.

Әниләребезнең, әбиләребезнең хәленә күз салыйк. Таң иртәдән караңгы төнгә кадәр болай да интектергеч эшне пәрәнҗәләргә төренгән хәлдә эшләп кайтканнан соң да әле, шәригать кушуы буенча, үзләрен узган-барган ир-ат күзеннән сакларга тиеш булалар. Билгеле, моның өчен тәрәзәгә юка гына пәрдә кору да җитәр иде. Ләкин алай хатынының күрмәсәләр, хатының ирләрне күрүе мөмкин ич!.. Шунлыктан Иран, Ирак, Төрек, Пакистан кебек саф ислам илләрендә, Бохара, Хива кебекләрдә урам якка тәрәзә кую бөтенләй булмый. Бу нәрсә узган гасырларда Идел буе татарларына да керә башлый, ләкин Идел агымы шәригатьнең бу караңгы йоласыннан көчлерәк булып чыга, безнең әниләр, әбиләр бәхетенә каршы, безнең якларга менеп җитә алмый кала.

Кайбер дин ислам илләрендә хатын-кызны ят ирләр күзеннән саклау мәсьәләсендә тагын да еракка китәләр. Фатимитлар мәзһәбенең Хәким исемле хәлифәләре хатын-кызларның хәтта пәрәнҗәләр киеп тә урамга чыгып, ир-ат күзенә күренеп йөрүләрен бөтенләй туктату теләге белән, илдә хатын-кыз аяк киемнәре тегүне тыя торган указ чыгара.

Хатын-кызны шундый «зур гөнаһ»тан саклау буенча күп кенә чаралар күргәннән соң, Мөхәммәт пәйгамбәр үз хатыннарына карата махсус аятьләр индерергә керешә:

«Әй, мөселманнар!— ди ул, алла исеменнән мөрәҗәгать итеп.— Пәйгамбәр өенә фәкать аш мәҗлесенә чакырылганда гына килегез. Ашап бетергәч, тегене-моны сөйләшеп тормастан, таралышу ягын карагыз. Пәйгамбәрне, зинһар, хафага салмагыз. Ул бу хакта сезгә үзе әйтергә уңайсызлана, ләкин алла сезгә тиешлесен әйтергә бер дә уңайсызланмый... Пәйгамбәр хатыннарыннан берәр нәрсә сораганда, чаршау аша гына сорагыз... Шулай иткәндә, аларның да, сезнең дә йөрәкләрегез азмас... Тагын шуны белеп торыгыз: Мөхәммәттән калган хатыннарга өйләнергә ярамый сезгә. Бу пәйгамбәрне хафага салу булыр иде, зур гөнаһ булыр иде бу.»

*(Коръән, «Төркемнәр» — «Әхзаб» сүрәсе, 53 аять.)*

Күрәсез, Мөхәммәт үзе исән чакта гына түгел, үлгәннән соң да хатыннарын көнләячәк әле!

Кемнәргә өйләнергә ярый, кемнәргә ярамый дигән инструктив аятьне онытмадыгызмы әле? Безне хәзер аның бер генә төше — «үз әниләрегезгә өйләнергә ярамый», дигән төше кызыксындыра. Бәгъзеләрнең алай ук түгелдер лә диюләре, ахмак сүз ич бу, үз әнисенә кем өйләнсен инде, диюләре мөмкин. Ләкин бу шулай, акка кара белән язылган. Һәм бу аятьнең дә асылында пәйгамбәрнең хатыннарын көнләве ярылып ята. Ул моның белән аерып җибәргән хатыннарын да, үзе үлгәннән соң тол калачакларын да башка ирләргә кияүгә чыкмаслык ясап куя. Төшенмисез? Ә с о ң  п ә й г а м б ә р  х а т ы н н а р ы н ы ң  һ ә р б е р с е  һ ә р  м ә э м и н  м ө с е л м а н г а  ә н и  т и я  т ү г е л м е  соң?

Шулай да, күрәсең, пәйгамбәр хатыннарының һәм майлы күз ирләрнең бу аятьләр белән бик үк хисаплашасылары килми (моның бер үрнәгеи алдагы биттә укырсыз). Инде 60 белән барган пәйгамбәр 16 белән 30 арасындагы дәртләре ташып торган берсеннән-берсе чибәр хатыннарына карап карап тора да, шиккә төшә һәм ул аларны куркытырга керешеп, алласы исеменнән берсеннән-берсе усал аять яудыра:

«Әй, пәйгамбәр хатыннары! Сез — бүтән хатыннар кебек түгел... Алладан курка торган булыгыз, югыйсә, бозык ирләрнең үзегезгә кызыгып куюлары мөмкин, кешеләр белән артык ягымлы итеп сөйләшмәгез. Өегездә генә утырыгыз».

*(Коръән, «Төркемнәр» — «Әхзаб» сүрәсе, 30—33 аятьләр.)*

«Әй, пәйгамбәр хатыннары! Кайсыларытыз Мөхәммәткә хыянәт итсә, аларга газапны ике өлеш бирәчәкмен, алла өчен бу җиңел эш».

«Әй, Мөхәммәт хатыннары! Сезләргә гыйбрәт булсын! Нух белән Лут пәйгамбәрләрнең хатыннары хыянәт иткән иделәр. Ләкин алар барыбер алладан качып котыла алмадылар. Без аларга җәһәннәмгә керергә куштык».

*(Коръән, «Тыю» сүрәсе, 10 аять.)*

Ләкин хатыннарын шундый пәрәнҗәләргә, күкрәкчә, хәситәләргә төреп утыртса да, өйләрен таш коймалар белән уратып алса да, тәрәзәләрен ишек алдына гына каратып уйса да, өстәвенә, шундый аятьләр белән ныгытып куйса да, пәйгамбәрне көнләштерерлек шундый бер хәл килеп чыга.

Сугыш вакытында була бу. Эш шунда ки, Мөхәммәт сугышка барганда берәр хатынын үзе белән ияртеп йөри торган була. Җирәбә буенча. Бу юлы җирәбә иң сөекле хатыны — әнкәбез Гайшәгә чыга. Бер заман, сугыш беткәч, Мөхәммәт хәрби чатырына

кайтып керсә, Гайшәсе юк!.. Әлбәттә, эз эзләмәгәннәрдер, кайдан гына эзләп бетермәгәннәрдер, ниһаять, пәйгамбәр һәм аның гаскәре өметен өзеп кайтырга чыга. Әнкәбез Гайшә Мөхәммәтне үзенең гаскәре белән байтак җир киткәч кенә куып җитә. Дөягә атланган, дөясен бер яшь егет җитәкләгән...

— Мәрҗәнем чәчелгән иде, шуны җыеп йөрдем, — ди чибәр хатын. Ләкин, ай-һай, чатыр авызында чәчелгән мәрҗәнне җыеп йөргәндә кешеләрнең кычкыра-кычкыра сине эзләп йөргәннәрен, ниһаять, гаскәрнең быргылар уйнатып, барабаннар кагып кайтып киткәнен ничек ишетмәдең икән соң син, Гайшә абыстай?.. Белмим, моңа нинди тиле бәрән орлыгы ашаган бәндә генә ышанды икән!

Гайбәт бөтен Мәдинәгә, бөтен тирә-якка тарала. Дуслар Мөхәммәткә теләктәшлек күрсәтә, дошманнар сөенә. Пәйгамбәр көнчелектән нишләргә белми. Юлдашлары әнкәбез Гайшәне аерып җибәрергә киңәш итәләр.

— Гали, әйт, кардәшем, син ни әйтсәң, шулай эшлим...

Сез Галине бераз төсмерләсәгез кирәк. Мөхәммәтнең туганнан туганы, ислам динен Хәдичәлән кала беренчеләрдән булып кабул иткән үсмер егет. Мөхәммәтне хәвефхәтәрсез Мәдинәгә качыру өчен аның урынына ятып калган кеше. Хәзер инде ул Мөхәммәтнең чәһреярларыннан берсе, арада сөеклесе. Оста сугышчы, чиксез гайрәтле ирәп. Соңыннан аның батырлыклары турында легендалар барлыкка килә. Имештер, канау сугышында калканы ярылгач, бер капканы тупсасыннан йолкып ала да, шуны калкан итеп, тәкбир әйтә-әйтә, дошман гаскәре эченә атылып килеп керә... Аның гөрзенә тарма, тарсаң — арма: бер селтәнүдә бил тиңентен җиргә сеңеп, җаның җәһәннәмгә киткәнне көт тә тор!..

Ислам дөньясының сөеклесе булган бу кешене кайбер мәзһәпләр үзе вафат булганның соңында Мөхәммәттән артык олылыйлар. Дин ислам дөньясында аның дәрәҗәсен күкләргә күтәрә торган берсеннән берсе көчле легендалар туа.

Җөмләдән берсе:

Алла Мөхәммәткә әйткән имеш, ди, әгәр син булмасаң, мин күкләрне ясап тормаган булыр идем, ә инде Гали туасы булмаса, сине дә тудырмаган булыр идем, дигән ди... Имештер, алла Гали белән Мөхәммәтне бертигез күргән икән, бу турыда Коръәндә «Ике йолдыз» исемле сүрә дә булган икән дә, хәзрәте Госман, үзе хәлифә булудан файдаланып, хәсетлек белән бу сүрәне төшереп калдырган икән...

Икенче легенда: Шигыйләр мәзһәбендә киң таралган риваятьләргә караганда, Гали Җәбраилнең ялгышуы сәбәпле генә пәйгамбәр булмый калган. Имештер, карга каргага, чебен чебенгә никадәр охшаса, Гали белән Мөхәммәт бер-берсенә тагын да күбрәк охшыйлар. Нәтиҗәдә, Җәбраил Галигә дип алып төшкән вәхине ялгыш Мөхәммәткә тапшыра. Ә алла: (нәкъ Якуп пәйгамбәр белән аның туганы Гаес әкияте!..) «Әйдә ярар инде, Мөхәммәт булса, Мөхәммәт булыр», — дип, дәшми кала...

Шул ук шигыйләр бүген дә менә нәрсәгә ышанып яшиләр: Гали алланың бер өлеше — ул үлмәгән. Көннәрдән бер көн болытлар өстендә пәйда булачак. Аннан җиргә төшеп, анда хәзер хаксызлык никадәр булса, шулкадәр хаклык урнаштырачак...

...Гали Мөхәммәткә Гайшәне шулай ук аерып җибәрергә киңәш бирә. Ләкин, син ни әйтсәң шулай эшлим, дигән Мөхәммәт сүзендә тормый... Гайшә — бердән, Әбүбәкер кызы, икенчедән, пәйгамбәрнең иң сөекле хатыны, яңа өлгереп җитеп килә, чибәрлектә тиңе юк. Өченчедән, хатынының хыянәтен икърар итү — Мөхәммәт өчен зур хурлык булыр иде. Бу аның пәйгамбәрлек репутациясенә, шулай ук ирлек репутациясенә тап төшерү булыр иде... Пәйгамбәр җәнҗалны йомып калу теләге белән шундук берничә аять индерә:

«Гайбәт дөрес икән, дүрт шаһит китерсеннәр, — ди ул. — Китермиләр икән, алар ялганчы. Сиксән камчы сугыгыз».

*(Коръән, «Нур» сүрәсе, 4 аять.)*

Пәйгамбәр... Тагын бер тыныш ясап алыйк. Бу сүзне гадәт буенча гына куллануыбызны, пәйгамбәр — киләчәктә ниләр буласын белеп хәбәр бирүче дигән сүз икәнен, Мөхәммәтнең исә алдагы минутта гына да нәрсә буласын белмәгәнен әйткән идек. Гайшә абыстай вакыйгасы моңа өстәмә дәлил. Хыянәт кыласын белгән булса, хәтта шикләндерер булса гына да, Мөхәммәт аны, әлбәттә, яныннан җибәрмәс иде, яки көчле сак астында тотар иде. Тагын хыянәт кылганын-кылмаганын болай да белер иде, шикләнеп, соң чиктә көнләшеп, шаһидләр эзләп йөрмәс иде...

Игътибар белән укыган укучы үзе дә күргәндер, Коръәндә бәян кылынган вакыйгаларның реальләре фәкать булып үткән вакыйгалардан гыйбарәт. Кичә уракка төшәләр, бүген гәзит шул хакта хәбәр итә. Коръән дә шулай, фәкать шулай. Коръәндә Мөхәммәтнең нибары бер мәртәбә пәйгамбәрлек итүе, ягъни киләчәктән хәбәр итүе билгеле.

«Румнар җинелде. Ләкин тиздән алар үзләре җиңәчәк», ди ул һәм бу раска килә. Ләкин моның өчен пәйгамбәр булуның бер генә дә хаҗәте юк. Гитлерның җиниләчәген пәйгамбәр түгел, хәтта гаскәр башлыклары да түгел, безнең бик күбебез белеп торды ич. Чөнки шартлар үзе шуны күрсәтеп тора иде. Мөхәммәт әйткән румнар белән дә эш шулай тора.

Алланың, чыны Мөхәммәтнең, тагын бер мәсьәләдә киләчәкне хәбәр итүе турында

сүз йөри. Имештер, кешеләрнең тимер кошларга (самолетларга) утырып йөриселәре Коръәндә хәбәр итеп куелган. Чеп-чи ялган. Коръәндә тимер кошларга хәтта ишарә дә юк, анда тик бер буталчык аять кенә бар:

«Җеннәр һәм кешеләр төркеме! Әгәр сез җирдән ары һәм күктән ары (?) менә алсагыз, менә бирегез. Ләкин хакимлек белән генә (?)»

*(Коръән, «Рахман» сүрәсе, 33 аять.)*

Биредә сүзнең самолетлар турында бармаганын шул ук «Рахман» сүрәсе, тагын «Сад» сүрәсенең 9—10 аятьләре әйтеп тора.

«Менсәгез — сезнең өскә төтенсез ялкын һәм куе төтен җибәрелер һәм сезгә ярдәм итүче булмас». «Менеп карасыннар соң. Нинди генә гаскәр бауга ябышып (?) менсә дә, куып төшереләчәк...»

70 ел инде, кеше (әлбәттә, җеннәрдән башка гына) күктә сәяхәт итә. Хәзер анда көн саен бернечә миллион кеше менеп төшә. Ләкин кеше өстенә алла вәгъдә иткән ялкынсыз төтен дә, куе төтен дә җибәргәннәре юк, куып төшергәннәре дә юк. Ә Коръәннең авторитетын күтәрү өчен безнең шарлатан муллалар уйлап чыгарган «тимер кошлар» — халык әдәбиятындагы очар палас, канатлы атларның бер начар варианты гына [1].

Пәйгамбәр белән әнкәбез Гайшә җәнапләренә кайтыйк.

Дүрт шаһит дигәч, халык аптырап кала.

Шаһит? Дүрт шаһит?! Соң андый эшне нинди тиле дүрт шаһит алдында эшләсен ди инде?..

Кыскасы, шаһитләр табылмый. Шуннан Мөхәммәт болай дип өсти:

«Дүрт шаһитләре булмый торып, гөнаһсыз хатыннарга гаеп ташлаучыларга 80 таяк сугыгыз».

*(Коръән, «Нур» сүрәсе, 4, 13 һ. б. аятьләр.)*

Кызганыйкмы пәйгамбәребезне, шул кирәк аңа, диикме? Кем ничектер, ә хатыннар, хәтта бу китапны мина бәддога кыла-кыла укучы абыстайлар, минемчә, шул кирәк аңар диючеләр ягында.

## 4

## «ХАТЫНЫҢ КИРЕЛӘНСӘ, ЯНЫҢА ЯТКЫРМА». «КӘКРЕ КАБЫРГАДАН ЯРАТЫЛГАН БИТ АЛАР!» УРАЗА АЕ ХӨРМӘТЕНӘ. ХӘЗРӘТЕ ГОМӘРГӘ РӘХМӘТ ТӨШСЕН.

Хатын-кыз мәсьәләсенә багышланган бүлекнең беренче юлларына әйләнеп кайтыйк әле — пәйгамбәребезнең, һәр мөселманга 4, үземә күпме теләсәм шул хәтле дигән җиренә. Бүгенге көндә теләсә кайсы хатын яки яшь кызга, 9 нчы түгел, икенче генә булып килергә әйтеп карагыз әле. Ул, уйнап әйтә дип белеп, кычкырып көләчәк, инде сүзеңне чынга алса, дөнья йөзендә йөрерлегеңне калдырмаслык итеп, хур итәчәк. Ә борын заманда хатын-кыз ничек риза булды икән соң?

Мәсьәлә шунда ки, хатын-кыз, Коръән өйрәтүенчә, иренең колы бит. Дөрес, ир үзе дә кол. Әүвәл башлап, ул алла колы, аннары хуҗа колы. Ә хатын-кыз, шулар өстенә, иренең колы. Ир каршында хатын ни дә, сыер яки сарык ни, тавык-чебеш ни. Пәйгамбәребез бу хакта әледән-әле безнең исебезгә төшерә тора. Һәм моны, үзенчә, бик төпле рәвештә нигезли дә. Анабыз Хава нәрсәдән яратылган? — Атабыз Адәм кабыргасыннан. Димәк, аның хуҗасы кем? Шуннан үзең аңла инде... Тагын шунысы: алла Иблисне, пәри-җенне, һәр хәшәрәтне үзе ясаган бит, дин китапларының раславына караганда, алла анабыз Хава белән үзе мәшәкатьләнеп тормаган, бу эшне Җәбраилгә генә тапшырган.

Соңга таба пәйгамбәр хатын-кызның нинди кол, нинди хайван икәнен ачыктан-ачык әйтеп бирә:

«Ирләр үзләренең дәрәҗәләре белән хатыннардан өстен. Алла ирләргә өстенлекне үзе бирде, — ди һәм безгә шундый боерык бирә: — Хатыннарыгыз киреләнсә, акылга утыртыгыз, кыйнагыз, яныгызга яткырмагыз».

*(Коръән, «Сыер» сүрәсе, 228 аять, «Хатын-кызлар» сүрәсе, 38 аять.)*

Сабыр, пәйгамбәр! Бәлкем, хатының хаклы рәвештә киреләнә торгандыр.

Буламы соң! Кабыргадан яралган дип әйтте бит ул. Ә кабырга һәрвакыт кәкре. Бәс шулай булгач, аның сүзе дә кәкре була инде. Ир аны гелән турайтып торырга тиеш. Турайт, мөселман, турайт!

---

[1] Мондый яһүдләрдә бар. Алар, имештер, Тәуратта ахыр заман алдыннан җир йөзен тимер чыбык чолгап алыр дип әйтелгән дип беләләр. Бу да тимер кошлар кебек үк чеп-чи ялган. Тәуратта андый сүз юк, була да алмый. Тәурат язылган заманнарда тимер чыбыкның үзе дә, сүзе дә булмый әле.

Кешене аллага сәҗдә кылдырган кебек, Мөхәммәт бер мәлне хатыннарны да ирләренә сәҗдә кылдыру тәртибен кертү уе белән дә хыяллана, тик, ничектер, моныына җөрьәт итми кала:

«Әгәр, — ди ул, — мин кешенең кешегә сәҗдә кылуын боерыр булсам, хатыннарны ирләренә сәҗдә кылырга кушар идем».

*(«Мең дә бер хәдис», 668.)*

Алла (чыны пәйгамбәр) хатын-кызны кимсетү өчен, мыскыллау өчен иң бозык ирләрнең дә башына килмәслек оятсыз сүзләр эзләп таба. Ата-бабаларыбыз ислам динен кабул иткәннән бирле бу сүзләрне, әлбәттә, мәгънәләрен белмәгән хәлдә, изге күреп, илаһи күреп, мәдрәсәләрдә селкенә-селкенә, мәчет идәннәрендә ауный-ауный ничәмә-ничә тапкырлар тәкрарламаганнардыр!.. Мәгънәләрен фаш итү өчен, шул ук вакытта пәйгамбәребезнең «әдәби сәләте» никадәр көчле булганны күрсәтү өчен, без ул сүзләрне, никадәр оятсыз күрсәк тә, кайберләрен телгә алып китәргә кирәк таптык:

«Хатыннар — сезнең иген кырларыгыз, — ди ул. — Үзегезнең бу кырларыгызга кайчан теләсәгез, шунда барып кайтыгыз».

Бу аять мөэмин мөселманга яхшырак аңлашылсын өчен дини китаплар бөтен әдәби сәләтләрен кызганмыйлар. Мәсәлән, «Тәфсир Ногмани»нең җөзьә әвәлнең 54 нче битендә без түбәндәгеләрне укыйбыз:

Яһүдләр әйтте: «Бер кемсә хатынын арт яктан җимагъ кылса, баласы чалыш күзле булып туар дип. Аллаһ тәгалә яһүдләр сүзен ялганга чыгару өчен әйтә: хатыннарыгыз сезнең иген урыннарыгыз. Бәс килегез игенлекләрегезгә теләсә кайсы яктан, — дип».

*(Коръән, «Сыер» сүрәсе, 223 аять.)*

Моннан соң да алланы һәм дини язучыларны өметсез шагыйрь дисәң!... Аты-юлы белән әйтмиләр, ә аңлашыла. Бу бит, борынгы кыргый «Талмут»ның: «Кеше итне теләсә кыздырып, теләсә пешереп, теләсә чи килеш ашаган кебек, хатыннарын да теләсә ничек файдалансын», дигәненнән әллә никадәр көчлерәк!

— Ә хатының теләмәсә?

— Шул хайванмы? Теләми генә карасын! Әнә пәйгамбәребез нәрсә әйтеп калдырган:

«Хатын дөя өстендә булса да, ир хезмәтеннән баш тартмаска тиеш».

*(«Мең дә бер хәдис», 391.)*

Аллаһ тәгалә мондый әдәпсез урыннарны аеруча төчеләнеп, тасвирлы итеп, агаененең күңеленә сеңеп калырлык итеп бизәкләгән. Мәсәлән, ураза ае хөрмәтенә «индергән» бер аятендә, якынлык кылу турында яңа күрсәтмәләр биреп, ул менә нәрсә ди:

«Ураза аенда сезгә төннәрен хатыннарыгыз белән якынлык кылырга рөхсәт итәбез. Алар сезнең киемнәрегез, сез аларның киемнәре... Алла сезнең үз-үзегезне алдаганыгызны белде, сезне гафу итте. Хәзер инде төне буе якынлык кыйлыгыз...»

*(Коръән, «Сыер» сүрәсе, 183 аять.)*

Күрдегез, гафу итеп кенә дә калмый, тыелып маташканнары өчен битәрли... Юмартланып китеп, хәтта, хатыннарны бер генә тапкыр булса да чын мәгънәсендә ирләр белән тигезли: алар безнең киемнәребез, без аларның киемнәре. Ә нәрсә өчен гафу итә алла, кемне гафу итә? Монысын безгә дини язучылар тирән дулкынланып, тирән дулкынланырлык итеп аңлатып бирәләр.

Эш шунда ки, ураза аенда җимагъ кылу авыз ачканнан алып ясигъ намазына чаклы гына дөрес була. Ләкин (өммәтебезнең бәхетенә каршы) көннәрдән бер көн: «Хәзрәте Гомәр ясигъ намазыннан чыкканның соңында җимагъ кылды. Җимагъ бәгъдендә, пешиман булып, рәсүлуллага хәбәр итте. Рәсүлулла әйтте, бик үк тиешле эш кыйлмагансың икән шул, кайнатай дип... Бәс хәзрәте Гомәр, бик кайгырып, өенә кайтып китте. Шуның сәбәпле аллаһы тәгалә уразада таң беленгәнчегә кадәр җимагъ кылуны рөхсәт итеп ушбу аятьне иңдерде».

*(«Тәфсир Ногмани», беренче җөзьә, 42 бит.)*

Мин болай дип уйлыйм. Бу юмартлыгы өчен аллага шөкерана кылудан әлек без хәзрәте Гомәргә рәхмәт әйтергә, аны яхшы сүзебез белән искә алырга тиешбез... Ягез, җәмәгать, рухына бер фатиха. Авыр туфрагы җиңел булсын. Амин. Ә шуннан Гомәр нишли, сәхәбәләр? Алар, алланың үзеннән шундый күрсәтмә булгач:

«Ясигъдан чыккачтын да (тиз генә кайтып) җимагъ кыла торган булдылар».

*(«Тәфсир Ногмани», беренче җөзьә, 42 бит.)*

Төп мәсьәләгә кайтыйк. Хатын-кызны оятсыз рәвештә мәсхәрәли, кимсетә торган, аны ачыктан-ачык мәхлүк дәрәҗәсенә төшерә торган аятьләр Коръән шәрифтә, изге дин китапларында болар гына түгел.

Ибраһим пәйгамбәрнең Мысыр иленә килеп, үз карчыгының тәнен сатып йөрү кыйссасын хәтерләгез. Лут пәйгамбәрнең «мәгез, теләсәгез нишләтегез», дип, кызларын азгын ирләр алдына чыгарып ташлавы үзе генә дә ни тора!..

Коръән хатын-кызның дәрәҗәсен җәмгыятьтә дә кимендә бермә-бер түбән итеп билгели. Мәсәлән:

«Судта гваһлык бирү өчен ике ир кеше булу тиеш. Ике ир булмый икән, бер ир, ике хатын булу шарт».

*(Коръән, «Сыер» сүрәсе, 282 аять.)*

Күрәсез, ике ирне хәтта дүрт хатын да алмаштыра алмый. Берсе тәгаен ир заты булырга тиеш.

Кайда-кайда, ә мирас малын бүлгәндә хатын-кызның дәхеле ир туганыныкыннан өстен булмаса да, кимендә, бертигез булырга тиеш иде. Ләкин, тот капчыгыңны, кызый! Пәйгамбәр абзаң әнә нәрсә дип әйтеп калдырган:

«Мирас малы ир балага ике өлеш, кызларга бер өлеш».

*(Коръән, «Хатын-кызлар» сүрәсе, 12 аять.)*

Ә кыз бала үз көнен үзе күрә алмастай сабый, яки гарип булса, яки тол булалрак, итәк тулы бала белән калса? Калмагае! Коръәннең хөкеме шундый.

Иргә ике өлеш, хатынга бер өлеш. Бу законның хәтта анабыз Хавага карата да шулай булганын дәлилләп, Рабгузи шундый бер әкият сөйли: алланың дәргаһыннан сөрелеп, җирдә каңгырып йөргән Адәм белән Хавага Җәбраил фәрештә җәннәттән кумәч алып төшеп бирә. «Күмәчне өчкә бүлеп, икесен Адәмгә, берсен Хавага тоттыра...»

Ә кыз балага җир бирелмәү? Бу да бит Коръән белән шул шәригать бакчаларында үскән ачы җимешләр.

Шунлыктан, кыз бала дөньяга килгәч, безнең ата-бабаларыбыз: «син туганчы бер таш туса, ичмаса берәр эшкә ярар иде кана...» дип уфтана торган булганнар. Уфтану җырларда да җирлек тапкан.

Кыз бала дөньяга килсә,
мендәр белән каплагыз.

5

## «ЯРТЫ АКЫЛЛАР, ЧҮПРӘК БАШЛАР». «СЕЗГӘ ДИГӘН ҖӘННӘТ ИРЛӘРЕГЕЗ АЯК АСТЫНДА». ТАЛАК ӘКӘМӘТЛӘРЕ.

Хатын-кызны кимсетмәгән дин юк. Мәсәлән, яһүд дине болай ди: «һәм әйтте алла Мусага болай дип: Исраил балаларына әйт, әгәр бер хатын йөккә калса һәм ир бала тапса, 7 көн пычрак булыр, 33 көн канынннан тазарып ятарга тиеш. Әгәр кыз бала тапса, 14 көн пычрак булыр, 66 көн канынннан тазарып ятарга тиеш».

*(Тәүрат, Левит, 12 бүлек, 1—5 җөмлә.)*

Ә христиан динендә, мәсәлән, бер заман «хатын-кыз кешеме — юкмы?» дигән мәсьәлә кузгала. Мәсьәләне хәл итү өчен төрле илләрдән иң зур чиндагы руханилар җыйнала. Берничә көн дәвам иткән каты бәхәстән соң гына (анда да бер тавыштан түгел, күпчелек тавыш белән) «шулай да хатын-кыз — кеше» дигән карарга киләләр. Бу — язучы фантазиясе түгел. 14 гасыр элек, Мөхәммәт пәйгамбәр туар илләрда, Грециянең Макаона шәһәрендә булган хәл.

Шулай да кеше... Ә Мөхәммәт әнә шул шулай даны да әйтми. Аның каравы, үзенең позициясендә нык торганы хәлдә, менә нәрсә ди ул:

«...Иң элек үз нәфесеңне вә үз хаҗәтләреңне тәмам кыл, үзеңнән артса, хатыныңның хаҗәтенә сарыф ит»...

*(«Җәвамигыль кәлим», 3 нче хәдис.)*

Капитал илләрендә хатын-кызга карата гадел булмаган законнар хәзер дә яшәп килә. Ләкин аларның берсе дә безнең алланыкыларга җитми. Хатын-кызның иренә, иренең хатынына хыянәт итүләре өчен бирелә торган җәзаларга гына күз төшереп үтегез.

«Хатыннарыгызның берәрсе хыянәт кылса, җаны чыкканчы бикләп тотыгыз. Яки алла аларга юл күрсәтер,— ди аллабыз.— Әгәр дә ирләрдән ике кеше шул эшне эшләсә, аларга җәза бирегез. Ә инде бу ирләр, тәүбәгә килеп, яхшы гамәл кылалар икән, тимәгез. Чөнки алла тәүбә итүчеләргә шәфкатьле, мәрхәмәтле».

*(Коръән, «Хатын-кызлар» сүрәсе, 19—20 аятьләр.)*

Икенче төрле итеп әйткәндә, бер үк гөнаһ өчен хатыннарны гомерлек зинданга ябып чертегез, ә ирләрне аркаларыннан сыйпагыз...

Хатын-кызны тагын ничек кимсетергә мөмкин, нинди сүз белән мыскыл итәргә? Бар да әйтелеп бетте кебек... Юк, бетмәгән әле. Пәйгамбәр безгә, хатыннар әле тагын Иблис ләгыйн хезмәтчеләре дә, ди.

«Хатыннар — шайтан арканыдыр», — ди ул. «Хатын — шайтан тозагыдыр»... Шайтан ләгыйн хезмәтендә буларак, элек заман хатыннар хәтта бөтен бер милләтне бәлаказага дучар иткәннәр:

«Бәни Исраил башына килгән фетнәнең хатыннар аркасында булганын хәтерегездән чыгармагыз».

*(184, 512, 185 хәдисләр.)*

Сүз нинди фетнә турында бара — билгеле түгел. Ләкин мәгънәсе ачык: хатыннарыгыздан сак булыгыз, милләтегез белән харап итеп куймасыннар.

Эш моның белән генә бетми. Пәйгамбәр үлгәч, дин башлыклары, хәлифәләр, аның хатын-кыз турындагы законнарын камилләштерү юлында нинди генә мөгез чыгармыйлар!.. Кайбер дин ислам илләрендә кеше үтергән өчен штраф. Бу җинаять өчен дә бичара хатын-кызны кимсетергә кирәк: хатын-кызны үтергән өчен штраф икеләтә ким алына!

Ислам дине хатын-кызның хайван хөкемендә икәнен мөселманнарның каннарына шулкадәр сеңдерә ки, аның шаукымы революциядән соң да озак дәвам итә әле. Бер мисал. Урта Азиядә 20 нче елларда була бу хәл. Партия мәктәбенә укырга кергән өчен хатынын кыйнап үтергәч, кулга алырга килгән милиционерларга ир болай ди: «Ирләре сүзеннән чыккан, ят ирләр белән сөйләшкән хатыннарны шәригать үзе үтерергә куша ич... аның өчен казый мине берни эшләтми, менә күрерсез...»

Бичара хатын-кыз мондый хәлләргә күнеп беткән була. Узган гасыр урталарында Казан шәһәренә сугылып киткән бер сәяхәтче шундый вакыйганың шаһите булуы турында язып калдырган. Бер хатын төрмә капкасы төбендә елап утыра. Бу: «Ник елыйсың?» — дип сорый.

— Иремне төрмәгә яптылар.

— Нәрсә өчен?

— Бер гаепсезгә. Без өч көндәш идек. Беребезне асып үтерде.

— Соң, шулай булгач, гаепсезгә була димени? Кеше үтерү зур җинаять.

— Менә тагын. Үз хатынын үтерде ич ул. Аскан бавына хәтле үзенеке, урланган бау түгел.

Мөслимәләр дөньядагы тигезсезлектән үлгәч тә котыла алмыйлар. Дин ислам илләренең бик күбесендә хатын-кызның кабере ирләрнекеннән чирек аршын тирәнрәк казыла. Янәсе, анда да ирләр белән бер тигез ятмасын!..

Ә хатын-кызга бер үк эш өчен ярты хак түләү?! Хатын-кызны мир җыелышларына кертмәү?! Хәтта мәчеткә!.. Дөрес, шәригать анысын ярамый дими, шулай да мәчет янына барырлыкларын калдырмый:

«Хатын-кызның ялгыз укыган намазы — мәчеттә укыганга караганда 25 мәртәбә саваплырактыр».

*(523 нче хәдис.)*

Тагын менә монысын кимсетү димичә ни дисең:

«Каберләрне зыярат кылучы хатыннарга алланың ләгънәте төшсен!»

*(653 нче хәдис.)*

Газиз баласы үлде, гомер иткән ире үлде, ә хатын аларны каберлеккә озата барса, алланың ләгънәте төшәчәк. Алла ләгънәте!.. Бу инде сиңа ирең йодрыгы гына түгел... Һәм бичара ана үзен тыеп калды. 1913 елда берничә хатын-кызның бөек шагыйребез Габдулла Тукайны зыяратка озата килүе татар дөньясында сенсация булды. «Аң» журналы бу хәлгә шатланып язды. Ә дин ислам әһеле алланың дәргяһыннан сөрелгән бу хатын-кызларга (512, 184 хәдис сүзләре белән әйтсәк, «шайтан тозакларына», «шайтан арканнарына») мәчетләрдә кул аркасын күтәреп, бәддога укыды.

Алда күреп үттек, ир хатынны сатып ала. Табигый ки, сатып алган нәрсә тузса, кеше аны чыгарып ташлый. Ир дә хатынын нәкъ шулай итә, моның өчен расходланып игълан биреп торасы юк, судка гариза язасы, айлар буена судның булганын көтеп йөрисе юк. Өч кәррә: «Талак, талак, талак!» — шуның белән вәссәлам. (Хәзерге мөфтиебез Шакирҗан Хәялетдин җәнапләре аңлатканча, бу — җаның җәһәннәмгә китсен дигән сүз була.) Һәм хатын башын колларча түбән иеп, бала-чагаларын җитәкләп, төенчеген кыстырып чыгып китәргә тиеш була.

— Ә хатын үзе аерылырга теләсә?

Тыныч бул, әй мөселман! Алла яклыйм дигәнен яклый инде ул... Менә кайчак кәҗәң белән ишәгең синнән китү турында сүз кузгата ала торган булыр — шул чак, бәлкем, шәригать, хатыныңа да сине талак итү хокукы бирер...

Ләкин бу талак дигәннең ирләр өчен дә бер көйсез ягы бар. Кайчак низагъ вакытында ир, алдын-артын уйламастан, кызып китеп, хатынына өч тапкыр «талак!» дип әйтеп ташлый. Аннан үкенә, ләкин эш узган. «Сыер» сүрәсенең 230 нчы аяте нигезендә, хәзер син хатыныңны берничә көн бүтән бер ир куенында йоклап чыкмый торып кире ала алмыйсың... Ләкин наян абзыйлар монда да җаен таба булганнар. Хатыннарына вакытлы кияүне үзләре сайлаганнар. Ниндине? Бер аягы җирдә, бер аягы гүрдә булган берәр картны, җенеси дәрманы беткән кешене!.. Яки Зөләйханың Йосыф пәйгамбәргә хәтле булган ире кебекне!..

Талак турында хикәя булырдай мәзәк вакыйгалар бар. Дин укытучы булырга имтихан тотып, ахырда дәһри булып киткән Г. У. Мөслимов үзенең «Коръәнгә ышанырга ярыймы?» исемле китабында Волгоград өлкәсенең Бәхтияр авылында яшәүче Габделмәновтан ишеткән шундый бер кызыклы вакыйга турында сөйли.

«Минем Харис исемле бер танышым бар иде. Бер тапкыр бу эчеп кайта да хатынына: «Талак, талак!» — дип кычкыра. Айныгач, күрше карчык моңа: «Нигә талак иттең? Мәнә хәзер хатының сиңа харам инде», — ди. Бу, ышанмыйча, муллага бара. Мулла күрше карчыкның сүзләрен Коръән аятьләре белән раслый, һәм, шәригать буенча хатынын берничә көнгә башка бирәүгә биреп торырга тиешлеген әйтә.

— Берәр җаен таба күр инде, хәзрәт, исерек баштан бит...

— Алып кил үзен, уйлап карарбыз.

Харис, бик шатланып, хатынын алып килә. Яшь, чибәр...

— Мәнә нәрсә, мелла кем-Харис... Хатының бездә калып торсын, бер өч көннән килеп алырсың, алла теләсә...

Шәригать, берни эшләр хәлең юк... Ә өч көннән соң әйләнеп килгәч, мулла абзый Харис белән сөйләшергә дә теләми. Ниһаять, Харис үзе кебек тилеләрне шушы юлга дүндереп тору шартын кабул иткәч кенә риза була мулла абзый».

Бәлкем, дөньялыкта шулай кимсетелеп яшәүләренең әҗерен хатын-кызга аллаһ тәгалә ахирәттә бирәчәктер?.. Буламы соң? Алла бер каныкканга каныга инде ул... Җәннәттә бичара хатын-кыз бөтенләй чутта түгел. Бигрәк тә җенеси мәсьәләдә. Табындагыга канәгать булмыйча, аракыны елгадан чүмереп ята-ята күзләре тонган берәр айнымас татарны эзләп тапсалар гына инде... Бичара хатын дөньяда бергә гомер иткән иренең 77 хур кызы кочагында ничек, ни рәвештә кәеф-сафа корып ятканын читтән күзәтеп тору бәхетенә ирешү белән генә канәгатьләнергә тиеш булачак.

Гыйльманнар (хур ирләр — җәннәт ирләре) дисеңме? Юк ул. Коръәндә Гыйльман дигәннең «г» сы да юк. Аны, күрәсең, мөслимәләр нәразыйлык күрсәтмәсен өчен, Мөхәммәт үлгәннән соң дин башлыклары уйлап чыгарган. Бәс шулай булгач, аллаһ тәгаләнең бу дөньяда дүртегезгә биргән бер ир затына шөкерана кылып, шуның кадерен белеп торыгыз, апайлар! Ә җәннәткә сез, гомумән, ирләрегез керсә генә, аңар ияреп кенә керә алачаксыз. Бу хакта Мөхәммәтнең вафатыннан соң чыккан шәригать китапларында бик ачык итеп әйтелгән:

«Сезгә дигән җәннәт ирләрегезнең аяк астындадыр».

Шунысы игътибарга лаеклы: хатын-кызга Мөхәммәт Коръәне өйрәткәнчә кыргый мөнәсәбәт Гарәбстанда һәм ислам дине көчләп тагылган бүтән илләрдә Мөхәммәткә кадәр бөтенләй булмый. Исламга кадәр әле хатын-кыз җәмгыятьтә тулы хокуклы. Хатын-кыз арасыннан патшалар була. Пәйгамбәрлек дәгъва итүче Җәзирә, Саджә кебек хатыннар килеп чыга. Халык үзләре хыял иткән аллаларны хатын-кыз исемнәре белән атый (Әльлат, Әльгузза, Манат). Хатын-кызны тигез күрү ислам кергәч тә әле халык арасында күп гасырлар дәвам итә. Халык төрле сәбәпләр аркасында, диннен үзен кабул итсә дә, хатын-кызны кимсетү белән килешә алмый. Һиҗри беренче гасыр азагына кадәр гарәп илләрендә хатын-кыз җәмгыять эшләрендә катнашып килә әле. Пәрәнҗә бөркәнми. Бу тарихи хакыйкать. Шәһри Болгарны ислам диненә өндәргә килгән гарәп илчеләренең берсе Ибне Фадланд, «күпме генә тырышсам да, ул татар хатыннарын ирләр алдында йөз яшерергә күндерә алмадым», дип язып калдырган. Хатын-кызны ир кол итүне, хайванга әверелдерүне Мөхәммәт һәм аның Коръәне хәдисләре көчләп кертә. Бу мәсьәләдә тарих битләрендә күп кенә кызыклы фактлар бар. Мәсәлән, миляди 847—861 елларда хөкем сөргән Бәгъдат хәлифәсе аш мәҗлесләрендә, тантаналы мәҗлесләрдә хатын-кызларны аерым табынга утырту турында махсус указ чыгарырга мәҗбүр була.

Хатын-кызны кимсетү белән килешмәү кайбер илләрдә тагын да озаграк дәвам итә. Әле миляди 1121 елда Урта Азиягә сәяхәт кылган кытай галимнәре Сәмәрканд хатын-кызларының ирләр белән бергә мәчеткә йөргәннәрен язып калдырганнар.

Һинд океанындагы Лаккади утравында яшәүче мөселман кабиләләрендә хатын-кызның тулы хокукы безнең заманга кадәр сакланып калган. Анда хәтта дини мөәссәсәләрдә (учреждениеләрдә) җитәкчелек итүче хатын-кызлар очрый.

Төньяк Һиндстанның миляди 1121—1123 елларда хөкем сөргән солтаны Ильтотмыш, берничә улы булуга карамастан, үзе үлгәндә тәхетен Разия исемле кызына мирас итә. Ә Минһаҗетдин дигән галим Разиянең хәрби талантка ия булган бөек патша икәнен әйтеп яза. Зәйнәп патшаны, Казан ханчәсе Сөембикәне хәтерләгез.

Ислам дине үзе күп халыкларга көчләп тагылган кебек, хатын-кыз турындагы вәхши канунnары да көчләп тагыла. Бу канунnарның күпчелеге пәйгамбәрнең үз иҗаты, яки аңардан соң яшәгән хәлифәләр тарафыннан кертелгән. Кайберләре исә ислам диненә, күп кенә бүтән юлалар белән бергә, Тәураттан яки борынгы яһүд диненнән, аның Талмутыннан кергән. Мәсәлән, яһүдләр әле бүгенгә кадәр иртәнге гыйбадәттән соң: «Мине хатын-кыз итеп тудырмаган өчен раббыма мең шөкерләр булсын», дип дога кылалар. Яһүдләрнең шул догаларыннан илһам алган Мөхәммәт; «Алланың балалары бар, диючеләргә биргән җавабында, шулай итеп, сезнең балаларыгыз ир, ә алланың кыз була димени инде? Болай итеп бүлү хәтерне калдыра бит»,— ди.

*(Коръән, «Йолдыз» сүрәсе, 21—22 аятьләр.)*

Бу аятьтән күренгәнчә, икенче төрле итеп әйткәндә, пәйгамбәрне, алланың балалары бар дию түгел, кыз балалары бар дию генә борчый.

«Чүпрәк баш», «чәче озын, акылы кыска» кебек әйтемнәр дә, «кыз бала дөньяга килсә, мендәр белән каплагыз» кебек җырлар да шул аять бакчасында үскән җимешләр.

Коръәнгә тәнкыйть күзе белән карарга җөрьәт иткән ачык фикерле хатын-кызлар мондый язмыш белән килешә алмаганнары хәлдә, борын-борыннан үзләренең тавышларын ишеттерә булганнар. Хосусән, татар хатын-кызлары кимсетү, җәберләүләргә каршы зарларын белдерә килделәр. Шагыйрә Гыйффәт туташ татар хатын-кызларының аһ-зарларын чагылдырып:

«Дүрт ягым рухсыз, тормышым нурсыз,
Интегә рухым, эсседә сусыз»,—

дип җырлады.

«Яшим читлек эчендә,
Юк миңа ямьле гүзәл көннәр.
Караңгы дүрт ягым,
Юк, ичмасам, йолдызлы ак төннәр»,—

дип зар елады.

Шагыйрә Маһруй Мозаффария 1907 елда:

«Вакыт инде, без дә торыйк, ирек алыйк,
Ирекләнер чаклар житте, ирекләник...»—

дип җырлады.

Шагыйрә Мәхмүдә Мозаффария моннан 60 ел элек үзенең шигырьләрендә азатлык байрагын күтәреп, хатын-кызга болай дип мөрәҗәгать итте:

«Әй ханымнар, әя сезнең күргән бармы,
Кырда матур чәчәкләрне, үләннәрне?
Иркен үсә ул үләннәр гыйбрәт безгә,
Чапаннарны, калын шәлләрне бөркәнми.
И ханымнар, вакыт инде уйганырга,
Үзебезгә кирәкләрне кулга алырга.
Абзарларга ябып куйган сарык төсле
Нигә соң без куркышабыз кузгалырга?»

Шунысы характерлы: бу өч шагыйрә өчесе дә мулла кызлары. Әлбәттә, болай җырлау алар өчен икеләтә куркыныч булгандыр. Безнең әниләребезне, әбиләребезне яктылыкка, тигезлеккә чакырган бу өч шагыйрәнең, кыю кызларның якты образлары алдына туктап баш иик.

«...Нигә соң без куркышабыз кузгалырга!..»

Һәм курыкмадылар, кузгалдылар хатын-кызлар. Бөек Октябрь кояшы яктылыгында дин белән алыш-бирешне өзгән мөслимәләр үзләренең нинди «чүпрәк баш», нинди «ярты акыл» икәннәрен эштә күрсәттеләр. Хатын-кыз түгел, хатын-кызны кимсетә, хурлый торган аятьләрне язучы пәйгамбәрнең үзенең чәче озын, акылы кыска булганны күрсәттеләр.

Халык пәйгамбәрнең:

«Үземнән соң ирләр өчен калдырган фетнәләрнең иң зарарлысы — хатыннар», дигәне белән дә, «ир кеше хатыннар сүзе белән йөрсә һәлак булыр», дигәне белән дә, «хөкүмәт эшләре хатыннарга тапшырылса, сезнең өчен җирнең асты-өстеннән артык булыр»[1], дигәне белән дә хисаплашып тормады, соңгы сайлауларда илебезнең иң югары органы булган СССР Верховный Советына 390 хатын-кыз сайланды. Союзный, автономный һәм җирле Советларда 740 000 хатын-кыз депутат бар. Шуларның биштән бере Мөхәммәт өммәте! Һәм бу хәл бездә һич кенә дә җир астына керү теләге тудырмый.

*(Ахыры бар.)*

[1] 933, 697 нче хәдисләр.

# *1965 әдәби ел йомгаклары материаллары*

*Фарваз Миннуллин*

## БЕЗ КИЧӘСЕ ҮРЛӘР

Соңгы елларда тәнкыйтьчеләрне язучы иҗатына карата үтә рәхимле һәм игелекле булырга үгетләп килдек. Мондый караш-тенденция тәнкыйть фикеренең активлыгын күпмедер дәрәҗәдә киметә, тәнкыйтьчеләрне берникадәр коралсызландыра төшсә дә, әдәби тәнкыйть, нигездә, дөрес юлдан бара. Партиябезнең XX съездыннан соң урнашкан иҗади активлык атмосферасы әдәбият фәне һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә гел үсә, гел көчәя килә.

Әдәбият фәне һәм тәнкыйть мәйданында узган елда ирешкән уңышларыбыз бу фикернең дөреслеген исбатлый торган бер дәлил булып тора ала. 1965 ел матур әдәбият турындагы фәнни-теоретик фикернең үсеше өчен һәр яктан уңайлы булды. Моннан бер ел элек, ягъни 1965 елның 14—15 январенда Татарстан язучыларының VI съезды булып узды. Шуннан соң ай ярым вакыт үткәч, Мәскәүдә РСФСР язучыларының II съезды ачылды. Һәр ике съезд уңае белән, үзәк һәм җирле матбугатта күп кенә мәкаләләр, чыгышлар басылды. Ул мәкаләләрдә татар совет әдәбиятының бүгенге хәле яктыртылды, гомуми үсеш тенденцияләре билгеләнде, әдәби хәрәкәтебезнең уңай һәм кимчелекле яклары күрсәтелде.

Бүгенге көндә без зур тарихи даталарны каршылау алдында торабыз. Алда Бөек Октябрьның һәм Татарстанның 50 еллыклары, Владимир Ильич Ленинның тууына 100 ел тулу бәйрәме. Бу даталар, гомумән әдәби хәрәкәтне бик нык җанландыру белән бергә, әдәбият һәм әдәби тәнкыйть үсеше өчен дә гаҗәеп киң мөмкинлекләр бирә. Инде бүген үк безнең күп кенә әдәбият галимнәребез һәм тәнкыйтьчеләребез үзләренең иҗат планнарын шушы зур даталарга бәйле рәвештә үзгәртеп коралар, күп кенә фәнни хезмәтләр һәм монографияләр әнә шул бәйрәмнәрне күздә тотып язылалар.

Шушы уңайдан Г. Халитның «Яңа герой ничек туды», А. Әхмәдуллинның «Көрәш һәм мәхәббәт» дигән мәкаләләрен күрсәтергә була. Узган ел Мәскәүдә рус телендә басылып чыккан «Татар совет әдәбияты тарихы»н галимнәребезнең Октябрь революциясенең 50 еллыгын каршылауга керткән лаеклы өлеше дип карарга кирәк.

Матбугатта чыккан һәрбер яңа әсәргә, һәрбер яңа китапка вакытында тиешле бәя биреп бара алмасак та, хәзер бездә бу эш тә шактый җанланып килә. Рецензияләр, китап күзәтүләр елдан-ел кызыклырак, укыла торганрак итеп языла. Бүгенге тәнкыйть фикере үсешендәге тагын бер үзенчәлекле яңалык шунда: хәзер теге яки бу әдәби әсәрне бәяләүдә, тәнкыйтьчеләр һәм әдипләр белән бергә, киң катлау укучылар да якыннан катнаша. Һәм еш кына гади укучыларның рецензияләре шул эшнең осталары язган әсәрләрдән бөтенләй диярлек аерылмый, аерым очракларда исә төплерәк һәм җитдирәк тә була.

Бик күңелле, бик куанычлы күренеш бит бу! Әдәбиятны тирәнтен аңлый белә торган, югары зәвыклы укучының үсеп җитүе һәм аның әдәби иҗат эшендә актив катнашуы турында сөйли торган факт бу.

Зур киләчәге булган менә шушы мөһим эшкә, ягъни укучылар тәнкыйтенә зур игътибар кирәк. Ләкин игътибар дигән нәрсә бездә әле җитеп бетми. Беркемгә дә сер түгел, без әле укучы фикеренә аз урын бирәбез. Бездә күбесенчә теге-бу әсәрне мактап язган укучы хатлары гына игълан ителә. Ә бит йөзләгән хатлар арасында язучы әсәренең кимчелекләрен күрсәткәннәре һәм дөрес күрсәткәннәре дә байтак була. Безнеңчә, андыйларын да матбугатта чыгара барырга кирәк.

Әдәби тәнкыйтьнең һәм әдәбият фәненең үсеше елдан-ел киңрәк колач ала бара. Бүгенге тәнкыйтьнең торышын «Казан утлары» журналы һәм «Социалистик Татарстан» газетасында басылып чыккан материаллар белән генә билгеләү тулы була алмаган кебек, аның торышын бары Казанда һәм Татарстанда чыгып килә торган хезмәтләр генә дә төгәл яктырта алмый. Бүгенге тәнкыйтьнең һәм әдәбият фәненең үсешенә турыдан-туры йогынты ясаучы иптәшләребез Мәскәүдә дә, Уфада да, илебезнең башка төбәкләрендә дә байтак. Һәм ул үсеш турында сөйләгәндә, әдәбият фәне буенча язылган махсус хезмәтләр, тәнкыйть мәкаләләре һәм рецензияләр белән генә чикләнү дә әдәби фикер үсешендәге тулы картинаны бирә алмас иде. Әдәбият мәйданына ел саен диярлек житлеккән, һәр яктан игътибар казанырлык хезмәтләр чыгып тора. Аларда әдәбиятыбызның бүгенгесенә һәм үткәненә караган күп кенә кызыклы, яңа мәгълүматлар була, тәнкыйтькә кагылышлы фикерләр әйтелә. Төрле әдәби даталар һәм күренекле әдипләребезнең юбилейлары уңае белән мәкаләләр языла, истәлекләр, хатлар басыла. 1966 ел — зур әдәби бәйрәмнәр елы. Күптән түгел без Фатих Әмирханның 80 еллыгын билгеләп үттек. Бу уңай белән шактый кызыклы материаллар басылды. Муса Җәлилнең 60, Габдулла Тукайның 80 еллыгы әдәби фикернең үсешен тагын да җанландырды, активлаштырды.

«Социалистик Татарстан» газетасында, Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил юбилейлары уңае белән башланып, инде берничә ай буе дәвам итеп килә торган әдәби бәхәстән без күп нәрсә көтәбез.

Узган елдагы һәм, гомумән, соңгы еллардагы әдәби тәнкыйтьнең игътибарга лаек булган кайбер якларына килгәндә, йомгак рәвешендә шуларны әйтергә була.

Әле кайчан гына теге яки бу әдәби әсәр турындагы бәхәсле мәсьәләләрне бергәләп тикшерү хыял сыман бер нәрсә булып исәпләнелә иде. Бүген үзара фикер алышу һәм әдәби дискуссияләр матур бер традициягә, әдәби тормышның гадәти нормасына әйләнеп бара. Бу исә безгә әдәбият әсәрләрен бәяләүдә субъективизмнан, берьяклылыктан, догматизмнан котылырга мөмкинлек бирә. Хәзер инде, кемнәргәдер ошамаган өчен генә бер ише әсәрләрне юкка чыгару мөмкин булмаган кебек, әдәби яктан зәгыйфь әйберләрне яклап калу яисә матбугатта чыгару да җиңел түгел. Ян Винецкийның «Мин ышанам» романы, Ә. Еникинең «Рәшә» һәм А. Гыйләҗевның «Өч аршын җир» повестьлары буенча булып узган бәхәсләр нәкъ шул турыда сөйли.

Мәскәү кешеләре аларда әдәби тәнкыйтьнең үсешен тоткарлаучы житди сәбәпләрнең берсе итеп группачылык көрәшен, алар арасындагы вак-төяк ызгыш-талашларны күрсәтәләр. Аллага шөкер дип әйтикме, бездә мондый ямьсез, начар нәрсә артык сизелми төсле. Дөрес, элеккерәк елларда кайбер тәнкыйтьчеләр бары тик шәхси антипатияләрдән чыгып кына, үзләре яратмаган өчен генә, җай чыккан саен, аерым язучыларга «төрткәләп» китәргә тырышалар иде. Хәзер без бу чирдән дә арынып киләбез. Шул ук вакытта әдәби тәнкыйтьтә иҗади кыюлык, принципиальлек кебек әйбәт сыйфатлар көчәеп килә. Әле кайчан гына, әдәбият турында сөйләшкәндә, «начарга» мисал кирәк булса, без һаман бер үк исемнәрне атый идек. Безнең «дежур тиргәлүчеләребез» бар иде. Һәм ул «дежур тиргәлүчеләр»нең күбесе гадәттә, әдәбиятны алга әйдәүче, аның йөзен, торышын билгеләүче кешеләр дә булмый иде. Тәгаен генә әйтә алмыйм, прозада һәм драматургиядә ул «исемлектә» кемнәр йөргәндер, поэзиядә, мәсәлән, Мәхмүт Хөсәенне тиргиләр иде. Хәзер тәнкыйть дөреслекне күзгә карап әйтергә өйрәнеп бара. Олы, күренекле язучымы ул, яшь язучымы — әгәр аның иҗатында кимчелекләр, җитешсез яклар бар икән, безнең күпчелек тәнкыйтьчеләр ул җитешсезлекләрне әйтүдән курыкмыйлар.

Тәнкыйтьчеләрне элегрәк әдәби әсәрнең үзенчәлекләрен, бигрәк тә, аның сәнгать әсәре булу хосусиятен аңламауда гаеплиләр иде. Безнең әдәби тәнкыйть мәкаләләрен һәм рецензияләрне укып канәгатьләнә алмаган язучылар еш кына: «Ә соң әдәбият ләззәт тә бирәме?» — дип сорыйлар иде бездән. Һәм, нигездә, алар хаклы иде. Әдәбиятның эстетик кыйммәтен ачыклауда бүген инде бөтен нәрсә эшләнде, бөтенесе хәл ителде, дип әйтеп булмый, билгеле. Әмма күпчелек тәнкыйть мәкаләләре һәм рецензияләр хәзер әдәбиятның әдәбият икәнлеген тирәнтен аңлап языла. Бүгенге тәнкыйть үзе дә әдәбиләшә төште, һәм тәнкыйтьне сәнгатьчә матур итеп, укылырлык итеп язарга омтылыш көчле.

Озак еллар буе гел орышып, гел пассивлыкта гаепләп килгәннән соң, ниһаять, Татарстан язучыларының VI съездында

әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләр адресына да җылы сүз әйтелде. Язучылар союзы идарәсенең председателе Мирсәй Әмир съездда ясаган докладында: «Бу съездда исә мин, бу жанрлар өчен куанып әйтә алам: соңгы елларда бездә әдәби тәнкыйть буенча да, әдәбият гыйлеме буенча да иҗат активлыгы көчәйде һәм күзгә бәрелеп торган уңышлы нәтиҗәләргә ирешелде».— диде. Һәм 1965 елгы әдәби тәнкыйтьнең, әдәбият гыйлеменең үсеше әлеге җылы сүзләрнең урынлы булуын күрсәтә.

Әйе, тәнкыйть тә, әдәбият фәне дә дөрес юлдан бара. Ә юл кешесенең юлда булуы хәерле, диләр. Безгә тынычланырга, туктап калырга бик иртә әле. Шул дөрес юлдан безнең әле алга таба күп җир үтәсебез, күп үрләр, таулар кичәсебез бар, безнең әле хәл итәсе бик күп мәсьәләләребез бар.

Баштан ук шуны әйтеп китәргә кирәк, бүгенге әдәбият фәненең һәм тәнкыйтьнең гомуми торышы, нигездә, канәгатьләнерлек булса да, әдәбиятның төрле тармакларын тикшерү тигез бармый. Моңарчы проза әдәбияты турында һәм, театр сәнгатенә, спектакльләргә бәйләп, драматургия турында күбрәк сүз булды. Хәзер менә поэзия турында сөйләшү дә җанланып бара шикелле. Ләкин әдәбиятның иң мөһим бер тармагы булган балалар әдәбияты һаман да җитди тәнкыйть игътибарыннан читтә кала килә. Татарстан язучыларының VI съездында сөйләгән докладында М. Әмир дә, «Социалистик Татарстан» газетасының узган елгы 11 апрель санында басылган «Балаларны онытмыйк» исемле мәкаләсендә Г. Бакир да бу турыда бик дөрес әйтеләр. Әйе, кечкенә укучыларыбызга зур игътибар кирәклеге турында сүз булмый дип әйтә алмыйбыз. Әмма конкрет эшкә килгәндә, әлегә берни эшләнелми диярлек. Татар балалар әдәбияты исә шундый конкрет ярдәмгә бик, бик мохтаҗ.

Бүгенге тормышыбыздагы уңай тенденцияләр, җитди тәнкыйтькә булган ихтыяҗ, ниһаять, татар совет әдәбиятының кызу адымнар белән алга баруы әдәби-фәнни фикернең үсеше өчен дә күп мөмкинлекләр, уңай шартлар тудыра. Әдәби тәнкыйть исә югарыда әйтелгән уңышларына да карамастан, һаман да әле язучыга иярүдән, теге-бу язучының иҗатын комментарияләүдән әллә ни ерак китә алмый. Еш кына очракта без язучыларыбыз ачкан яңалыкны өйрәнеп, тикшереп барырга да өлгермибез. Һәрхәлдә, тәнкыйтькә булган мөнәсәбәт, әдәбиятның гомуми торышы әдәби тәнкыйтьнең үсешен тоткарлый дип әйтү дөрес булмас иде. Алайса, әдәби тәнкыйтьнең үсешен нәрсә тоткарлый соң?

Әдәби тәнкыйть, әдәбият тарихы һәм, гомумән, иҗтимагый фикер тарихы, әдәбият белеме һәм фәнни-теоретик фикер бер-берсенә ярдәмләшеп, берсе икенчесенә булышып, үзара тыгыз элемтәдә яшиләр һәм үсәләр. Шушы бердәмлекнең, берсе икенчесенә нык тоташкан шушы чылбырның кайсы да булса бер буыны йомшый икән, моның зыяны калган барлык буыннарга да кагыла. Бүгенге әдәби тәнкыйтьнең кимчелекле яклары турында сүз барганда, безнең игътибар әлеге чылбырның аерым буыннарын гармонияле үстерүгә юнәлтелергә тиеш, чөнки бездә, әйтелгәнчә, «буыннар»ның үсеше тигез түгел. Һәм әдәби тәнкыйтьнең үсешен тоткарлаучы төп сәбәп тә шунда.

Әдәбият тарихын һәм әдәби тәнкыйтьне алыйк. Озак еллар буе галимнәребезне үткән чорлар, борынгы әдәбият белән мавыгуда, бүгенге әдәбиятка игътибар бирмәүдә гаепләп килдек. Бай тарихлы әдәбиятыбызның үткәнен өйрәнү, ничектер, кирәксез бер эш саналды, борынгы әдәбиятыбыз тарихын өйрәнүче галимнәрнең хезмәтенә тиешле игътибар бирелмәде. Торабара, бу караш начар бер модага, шаблонга әйләнеп китте. Мондый берьяклы карашның әле бүген дә бетеп җиткәне юк. Хәтта «Социалистик Татарстан» газетасында дискуссия уңае белән басылган мәкаләсендә Н. Фәттах та: «Аннары тәнкыйтьчеләрнең күбесе архивлар актарып, калын-калын монографияләр, диссертацияләр яза»,— кебек җөмләләр ычкындыра. Хәтта дим, чөнки кем-кем, ул инде борынгы әдәбиятны өйрәнүнең, «архивларда казыну»ның торышы ни дәрәҗәдә генә икәнен бик шәп белә. Үткән чорлардан аерыла алмаганнары өчен, тәнкыйтьчеләребезне һәм галимнәребезне орышып йөрдек-йөрдек тә бүген менә аңладык. Баксаң, борынгы әдәбиятыбыз бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән икән! Нинди ул безнең мең еллык бай әдәбият тарихыбыз? Аның үзенчәлекләре, аның эчке үсеш законнары ничегрәк? Мең еллык тарихны нинди җепләр белән XIX гасырга бәйләргә дә, ул җепләрнең кайсылары бүгенге көннәргә кадәр сузылган? Борынгы әдәбиятыбызга кагылышлы бу сорауларга, шундый характердагы башка күп сорауларга без әле төгәл генә җавап

бирә алмыйбыз. Борынгы әдәбиятыбыз бүгенге әдәби процесстан ничектер аерылып, өзелеп калды шикелле. Югалган малга ия табыла дигәндәй, вакытында күрә белмәгән, бәяли белмәгән шул бай тарихлы әдәбиятыбызны хәзер башка халыкларның әдәбият белгечләре үзләренчә тарткалый-йолыккалый башладылар һәм менә шуңа хәзер безнең ачуыбыз килә.

Тарихы җитәрлек өйрәнелмәү аркасында, әдәбиятның бүгенге хәле, бүгенге уңышлары, аерым язучылар иҗаты дөрес бәяләнми, әдәбиятның теге яки бу ягы турында фикер йөрткәндә, нәтиҗәләр чыгарганда борынгы традицияләр һәм элекке культура байлыгы исәпкә алынмый. Ф. Мусинның әдәби-тәнкыйть эшчәнлегендә яшь тәнкыйтьчеләргә үрнәк булырлык күп әйбәт сыйфатлар бар. Мин, аеруча, яшь тәнкыйтьченең иҗат активлыгын билгеләп үтәр идем. Безнең күбебезгә нәкъ шул активлык җитми дә инде. Ләкин, шуның белән бергә, ул кайбер мәкаләләрен уйлап җиткермичәрәк, ашыгыбрак яза. Татар әдәбиятының бай тарихына хөрмәт белән карап, аз гына уйлабрак фикер йөрткәндә, Ф. Мусин: Тукай һәм Җәлил татар әдәбиятын «тар милли җирлектән бөтендөнья киңлегенә алып чыктылар», «Тукай эшне милли шигырь техникасын тудырудан... башлады» кебек ялгыш һәм берьяклы җөмләләргә урын калдырмас иде[1]. Дөнья әдәбиятына Тукай, Җәлил кебек бөек шагыйрьләрне биргән, һәм Ф. Мусинга үтә тар булып тоелган «милли җирлекне» икенче бер милләт кешесе, немец әдибе Франц Лешнитцер менә ничек бәяли:

«Икенче фикергә дә нигез җитәрлек, тирән газаплар эчендә шагыйрь чын немецларга үзенең дуслык, туганлык хисен багышлаган икән, димәк, Муса Җәлилне тудырган **татар халкы** бер үк вакытта **культуралы** да, **бөек** тә»,— ди ул, «Моабит дәфтәре» безнең өчен дә язылган» исемле мәкаләсендә («Казан утлары» журналы, 1965 ел, 10 сан). Күрәсез җирлек тар дип зарланырга урын юк икән ләбаса!

Н. Юзиевның «Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт белән...» хезмәтен[2] мин узган елны матбугатта чыккан әдәби-тәнкыйть мәкаләләренең иң уңышлыларыннан санар идем. Автор хикмәтле сүз әйтү традициясенең эчке үсеш законнарын дөрес билгели алган. Күләме әллә ни зур булмаган бу мәкалә белән танышып чыккач, фикер поэзиясенең бөтен тарихы күз алдына килә. Автор әдәбият тарихын һәм борынгыдан килә торган традицияләрне яхшы белә, һәм әлеге мәкаләне язганда бу аңа нык ярдәм иткән. Ахырга кадәр ачыкланып җитмәгән кайбер урыннары булуга да карамастан, Г. Галиуллинның «Балладаларыбыз турында» дигән мәкаләсе дә игътибарга лаек. Мин, билгеле, мәкалә саен борынгыдан алып бүгенге көнгә кадәр булган бөтен әдәбият тарихын сөйләп чыгу мәҗбүри дип расларга җыенмыйм. Әмма тәнкыйтьче үзе яза, тикшерә торган мәсьәләсенең төбен, тарихын белергә һәм әйбәт белергә тиеш. Бу турыда бәхәс булуы да мөмкин түгел.

Әдәбият тарихының өйрәнелмәгән булуы яки авторның ул тарихны белмәве әдәби тәнкыйтьнең үсешенә никадәр зыян китерсә, әдәби тәнкыйтьнең артталыгы, үз чиратында, әдәбият тарихының үсешен дә тоткарлый.

Менә бер мисал. Үзәк һәм җирле матбугатта чыккан рецензияләрдә дә, моннан берничә ай элек СССР фәннәр академиясенең Казан тел, әдәбият һәм тарих институтында булып үткән фикер алышу вакытында да Мәскәүдә чыккан «Татар совет әдәбияты тарихы» үзенә лаеклы бәяне алды. Рецензияләрдә һәм фикер алышу барышында да, бу җитди һәм зур хезмәтнең бик күп уңай, әйбәт якларын билгеләү белән бергә, кайбер кимчелекләре дә күрсәтелде. Арадан берсе — соңгы чорның, партиянең XX съездыннан соңгы әдәбиятның тулы яктыртылмавы. Менә бу очракта инде бары тик әдәбият тарихын язучыларны гына гаепләү дөрес булырмы? Тарихчыларга әдәби тәнкыйтьнең артталыгы да комачауламадымы икән?.. Дөрес, соңгы еллардагы әдәбиятның, бигрәк тә проза әдәбиятының, үзенчәлекләре турында шактый язылды һәм язылып тора. Х. Хәйри, Р. Мостафин, И. Нуруллин, Н. Юзиев, Ф. Мусин һәм башка тәнкыйтьчеләрнең хезмәтләрендә бүгенге прозаның күп кенә үзенчәлекләре күрсәтелде. Ләкин, кызганычка каршы, монда күбрәк санап чыгу өстенлек алды. Прозадагы үзенчәлекләрнең берсе дә диярлек тирәнтен тикшерелмәде, соңгы еллар әдәбиятының үсеш тенденцияләре тиешенчә гомумиләштерелмәде, төп закончалыклары анык билгеләнмәде.

[1] Ф. Мусин. Аларга турылыклымы без? «Социалистик Татарстан» газетасы, 1965 ел, 26 сентябрь.

[2] «Казан утлары» журналы, 1965 ел, 9 сан.

Әдәби тәнкыйть тарафыннан бу эш башкарылган булса, ихтимал, әдәбият тарихы китабын язучылар да бүгенге көнгә ныграк якынлаша алган булырлар иде.

Кайчандыр бездә дә әдәбият белеме (литературоведение) булган, әдәбият белеме буенча фәнни кулланмалар, дәреслекләр чыккан. Галимҗан Ибраһимов кебек әдипләр бу фәнне булдыруда вакытларын һәм көчләрен кызганмаганнар. Соңыннан бу эш бездә ничектер тукталып калды. Соңгы еллар матбугатында, берничә мәкаләдән һәм филология фәннәре докторы, профессор Хатип Госманның «Татар шигыре» исемле китабыннан башка, әдәбият белеменә караган бер генә әйбер дә күренми диярлек. Бу һич тә аңлашылмый. Ничек инде шундый зур әдәбиятың була торып та, югары уку йортларында студентларга шул әдәбият укытылып та, үз ана телеңдә әдәбият белемең булмасын!.. Әдәбият белеменең эшләнмәгән булуы, фәнни-теоретик мәсьәләләрнең аз яктыртылуы аркасында, әдәби тәнкыйтьтә бәхәсле фикерләр, берьяклы карашлар тулып ята.

Без хәзер әдәбиятның төп өйрәнү объекты кеше дибез, һәр әсәрдән тормышчан характерлар таләп итәбез. Күп кабатлый торгач, шушы бик дөрес фикерне берьяклырак аңлата, шаблонга әйләндерә башламадыкмы икән? Бу — махсус сөйләшүне сорый торган зур мәсьәлә. Монда мин бу мәсьәләгә кыскача гына тукталам.

«Язучы бик дөрес юлда, сәнгатьнең бердәнбер максаты — бары тик кешене, аның язмышын күрсәтү»,— ди «Татарстан яшьләре»нең 10 апрель санында басылган рецензиясендә Г. Рябков. Икенче берәүләр эшләнгән, ышандырырлык образы юк икән, димәк, хикәя дә юк дип әйтиләр.

Әдәбиятның бурычын һәм максатларын, әдәби образ төшенчәсен менә шулай үтә ялангач итеп аңлату белән килешеп булмый. Миңа калса, әдәби образ үзмаксат түгел; ул, бер үк вакытта, чынбарлыкны танып-белү чарасы да һәм шул ук танып-белүнең җимеше дә. Аннан соң әдәби образ төшенчәсен характер, кеше образы дип кенә аңлату шулай ук төгәл түгел шикелле. Сәнгать әсәрендә, кеше образлары белән бергә, табигать күренешләре һәм тормышның җанлы картиналары — вакыйга образлары да була бит әле. Алары да бик кирәк, һәм вакыйга образларын тудыру да — катлаулы, авыр иҗат эше. Безнең әдәбиятта үзәккә кеше образлары һәм вакыйга образлары куелган әсәрләр дә байтак.

Безнең рецензентлар һәр әсәрдән — хикәяме ул, повестьмы, я булмаса романмы — бөтенесе бер үк дәрәҗәдә тулы да, ышандырырлык та эшләнгән образлар таләп итәләр. Дөрес, әсәргә кергән һәр образ, һәр персонаж тормышчан, ышандырырлык булырга тиеш. Әмма инде барлык образлардан һәм персонажлардан бер үк дәрәҗәдә тулылык таләп итү дөрес түгел. Образның тулылык дәрәҗәсе әсәрнең жанр үзенчәлеге, темасы, проблемасы белән, образның әсәрдә тоткан урыны һәм, ниһаять, язучының индивидуаль үзенчәлеге белән билгеләнә. Безнең тәнкыйтьтә әдәби геройлар диалектикасы бөтенләй кул тимәгән өлкә булып кала килә.

Образ үзмаксат дип карауның, һәр образдан тулылык таләп итүнең нинди зыяны бар соң? Зыяны күп, беренче чиратта һәм барыннан да бигрәк шунда, образларны әсәрнең идея-проблемасы, үзенчәлеге белән бәйләп карый алмау аркасында, әдәби процесс, җанлы иҗат эше нинди дер схемага, шаблонга тиңләштерелә, әдәби әсәрләр дөрес бәяләнми. Я без, монда яңа, оригиналь образлар, җанлы характерлар юк дип, күп кенә кызыклы әсәрләрне бөтенләй юкка чыгарып ташлыйбыз, яисә шактый йомшак эшләнгән һәм чын мәгънәсендә туып җитмәгән характерларны да бу яңа, менә дигән оригиналь образ дип бәяләргә мәҗбүр булабыз. Соңгысы күбрәк очрый бугай.

Безнең тәнкыйтьтә Р. Төхфәтуллин күп һәм, нигездә, урынлы макталды. Үзенчәлекле һәм талантлы бу язучының «Тамчылар ни сөйли» исемле яңа повестенда да игътибарга лаек урыннар, кызыклы омтылышлар бар. Ильяс — бик кызыклы уйланылган образ. Уңышлы чыккан очракта, бу образ бүгенге яшьләребезнең характерларын, уй-фикерләрен шактый тулы һәм дөрес чагылдыра алыр иде. Ләкин, дөресен әйтергә кирәк, «Тамчылар ни сөйли», «Авылдашым Нәби»дән дә, «Йолдызым»нан да кайтышрак. Безнеңчә, повестьның төп кимчелеге дә — үзәк образның тиешенчә эшләнеп җитмәвендә, кызыклы омтылыш кына булып калуында. Г. Рябковның бу повесть уңае белән язылган рецензиясендә исә әсәргә гаять югары бәя бирелә һәм баштан ахырга кадәр Ильяс образы мактала. Мондый рецензиянең файдасыннан зыяны күбрәк.

Газеталарда һәм журналларда басылган күп санлы рецензияләр арасында һәр яктан да күңелгә ошаганнары бармак белән генә санарлык. Шундыйлар рәтенә мин, беренче чиратта, Н. Юзиевның «Социалистик Татарстан»да басылган «Тылсымлы шигърият дөньясы» исемле рецензиясен, М. Мәһдиевның шул ук газетада «Борынгы татар әдәбияты тарихы»на язган рецензиясен, Г. Ахуновның «Казан утлары» журналының 12 санында «Хәсрәт дәрьясы»ның тәрҗемәсенә карата язылган рецензиясен кертер идем. Хәсән Хәйринең «Ак чәчәкләр» романы турында «Социалистик Татарстан» газетасында чыккан рецензиясе дә, әсәргә тулы бәя бирергә омтылуы, дәлилле булуы белән әйбәт тәэсир калдыра. Бу исемлекне тагын 4—5 рецензия исәбенә озайтырга мөмкин булыр иде. Ләкин алар гына безнең бүгенге тәнкыйтьтәге гомуми картинаны үзгәртә алмый: һәр яктан килгән, барлык таләпләргә җавап бирерлек чын рецензияләр бездә аз язылган. Рецензия, китап күзәтү, тәнкыйть-библиография исемнәре белән чыгып килә торган әйберләрнең күбесе, чынында, гап-гади аннотациядән узмыйлар. Аларның күбесендә бик коры тел белән тегебу китапның яки әсәрнең эчтәлеге сөйләнеп чыгыла, образларга аңлатмалар бирелә, һәм рецензент әлеге җыентыкны яки әсәрне укудан алган тәэсирләре белән уртаклаша. Билгеле, бүгенге укучыны мондый рецензияләр генә һич тә канәгатьләндерә алмый.

Безгә инде әдәби рецензиядән гади аннотацияне, эчтәлек сөйләүне аера белергә вакыт. Алар икесе ике нәрсә, һәм аларның максатлары да үзгә. Аннотациянең төп максаты — яңа әсәргә карата кызыксыну уяту, аны пропагандалау. Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимовларның яңа әсәрләрне пропагандалау ниятеннән чыгып язылган әйберләре ярты бит, бер биттән узмаган. Аннан соң пропаганданың, кызыксыну уятуның бердәнбер юлы эчтәлек сөйләү генә түгел бит. Пропаганданың башка формаларын табарга, бу эшне нык җанландырырга һәм төрләндерергә кирәк.

Әдәби тәнкыйть мәкаләләренең, рецензияләрнең кыйммәтен төшерә торган кимчелекләрнең берсе шунда — еш кына без язучыларның иҗат үзенчәлекләре белән хисаплашмыйбыз, дөресрәге, әдипләребезнең индивидуаль иҗат йөзләрен тиешенчә белмибез дә, өйрәнмибез дә. Язучылар союзының V съездында әдәби тәнкыйть буенча сөйләгән докладында Г. Халит: «Чыннан да, Ф. Хөсни стиле белән Ә. Еники стиле бер-берсеннән ничек аерыла? дип сораучга кайсы тәнкыйтьче кисеп җавап бирә алыр икән? Алар стилендә «бай психологизм бар» диюдән узмыйбыз шикелле»,— дигән иде. Бу сүзләр бүген дә үз көчендә кала.

Күренекле язучыларыбызның иҗат портретларын эшләү гамәлгә куелып килә шикелле. Ләкин узган ел басылганнардан, Р. Мостафинның Х. Туфанга багышланган һәм өлкән шагыйрь иҗатына тирән хөрмәт, мәхәббәт белән язылган хезмәтеннән кала, башка бу өлкәдә игътибарны җәлеп итәрлек әйберләр очрамады. Язучыларның иҗат үзенчәлеген өйрәнү, һәр язучының үзенә генә хас якларын тотып алу һәм күрсәтү җиңел эш түгел, әлбәттә. Теге яки бу язучының индивидуаль үзенчәлеге турында бик аз белүебез өстенә, безнең әдәби иҗат процессы һәм язучы хезмәтенең эчке закончалыклары турында мәгълүматыбыз да бик чикләнгән. Күренекле язучыларыбызның кульъязмалары бөтенләй диярлек сакланмаган. Бүгенге өлкән әдипләребез үзләренең иҗат тәҗрибәләре белән бик саран уртаклашалар. Моннан берничә ел элек Г. Галиевнең «Хикәя турында хикәяләр»е чыккан иде. Аннары узган ел «Казан утлары»нда Г. Әпсәләмов «Ак чәчәкләр» романын язу тәҗрибәсе белән уртаклашты. Г. Галиев башлаган һәм Г. Әпсәләмов дәвам иткән бу эшне даими бер гадәткә кертәсе иде. Әдәби иҗат процессын, язучыларның индивидуаль иҗат үзенчәлеген өйрәнми, белми торып, тәнкыйтьне алга җибәрү турында нинди сүз булырга мөмкин?

Күптәннән күтәрелеп тә, дөресрәге беркайчан да көн тәртибеннән төшмәгән, ләкин баркайчан да тиешле дәрәҗәдә ачыклык кертелмичә өстерәлеп килә торган мәсьәләләрнең тагын берсе — заман темасы. Заман темасы буенча бәхәсләр кабына да сүнә, кабына да сүнә. Ләкин бу мәсьәләгә әле һаман да фәнни-теоретик ачыклык кертелгәне юк. Әгәр дә мәгәр, берәр нәрсә уңае белән заман темасы турында бүгенге көндә бәхәс кузгала калса, бу мәсьәләне аңлау һәм аңлатуда тагын да бер чиктән икенче чиккә ташлану башланачак. Татарстан язучыларының VI съездында сөйләгән докладында М. Әмир заман темасын болайрак аңлата:

«Соңгы еллар өчен заман темасын әдәбиятта киңрәк, күләмлерәк итеп аңлау һәм шулай хәл кылу характерлы. Шуңа күрә,

бу елларда язылган, ләкин әчтәлекләре белән үткәнрәк елларга кагылган әсәрләрне дә заман темасыннан аерып йөртәсе килми».

Инде килеп, шул ук съездда чыгыш ясаган икенче бер докладчыны, Б. Гыйззәтне тыңлап карыйк: «Билгеле, бүгенге конфликтлар турыдан-туры бүгенге характерлар белән бәйләнгән. Шушы шартлар үтәлгән вакытта гына, бүгенге зур проблемаларны күтәрергә, заман темасын хәл итәргә мөмкин. Югыйсә, әле күптәнме, заман темасы инде бездә чишелгән нәрсә дип, бик өстән генә карап сөйләшүләр булгалый иде. Янәсе, бездә хәзер барысы да бүгенгене генә яза. Ләкин бу һич тә гади генә чишелә торган мәсьәлә түгел. Замандаш тема ул бары тик бүгенге көнгә генә хас булган, аның асылын тәшкил иткән төп, үзәк конфликтларын алып, бары тик бүгенге көнгә генә хас характерларны сәхнәгә чыгару дигән сүз».

Кайсы докладчының аңлатмасы дөрес, заман темасын кем дөресрәк хәл итә — ул кадәресенә мин тукталып тормыйм. Әмма шунысы ачык, монда заман темасын капма-каршы аңлату күзгә бәрелеп тора.

Ачыклыйсы, тикшерәсе мәсьәләләребез болардан башка да күп, бик күп әле безнең. Бездә хәзер проблема дигән сүз күп кулланыла. Аның активлашуы әдәбиятыбызның бүгенге үзенчәлеге, проблематик әдәбиятка әйләнә баруы белән аңлатылса кирәк. Безгә калса, кайбер тәнкыйть мәкаләләрендә сәнгатьтәге проблема белән фәнни проблема буталып йөртелә шикелле.

Тугандаш әдәбиятларның үзара бәйләнешен, аларның бер-берсенә йогынтысын өйрәнү дә күптән көн тәртибенә куелган мәсьәләләрдән. Бу турыда да без күп сөйлибез, кызганычка каршы, конкрет эшләү генә җитми.

Безнең әле бүгенге әсәрләребезнең конфликтлары, ул конфликтларның тормышчанлык дәрәҗәләре турында да, әдәби образларның, бигрәк тә «тискәре герой»ларның ышандыру көче, дәлилләнү һәм мотивлаштыру дәрәҗәсе турында да сөйләшәсебез бар, болардан башка да уртага куеп хәл итәсе әйберләребез бик күп. Шул эшләрне башкару өчен кадрлар кирәк. Татарстан язучылар союзы чыгарган исемлеккә 103 союз членының һәм 67 яшь язучының исем-фамилиясе теркәлгән. Барысы 170 була. Шулар арасында әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләр, картлары, яшьләре барысы бергә, ике дистәгә дә тулмый. Инде шул ике дистәгә тулар-тулмас кешене әдәбият фәненең төрле тармакларына бүлгәли башласаң, эшләр бик саегаеп кала шул. Союз һәм аның яшьләр белән эшләү комиссиясе яшь тәнкыйтьчеләр тәрбияләп үстерүгә тиешле игътибар бирмиләр шикелле. Мин хәтерләмим, соңгы 4—5 ел вакыт эчендә кайсы яшь тәнкыйтьченең иҗаты тикшерелгәне бар икән? Шагыйрьләрнең, прозаикларның, яшь драматургларның, ел саен диярлек, семинарлары булып тора. Ни өчендер, шундый ук семинарлар яшь тәнкыйтьчеләр өчен дә кирәктер дип уйламыйлар. Әгәр әдәби тәнкыйтьнең чыннан да үсүен телибез икән, аның әдәби процессны әйдәүче көч булуын телибез икән — яшь тәнкыйтьчеләр һәм галимнәр тәрбияләүгә җитди эш дип карарга кирәк.

■

Әдәби тәнкыйтьнең һәм әдәбият фәненең 1965 елдагы торышы турындагы гомуми күзәтүгә йомгак ясап, шуны әйтәсе килә. Татар совет әдәбияты элек-электән көчле тәрбия коралы булып килде. Шул көчле сыйфатларын һич тә югалтмаган хәлдә, бүген ул чынбарлыкны танып белүче, ачыш ясаучы һәм актив рәвештә тормышны яхшыртуга булышучы проблематик әдәбиятка әйләнеп бара. Әдәби тәнкыйтьнең дә төп юлы шул юнәлештә үсә һәм үсәргә тиеш. Безгә фәнни тирән һәм дәлилле, яңалык ачучы һәм проблематик тәнкыйть кирәк. Әйе, эшлисе эшләребез күп. Шул ук вакытта эшләргә теләк тә зур. Бүгенге темплар белән үсеп барганда, озаклмый безнең дә житлеккән әдәби тәнкыйтебез һәм әдәбият фәнебез булыр дип ышанырга кирәк.

*Әдип Маликов*

# НӘНИЛӘР ӨЧЕН

Кешенең өлкән чагы белән балалык еллары арасында ташкын дәрьялар, салкын окоплар ята, көл эченнән калкып чыккан калалар, ил кайгысы, ил шатлыгы...

Ләкинниләр генә булып узмасын, балачак тәэсирләре күңелдә ныграк саклана торган була. Шагыйрь әйтмешли, ул гомерең буе итәгеңә тагылып йөри. Балачакта укылган яхшы китап та күңелдә онытылмаслык эз калдыра. Бала тормышны китап аша таный башлый. Үзе дә сизмәстән, шигырь сөйләп йөри. Зурлар язмышын үзенә үлчәп карарга өйрәнә.

Язучы абыйлары соңгы елларда безнең нәни кешеләребез турында сизелерлек кайгырта башладылар. Матур рәсемнәр белән бизәлгән, эчтәлеге, әдәби эшләнеше һәм мавыктыргыч булуы ягыннан Мәскәүдә чыга торган китапларга һич бирешмәслек әсәрләр бездә дә, аз булса да, чыккалап тора. Ләкин башта ук шуны әйтергә кирәк: балалар мавыктыргыч калын китаплар укырга яраталар. Ә 1965 елда андый күләмле әсәрләр күренмәде диярлек.

Узган ел нәни укучылар кулына утызлап оригиналь китап керде. Шулар янына тәрҗемәләрне, кабаттан басылган әсәрләрне дә өстәсәк, ул сан шактый арта төшә. Балалар өчен китап язарга утырсак, безне еш кына дидактика бизгәге, акыл сату, үгет-нәсихәт бирү өянәге тота башлый иде. Шуңа да Ләбибә Ихсанованың «Робинзоннар лагеренда» дигән китабын укып чыккач, бер сөенеч артты.

Вакыйга җәйге лагерьда бара. Гөлшат исемле кыз күл буенда, каен күләгәсендә малайларны көтеп утыра. «Тәмәкенең зарары турында әңгәмә була» дигән белдерүне Гөлшат кичтән үк элеп куйган. Ә малайлар юк та юк. Килерләрме, юкмы? Инде күл селтәп лагерь ягына йөгерә генә башласа, иңкүлектә тәмәке пыскытып яткан малайларны күреп, кыз аптырап кала. Алар моны юри, Гөлшаттан көлү өчен эшлиләр. Арадан берсе яшь фельдшерга тәмәке тәкъдим итә. Шулай итеп, үзара аңлашу булмый кала. Гөлшатның күзләре яшьләнә...

Фельдшер кыз көлке дә, кызганыч та. Тәрбия эшен ул агитациядән, акыл сатудан башлап җибәрмәкче була. Автор моның белән безне алдан ук кисәтеп куя.

Алга таба да вакыйгалар тормышчан юнәлештә агалар. Отряд вожатые Сәфәргә карата малайларда беренче көннән үк кызыксыну уяна. Чөнки ул геолог. Геолог чүкечен тотып карау үзе генә дә ни тора! Җитмәсә, Сәфәр бик шәп итеп йөзә дә белә икән әле. Моңа кадәр үзен иң шәп йөзүчегә санап йөргән «Колга» кушаматлы малай — Әлфәрит, вожатый белән ярышка чыгып, хур була. Шушы хәлдән соң Сәфәрнең авторитеты тагын да үсә төшә. Әсәрдә аш пешерүче Мәһинур апа, отряд вожатые Сәфәр шикелле хәтердә кала торган образлар байтак. Лагерь начальнигы Гарифулла балаларның шуклыкларын, вактөяк гаепләрен гаугага әйләндерми. Балаларга бервакытта да кечерәйтеп, кимсетеп карамас. Автор балаларга аңлы тәрбия бирүне беренче планга куя. Лагерь начальнигы Гарифулла да, язучы Ләбибә Ихсанова да малайларны бик яраталар. Шуңа күрәме, усал малайларның күп кенә гөнаһлары кичерелә, хәтта либеральлек ноктасына барып терәлә.

Урыны-урыны белән әсәрдә ашыгучанлык сизелә. Балалар коллективын оештыруда отряд белән сәяхәткә чыгу искиткеч зур роль уйный. Менә шул бер атналык сәяхәт турында язучы ярты битлек информация белән генә чикләнә. Ләбибә Ихсанова — балалар әдәбияты өлкәсендә зур тәҗрибә туплаган язучы. Кайбер кимчелекләре булуга карамастан, балалар аның «Робинзоннар лагеренда»сын кызыксынып, яратып укырлар дип ышанасы килә.

Октябрь революциясенең 50 еллыгы уңае белән, соңгы елларда илебез халыкларының тарихи узганына тагын бер мәртәбә әйләнеп карау язучыларның игътибар үзәгенә куелды. Монарчы бездә Татарстан тарихы, татар халкының революцион үткәне хакында балалар өчен язылган әсәрләр юк дәрәҗәсендә аз иде. «Ялкын» журналында Гомәр ага Бәшировның «Туган ягым — алтын бишек» исемле автобиографик әсәреннән аерым өзекләр укыдык. Бер яктан, бу әсәрдә халкыбызның матур гореф-гадәтләре, хезмәт кешеләренә хас киң күңеллелеге ачылса, икенчедән, нәни уку-

чыларыбыз күренекле язучыны әзерләгән мохитны, шул чорның авыр хәлләрен, табигатьнең сихри көчен күз алдына китерә алачак. Гомәр аганың яңа повестен балалар да, өлкәннәр дә түземсезлек белән көтәләр.

Балаларга тормышның авыр, катлаулы, фаҗигале якларын күрсәтүдән дә, минемчә, тартынмаска кирәк. Балага гел кәнфит суыртып торсаң, ул тозлы кыяр сорый, ипигә горчица сылый башлый.

1965 елда чыккан әсәрләр арасында өлкән язучы Абдулла Әхмәтнең иң яхшы хикәяләрен туплаган җыентыгы белән рәттән, яшь авторларның да китаплары күренә. А. Тимергалинның «Ике хикәя — бер хыял» дигән китабы белән танышу минем өчен бер яңалык ачу шикелле булды. Китапка «Җир уллары», «Иң соңгысы» дигән хикәяләр һәм «Укытучы язмалары» кергән. Алардан тормыш сулышы бәреп тора. Авторның «Җир уллары» исемле фәнни-фантастик хикәясендә фәннең чиксез мөмкинлекләре, киләчәктә ирешәчәк казанышлары турында сүз бара. Ләкин, кызганычка каршы, кызыксынып укый башлагач кына, хикәя кинәт бетеп куя.

Кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматовның «Беренче мөгаллим»ен тирән дулкынлану белән укыдык. Менә шундый әсәрләрне татар әдәбиятында да күрәсе иде. Безнең язучылар арасында үзләре күп еллар укытучы булып эшләгән һәм хәзер дә шул эшне дәвам иттерүче иптәшләр бар. Һич югында, көндәлек кенә булса да алып барасы иде. А. Тимергалинның «Укытучы язмалары» бу юлда беренче адым булса кирәк. Автор бу язмаларын, психологик яктан тагын да тирәнәйтә төшеп, повесть дәрәҗәсенә үстерсен иде.

Җөмлә ахырында без тыныш билгеләре куябыз. Берәүләр нокта куеп сөйләшә, икенчеләре күп нокта белән, өченчеләрендә югары пафос — өндәү билгесе. Ә балаларга карата сорау билгесе кулланырга да мөмкин. Бала сөйләүдән бигрәк, үзе сораша. Ул һәр яңалыкны, киптергеч шикелле, үзенә сеңдерергә тырыша. Бездә моңа кадәр бер авыру яшәп килде. Баланың уй-хисләрен, хыялларын ишек алдында чабып йөргән этләр, чебиләр тирәсендә генә әйләндерү, дөнья белән уенчыклар аша гына таныштырырга азаплану нык җәелгән иде. Хәзер моңардан арына башладык шикелле. Чөнки заманы шундый. Әгәр эт турында сүз кузгатасың икән, бала синнән космоска менеп төшкән «Лайка» хакында сөйләвеңне сорый. Синең алдыңда йөз төрле сорау билгесе: еракмы ул космос, ничек очалар анда, «Лайка» хәзер дә исәнме?.. Нәни кешеләр хәзер ишек алдындагы чеби тавышларын гына тыңламыйлар, алар космостан килгән «пи-пи-пи»ләрне дә еш ишетәләр. 1965 елда тормышның төрле яклаын яктырткан, укучыларны киң хыял дөньясына алып чыгардай байтак проза әсәрләре барлыкка килде. Кыска хикәяләр остасы Гариф ага Галиев «Чәчәкле малайлары» дигән китабында авыл малайларының романтикага бай тормышларын, аларның җиргә, хезмәткә, димәк, бәхеткә якын торып үсүләрен шигъри итеп сурәтләп бирсә, Миргалим Харисов «Фаҗигале планета» исемле маҗаралы повестенда (повесть «Яшь Ленинчы» газетасында басылды) бала хыялын космос еракларына алып китә. Шул ук газетада басылган әсәрләрдән Газиз Мөхәммәтшинның «Бурзайлар командасы», Рафаэль Төхфәтуллинның «Алтын канатлы кош» дигән хикәяләре мактауга лаек. Чүпрәледән килгән «Партизан» кушаматлы малай: «Сез күңелсез яшисез, менә мин бурзайлар командасы оештырам», дип, кемнәрнедер шаккатырмакчы була. Ләкин мактанчык үзе көлкегә кала. Ә «Алтын канатлы кош» хикәясендә Харис белән Рәфис, алтын канатлы кош артыннан куып, кадерле минутларын югалталар, дәрескә соңга калалар. Ә кош дигәнең җил очырып җибәргән, кояшта ялтырап күренгән иске чүпрәк булып чыга. Юморга бай, шигъриятле, төчеләнүсез язылган чын хикәяләр болар. Әле балалар гына түгел, кайбер дәү кешеләр дә тормышта юк-бар артыннан куып, гомерләрен заяга уздыралар. Мораль темасына язылган, зур максат белән яшәргә өйрәткән мондый әсәрләр һава шикелле кирәк безгә.

Хәсән Сәрьянның балаларда дуслык, ярдәмчеллек, гаделлек тәрбияләү максаты белән язылган хикәяләр китабы да уңай тәэсир калдыра. Әмма «Классташлар» исемле хикәядә сюжет ягыннан да, характерларны ачу ягыннан да беркадәр ясалмалык бар.

Балаларга шигъри тел белән язылган очерклар да, ялкынлы публицистика да кирәк. Безнең янәшәбездә генә атаклы нефть табу осталары, бала чагы ятимлектә, хәерчелектә үткән, хәзер дәүләт эшлеклесе дәрәҗәсенә күтәрелгән Корбан ага Вәлиев кебек геройлар яши. Аның тормыш юлы искиткеч катлаулы, хезмәте романтикага

бай... Яки, фашистларның борын астыннан кулга самолет төшереп, әсирлектән үзебезнекеләр ягына чыккан легендар герой Девятаевны алыйк. Балалар мондый каһарманнардан үрнәк алып үсәргә тиешләр. Әлмәттә очрашу вакытында Михаил Девятаевның чыгышын балалар онытылып, ике сәгать буе авызларын ачып тыңладылар. Әгәр шул чыгышны магнитофон пленкасына гына язып алсаң да, менә дигән сюжетлы, детальләргә бай, яхшы әсәр барлыкка килер иде. Мондый китапларны тудыруда Язучылар союзы турыдан-туры катнашырга тиеш. Нәшрият андый китапларны алдан планлаштырып, язучыларга заказ биреп яздырсын иде.

Балалар драматургиясе, әүвәлгечә, көчхәл белән сөйрәлеп бара. Безнең хөрмәтле драматургларыбыз һәм драматург булмаганнарыбыз да, гүяки, колакларына мамык тыкканнар да, мәктәп сәхнәләренә аркалары белән борылганнар. Мәктәп сәхнәләре хәзер коргаксыган мичкәне хәтерләтә. Мәхәббәтнең ни икәнен дә белмәгән сабыйлар, аптырагач, унынчы-йөзенче тапкыр Галиябану белән Хәлил булып уйнарга тотыналар. 1965 елда балалар сәхнәсе өчен чыгарылган бердәнбер китап — Госман ага Бакировның пьесалары. Аның да әле тик берсе — «Звонок» дигәне генә уңышлы. «Безнең матуркайлар» дигән пьесада — балаларны хезмәткә өйрәтә, укуны тормыш белән бәйләп баруны пропагандалый торган әсәрдә — вакыйгалар агышы табигый түгел. Терлекләрне шефка алган пионерлар сыер савучы кыз Фәүзияне шәһәргә җибәрмәскә тырышалар. Тегесе ана-мона карамый, чемоданын күтәреп, иптәшләре белән хушлашырга фермага килә. Пионерлар Фәүзиянең «Матуркай» атлы сыеры беркемгә дә саудырмый дип хәйлә коралар. Хәйлә уңышлы чыга, кыз «Матуркай»ын кызганып, авылда торып кала. Пьеса Фәүзиянең шәһәргә китми калу тантанасы белән тәмамлана. Бакыр биш тиен шикелле шомарып беткән сюжет, шомарып беткән тема бу. Безгә яшь тамашачыларны тотып торырлык, бүгенге тормышның пульсын тоярлык яңа вакыйгалар табарга кирәк.

■

Нәни кешеләргә шагыйрьләр якынрак тора дисәк, башкалар рәнҗемәстер. Бөек Тукайдан килә торган бу әйбәт традиция хәзер дә дәвам итә. Узган ел басылып чыккан шигырь китапларына күз салганда, төшенкелеккә бирелерлек урын юк. Сибгат Хәкимнең «Күңелем Ленин белән сөйләшә», Әнвәр Давыдовның «Малайлар турында баллада», Гали Хуҗиевның «Кыюлар юлы», Шәйхи Маннурның «Нәниләргә, дәүләргә», Максуд Сөндекленең «Туган йорт» дигән китапларын алыгыз. Яшь буында патриотизм хисе, туган илне ярату тойгысы тәрбияләүдә бу әсәрләрнең урыны — иң алгы сафта. Әзмени әле үзе әчкән чишмәгә төкерергә әзер торучы мәгънәсезләр! Әзмени үзенең кем икмәген ашап үскәнлеген һәм хәтта нинди илдә яшәвен оныта башлаган шалапайлар!

Сибгат Хәкимнең «Күңелем Ленин белән сөйләшә» дигән китабын балалар да, зурлар да яратып укыячак. «Баһавиның моңы» исемле шигырьне укыганда күңелне изге бер моң биләп ала. Көтүче малай Баһавиның моңы, кыяр-кыймас кына, Ленинга килеп керә. Һәм ахырдан шундый гомумиләштерү:

...Ят сагышлар бассын юлларыңа,
Юлларыңа бассын Альплар...
Марсельезаларның арасында
Татарның бер моңын алып бар.

«Язгыз, җир уллары» дигән поэмасында менә бу строфаны һәр яшь кешенен тормыш юлына эпиграф итеп куясы килә:

Җитәрлекне юлга көч запасы?
Җитәрлекме юлга хыялы;
Яшьлекне син ачык күрим дисәң,
Яктысына җирнең куй аны.

Һәм артабан шагыйрь болай ди:

Үлчи яшьлек, бөтенесен үлчи,
Ленин белән басып янәшә...

Бөек Октябрь, Ленин темасы Гали Хуҗиев, Әнвәр Давыдов, Максуд Сөндекле шигырьләрендә дә балаларга якын телдә, үзенчәлекле яклары белән, көчле детальләр аша яктыртыла. Владимир Ильич әле Каплан пулясыннан савыгып та җитмәгән. Ә үзе, илдәге ач балаларга кайнар аш бирергә дип, декретка кул куя. Менә шушы тарихи фактны файдаланып, Гали Хуҗиев «Яңа декрет» дигән матур шигырь иҗат иткән. «Синең әтиең» исемле поэмада әти образы аша шагыйрь ил язмышын бирә.

Эшчеләрнең революциягә кадәрге тормышлары турында язганда, шагыйрь Максуд Сөндекле бик уңышлы детальләр таба. Ул шахтер әтисе турында болай ди:

Бу кулларга мин яшь чакта
Карадым өмет белән.
Бер тиен бакыр дип сузылсам,
Ул булды каты сөял.

Үзе үлгәч тә, карт шахтерның учлары, көрәк сабы тоткан шикелле, йомык калалар. Мондый детальләргә башка берни дә өстәргә кирәкми.

Әле күптән түгел балаларга «Муса абый» повестен бүләк иткән шагыйребез Әнвәр Давыдов «Малайлар турында балладa» исемле яңа әсәрендә меңәрләгән үсмерләрнең уртак уйларын табигый һәм матур итеп әйтеп биргән. Бала, үзенең язмышыннан зарланып, Идел ярында уйланып утыра. Революцияләрне дә аңардан башка гына ясаганнар, космоска да аңардан башка менеп өлгергәннәр. Ә чынлап торып уйласаң, романтика юк, зур эшләр калмаган дип зарланырга һич нигез юк икән бит:

Җир йөзе ята җәерәп,
Кул да тимәгән кебек,
Үзен бәхет бакчасына
Әйләндерүне көтеп.

Әнвәр Давыдовның шигырь һәм балладалары романтикага бай, аларда лирика белән публицистика аралашып бара.

Өлкән шагыйребез Шәйхи Маннурның «Ике саескан», «Күзлек кайда», «Бәбкәләр» шикелле телдән-телгә күчеп йөри торган күп кенә шигырьләрен беләбез. «Нәниләргә, дәүләргә» дигән җыентыкта да балаларны сөендерерлек мондый шигырьләр байтак. Бу китап нәни укучыны якты мәктәп залына алып керә, табигать дөньясы белән серләшергә чакыра.

Гамил Афзалның «Җәйге болытлар», Галимҗан Латыйпның «Җилферди лагерь байрагы», Мәхмүт Хөсәеннең «Кызыл галстук», Газиз Нәбиуллинның «Икмәк исе» кебек шигъри китаплары, Зәки Нуриның газета-журналларда басылган шигырьләре дә туган як табигатенә, җиргә мәхәббәт уяталар, пионер намусы турында сөйлиләр.

Газиз Нәбиуллин хезмәт турында, кара ипинең тәме турында яза. Ак булкига сары бал, ак май ягып ашарга гына өйрәнгән малайга, көн буе кырда йөргәннән соң, кара ипи дә бик тәмле булып тоела. Кара ипидән хәтта бал-май гына түгел, алма, чия, хөрмә тәмнәре дә килеп тора.

Баланың күңелен яулап алуда юмор— көчле чара. Иң житди фикерләрне дә юмор аша үтемлерәк итеп җиткерергә мөмкин. Шәүкәт Галиев — сатира-юмор өлкәсендә уңышлы һәм ялыкмыйча эшләүче шагыйрьләрнең берсе. Аның «Шәвәли» исемле шаян шигырьләр китабының беренче битен ачуга ук, көлеп җибәрәсең. «Фән кушканча», «Инкубатор күргәч» шигырьләрендә шагыйрь, балага сиздермичә генә, инкубатор турында, ферма тавыкларына ни өчен пыяла ашатулары турында төшенчә бирә. Кызганычка каршы, сатира-юмор өлкәсендә безнең язучыларыбыз әле бик аз эшлиләр. Гамил Афзал да, балалар турында яза башласа, бик житдигә әйләнә.

Нәниләр белән уртак тел табу аеруча зур осталык сорый. Шуңа күрәме, мәктәпкәчә яшьтәге нәниләр өчен китаплар бездә аз языла. Заһирә Гомәрованың «Иске ел кая китә», Әзһәр Габидинең «Без — яз дуслары», Абдулла Сәләхетдиновның «Тылсымлы касә», Резеда Вәлиеваның «Нәниләргә бүләк» исемле китаплары, әле күптән түгел генә чыгуларына карамастан, инде сатылып та беткәннәр. Нәниләр күңеленә якын булу ягыннан Заһирә Гомәрова, Зәкия Туфайлова, Мәрзия Фәйзуллина шигырьләре аерылып торалар.

Яшь шагыйрь Равил Фәйзуллин «Рәсем ясыйм» исемле беренче китабын нәниләргә багышлаган. Автор шигырьләрендә нәниләр белән шаян телдә сөйләшергә омтыла, һәм урыны-урыны белән, ул моңа ирешә дә. «Чыпчыклар», «Яңгырдан соң», «Таш» һәм башка шигырьләре уңышлы язылган. Китап матур рәсемнәр белән бизәлгән. Равил Фәйзуллин киләчәктә дә балалардан аерылмасын иде. Мәрзия Фәйзуллинаның «Малышка» нәшриятында «Пропала кошка» дигән әйбәт китабы басылып чыгу нур өстенә нур өсти.

«Ялкын» журналында Илдар Юзиевнең «Ганинең пони малае нәни Җирәнкәйне эзләве турында» шигъри хикәясе басылды. Автор баланы зоопарк буенча йөртеп, бер сәгатьтә бар дөньяның хайванын-кошын күрсәтә. Әсәр нәниләр кызыксынып укырлык итеп язылган.

Шул ук журналда Резеда Вәлиеванын «Җәй килә» кебек уңышлы гына шигырьләре бар. Ә менә аның «Нәниләргә бүләк» дигән шигырьләр китабында ясалмалык көчле. Ялкау карга баласы турындагы әкияттә инде өч баласы булган бер карга агач башына оя кора. Укый башлауга шиккә төшәсең: бу карга соң балалар чыгаргач оя корды микәнни? Автор карга балаларына чиләк белән су ташыттыра.

**Төпчеге, ялкаурагы, сүз тыңламыйча, урманга кача. Инде төпчеге дә очып йөри торган булгач, карга балалары нишләп ояда утыралар соң?.. Әкияттә дә чаманы белеп ялганларга кирәктер.**

**Нәтиҗә ясап, шуны әйтәсе килә: узган елда балалар егылып укырдай зур күләмле проза әсәрләре булмады дияргә ярый. Кайда йөри икән бүгенге көннең «Замана балалары», «Бәхет орлыклары», «Кара борынның дусты», «Рөстәм мажаралары», «Батыр исемле малай турында хикәяләр» шикелле әсәрләре? Абдулла Алиш әкиятләре туган заманнар сагындырып куя...**

**Балалар әдәбиятын үз агымына куярга ярамый. Макаренко әйткәнчә: «Балаларга дөрес тәрбия бирү — ул безнең бәхетле картлыгыбыз. Начар тәрбия — безнең киләчәктәге кайгы-хәсрәтебез, күз яшьләребез. Ул — башка кешеләр алдында, бөтен ил алдында гаепле булып калуыбыз».**

*Нур Гыйззәтуллин*

# ОЧЕРК — ЗАМАН ЮЛДАШЫ

Моннан ун еллар элек менә шушы клубта очерк жанры турында бер сөйләшү булган иде. Шуннан соң бу турыда махсус сөйләшү булганы юк кебек. Хәтта съездларда да, әдәби ел йомгакларына багышланган беренче киңәшмәдә дә очерк онытылып калды. Бәлки, безнең идарә, әдәбиятның тулы хокуклы бу жанрын әнә шул рәвешчә үги итүнең хаксызлыгын аңлап, быел аның турында аерым чыгыш ясауны кирәк дип тапкандыр? Ничек кенә булмасын, иртәме-соңмы, безгә барыбер хәзерге очерклар турында сөйләшеп алырга кирәк иде.

Безнең әдәбият тарихында очерк жанрының матур традицияләре бар. Ул һәрвакыт яңа тормыш төзү өчен көрәшнең алгы сафында килде, чынбарлыктагы яңалыкны беренчеләрдән булып күтәреп алды, аны пропагандалауга хезмәт итте. Татар әдәбиятында очерк жанры утызынчы еллар башында, илдә социализм төзү өчен кискен көрәш барган чорларда күтәрелеп китә. Казанда Ленин районы барлыкка килә — аның турында беренче булып очеркистлар язып чыга. Мехкомбинат, яңа заводлар, фабрикалар күтәрелә — алар турында да беренче булып очерк хәбәр итә, колхозлар тормышы да очеркларның сурәтләү объектына әверелә. Бөек Ватан сугышының дәвыллы елларында очерк жанры яңа югарылыкка күтәрелә. Бу елларда очерк жанрында эшләмәгән берәр татар язучысы булдымы икән? Совет солдатының данын, аның рухи бөеклеген чын дөреслек белән сурәтләп биргән документаль очерклар, очерк-портретлар, сугышчы язмалары, хәрби корреспонденцияләр, Советлар Союзы Герое исемен алган якташларыбыз турындагы очерклар һәм, ниһаять, шуларны бергә туплаган «Батырлар китабы» — болар бит барысы да Бөек Ватан сугышының документаль елъязмалары!

Илленче елларның беренче яртысында очеркларның алгы планга чыгуы да бу жанрның безнең әдәбиятта разведчик ролен үтәве белән бәйләнгән иде. Нәкъ шул елларда Татарстан нефтьчеләренең хезмәте, Казан порты һәм Волгоград ГЭСы төзелешләре, колхоз кешеләренең иҗади хезмәте, беренче башлап, очеркларда чагыла башлады һәм шуннан соң гына повесть-романнарга килеп керде.

Кайсы гына чорны алма, очерк жанрының илебез тормышындагы кискен борылыш моментларында алгы планга күтәрелүен күрәсең. Партиябезнең узган елгы Март һәм Сентябрь пленумы карарлары бөтен илдә яңа хезмәт күтәренкелегенә китерде. Һәм бу хәл очерк жанрын тагын да активлаштырып җибәрде. Очеркистлар өчен искиткеч зур мөмкинлекләр ачылды, алар алдына яңа бурычлар куелды.

Ә соң безнең очерклар әнә шул бурычларга ничек җавап бирәләр? Очерк жанрының үсешендә нинди дә булса яңалык бармы, әллә без һаман да элекке урында таптанабызмы?

Дөресен әйтергә кирәк, соңгы берничә ел эчендә, аерата узган 1965 елда, бездә очерк жанры бераз җанлана төште. Зәки Нуриның «Батырлар һәм матурлар» исемле китабында Түбән Кама кешеләренең романтик батырлыклары һәм рухи хисләре бирелсә, Малик Хәмитов белән Мәхмүт Хәсәеннең «Күтәрелештә» һәм «Бөркетләр юлы» дигән



Тәнәфестә

китапларында, Р. Ишмуратованың «Авылда бер көн», М. Хөснимәрдәновның «Якташларым» исемле очеркларында колхоз кешеләренең матур сыйфатлары сурәтләнә. «Хыялый Хәйрүш егетләре» исемле җыентыгына урнаштырылган очеркларында Г. Ахунов Татарстан нефтьчеләренең реалистик образларын күрсәтә, Әдип Маликов матур һәм самими хисләр белән язылган «Кембригә юл салучылар» исемле очеркында нефтьче якташларыбызның ерак Себер тайгаларындагы батыр хезмәтенә дан җырлый. Ш. Рәкыйповның «Барып аласы хат» һәм М. Ханнановның «Бормалы юлларда» исемле китаплары, тормышның үзеннән алынган фактларга таянып, бүгенге мораль мәсьәләләрен күтәреп чыгулары белән кызыклы.

Былтыр без Бөек Ватан сугышының тарихи җиңү белән тәмамлануының егерме еллык юбилеен үткәрдек һәм сугыш геройларын, яңадан бер тапкыр, иң җылы йөрәк хисләребез белән искә алдык. Шул уңай белән язылган очерклар арасында иң уңышлысы А. Шамовның «Пулялар белән язылган гариза»сы булды. Якташыбыз Шәриф Гәраев турындагы бу очерк документаль дөреслеге белән дә, динамик стиле һәм тыгыз сюжеты белән дә безнең күп очерклардан уңай якка аерылып тора. Р. Ишморатның «Кыю ир — ил күрке», К. Латыйповның «Батыр экипаж», Т. Таһировның «Бер язмышта туган зур дуслык» кебек очерклары совет кешеләренең Бөек Ватан сугышы фронтларындагы геройлыгын документаль дөреслек белән сурәтләп бирделәр. Р. Тимергалинның «Польша буйлап ике мең чакрым» дигән рубрика белән басылып килгән «Освенцимны онытма!», «Юзефның кәефе шәп», «Туганлык күпере» исемле публицистик очерклары да документаль материалга нигезләнгән. Аларда Бөек Ватан сугышы елларындагы Польша белән хәзерге Польшаны чагыштырган матур күзәтүләр бар. «Социалистик Татарстан» газетасында чыккан бу очерклар укучылар тарафыннан бик җылы кабул ителделәр. Шулар янына тагын Н. Мостафинның Казан педагогия институты галиме Әнвәр Тукаевка багышланган «Солдат язмышы» исемле зур документаль очеркын өстәргә мөмкин. Ф. Әгъзәмовның «Ил чәчәкләре» исемле матур очеркы да материалы белән нәкъ шушы проблемага килеп бәйләнә.

Очерк өлкәсендәге бер еллык уңышны кыскача барлап чыкканда да тематиканың төрлелегә ачык күренә. Очерклар төрле стильдә, төрле алымнар белән язылганнар. Аларның күбесе бүгенге тормыш фактларын һәм күренешләрен тирәнтен өйрәнү нәтиҗәсендә барлыкка килгән.

Башта, күп санлы очерклар арасыннан, М. Хәмитовның «Күтәрелештә» исемле әсәренә тукталыйк. Авторның игътибар үзәгендә — Буа районының «Ирек» колхозы кешеләренең тырыш хезмәте. Бу артельнең соңгы еллардагы үсешен автор колхозның экономикасын анализлау белән бергә кушып сурәтли. Китапның баштагы бүлекләрендә художестволы очерк алымнары файдаланылса, сюжет үсә бару белән автор документаль очерк стиленә дә мөрәҗәгать итә, колхозның экономикасы үсүен күрсәтүгә бәйләп, публицистика элементларын да кушып җибәрә. Нәтиҗәдә, төрле алымнарның матур синтезы барлыкка килә.

Элегрәк елларда, ди автор, бу колхоз «чүп-чар белән буылган чишмә суы кебек, һаман торгынлыкта булды. Чишмәнең ашкынып агып китүе өчен ермакны тазар-

тырга кирәк иде». Партия оешмасы ярдәме белән, председатель Әдһәм Каюмов колхозны күтәрү өчен көрәшнең алгы сафында бара, игенчелек эшен фәнни нигезгә салуны оештыра. «Кешеләр белән эшли белү, аларга игътибарлы булу, ышаныч күрсәтү — болар Каюмовка хас сыйфатлар». Бу — авторның Каюмовка биргән бәясе. Геройның бу сыйфатлары бөтен очерк дәвамында ачыла бара һәм нәтиҗәдә замандашыбызның җанлы портреты матур әдәбият әсәренә үзенең чын исеме белән килеп керә.

«Күтәрелештә» исемле очерк авторның үзе яза торган материалны яхшы белүе белән отышлы. М. Хәмитов, чынлап та, «Ирек» колхозы белән яхшы таныш. Матбугатта аның бу колхоз кешеләре турында элегрәк берничә очеркы басылып чыккан иде. Ул хәзер тагын да уйланган, вак детальләрне төшереп калдырган, фактларны ачыклаган һәм элек язганнарын бер бөтен әсәр итеп оештырган. Бер колхоз тормышын биш ел дәвамында өйрәнү матур нәтиҗә биргән.

М. Хөсәеннең «Бөркетләр юлы» исемле китабы эчтәлеге белән М. Хәмитов очеркына якын. Монда да бер колхоз тормышы сурәтләнә. Автор биш ел буенча Чаллы районындагы Муса Җәлил исемендәге колхозның тормышын өйрәнгән һәм бу колхоз кешеләренең матур хезмәтләрен сурәтләгән. Председатель булып Фатих Якупов килгәндә, бу колхозның хәле бик авыр була. Райком бюросында чыгыш ясаган бер абзый туп-туры итеп: «Бер артель белән дә бу кадәре чиләнгән юк иде. Уйлап карагыз: сигез елда унике председатель! Хурлык бит бу. Баштагы бүрекне дә ул хәтле еш алыштырмыйлар»,— ди. Артельнең элекке житәкчеләре Якуповка мирас итеп эскертләнмәгән салам белән егерме көнлек комбиазык калдырганнар. Ягарга утын юк, колхозчыларга ярты елдан бирле эш хакы түләнмәгән...

М. Хөсәен соңгы елларда проза өлкәсендә дә каләм сыный башлады. Башта ул туган ягы Казагыстан җирләрендә чирәм күтәрүче яшьләрнең фидакарь хезмәтен сурәтләгән очерклар язды һәм «Чирәм җирләр сулышы» исемле китап чыгарды. Аннан соң Братск ГЭСын төзүчеләр турында «Ангара утлары» исемле очерклар җыентыгы бастырып чыгарды. Хәзер ул укучыларга үзебезнең Татарстан игенчеләре турында яңа китап тәкъдим итә. Күрәсең, шагыйрь, үз күңелендәгене шигырь белән генә әйтеп бетерә алмаганда, очеркка да мөрәҗәгать итә. Аның очеркларына мул булып поэтик элементлар килеп керә. Хәтта китапның аерым бүлек исемнәре дә («Көмеш ай һәм утырыш», «Болытлы таң», «Назлы тургай һәм игеннәр», «Китаплар дөньясында», «Яз шатлыгы» һ. б.) авторның шагыйрь икәнлеген белдереп торалар. Поэтик элементлар геройларның портретларын бирүдә дә сизелә. Очеркның үзәк герое Якупов образы шулай тасвирлануы белән отышлы.

Ләкин авторга очерк жанрының үз законнарына ныграк игътибар итәргә кирәк әле. Прозага шигърият өстим дип, документаль фактларга нигезләнгән һәм реаль кешеләр турындагы очеркка помпезлыкпарадлылык рухы бирә торган, артык кабартылган һәм күпертелгән чагыштырулар кулланы белән ул, безнеңчә, ялгыша. Мәсәлән, ул парторг булып эшләүче ханымны карт имәнгә тиңли: «Калкулыкта, яшел маяксыман, бер имән күренде: калын төпле, юан кәүсәле, күп тармаклы, куе яфраклы. Тамырлары белән бик тирән киткән ул. Көзге ачы җилләр дә, кышкы дуамал бураннар да, язгы ярсу яңгырлар да, җәйге әлсерәткеч эсселәр дә какшата алмый аны: утырганы утырган. Йөзендә мескенлекнең әсәре дә юк. Аруны да, талчыгуны да, ялыгуны да белми имән: ямь-яшел яфракларын житез лепелдәтеп, ишетелеришетелмәс кенә җырлый, сизелер-сизелмәс кенә селкенә. Горур-мәгърур да, мәһабәтолуг та, көчле-куәтле дә ул! Көенгәндә, яфраклары кара яна. Сөенгәндә, яфраклары һава яра, ә гәүдәсе гел туры кала: бөгелми дә, сыгылмый да. Ат әйдәп баручы кыю ханым әллә нигә әнә шул галиҗәнап имәнне хәтерләтә».

Беренчедән, бу символик образ оригиналь түгел. Без инде аны, Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар»ыннан соң, Р. Төхфәтуллинның «Авылдашым Нәби»ендә дә, тагын башка әсәрләрдә дә күрдек. Икенчедән, ничек инде хатын-кызны «калын төпле, юан кәүсәле, күп тармаклы... гәүдәсе бөгелми дә, сыгылмый да» торган имән белән чагыштырып була икән!..

Инде сүз чыккач, тагын бер мисал китерик. Кышкы юл буйлап, артта калган колхозга яңа председатель бара. Аның бар курыкканы — юлдан адашу. Менә шул вакыт «ат кинәт, читкә тайпылып, муеныннан көрткә чумды... Дүрт ягы да тоташ стена. «Төпсез упкын шулдыр инде»,— ди безнең герой һәм «билдән салкын карга, эчтән кайнар тиргә бата-чума җиреннең алдына басты.

Атның тезгененнән тоткан килеш, олауны юлга алып чыкты... Кинәт җил басыла төште. Давыл тынды. Сукмак олы юлга кушылды. Батыр кучер да (ягъни герой үзе — Н. Г.), сабыр кашка да җиңеләеп сулыш алды».

Бу чагыштыруның да символик мәгънә дәгъвәләве кычкырып тора. «Кучер — председатель, ат — колхоз» дип кенә әйтәсе калган.

Ләкин, бу мисаллардан чыгып кына, бөтен очерк шул стильдә язылган дигән фикер калмасын. М. Хөсәен матур очерк язган. Иңгерек теле, оста чагыштырулары, эчке шигърияте белән ул бездәге очерк жанрын баетуга хезмәт итәчәк. Очеркның һәр бүлеге — үзе бер хикәя шикелле. Тәмамланган сюжетлы һәр бүлек, берсе икенчесенә ялгана килеп, очеркның гомуми эчке сюжетын барлыкка китерәләр. Авторга тик чамасыз пафос белән ясалма матурлыктан гына сакланырга кирәк. Ә сәнгатьчә чын гадилекнең әле бер язучыга да зарар иткәне юк.

Башка жанрлардагы кебек үк, очеркта тормыш күренешләре, чынбарлыктагы фактларның конкрет дөреслеген саклаган хәлдә, типиклаштырылып бирелә. Очеркист реаль фактларга таяна. Ләкин «факт үзе генә әле,— ди М. Горький,— тулы дөреслек була алмый. Ул чимал гына. Шул чималдан чын сәнгать дөреслеге коеп чыгарырга, эшкәртеп алырга кирәк. Бу сәнгать дөреслеге авторның фактка мөнәсәбәтеннән килеп чыга. Ә очерк үзе фактны гади генә сурәтләү түгел, ә факт турында, аның художник тарафыннан ничек үзләштерелүеннән, аның карашлары системасыннан һәм кичерешләреннән чыгып язылган хикәя ул». Шуңа ук бәйләп, М. Горькийның художестволы очеркның фәнни тикшеренү белән хикәя арасында торуы, ягъни эчтәлеге белән фәнни тикшеренүгә, ә формасы белән хикәягә якынлашуы турындагы фикерен дә искә алырга кирәк.

Укучы синең язганыңны күреп, күңеле белән сизеп торсын өчен, яза торган материалыңны бик яхшы белергә, өйрәнергә кирәк. Бу таләп очерк жанры өчен аерата әһәмиятле. Беседа вакытында блокнотка теркәп барган саннарга, яки узып барышлый гына күз ташлап үткән күренешләргә, беренче тәэсирләргә генә таянып чын художестволы очерк язу мөмкин түгел. З. Нуриның «Батырлар һәм матурлар», Ә. Маликовның «Кембригә юл салучылар» исемле очерклары материалны яхшы өйрәнү нәтиҗәсендә туганнар. Алар сурәтләгән кешеләр укучы күз алдына үзләренең бөтен матурлыклары белән килеп басалар. Ул кешеләр — бүгенге көннең чын хуҗалары.

Матур әдәбиятның барлык жанрлары турында сөйләгәндә дә, типиклаштырудан башка чын әдәби әсәр була алмый, дибез. Тик чынбарлыктагы фактларны һәм күренешләрне, образларны типиклаштыру һәр жанрның үз законнары буенча эшләнә. Очеркта да типиклаштыру процессының үзенчәлекләре жанрга килеп бәйләнә. Ул очеркның художество әсәре дә, тикшеренү-анализлау нәтиҗәсе дә булуы белән билгеләнә. Менә шуның өчен дә очеркта публицистик элементлар, хикәяләргә һәм повестьларга караганда, үзләренә бер махсус роль уйныйлар. М. Хәмитов белән М. Хөсәен дә, З. Нури һәм Ә. Маликов та үзләренең очеркларында публицистика алымнарын кулланалар, һәм ул алымнар үзләре үк типиклаштыру чарасы булып хезмәт итәләр.

Ләкин публицистика белән артык мавыгу да, яки аны бөтенләй онытып җибәрү дә очеркка зарар китерә. Бездә хикәя белән очеркны, яки очерк белән публицистиканы бер-берсе белән бутау, жанр буларак аларның чикләрен югалту — еш очрый торган хәл. Хәтта авторлар үзләре дә язган әйберләренең нинди жанрда икәнлеген кайвакыт ачык билгели алмыйлар. М. Хөсәен «Бөркетләр юлы» исемле китабын «очерк-новеллалар» дип атаса, З. Нури үз язмаларына «Түбән Кама күренешләреннән» дигән аңлатма бирә. «Казан утлары» редакциясе исә «Истамбул һәм Суэеш каналы аша Ямәнгә сәяхәт» һәм «Кхмерлар илендә» дигән юльязмаларны, исемнәре үк кычкырып торуга карамастан, укучыларга очерк дип тәкъдим итә! Г. Ахунов «Хыялый Хәйрүш егетләре» исемле китабының икенче яртысында урнаштырылган әсәрләренең бөтенесен бергә «хикәяләр-очерклар» дип кенә билгели...

Бәлки, хикмәт очеркларга караганда хикәяләрнең нәшриятта үтемлерәк һәм «хикәя» исеме астында тираж алуның җиңелрәк булуына бәйләнгәндер? Чыннан да, тормышны дөрес чагылдырса, хикәя булса да, очерк булса да барыбер түгелме? Юк, барыбер түгел. Жанрның ачык билгеләнмәве аның эчке законнарының бозылуына китерә. Нәтиҗәдә — ни очерк, ни хикәя!

Г. Ахуновның «Оператор Шейхеразый» исемле әсәренең бөтен эчтәлеге, андагы

публицистик алымнар, стиле — аның очерк икәнлеген раслыйлар. Ләкин очерк сюжеты принципларын новелла сюжеты принциплары белән алыштыру аркасында, әсәр үзенең тормышчанлыгын, ышандыру көчен югалта.

Очеркның сюжеты реаль вакыйгалардан, реаль кешеләр тормышыннан читкә чыга алмый. Очеркның материалы, аның сурәтләү объекты үзе үк сюжетны билгеле рамкаларга кертә. Нәкъ шушы мәсьәләдә кайвакыт Г. Галиев кебек танылган очеркистлар да ялгышып куялар. «Бөгелмә иманлеге» исемле әсәрендә Г. Галиев: «Әгәр без бу язмаларны хикәя дип атасак, аны мөмкин кадәр мавыктыргыч сюжетка кору, ә инде очерк дип исем бирсәк, белгән-күргәннәрне барысын да хронологик тәртиптә сурәтләү кирәк булыр иде».— дип яза. Ә хронологик сурәтләү ярдәмендә юньле очеркның дөньяга килгәне бармы соң? Хронология икән, ул әле елъязмада, яки юлъязмада очрарга мөмкин. Ләкин чын художестволы очерк вакыйгалар хронологиясеннән бик ерак тора. Бездә еш басыла торган урта кул очеркларның художестволы әсәр булып чыкмавының бер сәбәбе дә әнә шул хронологик сурәтләү, очерк героеның тормышын рәттән сөйләп бирергә тырышу белән аңлатыла булса кирәк. Очерк укучыга барып житкәнче үк искереп бетә торган саннар аның кимчелеген көчәйтә генә.

Бүгенге тормыштагы катлаулы проблемаларның бөтенләй диярлек күтәрелмәвен, вакыйгаларны иллюстрацияләп кенә баруның күплеген, проблематик һәм бәхәсле мәсьәләләр күтәреп чыгудан куркуның очеркларга бик зур зарар китерүен ачык әйтергә кирәк. Болар бит барысы да — очеркистларның әле һаман да тормышның эченә тирән керә алмауларының нәтиҗәсе.

Байтак очеркларның чиле-пешле һәм кытыршы язылуы, яки артык бизәкләнгән, акшарлы һәм бөдрә фразалардан оештырылуы да, чынлап караганда, авторның тормыштагы яңалыкларны бөтен тирәнлегендә күреп һәм аңлап житкерә алмавына килеп бәйләнә. Ә очерк бит, башка жанрларга караганда да, язучыдан искиткеч күзәтүчәнлек сәләте, конкретлык, геройларның җанлы интонациясен саклауны, фактларның документаль дөреслеген таләп итә. Сыер савучы яшь кенә кыз үз эшенә: «Олы диңгез кечкенә елгалардан хасил була» [1].— дип бәя бирә икән, бу инде — фальшь. Артта калган бер колхозга председательлеккә тәкъдим ителгән кешенең райком бюросы членнарына: «Һәлакәткә очраган корабльнең штурвалын партия ышанып миңа тапшыра икән, нигә көчне сынап карамаска» [2].—дип, «пафослы» җавап бирүен дә шулай ук кем табигый дип әйтә алыр?

Кайбер авторлар күзәтүләрнең азлыгын, геройларны, аларның тормышын белмәүне матур фразалар, канатлы чагыштырулар, күтәренке, пафослы тон алыштыра ала дип уйлыйлар, ахрысы. Югыйсә, геройларга «нииндидер тылсымлы канат үсеп чыккандай була, я ниндидер сихри җилкән киергән һава көймәсенә янәшә утырып алалар. Аннары биектә, җирдән бераз югарыда, йолдызлар арасында сәяхәт башлана» [3] кебек мелодекламацияләр килеп чыкмас иде.

Сөйләмне кирәксезгә бизәкләү, урынсыз декламация, һәр күргән нәрсәгә «ах!» та «ух!» дип шаккату, төзелешләрне дә, күтәрелеп караганда, бүрегең төшеп китәрлек итеп күрсәтү, югарыдан күз салганда күлелгаларның көзгедәй җәйрәп ятуларын тасвирлау — болар барысы да кабинетта утырганда түшәмнән алынган, бармактан суырылган буш сүзләр. Әнә шул «матурлыкларга» өстәлеп, «үзләреннән башканы һич белергә теләмичә... мин-минлек бишегендә ваемсыз чайкалучы дулкыннар», «шаулап торган симфония булып туучы яңа шәһәрләр» [4] төзелә, «көмеш ай дәрьясыннан агылган нурлар ап-ак келәм өстендә энҗеләр тәгәрәтә» [5] башлый, «басу — аның стихиясе, кырлар — аның өчен романтика кебек «оригиналь» җөмләләр китә.

Менә мондый күренешләр телнең табигыйлеген генә бозып калмыйлар. Алар укучыда: «Тукта әле, туган, болай ук булырмы икән? Син нәрсәдер алдыйсың түгелме?» — дигән шикләнү дә уяталар. Ә укучының ышанычын югалту — язучының фаҗигасе.

Югарыда китерелгән мисаллардан соң, ирексездән, бер рус очеркистының әсәрендәге «Ах, нинди су! Әчү өчен ул, хрусталь шикелле...» дигән сүзләре искә төшә. Нәкъ шушы юллар турында тәнкыйтьчеләрдән берәү: «Суны, аның үтә күренмәле булуын күз алдында тотып, хрусталь белән чагыштыралар икән, искитәрлек оригинальлеге һәм яңалыгы булмаса да, бу ча-

[1] М. Хөсәен. Бөркетләр юлы. Казан, 1955 ел, 35 бит.
[2] Шунда ук, 10 бит.
[3] З. Нури. Батырлар һәм матурлар. 3 бит.
[4] Шунда ук.
[5] М. Хөсәен. Бөркетләр юлы. 3 бит.

гыштыруда нинди дер мәгънә бар әле, әмма инде «хрусталь» «әчү» сүзе белән бәйләнештә бирелсә, мондый образдан соң кеше ирекле-ирексез үзенең тамагында пыяла бөке сизә башлаячак»[1],— дип язган иде. Безнең кайбер очерклардагы ялган пафосны, ялган матурлыкны тамакка тыгыла торган әнә шундый пыяла кисәге дими, нәрсә дисең инде?

Чыгыш өчен бирелгән вакытның бик аз булуы сәбәпле, без узган елда чыккан барлык очеркларга да туктала алмадык. Очеркның жанр үзенчәлекләре, андагы публицистик элементлар, сюжет, тел-стиль мәсьәләләре, очерк жанрының үз эчендәге төрләре турында киләчәктә махсус сөйләшүләр булачагына өметләнеп, без хәзерге очеркларга караган аерым мәсьәләләргә генә тукталдык.

Хәзер инде чыгышның башында ук куелган сорауга килик. Әйе, бездә соңгы вакытларда очерк өлкәсендә бераз җанлану бар. Сирәк булса да, очерклар аерым китап булып чыгып килә, алар газета-журналларда да басыла. Ләкин сыйфат ягыннан без, элекке еллар белән чагыштырганда, искитәрлек алга китә алмадык әле.

Бигрәк тә, зур проблемалар кузгаткан очеркларның булмавын төп кимчелекләрнең беренчесе итеп әйтергә кирәк. Октябрьнең 50 еллыгына әзерлек уңае белән очерклар бик аз языла. Хәзергә Г. Галиевнең «Землемер баганасы» һәм С. Шакирның Хәйретдин Мөҗәй турындагы «Ялкынлы көрәшче» исемле очеркларыннан башка, бу темага багышланган юньле әсәрләр күренмәде шикелле. Бөек Ватан сугышының яңа геройларын эзләп тапкан, исемсез батырларыбызның исемнәрен ачып биргән очеркларның азлыгын әйтми булмый. Алдынгы совет кешеләренең югары мораль сыйфатларын, иҗади хезмәтләрен күрсәткән очерк-портретлар да күбрәк булырга тиеш.

Ләкин нинди генә темага багышлануына, сурәтләү объекты итеп нәрсәне генә алуына карамастан, очерк чын мәгънәсендә художестволы әсәр булырга тиеш. Югары идеяле, авторның вакыйгаларга һәм кешеләргә позициясе ачык булган чын сәнгать әсәрләрен генә укучыларга очерк дип тәкъдим итәргә кирәк. Бары шул вакытта гына безнең очеркистлар үз әсәрләренең әдәбиятыбызның тулы хокуклы, яшәргә һәм үсәргә лаеклы, кирәкле һәм файдалы бер аерылмас өлеше икәнлеген исбат итә алырлар.

[1] В. Росляков. Советский послевоенный очерк. Мәскәү, 1956 ел, 270 бит.

# ЗАМАН ЯХШЫРАК ӘСӘРЛӘР СОРЫЙ

Докладлар буенча фикер алышуда уннан артык кеше катнашты. Чыгыш ясаучылар бүгенге әдәбиятның аерым жанрлары турында сөйләнгән докладларның күп уңай, әйбәт якларын билгеләп үттеләр, алардагы кайбер төгәлсезлекләргә, ахыргача уйланып җитмәгән аерым моментларга тукталдылар, язучылар җәмәгатьчелеген борчый, уйландыра торган бүтән әһәмиятле мәсьәләләрне кузгаттылар. Кыскасы, 1965 әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышта берьеллык иҗат уңышларыбыз, бүгенге әдәбиятның торышы, бурычлары турында шактый тулы, җитди һәм файдалы сөйләшү барды.

— Балалар әдәби китапларны күп укучан булалар, — диде Л ә б и б ә  И х с а н о в а. — Без балаларны ни хәтле генә тыйсак та, зурлар өчен язылган китапларны да алар барыбер укыйлар. Шуның өчен олыларга атап язылган әсәрләрдә дә тәрбия мәсьәләләренә зур игътибар бирелергә тиеш. «Корыч ничек чыныкты», «Алтын йолдыз» романнары болай балалар өчен язылган әсәрләр дә түгел, шулай да балаларның иң яраткан китапларына әйләнгәннәр. Бу әсәрләр балаларны нәрсә белән җәлеп итә соң? Минемчә, геройлары кызыктыра. Кечкенәләр укый торган китапларда «Корыч ничек чыныкты», «Алтын йолдыз» романнарындагы кебек үрнәк булырлык геройларның хәзер азрак очравы эчне пошыра. Балага күбрәк тормышның матур якларын күрсәтергә тиешбез.

Соңгы елларда тарихи шәхесләргә багышлап язылган әсәрләребез күбәйде: Р. Ишморатның «Давылга табан» пьесасы, М. Ногманның «Яшенле җәй» поэмасы аерым китап булып чыкты, С. Шакирның «Сталинград батырлары» исемле әсәрен дә балалар яратып каршылады. Ләкин еш кына бөек шәхесләрнең балалык елларын без берьяклырак сурәтлибез. Балаларда очрый торган шаянлыклар, төрле ялгышулар зур тарихи шәхесләр өчен дә хас бит. Нигә соң аларны бишектә чакта ук даһи итеп күрсәтергә кирәк? Бу яктан караганда, М. Ногман поэмасы уңышлырак шикелле. Ленинны ул бала иттереп бирә. Тарихи шәхесләргә багышланган әсәрләрдә шул юл белән барсак, әйбәтрәк булыр, минемчә.

Ә м и р х а н  Е н и к и тормыш һәм әдәбият, аларның бербереcенә йогынтысы турында сөйләде, үзен һәм каләмдәш дусларын борчыган башка мәсьәләләргә тукталды.

— Язучының уйланмыйча



Президиум. Сулдан уңга: С. Хәким, М. Әмир, Г. Минский, М. Мөхәррәмов.
Трибунада Р. Мостафин.

торган сәгате була микән? — дип башлады ул сүзен. — Ул һәрвакыт уйлана һәм тормыштагы вакыйгаларның зурысы турында да, кечкенәсе турында да уйланырга мәҗбүр. Барысыннан да бигрәк уйландыра торган нәрсә — заман үзе. Үзебезнең тирә-юнебез, заманыбызны тирәнрәк, киңрәк һәм ачыграк белергә вакыт.

Әдәбият тормыш белән, үзенең чоры белән нык бәйләнгән булырга тиеш дип әйтәбез. Бу — дөрес. Ләкин һәр язучының заманны ничек, нинди тирәнлектә аңлавы бар бит әле. Минемчә, язучы кеше тормышны ачык машинада аягүрә басып үтешли генә өйрәнә алмый. Әгәр шулай выжлатып кына узып китсә, язучы халыкның нәрсә көткәнен, нинди теләк-омтылышлар белән яшәгәнен сизеп-белеп өлгерә алмас иде. Заманны танырга теләгән вакытта, без аны югарыдан һәм читтән торып түгел, ә тормышның эчендә торып, эчендә кайнап күрергә һәм аның сулышын тоя, аңлый белергә тиеш.

Бүгенге заман ниндиерәк заман соң ул? Сез барыгыз да беләсез: шушы ел ярым, ике ел вакыт эчендә партиянең ике пленумы булып узды. Ул пленумнар тормышыбызга зур үзгәрешләр кертте. Заманыбыз эзләнүләр белән, борылмалар да ясап, кайчагында чигенә дә төшеп, яңа юллар сала-сала, алга бара. Яңа юллар табу җиңел генә түгел, ул яңа стильләр, яңа формалар табу, киеренке иҗади эш белән бәйләнгән. Күрәсез, нинди катлаулы процесс. Әдәбиятта да заманыбыз үзенең бөтен катлаулылыгы, киң коламы белән чагылдырылсын иде.

Без әдәби әсәрнең үзәгендә кеше тора, дибез. Өстәвенә, ул безнең замандашыбыз булсын дигән таләпне дә куябыз. Монысы да бик дөрес. Шуның белән бергә, заман шундый катлаулы, иҗади процесс икән, димәк, шул процесска катнашучылар үзләре дәниндидер плакатный кешеләр генә була алмыйлар. Нинди ул безнең бүгенге замандашыбыз? Коммунизм җәмгыяте төзүче бүгенге кешеләребез барысы да бер төсләр, бер калыптан төшкәнәрме? Минемчә, хәзерге заман кешесе ул, барыннан элек, уйланучан, эзләнүчән кеше. Ул шул уйланулар, эзләнүләр нәтиҗәсендә бәхәскә керә торган кеше, аның нәрсәнедер яклыйсы, нәрсәнедер кире кагасы һәм тормышта үз урынын билгелисе килә.

Мин бу сүзләрне ни өчен сөйлим соң?.. Бездә хәзер әдәбиятыбызны ике сортка бүлеп йөртү бар. Беренче сортка тормышның гел якты, матур якларын гына күрсәтә торган әдәбият, икенче сортка карарак әдәбият керә. Минемчә, безнең әдәбиятны шул рәвешчә бүлү-сортлау ясалма әйбер. Әлбәттә, әдәби әсәрләрнең эшләнеш дәрәҗәләре төрлечә булырга мөмкин, анысында сүз юк. Ләкин нинди материал сайлау гына әле бу әсәр якты, монысы караңгы дип бүлгәләп йөртергә җирлек бирми. Хикмәт максатта, язучының идеалы якты булсын. Без язучыларны тормышны дөрес аңларга, позицияләренең һәм максатларының ачык булуына өндәргә тиешбез.

«Ялкын» журналының җаваплы редакторы Роза Хафизова балалар әдәбияты өлкәсендәге кимчелекләр, хәл ителмәгән мәсьәләләр турында сөйләде:

— Соңгы берничә ел эчендә редакциягә фәнни-фантастик повесть дип әйтмим, хәтта шундый хикәя кергәне юк. Кайчанда булса андый әсәрләр килер, алар белән укучыларыбызны шатландырырбыз дип өметләнергә дә туры килми: беркем дә бу өлкәдә җитди рәвештә эшләми. Һәм без, теләсәк-теләмәсәк тә, тәрҗемә әсәрләргә тукталырга мәҗбүр булабыз.

Әдәби әсәрләрдә мәктәп тормышы, пионерларның бүгенге эшләре тиешле чагылыш тапмый. Өлкән язучыларыбызның балалар әдәбиятына игътибарлары җитәрлек түгел. Г. Бәширов, Г. Галиев, Г. Бакировтан

гайри, бер генә өлкән язучының да безнең журналда катнашканы юк.

Тагын бер житди мәсьәлә. Бездә матур әдәбияттан иң мәхрүм кешеләр — мәктәпкәчә яшьтәгеләр һәм кече яшьтәге мәктәп балалары. Нәниләр өчен, бер генә табак күләмендә булса да, айлык журнал кирәк. Ата-аналар, тәрбиячеләр бездән нәниләр өчен язылган материаллар сорап аптырыйталар. Барлык союздаш республикаларда мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече мәктәп яшендәге балалар өчен махсус журналлар бар. Аларның тиражы гадәттә 100 меңнән артык. Бездә дә шундый журнал чыгарырга бөтен мөмкинлекләр бар.

— Безнең татар әдипләре башка әдәбият вәкилләре белән тиешле ижади бәйләнештә яшәмиләр әле, — диде Мәскәүдә яшәүче әдәбият галиме һәм тәржемәче Вил Ганиев. — Төрки әдәбиятлар белән бәйләнеш не алый[к]. 20 елларда татар әдәбияты ул әдәбиятларның үсүенә көчле йогынты ясап килде. Һ. Такташ поэзиясен үзбәк укучылары да яратып кабул иттеләр, Г. Ибраһимов Төрекмәнстанда житди проза тудыруга ярдәм итте. Безнең әле хәзерге көндә дә аларга үрнәк булырлык әдипләребез күп. Шуның белән бергә, соңгы 40—50 ел вакыт эчендә төрки әдәбиятлар да бик нык үстеләр, камилләштеләр. Ләкин без аларның уңышларын житәрлек белмибез дә, өйрәнмибез дә.

Безнең әдәбият белән чит илләрдә дә кызыксыналар, аңа игътибар белән карыйлар. Татар әдәбияты белән кызыксынучы чит ил галимнәре арасында безнең дусларыбыз да, дошманнарыбыз да күп. Дошманнар арасында да төрлесе бар. Ул галимнәрнең безнең әдәбиятка караган хезмәтләрен без белергә тиеш һәм ул хезмәтләргә үз мөнәсәбәтебезне дә белдерергә бурычлы.

Татарстан радиосының әдәби-музыкаль тапшырулар буенча баш редакторы Юныс Әминов:

— Язучылар радио тапшыруларда ешрак катнашсыннар, активрак чыгыш ясасыннар иде, — диде. — Без язучылардан көндәлек вакыйгаларга карата публицистик очерклар, чыгышлар көтәбез. Дөрес, безнең регуляр рәвештә эшләп килә торган авторларыбыз бар. Мәсәлән, Г. Әпсәләмов, Г. Кашшаф, З. Нури, Г. Бәширов, Г. Минский, С. Хәким кебек әдипләребез безгә ярдәм итәләр. Ләкин бу бик аз.

Аннан соң Ю. Әминов жыр текстларына тукталды, бу өлкәдәге житешсезлекләр, ул житешсезлекләрне бетерү юллары турында сөйләде.

Меңләгән китап сөючеләр исеменнән чыгыш ясаган Н. Абдршинны язучылар жәмәгатьчелеге кызыксыну һәм игътибар белән тыңлады.

— Әдәбиятыбыз елдан-ел киңрәк адымнар белән алга, яңа биеклекләргә таба атлый, — диде ул. — 1965 елда без киң күләмле, тирән мәгънәле байтак яңа әсәрләр күрү бәхетенә ирештек. Ул әсәрләр арасыннан күпчелек укучыларга аеруча ошаганы Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романы булды. Бу романда медицина эшчеләренең фидакарь хезмәте, халыкның ул кешеләргә булган ышанычы һәм хөрмәте күрсәтелә, әсәрдә соклandыргыч, матур сурәтләнгән образлар күп.

Үткән елда чыгып, укучылар тарафыннан яратып каршы алынган зур күләмле әсәрләрнең икенчесе — Ш. Маннурның «Муса» романы. Бу — танылган өлкән шагыйребезнең беренче проза әсәре. «Муса» татар әдәбиятында тарихи-биографик жанрда язылган әсәрләрнең иң уңышлыларыннан дияргә була. «Тар шигырьләр үлчәве» нәнән чыгып китеп, урыны-урыны белән кирәгеннән артык жәелүләрне, кайбер тел кытыршылыкларын исәпкә алмаганда, бу романны Ш. Маннур аганың зур уңышы санарга кирәк. Поэзиядәге кебек үк, прозада да ул әле безгә матур, ләззәтле жан азыклары күп бирер дип ышанабыз.

Ахырдан Н. Абдршин иптәш Ф. Хөсниненең «Минем тәрәзәләрем» повесте, С. Кудаш һәм И. Рәми истәлекләре турындагы фикерләрен әйтте, әдәби әсәрләрне иллюстрацияләүдәге кимчелекләргә тукталды.

Фатих Мөсәгыйт тәнкыйтьче Рафаэль Мостафинның «Казан утлары» журналының 1965 елгы 8 санында басылган «Алга барышлый» исемле мәкаләсе турында үзенең фикерләрен әйтте.

— Ижади эшләребезгә йомгак ясагачда, шатлыклы бер күренеш турында әйтми китә алмыйм, — диде Госман Бакиров, — арабызда яшьләр үсә, яңа исемнәр күбәя. «Казан утлары» журналының соңгы елда чыккан саннарында гына да әллә никадәр яңа авторлар күрәбез. Куанычлы хәл бу. Шул ук вакытта яшь каләмнәрне тәрбияләү эшенә житди игътибар да кирәк. Мондә кайбер иптәшләр яшь шагыйрьләрнең әсәрләрен күккә күтәреп мактадылар. Бу кадәресе белән үк мин килешә алмыйм. Мин моны яшьләребезне тыйнаклыкка өйрәтү теләге белән әйтәм. Ярый ла, алар мактау сүзләрен дөрес аңласалар. Күккә күтәреп макталучылар арасында масаеп китүчеләр дә байтак. Аларны барыбыз да беләбез. Безнең танылган язучыларыбыз ижат эшләренең башлангыч чорында мондый макталуны белмәделәр һәм аңа мохтаж да булмадылар.

Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясе мөдире Сафа Сабиров язучыларны нәшриятның 1965 елда башкарган эшләре, 1966 елга эш планы белән таныштырды.

— Әдәби елга йомгак ясаганда барыбызны да уйланырга мәжбүр итәргә тиешле кайбер мәсьәләләргә тукталмакчы булам, — диде ул ахырдан. — Татарстан индустриаль республикаларның берсе. Зур-зур төзелешләр бара, завод-фабрикаларыбыз, эре предприятиеләребез күп безнең. Аларда дистәләрчә меңләгән кешеләр эшли. Шул кешеләр үзләре турында язылган әсәрләр көтәләр. 1964—65 елларда эшчеләр темасына язылган әсәрләр юк диярлек яки бик аз. 1966 елгы планда да андый әсәрләр күренми. Бу хакта нык уйланырга кирәк безгә.

Тәнкыйть турында доклад ясаучы әдәбият белеме, әдәбият тарихы һәм бүгенге әдәбият турында китаплар аз булуын әйтте. Бу, чыннан да, шулай. Безнең кулда һәрьяктан канәгатьләнерлек тәнкыйть әйберләре юк диярлек. Булганнарының күбесе шактый сай һәм примитив. Безгә әдәбиятның әдәбият икәнлеген аңлап язы-

ган, шул ук вакытта халык аңларлык популяр телдә язылган тәнкыйть әсәрләре кирәк.

Халык театрлары, үзешчән сәнгать коллективлары өчен сәхнә әсәрләренә дә мохтаҗлык зур. Драматурглар бу нәрсәгә дә игътибар итсеннәр иде.

— Үзем прозаик булмасам да, прозаның төп әсәрләрен укып барырга тырышам, — диде шагыйрь Сибгат Хәким. — Бүгенге прозада күзгә ташланган төп сыйфат — тормышның катлаулы проблемаларына үтеп керергә тырышу, хакыйкатьне әйтергә омтылу. Әнә шул нәрсәне, хакыйкатьне әйтергә омтылуны, мәсьәләне мөмкин кадәр тирәнрәк алырга тырышуны яшьләрдә булсын, өлкән буын вәкилләрендә булсын бик нык сизәм һәм моңа куанам.

Хәзерге поэзиядә барган бәхәстә миңа ошамаган бер як бар, ул да булса бу бәхәсне кузгаткан кешеләр, яшь тәнкыйтьчеләр үзләре дә, сәер әйбер әйтәләр. Имеш, шагыйрьгә аңа бары форма гына кирәк, әгәр шул форманы тапса, ул бөтен Советлар Союзына шаулар иде, танылып китәр иде. Мин форма эзләүгә каршы түгел, ләкин ниндидер формалар белән генә мавыгуны шагыйрьнең ясалма эзләнүе дип әйтер идем. Тукай, Такташ, Маяковский, Есенин барысы да зур шәхесләр, аларның әйтерлек фикерләре, уйлары бар, «ходай тәгалә биргән» талантлары бар.

Госман Бакиров яшьләргә карата шактый зур кисәтү ясады. Ул кисәтүне мин яшьләрнең мораль якларына карата дөрес дип саныйм. Ләкин инде аларны күккә чөяргә кирәкми дигән фикер белән килешмим. Билгеле, әгәр шагыйрьнең мактарлык әйбере юк икән, мактамаска кирәк. Әгәр кеше, чыннан да, талантлы икән, вакытында аның талантын күрергә кирәк. Русларның яшь шагыйрьләре белән чагыштырганда, мин үзебезнең егетләрне, шул ук Р. Фәйзуллин булсын, Р. Гатауллин булсын, бер дә алай кимсетеп карамыйм. Үзебезнең егетләрнең, поэзиягә килә торган егетләрнең әзерлексез түгел, ә бәлки, шактый ук югары дәрәҗәдә торырлык кешеләр икәненә ышанам. Зур киңлекләргә чыккан, күп санда бик әйбәт шагыйрьләре булган рус әдәбияты яшь авторларны үстерүгә зур игътибар бирә икән, безгә бу турыда күптән уйларга кирәк.

Татарстан язучылар союзы идарәсе секретаре Зәки Нури башта «Социалистик Татарстан» газетасында М. Җәлил һәм Г. Тукай юбилейлары уңае белән бара торган дискуссия материаллары турында сөйләде. Әдәби дискуссияне тагын да җанландыра һәм җитдиләндерә төшәргә кирәклеген әйтте. Ахырдан яшь язучылар тәрбияләү мәсьәләләренә тукталды:

— Яшьләр мәсьәләсендә Сибгат ага бик дөрес әйтә. Аларга булышырга кирәк. Яшьләр бүгенге тормышны, бүгенге кешеләрне тирәнрәк, якыннанрак өйрәнергә тиешләр.

Быел республикада алты районда зур китап базарлары булды. Пермьдә, Ленинградта уздырылган атналыклар вакытында Г. Әпсәләмов, Г. Минский, Н. Дәүли, М. Садри, Г. Ахунов, И. Юзиев кебек язучыларыбыз актив катнаштылар һәм нәтиҗәле эш алып бардылар. Ләкин бу мәсьәләгә читләтеп караучылар да бар, андый кешеләр яшь язучылар арасында да байтак. Язучыларның 25 проценты масса-тәрбия эшеннән читтә калып килә. Язучылар җәмәгатьчелегендә мондый пассивлык булмаска тиеш.

Әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышны Татарстан язучылар союзы идарәсенең председателе Мирсәй Әмир япты.

— Минемчә, — дип башлады ул сүзен, — ярыйсы гына фикер алышу булды шикелле. Докладлар шактый эчтәлекле булды. Докладчыларның нигездә яшьләр булуы игътибар итәрлеге тиешле момент. һәм бу, чынлап та, безнең коллективыбызның яшьләр исәбенә үскәнлеген һәм әйдәү эшенең яшьләр кулына күчә баруын күрсәтә торган әйбәт факт.

Илдар Юзиев доклады турында байтак сүз булды. Илдар әйбәт доклад ясады. Үзебезнең поэзияне союз күләмендәге һәм дөнья күләмендәге поэзия фикерләре белән бәйли алды. Ул монда Р. Фәйзуллин турында әйтеп китте. Аны бик нык күтәрде, әлбәттә.

Р. Фәйзуллин үзенең беренче шигырьләре белән укучыларның һәм әдәбият кешеләренең игътибарын җәлеп итте. Аның ул шигырьләре, чыннан да, поэзия дөньясына яңалык алып килде. «Нюанслар иле»н укыгач, миңа беркадәр күңелсез булып китте. Анда чын мәгънәсендә тирән фәлсәфи фикер дә, поэзиябезне алга әйдәрлек яңалык та юк әле.

Шигырь өлкәсендә әдәбиятка шактый өметле генә яшьләр киләләр, соңгы елларда поэзия күзгә күренеп үсеп бара. Докладчы булгач, үзе турында Илдар Юзиев берни дә әйтмәде. Шагыйрь буларак аның үрнәк ягы гади һәм тыйнак булуында. Ул поэзиягә тыйнак рәвештә килеп кергән, булган традицияләргә зур хөрмәт белән караган кеше. Ул хәзер Тукай, Җәлил традицияләрен оста дәвам итеп, үстереп бара.

Драматургия буенча доклад ясаган Б. Гыйззәт иптәш безгә драматургиянең артка калуының төп сәбәпләрен ачып бетермәде. Драматургия секциясе дә бу эшкә бик тыныч карый.

Үзенең чыгышында М. Әмир Нурихан Фәттахның «Артта калган юллар» хикәясенә һәм Ә. Баяновның «Күзләре нинди иде» исемле пьесасына тукталды.

— Бу әсәрләр белән танышкач, — диде ул, — авторларның нинди идея үткәрергә теләгәннәрен ачык аңлап булмый. Борчылып әйтәсем килә: иптәшләр, бигрәк тә яшь иптәшләр, үзләренең позицияләре турында, язган әйберләреннән нәрсә килеп чыгуы турында ныграк уйласыннар иде.

М. Әмир йомгаклау сүзен болай дип бетерде:

— Хәзер безнең республикабыз ифрат дәрәҗәдә алга китте. Татарстанның үсеш дәрәҗәсе белән чагыштырганда, әдәбиятыбызның безне канәгатьләндерерлек югарылыкка күтәрелеп җитә алганы юк әле. Дөрес, безнең союз күләмендә яңгырарлык әсәрләребез юк түгел. Ләкин алар елдан-ел күбәя барырга тиеш. Уйланулар шушы тирәдә барса, бик әйбәт булыр иде. Безне әйләндереп алган тормыш, һәр яктан таләпчәнлек белән, тизрәк, яхшырак әсәрләр язарга өнди. Без менә шушы өндәүгә колак салыйк һәм шуңа буйсыныйк дип әйтәсе килә.

Халит Кумысников

# ЯКТЫ ЙОЛДЫЗ

Габдулла Кариев зур табигый талант иясе, атаклы артист иде. Ул Шекспирча тирән, Щедринча фаш итү көченә ия булган дистәләрчә сәхнә образлары иҗат итте.

Татар театрында исемнәре милли культурабыз тарихына алтын хәрефләр белән язылырлык артистлар плеядасы эшләгән һәм эшли. Аларның күбесен сәнгатьнең олы юлына Габдулла Кариев чыгарды, ул менә дигән режиссер һәм талантлы педагог иде.



Кариев зур оештыру сәләтенә ия җитәкче була. Ул татар артистларын алдынгы идея-политик юнәлешле бер труппа тирәсенә туплый алды, һәм бу труппа Бөек Октябрьны шатланып каршылады.

◆

Бөек татар артисты шактый гыйбрәтле, фаҗигале тормыш юлы үтте. Ул яшәгән һәм иҗат иткән чор караңгы, кыйблассыз, тынчу атмосфералы булды, чын талант иясен, әгәр ул капиталга буйсынмаса, төрлечә кыерсытулар, кимсетүләр көтә иде.

Габдулла Кариев (Хәйруллин) 1886 елның маенда Чистай өязе Кульбай Мораса авылында яшәүче Хәйрулла исемле крестьян гаиләсендә туа. Берничә ел авыл мәдрәсәсенә йөргәннән соң, аны күршедәге Такталы мәдрәсәсенә җибәрәләр. Ярлы Хәйрулланың тумыштан зирәк һәм искиткеч хәтерле бу малае унике яшендә үк инде, бер дә ялгышмыйча яттан сөйләрлек дәрәҗәдә, корьәнне үзләштерә. Шул уңышлары өчен аңа «Корьән-Хафиз», ягъни корьәнне яттан белүче дигән дини дәрәҗә бирелә.

Яшь дин хезмәтчесенең исеме теллэрдән төшми, даны бөтен өязгә тарала. Шулай берничә ел уза. Җирле байлар, малайның искиткеч талантлы икәнен исәпкә алып, аны Уральскига — мәдрәсәгә җибәрергә булалар. Янәсе, зуррак дөньяны күрсен, укысын, белемен күтәрсен. Шулай итеп, тук тормышта яшәү, югары дини дәрәҗә һәм дан-шөһрәт алу өчен аңа бөтен юллар ачыла; укы гына, тырыш кына...

Баштарак шәһәр мәдрәсәсендәге тәртипләр артык рәхимсез, чыдый алмаслык дәрәҗәдә каты булып тоела, яшь шәкерт, ирексездән, авылда укыган чакларын сагынып куя. Нишлисең, тешне кысып булса да, түзәргә кирәк, белем алу әнә белән кое казу, дигәннәр бабайлар. Тора-бара ул тынчу, күңелсез мәдрәсә тормышына бераз ияләшә төшә. Яңа танышлары, дуслары күбәя. Шуларның берсе Габдуллага караганда да белемле, күпне күргән һәм күпне ишеткән Сиражетдин исемле шәкерт була. Яңа танышы тормышта һәркөн туып торган яңалыклар, әдәбият, сәнгать турында сөйли, укырга китаплар биреп тора. Бер көнне Сиражетдин «Ревизор», «Өйләнү»

исемле әсәрләрнең тәрҗемәләрен табып кайта. Бөек Гогольнең гүзәл драма әсәрләре Габдуллага шулкадәр ошый, бу әсәрләрне хәтта мәдрәсәдә уйнап карарга да теләге зур була аның. Билгеле, моннан берни дә барып чыкмый, бу хыялны тормышка ашыру бары 20 елдан соң гына насыйп була...

Шулай бервакыт Сиражетдин Беляков Кариевны күршедәге Мотыйгулла хәзрәт мәдрәсәсенә алып бара һәм аны чит бер шәкерт белән таныштыра.

— Тукай,— дип таныштыра шәкерт үзен.

Тукай... Тукай... Таныш исем, ничектер, ишеткәнем бар шикелле.

— Соң, теге вакытта мин алып кайткан шигырьләр Тукайныкы иде бит, — ди Беляков.

— Әйе, әйе, хәзер искә төште.

Яңа танышы ошый Кариевка. Үзен иркен тота, шул ук вакытта тыйнак һәм инсафлы да икән.

— Ә сез халык җырларын яратасызмы? — дип сорый Тукай.

— Әлбәттә. Үзем дә җырлаштыргалыйм әле.

— Алайса, иртәгә, кояш баткач, тагын безгә килегез.

Шул рәвешчә, уйламаганда-көтмәгәндә, Габдулла Кариев яңа җирдә беренче тапкыр шәкертләр кичәсенә эләгә. Тукай, көйләп, үз шигырьләрен укый, бергәләшеп, төрле шаян җырлар башкаралар.

Озакламый Уральск мәдрәсәсендә укучы өч шәкерт, «аек акылга» каршы барып дигәндәй, мәдрәсә ташлап чыгалар. Тукай белән Беляков, берсе наборщик, икенчесе конторщик булып, типографиягә эшкә урнашалар, Кариев газета-журналлар сатып көн күрә башлый. Бу — революцион вакыйгалар югары ноктага күтәрелгән 1905 еллар була. Россиянең башка күп шәһәрләрендәге кебек, Уральскида да капитал властена каршы забастовкалар, демонстрацияләр башлана. Шәһәрдә беренчеләрдән булып, Тукай һәм Беляков эшләгән типография эшчеләре кузгала. Бу көннәрдә Кариев төрле әдәби кичәләр оештыру белән мәшгуль була. Ул кичәләрдә революцион эчтәлекле шигырьләр укыла, азатлык җырлары җырлана. Кариев, бик теләп һәм яратып, Габдулла Тукай шигырьләрен сөйли:

Күп яттык без мәдрәсәдә,
Аңламадык бернәрсә дә...

Ул хәтта «Гыйшык бәласе» исемле бер комедия уйнарга да омтылыш ясап карый. Тик план тормышка ашмый: консерватив карашлы байлар, искелек тарафдарлары элекке шәкертләрнең бу эшенә дини хисләрдән көлү, зур бозыклык дип карыйлар.

Татар әдәбияты һәм сәнгате үсешенә зур өлеш кертәчәк ике яшь егетнең Уральск чоры дәвамлы булмый: Тукай Казанга, Кариев газета-журналлар сатарга Мәкәрҗәгә китә.

Мәкәрҗә ярминкәсе. Монда Россиянең бөтен почмакларыннан сәүдә кешеләре җыелган; монда алдыйлар, алданалар, баеыйлар. Шәһәрнең үзәк бер җирендә цирк урнашкан. Читтәрәк төрле ансамбльләр, театр труппалары чыгыш ясый. Матур хәрефләр белән язылган зур-зур игъланнар ярминкә халкын Кудашев-Ашказарский җитәкчелегендәге труппаның спектакльләрен карарга чакыра. Профессиональ татар труппасының беренче спектакленә Габдулла Кариев та эләгә. Кариевка спектакль шундый ошый, аны шулкадәр нык дулкынландыра, ул куанычыннан сәхнәгә баш киемен чөеп җибәрүен дә сизми кала.

1907 елның истәлекле 14 августыннан башлап, Кариев Кудашев-Ашказарский җитәкчелегендәге татар театр труппасының барлык спектакльләрен карап чыга һәм шул вакытта артист булырга дигән ныклы бер фикергә килә. Ул, җаен туры китереп, Гыйззәтуллина-Волжскаядан труппага артист булып урнашырга ярдәм итүен үтенә. Билгеле, Волжская кебек артистканың үтенечен кире какмыйлар, Ашказарский, икеләнебрәк булса да, яшь энтузиаст егетне труппага алырга ризалык бирә. Шулай итеп, Кариев сәхнәгә менә.

Ул дин хезмәтчесе булырга, ислам догмаларын пропагандаларга туган кеше иде, ләкин театр сәнгатен пропагандалаучы булып китте. Халыкны капитал властена буйсынырга, коллыкка өндәргә тиеш иде ул, чынлыкта исә, азатлык өчен көрәшкә чакыручы булды. Ул халыкны гөнаһлы эшләрдән, «шайтан коткысыннан» тыярга тиеш

иде, театрга эшкә кереп, үзе үк «шайтан хезмәтче»сенә әйләнде. Нәрсә, нинди көч суфилык кагыйдәләрендә тәрбияләнгән шәкертне, мәдрәсәнең караңгы бүлмәләрен ташлап, театрга килергә мәҗбүр иткән соң? Андый көчне Тукай, Кариев кебек яшьләрнең халык массаларына якынлыгыннан, беренче рус революциясенең демократик идеалларыннан эзләргә кирәк.

◆

Мәкәрҗәдә Кудашев-Ашказарский җитәкчелегендәге труппаның гастрольләре уңышлы үтә. Артистлар яңа шәһәрләр, Россиянең татарлар күп яши торган районнары буйлап сәфәр чыгалар һәм, якты уйлар, зур өметләр белән, Касыйм шәһәренә килеп төшәләр. Үз ана телендә моңарчы бер генә тапкыр да театр күрмәгән шәһәр халкы өчен «Кызганыч бала» исемле әсәр уйнала. Шушы спектакльдә Кариев, беренче мәртәбә, сәхнәгә чыга. Һәм, дөресен әйтергә кирәк, яшь артистның сәхнәдә беренче адымы шатланырлык та, куанырлык та булмый. Ул, коръән сүрәләрен укыгандай көйләп, ялыктыргыч тонда үзенә тапшырылган рольнең сүзләрен сөйләп чыга. Труппа башлыгы Ашказарский егетнең уенын ошатмый, ул хәтта Гыйззәтуллина-Волжскаяга үпкә дә белдерә әле. Янәсе, әгәр син якламасаң, ул шәкертне труппага аласым юк иде.

Касыйм шәһәреннән соң труппа башта Рязаньда була, аннан Мәскәүгә китә. Ләкин фанатик милләтчеләр, реакцион дин әһелләре татар артистларын һәркайда начар каршы ала, аларны төрлечә мәсхәрәлиләр, кимсетәләр. Труппаның хәле начарланганнан-начарлана бара. Акча җыелмый, артистлар ач-ялангач кала. Алар арасында төрле ризасызлыклар, ызгыш-талашлар көчәя. Ашказарский ризасызлык белдергән артистларның труппадан китүен таләп итә башлый. Шуннан соң да эшләр рәткә салынмагач, коллектив труппадан Ашказарскийның үзен куарга мәҗбүр була. Ул киткәч, труппаның режиссеры һәм җитәкчесе итеп Габдулла Кариев сайлана. Кариев һәм Гыйззәтуллина-Волжская әнә шул кыен чорда беренче татар театрын саклап калу һәм аны тагын да ныгыту өчен искиткеч зур тырышлык күрсәтәләр. Кариев репертуарны яхшырту чараларын күрә, дуслары, хәллерәк таныш-белешләре ярдәме белән бераз акча юнәтә. Күп шәһәрләр буйлап спектакльләр куеп йөргәннән соң, 1907 елның декабрь ахырында труппа Уральскига кайтып төшә.

Январь башларында Галиәсгар Камалның «Бәхетсез егет» драмасы күрсәтелә, шәһәр халкы спектакльне алкышлап каршылый. Кәрим бай ролен башкарган Кариев аеруча уңыш казана. Яшьли үк купецлар арасында күп кайнаган, аларның гадәткыланышларын әйбәт белгән Габдулла тамашачыны ышандырырлык һәм сокландырырлык сәхнә образы тудыра. Уральскида берничә спектакль уйнаганнан соң, труппа Казанга китә. Монда килүгә Кариев Г. Камал белән таныша һәм аның яңа комедиясен әзерли башлый. Театр сәнгатенең дошманнары спектакльне куйдырмас өчен күпме генә тырышсалар да, теләкләренә ирешә алмыйлар. Киресенчә, хурлыкка гына калалар: искелек тарафдарларын сатира утына алган комедия — «Беренче театр» сәхнәгә барыбер менә.

Хәмзә бай роле Кариевка бирелә. Һәм бу рольне уңышлы башкарып чыгу өчен, ул күп эзләнергә, шактый вакыт баш ватарга мәҗбүр була. Бигрәк тә, артист беренче күренешкә ачкыч таба алмый йөдәп бетә. Көне буе төрле канцелярия һәм учреждениеләр бусагасын таптап та, үз теләгенә ирешә алмаган Хәмзә бай, җене чыгып, шартлардай дәрәҗәгә җитеп, өенә кайтып керергә тиеш. Шул күренешне һич кенә үзе теләгәнчә чыгара алмый бит. Аптырагач, нәрсәгә дә булса бик нык ачуы чыккан берәр кешене күзәтеп торырга кирәк, дигән фикергә килә бу. Бу турыда халык артисты К. Шамил шундый истәлек сөйләгән иде:

Казанда саранлыгы һәм вакчыллыгы белән даны чыккан «Садыйк җинги» дигән кушаматлы бер кибетче була. «Җинги» дип дәшүләрен ишетсә, үзе шулкадәр гарьләнә, шулкадәр кимсенә икән, ачуыннан хәтта сугышыр дәрәҗәгә җитә, ди. «Өйрәнү объекты» итеп Кариев шул кибетчене сайлый. Көннәрнең берендә, урамда эшсез йөргән бер малайны яллап, аңа нәрсә эшләргә кирәклеген әйбәтләп төшендерә дә, үзе әлеге Садыйк янына юнәлә бу. Кибеткә керә, хәл-әхвәл сораша, күп итеп товар сатып алырга нияте барлыгын әйтә. Нәкъ шул чагында Кариев яллаган теге малай килеп керә һәм, һәркем ишетерлек көчле тавыш белән:

— Абый, әйт әле: Садыйк җиңгине ничек күрергә була икән, — дип сорый.

Хуҗа кызарып-бүртенеп чыга, куллар йодрыклана.

— Акрын, малай актыгы, әйт, нәрсә кирәк,— ди Садыйк, ачуын көч-хәл белән тыя төшеп.

Ә малай, берни аңламагандай, ваемсыз кыяфәт белән, тагын әүвәлге соравын кабатлый. Садыйк нишләргә белми, борын тишекләре киңәеп китә, күзләре акая моның. Шул рәвешчә, күпмедер вакыт үзен мәсхәрәләүчегә карап тора да, кинәт зур йодрыкларын болгап, сүгенә-сүгенә малайны кыйнарга ташлана. Ә малай ул арада инде табан ялтыраткан була.

— Ачкыч табылды, — ди Кариев, «Садыйк җиңги» белән булган тамашаны карап торганнан соң. Ләкин ачкыч табылып җитмәгән икән әле. Күпме генә тырышса да, ул теләгән эффект барып чыкмый.

Менә премьера көне. Театрга ул бик кәефсез килә, декорацияләрнең ничек куелуын карарга да чыкмый хәтта. Спектакль инде башланган да, озакламый ул сәхнәгә чыгарга тиеш. Кариев өзлексез йөренә, борчыла, уйлана.

— Кариев, сәхнәгә! — диләр. Ул ишетми кала. Шул ук сүзләрне, кычкырып икенче мәртәбә кабатлагач кына, ул, ашыга-кабалана, сәхнәгә юнәлә һәм, керә-керешкә, дөбердәп идәнгә барып төшә. Кемдер идәнгә планка кагып куйган, Кариев күрмәгән икән. Залда кемдер көлеп җибәрә. Бары шуннан соң гына Кариев айнып китә: ул бит сәхнәдә, аңа уйнарга, сөйләргә кирәк. Үзенең булдыксызлыгына һәм идәнгә каһәр суккан әлеге планканы кадаклаган кешегә җен ачуы чыккан артист, егылу алдан уйланып эшләнгән бер трюк иде дигән кыяфәт белән, тамак кыра-кыра, аякка баса. Сәхнәдә Хәмзә байның беренче фразалары яңгырый. Һәм алар нәкъ Кариев теләгәнчә, табигый, дөрес яңгырыйлар. Көтелмәгән хәл аркасында тиешле тон табыла, артист рольгә керә...

«Беренче театр» спектакле татар дөньясы өчен аяз көнне яшен сугу белән бер була. Спектакль уңае белән реакцион даирәләр зур шау-шу куптаралар. «Беренче театр» мәсьәләсе мөфтигә барып җитә. 1908 елның январенда югары дини назарият һәртөрле спектакль, концерт куюларны катгый рәвештә тыю турында махсус карар чыгара. Милләтче буржуазия вәкилләре, кадимче муллалар татар артистларын төрлечә мәсхәрәләгән һәм эзәрлекләгән, театрны ябу, бетерү өчен махсус карарлар чыгарган бер вакытта, халкыбызның большевик Х. Ямашев, пролетариат язучысы Г. Колахметов, халык шагыйре Г. Тукай кебек алдынгы уллары милли театрга зур өмет багладылар, аны үстерү, яшәтү өчен көчләрен кызганмадылар. Һәм татар театры яшәде. Кара реакция елларында да халыкны ирекле, азат тормыш өчен көрәшкә өндәде.

◆

«Сәйяр» — ил гизүче, сәяхәтче дигән сүз. Беренче профессиональ театр труппасына бу исемне Габдулла Тукай биргән иде. Труппа коллективы «Сәйяр» исемен тулысынча аклады. Шәһәрдән-шәһәргә йөрүче күчмә театр халыкка юл күрсәтүче маяк ролен үти. Татар артистлары аркылыга-буйга бөтен Уралны йөреп чыгалар, Урта Азия, Кырым, Кавказ шәһәрләрендә булалар.

Кавказда гастрольләрдә йөргәндә, «Сәйяр» артистлары танылган трагик Гуссейн Араблинский житәкчелегендәге әзербәйҗан труппасы белән очраша. Әзербәйҗаннарны бик куандырган һәм шактый гаҗәпләндергән нәрсә — безнең труппада хатын-кызларның да катнашуы була. Араблинский, әзербәйҗан-татар труппасы төзеп, гастрольләрне бергә үткәрергә тәкъдим ясый. Кариев ризалык бирә. Шулай итеп, ике тугандаш халыкның сәхнә осталары күпмедер вакыт бергә эшлиләр.

Араблинский — татар театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш керткән кеше. Ул безнең артистларга сәхнә осталыкларын күтәрергә ярдәм итә, аларда Шекспир, Шиллер, Гете әсәрләренә мәхәббәт тәрбияли, татар театрына романтик рух кертә. Әзербәйҗан труппасы белән бергә «Сәйяр» берничә спектакль әзерли, шулар арасында иң әһәмиятлесе — Н. Наримановның «Надир шаһ» трагедиясе. Төп рольне Г. Араблинский үзе башкара, Г. Кариевка Надир шаһның карт агасын уйнарга тәкъдим итәләр. Араблинский кул астында Кариев зур тәҗрибә мәктәбе уза.

К. Шамилнең әлегә матбугатта чыкмаган кулъязма истәлекләрендә «Сәйяр»ның Кавказ чоры турында кызыклы мәгълүматлар бар. Танылган әзербайҗан трагигы Г. Кариевның табигый талантлы зур артист булачагына ышана һәм, бик теләп, аңа актерлык осталыгының, режиссерлык сәнгатенең күп серләрен, закончалыкларын ача.

— Мин ышанам: Сез чын артист булырсыз! — ди ул Кариевка, аерылышыр алдыннан.

Казанга кайтуга, тагын да зур дәрт һәм омтылыш белән, Кариев ныклап эшкә керешә. Беренче чиратта, репертуар мәсьәләсен юлга салырга, тулы канлы, тирән эчтәлекле сәхнә әсәрләре тупларга кирәк. Татар театрының зур патриоты Г. Камал «Сәйяр» өчен рус һәм көнбатыш драматургларының әсәрләрен тәрҗемә итә, кайберләрен татар тормышына яраклаштырып үзгәртә һәм мөстәкыйль әсәрләр язуын дәвам итә. Озакламый күренекле драматургның «Безнең шәһәрнең серләре» исемле зур, җитди яңа әсәре язылып бетә. Труппа әсәрне хуплап каршылый. Аны тиз арада сәхнәгә куярга булалар. Кариев, ничек итсә итә, Петербургка барып, Үзәк цензура комитетыннан әсәрне сәхнәдә уйнарга рөхсәт тә алып кайта. Шуннан эшкә тотыналар.

Иң авыр рольне — Шкафчы образын Габдулла Кариев башкарырга тиеш була. Кариев яхшы аңлый: бу образ аша барлык Печән базары әһелләрен, һәртөрле искелек тарафдарларын кискен фаш итәргә, халыкка аларның чын йөзен ачып салырга, аларны хурлык баганасына терәргә кирәк. Ләкин моңа ничек ирешергә соң?

Актер буларак, Кариевның бер индивидуаль үзенчәлеге шунда, образга ул, гадәттә, аның тышкы билгеләре аша якын килергә ярата. Сәхнәдә нинди дә булса образ иҗат итү өчен, аңа героен башта әле тормышта күрергә кирәк. Һәм ул үзе уйнаячак образның прототибы — Печән базары «каһарманнарыннан» Мөхәммәтҗан Хафиз дигән кеше белән «дуслашырга», аның ышанычын казанырга карар кыла. Иң беренче эш итеп, Кариев, вакытлыча, сәхнәне ташлап тора. Бервакыт киемнәрен алмаштырып пишкадәм кыяфәтенә кергән Кариев Печән базарына килеп чыга. Хафиз һәм аның иярченнәре «сәләмә киемле пишкадәмне» оятсыз, мыскыллы сүзләр белән каршылыйлар. Ә бу бөтенләй үпкәләми тегеләргә. Хәтта хөрмәтле Хафиз адресына берничә мактау сүзе дә әйтеп куя әле. Билгеле, бу Хафизга бик ошый, ләкин ят егетне якын җибәрергә ашыкмый әле. Шулай күпмедер вакыт уза. Пишкадәм көн дә Хафиз тирәсенә килә, җаен туры китереп, сүз арасында гына, тегене мактап куя. Һәм һәр сөйләгәнен, коръәннән берәр аять китереп, беркетеп тә җибәрә. Тора-бара ислам диненең турылыклы хезмәтчесе Хафизга ошап ук куя бит. Сирәкмирәк кенә булса да, Печән базары герое ярлы пишкадәмне өенә кунакка да алып кайта. Шулай әйбәт кенә йөргәндә, Хафизның яраткан пишкадәме юкка чыга. Тегенең исемен белүче дә, каян килеп кая китүен әйтүче дә табылмый. Ул да булмый, Печән базары әһелләре җыелып киләләр дә Хафизны сугәргә, әрләргә тотыналар.

— Син,— диләр аңа,— безне театрга йөрүдән тыясың, ә үзең алла каһәре төшкән шул йортта кәмит уйнаудан да җирәнмисең.

— Я ходай! Нәрсә сөйлисез сез? Кем мине шундый пычракка күмгән? — ди, тәмам аптыраган Хафиз.

— Ах, алай икән, пычракка күмгәннәр икән,— дип тагын ябышалар моңа.— Бу турыда бөтен шәһәр сөйли. Билетлары ике көнгә алдан сатылып беткән, ди. Барысы да синең аркада, гөнаһ шомлыгы!..

Хафиз ни әйтергә дә белми. Башка чара калмый, ул театр дигән әлеге бозык йортка үзе барырга һәм җыелган халык алдында ялганчыларны фаш итәргә була.

Кич. «Шәрык» клубының бәләкәй залы шыгрым тулы. Спектакль бара. Актерларның һәр сүзен хуплап залда көлгән, кул чапкан тавышлар яңгырый.

Сәхнәдә һәркемгә таныш Печән базары, әшәкелек белән даннары чыккан көфер почмагы әһелләре. Шунда тамаша карап утыручыларның берсе:

— Җәмәгать! Карагыз әле, карагыз: сәхнәгә Мөхәммәтҗан Хафиз үзе менгән ич,— дип кычкырып җибәрмәсенме. Икенче берәү өстәп куя:

— Әйе шул, нәкъ үзе, суйган да каплаган!

Тамаша залы көлешә, шаулаша башлый:

— Театрга йөргән өчен безгә бәддога белән яный. Ә үзе, карт алдакчы, комедиант икән.

Шул чак караңгы залдан, шау-шуны басып көчле тавыш ишетелә:

— Мөселманнар, туктагыз, сабыр итегез! Сәхнәдәге Хафиз — теге шарлатан пишкадәм. Сез ул алдакчыга ышанмагыз. Чын Хафиз — менә мин.

Зал тагын гөж килә:

— Алаймыни әле?!. Безне театрга йөрүдән тыя. Үзе беренче рәткә килеп утырган.

Тәмам хурлыкка калган Хафиз көч-хәл белән качып котыла. Бу гыйбрәтле хәл күп Печән базары каһарманнарын акылга утырта.

Шул рәвешчә, актер сәнгате белән драматург иҗаты җиңеп чыга, яңалыкка каршы торучылар хурлык баганасына терәлә. Спектакльдәге иң уңышлы образ, әлбәттә, Кариевныкы була. Ләкин актерның Шкафчы образын иҗат итүдәге тәҗрибәсен берьяклы аңларга ярамый. Бу тәҗрибәне реаль тормышта яши торган берәр кешенең барлык тышкы сыйфатларын механик рәвештә күчереп алу һәм сәхнәдә шуларны кабатлап чыгу дип кенә бәяләү дөрес булмас иде. Бу — образ өчен иң характерлы детальләр сайлау, ул детальләргә кирәкле тон бирү белән бәйләнгән авыр, катлаулы иҗат эше.

Кариев, бик хаклы рәвештә, реалистик портрет остасы саналды. Беренче карашка әһәмиятсез күренгән кечкенә детальләр, вак-вак штрихлар ярдәмендә ул үзе башкарган образларга «җан өрә», аларны тулы канлы, тормышчан характерлар дәрәҗәсенә күтәрә белде. Кариев яшәп килүче иске стройны фашлаучы, азатлык идеалларын яклаучы сәнгатьче иде.

Габдулла Кариев иҗат иткән дистәләрчә сәхнә образларының тагын берсе һәм иң уңышлысы — Г. Камалның «Банкрот» комедиясеннән Сиражетдин Туктагаев роле.

Көннәрнең берендә Сиражетдин үзен банкрот дип игълан итәргә була. Имештер, аны талаганнар. Бу аңа шулкадәр нык тәэсир иткән, ул инде, янәсе, акылдан ук язган. Исәбе, билгеле, бурычлар түләүдән һәм төрмәдә утырудан котылып, баеп калу.

Сиражи роле башкаручыдан камил техника, зур осталык сорый. Кариев бу рольне чын илһам белән, тетрәтерлек итеп уйнады, дип сөйлиләр артистның замандашлары. Артистның бөтен барлыгы — ирексездән йомарланган куллар, песинекедәй сак адымнар, ялт-йолт каранучы күзләр — Сиражиның комсыз табигатен ачуга хезмәт иткән. Образның акылдан язу күренешен Кариев шаккатмалы уйный иде, диләр. Менә ул, гайри табигый хәрәкәтләр ясап, бүлмә буйлап йөгерергә тотына. Әле этәч булып кычкырып җибәрә, әле, ярдәмгә чакырып, акыра башлый. Һәм артист шуларның һәммәсен бик табигый, бер дә көчәнмичә эшли...

◆

Кариев акыллы һәм алдан күрүчән җитәкче була. Татар актерларына милли репертуар белән генә чикләнергә ярамаганлыгын ул яхшы аңлый. Артистның яңалыкны тою хисе томаланырга, уен техникасы ярлыланырга мөмкин. Шундый хәл тумасын өчен, әледән-әле тәрҗемә әсәрләре, рус һәм көнбатыш классикларына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Дөрес, татар театры, беренче адымнарыннан ук, тәрҗемә әсәрләрен аз куймый. Арада уңышлы гына чыкканнары да байтак. Ләкин аларның күбесе, нигездә, татар тормышына җайлаштырып тәрҗемә ителгән һәм сәхнәгә дә татарчарак куелган әсәрләр була.

Труппа инде шактый көчле, өлкән артистлар да, талантлы яшьләр дә җитәрлек. Нигә тәрҗемә әсәрләрен бозмыйча, татар тормышына җайлаштырмыйча уйнап карамаска?! Кариев ныклы карарга килә.

Тиздән труппа Гогольнең «Өйләнү» комедиясенә туктала, режиссер итеп Н. Зимовой чакырыла. «Татарчалаштырылган» тәрҗемәләр белән генә эш иткән артистлар баштарак шактый кыен хәлдә калалар. Репетицияләрдә иң нык җәфаланган кеше Кариев үзе була. Драматург тудырган чын Подколесин чыкмый гына бит. Кариев аны шул барып чыкмаган килеш уйный да: аның Подколесины, Гоголь чиновнигы булудан бигрәк, татар баен хәтерләтә.

1911 елдан башлап, труппа кышларын Казанда торып эшләүгә күчә, «Шәрык» клубы «Сәйяр» карамагына тапшырыла. Бер урында яшәүдән файдаланып, Кариев артистларның диапазонын киңәйтү, техника һәм осталыкны үстерү мәсьәләләренә




М. Вахитовка һәйкәл салу өчен куелган спектакльнең афишасы.

җитди игътибар бирә. Татар артистларына русча спектакльләргә йөрү мөмкинлеге ачыла, алар рус сәхнә культурасы ирешкән казанышларны үзләштерәләр. Стационарда эшләүгә күчкән беренче елларда ук «Шәрык» клубы сәхнәсендә Гоголь, Островский әсәрләре, Гейне, Шиллер трагедияләре куела.

Ләкин уйламаганда-көтмәгәндә Кариев бик каты авырып ала. Авыру эзсез генә бетми — аның тамагы карлыгып кала. Нәтиҗәдә, ул режиссерлык эшенә күчә. Тамагы карлыккан булуга да карамастан, әсәрне беренче мәртәбә һәрвакыт үзе укый, шунда ук рольләрне уйнап та бара. Ул үзе башкарачак рольнең тулы текстын яттан белә торган була, хәзер режиссерлык эшенә күчкәч, башкалардан да шуны ук таләп итә. Кариев артистларга:

— Иң әһәмиятлесе шул, сәхнәдә үз-үзегезне уйнамагыз. Әгәр һәр әсәрдә үзегезне кабатлау белән генә чикләнсәгез, тамашачы сездән тиз туяр, — ди торган була. Артисттан ул табигый, тормышчан образ, ышандырырлык характер таләп иткән. Кариевның режиссерлык алымнары турында сөйләгәндә, бер нәрсәне истән чыгарырга ярамый. Татар театры шул елларда ук МХАТ традициясен дәвам итә. Һәр ике театрның күзгә бәрелеп торган уртак сыйфатлары шунда, алар чын тормыш дөреслеге, реалистик сәнгать өчен көрәштеләр.

«Сәйяр», нигездә, табигый талантлар хисабына оешкан труппа иде. Дөрес, баштагы состав гел үзгәрә торды. Берәүләр труппадан китте, алар урынына яңалар килде. Кариев труппага актерлар сайлап алу эшенә аерым игътибар бирә. «Сәйяр»ның беренче адымнарыннан ук, ул халык алдында сәхнәнең һәм актерның бәясен, дәрәҗәсен күтәрде. Ул вакытларда актерга, ничектер, кимсетеп, мыскыллап карау бар иде. Кариев моңа чик куйды. Ул, армый-талмый, актерның мораль йөзен, кеше буларак кадерен күтәрү өчен кайгыртты. Әйе, алар еш кына ертылып-ямалып беткән

киемнәрдә йөрделәр, ләкин эш урынында гына. Урамга чыгу өчен, аларның көч-хәл белән юнәткән әйбәтрәк киемнәре була. Халык алдында актер җыйнак, пөхтә йөрергә, сәхнәдәге кебек үк, тормышта да һәрьяктан үрнәк булырга тиеш. Кариев югары мораль һәм әхлак нормалары белән яшәүче коллектив, алай гына да түгел, идея ягыннан бер максатка юнәлгән коллектив туплый алды. Габдулла Кариев җитәкчелегендәге бу коллектив бөек Октябрьны Максим Горькийның «Мещаннар» пьесасы белән каршылады.

◆

Революция алдыннан килгән ике ел Кариевның иҗат таланты иң югары ноктага күтәрелгән еллар исәпләнә. Ул яңадан сәхнәгә кайта, үз репертуарында иң уңышлы рольләрне шул елларда башкара. Алар арасында Островскийның «Гаепсездән гаеплеләр»еннән Дудукин, Гетеның «Әльмансур» трагедиясеннән Хәсән, Наримановның «Надир шаһ» трагедиясеннән Надир, «Трильби» исемле мелодрамадан Свингали кебек образлар бар. Ул үзен романтик трагедия һәм күңелле комедиядә дә, психологик драмада һәм мелодрамада да бер үк дәрәҗәдә оста уйнарлык, киң диапазонлы актер итеп танытты.

Кариев иҗат иткән образларның барысына да тукталып тормастан, Гогольнең «Ревизор» комедиясе турында гына берничә сүз әйтәсе килә. 1916 ел. Шәһәр халкы зур театр бинасына җыелган. Һәркем дулкынлана. Озак вакытлар сәхнәдән китеп торганнан соң, татарның сөекле артисты яңадан уйнаячак. Бүген аның бенефисы. Ул Щепкин кебек бөтендөньяга мәгълүм артистлар уйнаган Городничий ролендә чыгыш ясаячак.

Тамашачы Кариев-Городничийны алкышлар белән каршылый. Спектакль баштан ахырга кадәр көчле алкышлар белән бара. Казан халкы тагын бер мәртәбә чын сәнгать белән, бөек артист белән очраша...

1920 елның 7 январенда Кәрим Тинчуринның «Сәяси сакал» исемле әсәре буенча эшләнгән спектакльнең премьерасы була. Яраткан артистын тамашачы соңгы мәртәбә шул спектакльдә күреп кала. Тагын өч атна үткәч, рәхимсез үлем аны безнең арадан тартып ала.

*Заһидә Тинчурина*

# БЕЗНЕҢ КАРИЕВ

Гимназиянең югары классларында укыганда ук, без яшьләр үзебезнең шәһәрдә бара торган концерт, спектакльләрдә шактый еш була идек. Колобов, Тинский, Двинский, Слонов, Саблина-Дольская кебек артистлар уенын карап ләззәтләнгән, Гольденвейзер, Нежданова, Скрябин, Рахманиновтай рус сәнгате корифейлары концертларында утыру бәхетенә ирешкән, Максаков, Секар-Рожанский, Борисенко, Хохлов, Петрова-Званцовалар шикелле мәшһүр җырчылар катнашында куелган опералар тыңлаган яшь җилкенчәк без.

Гаҗәп бит, үзебез даннары бөтен илгә таралган күпме сәнгать осталарын күргән кешеләр, ничә мәртәбә менә дигән шәп бинalы Шәһәр театрында[1] булганыбыз бар, ә күңелләр, белмим, нинди хикмәт булгандыр инде, шулай да, бәләкәй генә тамаша залы, уч төбе хәтле генә сәхнәсе булган «Шәрык» клубына тартыла. Хәер, ныклабрак уйласаң, сәбәпләре дә юк түгел, күңел бер дә юкка гына шушы бәләкәй клубка ашкынмаган икән: монда һәрвакыт ягымлы һәм эчкерсез атмосфера хөкем сөрә. Һәркем

[1] Ул 1919 елда янды.

спектакль бетүгә, тамаша залындагы урындыкларны стена буйларына күчереп куялар да, я танцы, я төрле уеннар башлана. Монда татар, казакъ, кыргыз, әзербайҗан яшьләре җыела. Аларның күбесе студентлар, училище укучылары, курсисткалар, гимназисткалар. «Шәрык» клубында Ә. Мөхетдинова, Г. Камал, Г. Рәхим, Г. Кәрам, Г. Гобәйдуллин кебек интеллигентлар еш була. Һәрбер спектакльдә, һәрбер кичәдә мөлаем йөзле, көр күңелле Фатих Әмирхан... Уңайлы момент чыгу белән, ул, коляскасын тәгәрәтеп, яшьләр янына килеп җитә: кызларга комплиментлар әйтә, төрле кызык хәлләр, мәзәкләр сөйләп, көлдереп бетерә. Юмор, сатира утына лаек бер генә нәрсә дә аның үткен карашыннан качып котыла алмый.

Клубның бәләкәй сәхнәсендә искитмәле, сокландыргыч спектакльләр уйнала. Уйный башласаң, бүген менә аптырап каласың. Юньле-башлы спектакль куярлык шартлар бөтенләй юк бит инде. Ә куялар, ничек кенә куялар әле! Дөресен генә әйткәндә, Габдулла Кариевта теләсә нинди авырлыкларны җиңеп чыгарлык зур ихтыяр — «тылсымчы» көче бар иде.

Хәзер тәгаен генә хәтерләмим инде, 1917 елның октябрь ахырлары идеме, әллә ноябрь башлары булдымы икән? Шулай бер көнне, һич тә уйламаганда-көтмәгәндә, безгә Габдулла Кариев үзе килеп чыкты.

Башта бөтенләй игътибар итмәдем, кем килмәс тә, кем китмәс, безнең йортта кеше бетеп торганы бармыни?! Бераздан тыңлыйм, әнием, бик нәзакәтле һәм ягымлы тонда, кем беләндер әңгәмә алып бара. Күпмедер вакыттан соң, мине дә чакырдылар. Бераз каушап һәм уңайсызланыбрак кунак бүлмәсенә барып керсәм, ни күрим — анда Кариев утыра икән. Уртачадан озынрак, төз, нәфис һәм ирләрчә матур буй-сын. «Киенә белә торган кеше» булуы, гәүдәсенә кием ятып торганлыгы әллә каян күзгә ташлана. Сизелер-сизелмәс кенә елмаю яшеренгән иреннәр, аз гына ирония белән караучы матур, зәңгәр күзләр. Дистәләрчә сәхнә образлары иҗат иткән, танылган һәм яраткан артистыбыз менә нинди икән! Күрәсең, җәмгыяте хәйрия файдасына оештырылачак берәр кичә турында сөйләшергә килгәндер инде?.. Бу вазифа нигә аңа тапшырылды икән? Башкалар беткәнмени? Кариевны күрүгә башта туган беренче уйлар шул булды.

Ләкин мин нык ялгышканмын. Драматургия курсларын тәмамлап, Казанга — «Сәйяр» труппасында эшләргә — Әшрәф Синяева кайтып төшкән. Зур театр бинасында аның беренче спектакле булырга тиеш икән. Дебют өчен ул Сумбатовның «Лачыннар һәм каргалар» әсәрен сайлаган. Әсәрдә өч хатын-кыз образы бар: берсен Болгарская, икенчесен Синяева үзе башкарачак. Өченче образга исә, кызганычка каршы, артистка юк икән. Кариев шул рольгә мине чакыра, зинһар спектакльне өзмәгез инде, ди. Нигә мине чакыра, нәрсәгә ышанып миңа шундый җаваплы эш тапшыра — һич аңламыйм. Профессиональ театрда уйнау түгел, минем хәтта өй спектакльләрендә дә катнашканым юк. Мин бу вакытта университетның медицина факультетында укый идем: бар белгәнем китаплар да лекцияләр. Юк, бу минем кулдан килердәй эш түгел, һич риза буласым юк, дип уйлыйм үзем эчтән. Шул ук вакытта җиңел генә баш тарту да, ничектер, уңайсыз, кыен. Карлыкканрак, ләкин тыныч һәм ышанычлы тавыш белән, Кариев труппадагы кыенлыклар, артисткалар җитмәү, татарның интеллигенция вәкилләрен «Сәйяр»га тартырга теләве, труппа тормышына кагылышлы башка күп мәсьәләләр турында тезеп сөйләп китте. Күренеп торган талантың да, сәләтең дә булмаган хәлдә, ничек инде шундый җаваплы эшкә ризалык бирергә мөмкин, дип каршы төшкәч, ул, җавап биреп: «Пьесаның характерына һәм идеясенә төшенә алсаң, үзең башкарачак образның сүзләрен аңлап-төшенеп хәтергә бикләсәң — шул җитә»,— диде. Ярар, дип уйладым үземчә, миннән әллә ни күп көтмиләр икән ләбаса! Ике көннән ул тагын безгә керде, мин уйнарга тиешле рольнең текстын китергән. Аңа күтәрелеп карауга, бернәрсәгә ышандым: әгәр шушы минутта спектакльдә катнашудан баш тартсам, мин аның нәфрәтле мыскылына гына тап булачак идем. Ул, өйрәтергә, әгәр сәхнә өчен бөтенләй яраксыз булсам, дөресен әйтергә сүз биреп, чыгып китте.

Менә пьесаны бергәләп кычкырып уку көне дә килеп җитте. Сәгать 11 гә барлык артистлар Зур театрның фойесына җыелдык. Генеральный репетициядән кала барлык өйрәнүләр шушында булачак икән. Спектакльнең режиссеры килде. Кариев күренми. Мөгаен, укулар вакытында килеп тормыйдыр инде...

Ул соңгы репетициягә генә килде. Өйдә булмаган, каядыр барган, дип сөйләделәр.

Нишлисен, мине «өйрәтергә» соңга калды инде. Хәтердә ачык саклангany шул, мин сәхнәгә чыгарга куркып, калтырап торганда, килеп: «Заһидә туташ, курыкмыйча, ныграк басып атлагыз: театр тарихында моңа кадәр сәхнә идәне җимерелгәне юк әле»,— дигән иде.

Дебютантка күп итеп чәчәкләр китерделәр, билгеле, миңа да чәчәкләр бирделәр. Ләкин миндә ул кайгымыни, әле һаман тез буыннары калтырый. Шулай «дебют» узып та китте. Янадан элеккеге, күнегелгән тормыш, янадан университет, лекцияләр...

Байтак вакыттан соң Кариев тагын безгә килде — кулында текст. Бу юлы Ф. Бурнашның «Язмыш» пьесасыннан а н а образын алып килгән. Кабат аптыраш хәл, кабат уйнарга кеше юк икән. Роль артыннан роль китте. Теләсәң-теләмәсәң дә, медицина факультетын онытырга туры килде. Кариев айлык оклад та билгеләп куйды. Болгарскаяга 700 сум, Синяевага —500 сум, Арапова белән миңа 3 әр йөз сум.

Табигате белән Кариев тиз кабынучан, кызу канлы кеше иде. Кызган чакларда, еш кына, арттырып та җибәргәли, әмма тынычлану белән, оялчан елмаеп, гафу үтенә. Бәхәсләшергә ярата иде, һәм аның белән бәхәсләшү дә кызык иде. Кирелектән, бары үз сүзен бирмәү өчен генә карышып маташмый. Хаксыз икәнен аңлау белән, үзен җиңелгән саный, бирелә. Хәтеремдә әле, һәм поэзия, һәм проза әсәрләрен бик оста башкаручы Максимов дигән артист кайсыдыр елны Казанда гастрольдә булды. Концерттан соң икенче көнне безнең репетиция иде. Шунда Максимовны мин, күрәсең, артыграк мактап ташлаганмын. Кариевны күрсәгез иде: кызарынган, күзләре шундый усал. Шуннан тотынды бу мине «кыздырырга». Ничек инде шундый кешене мактарга мөмкин, ул кешенең зур реалистик сәнгатькә нинди катнашы бар, «Сәйяр» кебек труппаның актрисасы Максимовише бер бәндә турында шулай зурлап сөйли икән, бу инде үзе — хурлык, янәсе. Эш бу кадәргә җиткәч: «Мин актриса да, гомумән, беркем дә түгел»,— дип әйтеп ташлаганмын бит. Кариев тагын элеп алды: «Инде «Сәйяр»да эшлисез икән, сез аның данын төшермәскә тиеш», ди. Белмим, шул вакыт: карагыз әле, Сез соң аның Блок һәм Брюсов шигырьләрен укуын, Горькийның «Давыл хәбәрчесе»н, Толстойның «Сугыш һәм тынычлык» романыннан өзекләр башкаруын бер дә ошатмадыгызмыни, дип сорамасам, без кая кадәр җиткән булыр идек икән. Шулай сорауга, Кариев кинәт туктап калды. Баксаң, артист турында начар кинолар буенча гына хөкем йөртә, аның Максимов концертында булганы да юк икән әле. Максимовның икенче концертына Кариев үзе китте.

Кайбер иптәшләр Кариевны эгоистлыкта, власть сөюдә гаеплиләр. Шактый җитди мәсьәләләр турында аның белән байтак бәхәсләшкән бер кеше буларак, шикләнмичә әйтә алам: ул үтә намуслы, туры һәм кечкенә мәсьәләдә дә, зурында да дөреслек яратучан иде. Әйе, ул тәкәббер кешеләрне, мактанчыкларны, үз эшенә салкын караучыларны яратмады. Бик таләпчән кеше, спектакль барганда һәрнәрсәне хуҗаларча күзәтеп тора, ләкин юкка вакланмый. Кирәккә-кирәкмәскә сәхнә артына кереп йөрүче чит кешеләрне җене сөйми... Үзенә дә һәм сәхнәдәш иптәшләренә карата да бик таләпчән, принципиаль кеше иде. Без шәхси интересларны җәмәгать интересларына буйсындыру турында күп сөйлибез. Кариев сөйләп кенә калмый, шулай яши, шулай эшли иде. 1916—17 елгы театр сезоны ахырында булса кирәк, Кариевның бары үз шәхси тормышына гына кагыла торган мәсьәлә күтәрелде. Бу очракта да ул күпчелеккә, коллектив фикеренә буйсынды. Габдулла Кариев һәм аның дуслары, армыйталмый, труппаның мораль сафлыгы өчен көрәштеләр, аны мещанлык, обывательлек кебек начар сыйфатлардан саклап калу өчен, күп көч һәм энергия сарыф иттеләр.

Миңа Кариевның партнеры булып уйнарга туры килмәде диярлек. Болай аның һәр уенын тирән дулкынлану һәм зур кызыксыну белән күзәтә идем. Сәхнәгә чыгар алдыннан Кариев дәшмәс-сөйләшмәс, артык киеренке бер халәттә була. Ләкин, ни әйтсәң дә, бу әле — Кариев, Габдулла Кариев; нәрсә турында булса да сорашырга, ярдәм сорап, аңа мөрәҗәгать итәргә мөмкин әле. Менә ул сәхнәгә аяк баса. Шул минуттан моңарчы без белгән, тормыштагы Кариевтан берни дә калмый. Ул инде бөтен барлыгы белән Сиражи яки Свингали, я булмаса «Яшь йөрәкләр»дәге чуваш карты...

Кариевның актерлык диапазоны гаҗәеп киң иде. Бүген Кариев башкарган рольләрнең барысын да сөйләп чыгып булмас, алар бик күп. Ул башкарган рольләр арасында бер-берсенә бөтенләй охшамаган, хәтта бер-берсенә капма-каршы полюслар-

да торган дистәләрчә характерлар бар. Һәм аларның барысын да Кариев хәтердә калырлык, ышандырырлык итеп уйнады. Кариев сәхнәдә вакытта, аның йөрәк тибеше дә, тамырлары буйлап кан агуы да сизелә, дип сөйлиләр иде партнерлары. Мондый нервчан киеренкелек тагын бер генә актерга — Әпсәләмовка гына хас иде.



Г. Кариев «Әльмансур» трагедиясендә Хәсән ролендә.

Ул хәтта репетицияләр вакытында ук тулысы белән үзе башкарачак образлар стихиясендә яши торган иде. Авторы Шиманский булса кирәк, «Кан» исемле бер спектакльдә бәләкәй генә күренешне Кариев белән уйнадык. Менә ул, әсәрдә язылганча, кулдан эләктереп алды һәм, кискен хәрәкәт белән, мине шунда ук ыргытып та бәрде. Барып төштем, аңа ошамый: «Аңлагыз, Сез бит карчык инде,— ди бу миңа.— Ә карчыклар болай егылмый. Авыррак, акрынрак егылыгыз!» Никадәр азаплансак та, мин барыбер Кариев теләгәнчә егылырга өйрәнә алмадым. Премьера килеп җитте. Куркынып, калтыранып әлеге күренешне көтәм. Үзем, сиздермичә генә, Кариевны күзәтәм. Менә без сәхнәдә. Нииндидер тыелгысыз бер көч белән бу мине эләктереп тә алды, чөеп тә атты. Кычкырып җибәрдем, юк, авыртканга түгел — куркудан. Ә кулда кып-кызыл булып Кариевның бармак эзләре калган. Икенче көнне репетициягә килгәч, ул, кызарып һәм уңайсызланып, миннән гафу үтенде. Иптәшләр аны шаяртып та алдылар әле. Болай кылана башласаң, син бөтен актрисаларны качырып бетерерсең, янәсе.

1918 елның җәендә труппа Казанда эшләмәде, каядыр таралып беткән иде. Мин Буага авыл укытучыларының белемен күтәрү курсларына укытучы булып киттем. Кызганычка каршы, курсларны тәмамларга мөмкин булмады: шәһәргә ак чехлар керде. Мең бәлаләр белән Казанга кайтып төшсәм, монда да ак чехлар хөкем сөрә икән. Озакламый аклар куылды, шәһәргә Кызыл гаскәр хуҗа булды. Миңа, кичекмәстән, партиянең губерна комитетына барырга куштылар. Шулай итеп, яңадан театрга әйләнеп кайтырга туры килде.

Театрга барсам, Кариев юк. З. Солтанов, И. Кулиев, К. Тинчуриннарны да очратмадым. Синяева, труппа кешесе исәпләнсә дә, авыру сәбәпле, эшкә йөри алмый икән. Бөтен эш Камал II кулында: үзе актер, үзе режиссер, үзе оештыручы. Труппага, һәркөн саен диярлек, яшь-яшь кызлар өстәлә тора. Ләкин тиздән аларның күбесе, комиссарларга кияүгә чыгып, таралышып та беттеләр. Бераздан Тинчурин кайтып, театр белән җитәкчелекне үз кулына алды. Мангушев, Кулиев кайтты, Синяева эшкә чыкты.

Кариев Казанга 1919 елның ахырларында гына кайтып төште. Ләкин ныклап эшли алмады, тимгелле тиф белән авырып китте. Бик озак, авыр яткы ул, шулай да терелде тагын. Терелүен терелде, ләкин тифның үпкәгә тәэсире булмагае, үпкә туберкулезы башланмагае дип куркып йөрде. Авыр вакыт, дарулар юк. Дәвалану өчен башка юньле әйбер булмагач, ат мае эчә башлады. Көн саен 2—3 стакан эретелгән ат мае эчте. Без аны шундый авыр азыкның организм өчен үтә зарарлы икәненә күпме ышандырырга тырышсак та, файдасы булмады. Шул ат мае аны аяктан екты да инде.

Кариевны күмәргә Казанның бөтен татар халкы катнашты. Кышның зыкы салкын бер көнендә артистның сәхнәдәш иптәшләре, дуслары, меңләгән тамашачылар зурлап аны соңгы юлга озаттылар. Аннан соң күп гомер узды, күп сулар акты. Башкарган эшләре күңелгә уелган, якты образы хәтердә саклана.

# Син безнең күңелләрдә

*19 июньдә җомга көн кич Панаевский бакчаның ябык театрында «Хуҗа һәм приказчик» нам пьеса тамашага куелды... Театр сафыннан тәрәкъкый иттерүне үзләренә идеал итеп алган бу труппа артистлыктан башка эш илә шөгыльләнмәгәнгә, табигый инде, эч пошканнан гына театр уйнарга керешкән любительләргә кыясь итәрлек дәрәҗәдән күптән үткән вә үзенә тамашачы күңелен җәлеп иткәндер.*

*Шунлыктан болар «Хуҗа һәм приказчик» шикелле эшләнүе җитмәгән пьесаны да матур итеп чыгара белделәр.*

*Галимҗан ролен уйнаучы Кариев үзенең җанлы хәрәкәте вә килешле кыйланышы вә кирәк урыннарда төсен вә сүзнең «тон»ын үзгәртә белүе илә хәзер генә базардан сәхнәи тамашага тотып кертелгән бер татар бае иде.*

**ГАБДУЛЛА ТУКАЙ**

◆

*Кариев, Болгарская, Байкина — якынлашып килгән яңа тормышның беренче ягымлы нурлары, киләчәк буыннар шатлыгы өчен үз-үзләрен аямыйча, армый-талмый эшләүчеләре... Алар икейөзлелек һәм бозыклык белән тулган бай аристократ салоннарыннан түгел, ә бәлки, халык арасыннан күтәрелделәр һәм мещанлык морале белән пычранмаган саф җаннарын чын гуманистик сәнгать өчен корбан иттеләр...*

**МУЛЛАНУР ВАХИТОВ**

◆

*Кариев өчен тормыш, дөнья, бәхет, сәгадәт юк, тик театр бар, шул театрны үстерү өчен яну, шуның белән көю бар иде.*

**ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ**

◆

*Олуг революциягә без халык театрыбыз булган хәлдә килеп кермәгән булсак, аны куеп җибәрү — хезмәт гаммабыз өчен гаять авыр булачак иде. Шул авырлыкны җиңеләйтүгә Кариевның гаять зур хезмәте сәбәкать итте.*

**ФАТИХ ӘМИРХАН**

◆

*Беренче труппа артистлары йөзендә бу комедия оста башкаручыларны тапты һәм «Беренче театр» комедиясе зур уңыш белән барды.*

*Кариев Хәмзә бай ролендә, зур юмор белән, тышкы яктан көчле, ә чынлыкта исә үлемгә дучар ителгән фанатикны күрсәтте.*

**РСФСРның атказанган артисты ЗӘЙНИ СОЛТАНОВ**

◆

*Сөекле артистыбыз Габдулла иптәш Кариевның вафаты мөнәсәбәте илә татар сәхнәсе матәм тота.*

*Шул сәбәптән, пәнҗешәмбе көн, җомга көн Казан сәхнәләрендә игълан ителгән спектакльләр куелмый.*

**„Эш“ газетасы, 1920 ел, 29 январь**

Сәҗдәгә кил, эй нәфасәт дөньясы,
Мондадыр татар театр кыйбласы,
Монда «Сәйяр»ның сөекле, мәгънәви
Әткәсе — даһи Кари Габдулласы.

**Ф. БУРНАШ. Кариевның кабер ташына**

◆

*— Иптәшләр! Без бүген, беренче татар театрының нигезе буларак, беренче ташны салабыз. Кызганычка каршы, үз театрыбызның нигезен салганда, шул театрның мәгънәви нигезен корып җибәрүче Габдулла Кариев кына юк.*

**СӘЕТГАЛИ СӘЕТГАЛИЕВ**

**Җыючы: Х. ГОБӘЙДУЛЛИН**

# Түгәрәк өстәл тирәсенә

## МУСА ҮЗЕ СОРАДЫ КЕБЕК...

Инде эч серләремне чишәргә мәҗбүр иткәнсез икән, дөресен әйтим: Муса әсәре журналда басылып чыгып, укучылардан беренче фикерләр килә башлаганчы, гел курку эчендә яшәдем мин. Бу эшкә тотынып ялгыш итмәдемме? Укучыга җан азыгы бирә алырмынмы? Муса һәм якын иптәшләре образы укучы күңеленә барып җитәрме? Күп кенә шундый сораулар борчып торды. Курыкмаслык та түгел бит. Кырык ел буе бары тик шигырь белән генә шөгыльләнгән дә, һичбер тәҗрибә-нием булмаган килеш, проза белән роман язарга тотын, имеш! Бу нинди дер җиңел баштан килеп чыккан бер хәл сыман иде. Шулай да бу зур җаваплы һәм кыен эшкә керешмичә булдыра алмадым мин...

Ниһаять, хөрмәтле укучылар мине куркып яшәүдән коткардылар. Ике ай эчендә (декабрь, январь) илледән артык хат килде, ул хатлардагы саф күңелдән чыккан җылы сүзләр Муса, Алиш, Кормаш, Арыслан, Әлбидә образларын һәм, гомумән, романны үз итеп кабуллау фикерләре мине бик сөендерде. (Бу хатларның кайбер үрнәкләре «Казан утлары»ның өченче санында басылып та чыкты.)

Хәзерге укучының культура дәрәҗәсе, эстетик зәвыгы һәм идея тирәнлеге югары булуга сокланмыйча, чын күңелдән куанмыйча мөмкин түгел. Алар авторның төп ниятен, ягъни әсәрнең эчтәлеген, анда бирелгән образларны бик дөрес аңлыйлар һәм үзләренең дөрес бәяләрен бирәләр. Хәзерге укучы моның белән генә калмый, аның тагын да күбрәк беләсе, тирәнрәк мәгълүмат аласы килә. Шуңа күрә ул авторны укучылар конференциясенә яки түгәрәк өстәл тирәсенә чакыра.

«Г. Әпсәләмовның «Түгәрәк өстәл янына» дигән мәкаләсен мин ике тапкыр укып чыктым. Моның өчен данлыклы романчыбызга да, редакциягә дә зур рәхмәт... Хөрмәтле язучыбыз Шәйхи Маннур да «Муса» романының ничек язылуы турында сөйләргә безне «түгәрәк өстәл» янына чакырса, бик яхшы булыр иде. «Муса» романы бик тирән эчтәлекле, искиткеч яхшы язылган тарихи роман бит ул. Шул ук вакытта аны документаль роман дияргә дә була. Шуңа күрә аның язылу тарихын ишетү бигрәк тә файдалы булыр иде», дип яза укытучы Мәрьям Маннапова Түбән Шөн авылыннан (Киров өлкәсе). Моңа охшашлы фикерне башка иптәшләр дә кузгата. «Мусаны үзегезнең якыннан белүегез турында хат яза алмассызмы? Ул материалларны ничек тупладыгыз?» — дип сорый укытучы Люция Хәбибуллина (Төмән өлкәсе). Арчадан хат язучы Насыйров та: «Бу әсәрне язганда архив материалларыннан файдалану булганмы? Архивта М. Җәлил эшләре турында материал бармы?..» — дип сорый. Болар һәммәсе дә бер ноктага кайтып кала шикелле. Җавапка керешеп карыйк.

Һәрбер уй, ният яки максатның тууына мөһим бер тышкы этәргеч була. Муса «мәсьәләсе» хәл кылынып, аның тоткында язылган шигырьләре дөньяга чыгуга дүрт-биш ел узып китте. Бу вакыт эчендә Муса турында татарча, русча драма әсәрләре, Әхмәт Фәйзи либреттосына Җиһанов операсы, күпләгән шигырь, поэмалар, мәкалә һәм әдәби тикшеренү очерклары, кайбер истәлекләр басылып чыкты. Ләкин бу әсәрләр бирсә дә, үзләренең тар калыплары аркасында, җәлилчеләр алып барган зур кө-

рәшнең тулы картинасын киң колач белән күрсәтеп бирә алмадылар. Ә танылган романчыларыбыз бу эшкә ни өчендер бик ашыгып тотынмадылар. Менә шушы хәл, ягъни 1958 елга хәтле Муса һәм иптәшләренең соклангыч көрәш юлы турында киң полотналы проза әсәре әле һаман булмавы, миндә бу эшкә тотыну теләге тудырды. Әмма бу теләк шунда ук бик куркыныч булып күренде: кырык елга якын шигырь белән генә яшәлгән, чәчмә сүз белән хикәя кылу тәҗрибәсе юк. Дөрес, кайбер очерк, истәлекләр язу практикасы бар барын, ләкин роман хәтле роман өчен болар гына, әлбәттә, җитмәячәк бит. Шулай да мин бу эшкә керешмичә булдыра алмадым. Муса үзе сорый кебек тоелды миннән бу эшне.

Ә Мусаны мин яхшы белә идем. Яшьлек елларыбызның шактый вакыты бер иҗат мәйданында узды, янәшә бүлмәләрдә һәм бергә эшләгән чакларыбыз да аз булмады, шигъри бәхәсләр дә, фикердәшлек тә, бергәләп коллектив поэмалар язу да, икебез бер кызга кызыгып йөрүләр дә, бер бүлмә идәнендә рәттән тезелеп ятып йоклаулар да, бергә су коену, чаңгы шуу, күңел ачулар да булды. 1929—32 еллар дәверендә мине «кулак сандугачы», «пессимист», «есенинчы» һ. б. лар дип, язучылар оешмасыннан кудылар, кичә генә дус булып, кочаклашып йөргән егетләр мине танымас булдылар. Муса бу вакытта да миңа карата элекке мөнәсәбәтен һәм фикерен үзгәртмәде. Бу кыен елларда безнең иптәшлек беренче сынауны уздырды. Шул чакларда мин чын дусларны танырга өйрәндем.

Шулай итеп, Муса белән шактый якын аралашып кичерелгән үндүрт ел эчендә миңа аның холкы-фигыле, гореф-гадәтләре, сөйләшү-фикер йөртү үзенчәлеге, ялкынлы табигате, мораль сафлыгы, һәйбәт коммунистлыгы, зур оештыру сәләте, кече күңеллелеге, кыскасы, аңа хас булган бөтен сыйфатлары — уч төбендәгедәй ачык иде.

Ләкин роман язу өчен болар гына җитми бит әле. Шуңа күрә иң элек Мусаның үз кулы белән язылган ике дәфтәрне яңадан укып чыктым, алардагы бозылган сүзләргә, даталарга, аерым билгеләргә кадәр өйрәнергә, ачыкларга тырыштым. Аның:

Әкияттәге серле йомгак булып
Җырым калды сүтелеп юлымда,
Сез табарсыз килеп шушы эздән
Мине соңгы йөрәк җырымда, —

дигән юлларының эчке мәгънәсен, биографиясен ачарга омтылдым. Алай гына да түгел, ул дәфтәрләрдәге бик күп шигырьләрне кат-кат укып, кайчан, нинди урында, нинди кәеф-кичереш, нинди рухи халәттә язылулары турында озак уйланырга туры килде. Бу шигырьләр киләчәктәге эш планымны, язу мәйданымны киңәйтеп җибәрделәр һәм Муса узган юлларның географиясен өйрәнергә куштылар.

Чынлап та, әсәрдәге геройлар нинди урыннарда йөргән яки йөрергә тиеш булсалар, язучы үзе дә шул җирләр белән ичмаса бер кадәр таныш булырга тиеш бит.

Минзәләгә чыгып киттем, андагы училище, Дусайкичү авылы, Ык буйлары белән таныштым. Мусаны белгән кешеләр белән сөйләштем. Аннары Оренбургка, Мостафа авылына бардым, яшьтәшләре белән очраштым, алар Мусага бәйле бөтен урыннарны күрсәттеләр. Оренбургта Мусаның сеңелләре Зәйнәп һәм Хәдичәдән бик бай истәлекләр алдым, алар мине героем йөргән эзләрдән йөрттеләр. Аннан кайтышлый Әминә ханым белән очрашып, шулай ук бик кирәкле истәлекләр алдым. Шул уңайдан элекке Волхов фронтына кергән «Мясной бор» станциясенә барып, Муса сугышып йөргән һәм, бүленештә калып, әсирлеккә эләккән җирләрне карап уздым. Шуннан Ленинградка җитеп, Муса белән «Отвага» газетасында очрашкан рус язучыларын күреп сөйләштем. Кайтышлый яңадан Мәскәүгә туктап, хәрби архивка кагылдым, ләкин анда Муса турында материаллар табып булмады. Берлинда Муса белән очрашкан Исмәгыйлевне табып сөйләштем, Мусаның Мәскәү читендә яшәүче яшьлек дусларын эзләп таптым. Алар һәммәсе дә теге яки бу күләмдә файдалы истәлекләр сөйләде миңа. Казанга кайткач, Алишның тормыш иптәше Өркыя ханым белән очраштым. Абдулла Алишның холкын-фигылен үзем дә азмы-күпме белә идем. Ул минем күз алдымда юаш кына холыклы, кешеләргә карата эчкерсез, бик кече күңелле һәм яхшылыклы, чын дусы өчен җан аямас бер иптәш булып, бер дә шапырынуны яратмый торган тыйнак бер язучы булып калган. Өркыя ханым сөйләгән истәлекләрдә аның тагын да бик күп гүзәл яклары ачылып, Алиш образы минем күзаллавымда күп өлеш

баеп, ачылып, мәһабәт булып китте. Аны мин Муса белән рәттән куеп ярата башладым һәм Мусаның аңа багышланган «Дуска» дигән шигыре нинди кадерле хисләр агышында язылганын тирәнтенрәк аңладым. Димәк, Алиш анда да бу гүзәл сыйфатларын җуймаган, Мусаның уң кулы булган! Шуңа күрә мин аларның образын Шота Руставилинең Тариэле белән Автондиле төсендәрәк сурәтләргә тырыштым.

Ниһаять, комсомол туристлар төркеменә ияреп, Берлинга киттем. Анда бик күп нәрсәләр табардай хыялланган идем, тик соңга калганмын шул. Мусалар һәлак булудан соң ундүрт ел узып киткән! Әгәр без аларның көрәш юлын ачыклауга үз вакытында тотына алган булсак, күпме әйберләр тапкан булыр идек. Эзләгән кешеләремнең берсен дә күрү насыйп булмады. Картраклары үлгән, исәннәре күчеп киткән, гаепләләре теге якка сызган. Шулай да Муса һәм иптәшләре йөргән урыннарны күрдем. Германиянең ландшафты, кешеләренең көнкүреше, ил үзенчәлеге белән танныштым. Көнбатыш Берлинга чыгып, Мусалар утырган төрмәләрне кырыйларыннан гына булса да карап уздым. Аларның өчесе җимерек, тик Шпандау гына сакланган иде. Эчләренә керү, әлбәттә, мөмкин булмады, чөнки «теге» якта бит.

Шулай да анда католик мулласы Юрытко әфәндене эзләп таптым. Ул Мусаларның соңгы урыны булган Шпандау төрмәсенә католик тоткыннар янына йөргән. Шунда Муса белән Фоат Булатовны очраткан, танышып сөйләшкән. Юрытко әфәнде миңа аларның соңгы көннәре турында сөйләп бирде. Әлбәттә, кирәкле материал иде бу.

Берлиннан кайткач, Дәүләт куркынычсызлыгы архивларында утырдым. Аннан алган мәгълүматлар романда катнашучы башка персонажларны эшләү өчен күп кенә ярдәм итте. Шул ук вакытта Рушат Хисаметдинов, Фәрит Солтанбеков, Фәйзелхак Миңгалин иптәшләрнең истәлекләре белән дә таныштым.

Шулай итеп, 1958 ел узып китте, «түл җыю» чоры тәмам булды. Илле тугызынчы елның январенда, каләм тотып, эшкә утырдым. Яза башлагач та романчылык тәҗрибәм юклыгы бик ачык мәгълүм булды. Укырга тотындым. Лев Толстойның «Сугыш һәм солых» эпопеясен яңадан җентекләп өйрәнеп чыктым. Башка бик күп романнар укырга, энциклопедияләр актарырга туры килде һәм бу уку, өйрәнүләр әсәремне язып бетергәнче дәвам итте, кимендә йөзләп роман укылгандыр, һәм ул чор миңа үзе бер мәктәп булды. Мусаны белгән һәм хәбәрдар булган Салих Ганиев, (Магадан), Әнвәр Газетдинов (Мөслим районы) һ. б. иптәшләрдән хатлар килә торды. 1960 елны Башкортстанның Сибай каласындагы Гариф Хафизов янына, Зәй районындагы Фәйзелхак Миңгалин янына барып кайттым. Алар белән сөйләшү Мусаның Двинск лагерендагы чагын һәм Берлиндагы яшерен эш чорын ачыкларга ярдәм итте.

Менә шулай итеп, әсәр әкренләп барлыкка килә башлады һәм биш ел тулганда беренче каты язылып бетте.

Сорауларның икенче төренә килик. «Язучы үлем картинасын кем сөйләве буенча яза, Паульнең рәсемнәре нигездә ятмыймы?» — дип сорый Сөембикә Ихсанова Уралдан. Шул ук мәсьәлә белән Алабугадан Галия Закирова һәм Казаннан Р. Бикташева да кызыксына.

Мин инде эшемнең ахырына җитеп килә идем һәм геройларымның һәлак булу картинасын ничек язарга белми җәфалана идем. Чөнки батырлар гомеренең бу актыкны минутлары турында кайбер имеш-мимештән башка төпле бер материал юк иде. Шул чакта минем өйгә ир уртасырак бер кеше килеп керде (аны бер язучы иптәшем җибәргән) һәм Әнвәр Газетдинов дип үзе белән таныштырды да сөйләп китте. Мин аны кочаклап үбәрдәй булдым. Ул кайчандыр үзенә Пауль сөйләгәннәрне түкмичәчми миңа тапшырды. Шулай итеп, Пауль дә, бу егет үзе дә романга килеп керделәр. Шулай итеп, соңгы картина алар сөйләве нигезендә сурәтләнде. Чөнки, уйлап чыгару фантазиясенә караганда, тормыш чынлыгы һәрвакыт көчлерәк һәм матуррак була. Әлбәттә, язучы тормыш вакыйгаларын бервакытта да ялангач көйгә генә алмый, ул аны фактография генә булыр иде, шуңа күрә ул аны «сиплэп», үзенең уй һәм хисләре белән җылытып, тулыландырып укучы күңеленә тапшыра.

«Әлбидә образы ничек барлыкка килде?» — дип сорый Саҗидә Ганиева Башкортстаннан. «Әлбидә образы язучы образы гына түгелме?» — ди С. Ихсанова. Бу образ белән башка укучылар да кызыксыналар.

Әдәби образларның ничек тууы турында Г. Әпсәләмов үзенең «түгәрәк өстәл»

җавабында бик төпле генә аңлатмалар биреп киткән иде инде. Мине икенче сораудагы «язучы образы гына түгелме?» дигән сүз борчый. Безнең кайбер укучыларыбыз, кызганычка каршы, иясе, адресы билгеле булган геройларны гына игътибарга лаеклы санап, иҗади образларны уйлап чыгарылган нәрсә генә дип карыйлар әле. Бу караш, әлбәттә, ялгыш. Әгәр болай карасак, язучы һәм художник үзләренең бөтен әсәрләрен һәм образларын билгеле бер кешенең тормышыннан, портретыннан күчереп язарга гына тиеш булалар. Ә безнең әдәбият һәм сәнгатьнең, гомумән, бөтен дөнья әдәбиятының кимендә 80—90 проценты шул «язучы образы»ннан гыйбарәт бит. Һәм бу эш бер дә кирәкмәгәннән генә, авторның «кулы кычытып», кемнедер мактарга яки кемнедер яманларга теләвеннән генә эшләнми. Бу эшне тормыш һәм аның зур, давыллы вакыйгалары художникка үзе куша. Язучы булган кеше халык һәм заман тормышындагы хәлләрне, күп кешеләрнең эш һәм яшәешләренә хас вакыйгаларны чагылдырмыйча кала алмый. Һәм ул боларны үз кичерешләре, үз аңлавы аша сурәтләү чараларына керешә. Бу уңай белән мин, шактый сәер тоелса да, язучыны бал кортына охшатыр идем. Бал корты болын, басу, урман һәм бакчалардагы һәртөрле чәчәкләрдән, хәтта тигәнәк, әрем, билчән, бакыра чәчәкләреннән дә, нектар суырып йөри дә, умартага алып кайтып «бушата». Нәтиҗәдә, бик татлы һәм файдалы бал килеп чыга. Язучы да кешеләрнең һәртөрлесен, алар тормышындагы драматик яки көлке вакыйгаларны, үзе яшәгән заманның төп сыйфатларын һәм башка санап бетергесез «нечкә» якларын күзәтеп-өйрәнеп йөри-йөри, күңел түренә сеңдерә дә, эш өстәленә утыра һәм зур иҗат газаплары аша образлар тудыра, әсәр яза. Ул, әлбәттә, күпләр өчен уртак образ, үз заманына хас әсәр барлыкка китерергә тырыша. Тик аның бу эше бал шикелле ансат һәм татлы килеп чыкмавы гына мөмкин. Монысы инде талант һәм осталыкка кайтып кала.

Әлбидә дә романга тикмәгә генә килеп кермәде. Дүрт ел фронтта йөргән вакытымда мин күп кенә татар кызларын очраттым. Алар врач, медсестра, санитарка, радистка, артистка, кер юучы, аш пешерүче, разведчица, юллар чатында яшел флаг тотып торучы һәм башкалар иделәр. Аларның иң зур күпчелеге үз хезмәтләрен намус белән үтәүче, саф күңелле һәм Ватан өчен батырларча һәлак була белүче асыл кызлар иде. Мин алар турында поэма һәм шигырьләр дә яздым һәм аларга булган җылы хисләрем бүген дә сүрелмәгән әле. Муса сугышкан Волхов фронтында да шундый һәйбәт кызлар бер генә булмаган. Аннары Берлинның үзендә дә Донбасс якларыннан көчләп китерелгән татар кызлары булган, аларны хәрби заводта эшләткәннәр. Бу безгә Миңгалин һәм башкаларның истәлекләре буенча да мәгълүм. Халкыбызның фронтта сугышкан һәм дошман кулына эләгеп тә, аңа баш имәгән әнә шул батыр кызлары Әлбидә образын иҗат итәргә куштылар миңа. Һәм мин аны бик яратып эшләдем, бар көчемне биреп. Халык кызы образын тудырырга тырыштым. Борынгы фольклор һәм легендалардагы Зөһрә, Зөлхәбирә һ. б. ларның бу замандагы үсешен бирергә теләдем. Димәк, менә кемнәр тора Әлбидә артында. Аңа, «язучы образы гынамы?» дип, кимсеткәндәйрәк карау яки «роман героинясы» итеп кенә кертелгән дип әйтү белән мин һич тә килешә алмыйм. Фронтта булган кызлар да моның белән, әлбәттә, килешмәсләр.

Сорауларның өченче төре романда күренгән герой һәм персонажларның язмышына карый.

«Алпамшадай олы, анадай мәрхәмәтле Арыслан абзый кая китте?» (Р. Бикташева). «Бик беләсебез килә: андагы Әхмәт Симаев, Арыслан, Фая, Фәхриләр үз илебезгә исән кайта алалармы?» (М. Закирова, Д. Байкиева, Мамадыш). Шул тиклем немецларга сатылган Шәфи Алмаз чынлап та безнең татар кешесеме? (Г. Шаяхмәтова, Свердловск шәһәре). «Шәфи Алмаз, Усман мулла һәм Мусаларны аткан немец офицерлары кайсы якта калды икән, аларга тиешле җәзалары бирелдеме икән? Димски Мусага биргән вәгъдәсен үтиме? Ике сатлык җан — алар ничек?» (Сугыш инвалиды Г. Муллаяров, Башкортстан, Ялгызнарат авылы). «Паульнең фотолары һәм Мусаның аңа биргән хаты илгә ирештеме?» (Г. Закирова, Алабуга). «Ни өчен язучы кыска гомерле бу зур тормышның иң ахыргы кисәген генә гәүдәләндергән?» (М. Газизова, Дербышки). «Ни өчен «Муса» романы икенче кисәктән генә басыла башлаган?» (М. Маннапова, Киров өлкәсе). Тагын күп кенә укучылар хатларында шушы ук характердагы сорауларны куялар.

Иң элек Әхмәт Симаевтан башлыйк. Бу батыр егетне фашистлар, Плетцензее төрмәсенә алып китеп, Мусалар белән бер көнне, бер сәгатьтә җәзалап үтерүе турында Көнбатыш Берлин прокуратурасы архивыннан табылган документ безнең матбугатта басылып чыккан иде. Шул сәбәпле романда Симаевны үлемгә алып китүгә ишарә ясау да җитәрдер кебек тоелды. Мусаларны аткан фашистлар, Шәфи Алмаз, Усман мулла һ. б., әлбәттә, үз вакытында качып өлгергәннәр. Бу җинаятькә бәйле адәмнәрнең бүгенге көнгә кадәр табылганнары юк.

Сорауларның калган өлешенә җавапны романның беренче һәм ахыргы кисәкләреннән табарга була. Минем тәҗрибәм җитмәгәнгә күрәдер, ул әсәр бик озынга сузылып, илле басма табак күләменә җитте. Ә журнал бары тик утыз табагын гына баса алды, чөнки аның битләрендә ел буена бер генә әсәрнең сузылып баруы мөмкин түгел бит. Мин хәзер әсәремне яңадан бер кат карап, төзәтеп, кыскартып ятам, китап итеп әзерлим. Сез инде, кадерле укучыларым, әз генә сабыр итегез, әсәр тулысы белән шушы ел эчендә басылып чыкса кирәк, ул китапны мәшәкать булса да тагын бер кат укырга чакырам сезне, чөнки анда әле бик күп яңа нәрсәләр булачак.

Төзәтү дигәннән, тагын бер мәсьәләгә җавап бирәсем бар икән әле. Сарман райкомы секретаре М. Низамиев, газета сотруднигы М. Юсупов, романда күрсәтелгән Зиннәт Хәсәновның энесе Ш. Хәсәнов иптәшләр имзасы белән язылган хатта: «Тарихи романнарда, гадәттә, шәхесләр артык үзгәртелмиләр. Без моны «Петр I» «Яшь гвардия» һ. б. әсәрләрдә ачык күрәбез. Якташыбыз Зиннәт Хәсәновның биографик детальләре бөтенләй тормыштагыча түгел. Ш. Маннур Зиннәтнең Сарманда хатыны, өч баласы бар итеп күрсәтә, ә ул өйләнмәгән егет кеше. Туган елы 1906 түгел, 1916. Профессиясе механизатор түгел, товаровед иде...» — ди.

Мондагы кайбер фикерләргә минем бик үк кушыласым килми. Мәсәлән, «Муса» тарихи роман да, документаль роман да түгел, бүгенге заман романы. Бөек Ватан сугышында җиңеп чыгуыбызга егерме ел тулып узган булса да, ул авыр көннәрнең дәһшәтле туп авазлары колак төбебездән һаман да китеп бетмәгән кебек әле. Муса һәм аның батыр иптәшләре дә, нинди дер ераклыкка чигенгән тарихи шәхесләр булудан бигрәк, кичә генә бергә шаулап-гөрләп яшәгән дусларыбыз, якын замандашларыбыз булып, күз алдында басып торалар әле.

Фадеев тарафыннан сугыш бетәр-бетмәстә үк язылган «Яшь гвардия» дә тарихи роман түгел. Лев Толстой «Сугыш һәм «солых»ны вакыйгадан илле еллар соң язса да, тарихи роман дип атамаган. Әгәр автор бу очракта тарихилык кысасына кереп, фәкать документ, төрле язма чыганак һәм истәлекләргә таянып кына эш итсә, үзен бик кыен хәлгә калдырыр һәм, ихтимал, роман туа алмаган да булыр иде. Чөнки Муса һәм иптәшләренең бу зур көрәш эпопеясе әле хәзер дә тулысынча ачыкланып бетмәгән, әле безгә бик күп нәрсәләр мәгълүм түгел. Шул сәбәпле, бу әсәрне язарга керешкәч тә, мин үземне билгеле бер дәрәҗәдә иреклә тотарга, иҗат фантазиясен дә чикләмәскә тиешлекне аңладым.

Зиннәт Хәсәновны рәсемләүдәге «иркенлек»тә, ихтимал, шуннан килгәндер. Муса аны бик җитди һәм төпле кеше саный, шуңа күрә батальон командиры итеп билгели. Зиннәтнең исән калган иптәшләре Ф. Солтанбеков, Р. Хисаметдиновлар да аның шундый ук җитди сыйфатларын раслыйлар. Шуның өстенә, язма чыганакларда ул чыннан да Муса яшьтәше (1906) булып йөри. Менә шулардан чыгып, миңа Зиннәтне шундый сыйфатларда төсмерләргә туры килде һәм бу эштә артык зур «гөнаһым» да юк шикелле. Ник дисәң, төп хикмәт Зиннәтнең өйләнмәгән егет һәм товаровед булуында түгел бит, төп сыйфат Зиннәтнең әнә шундый зур җаваплы бурычны өстенә йөкләрлек ышанычлы көрәшче булуында, төрмәгә эләккәч тә дошман алдында баш имичә, үзен Мусалар шикелле үк батыр тота белүендә һәм актык сулышына кадәр алар белән бергә баруында. Менә аның егетлеге нәрсәдә!

Шулай да, әсәрне китап итеп эшләгәндә, Зиннәт хакында мин тагын бер кат уйлап караячакмын әле. Шулай итеп, укучы иптәшләрнең күпчелек соравына бик үк тулы булмаса да, әзме-күпме җаваплар бирелде шикелле. Инде сүз ахырында шуны әйтәсем килә: «Муса» романын укып, үзләренең җылы сүзләрен, фикер һәм киңәшләрен әйтеп хат язган барлык иптәшләргә ихлас күңелемнән рәхмәт укыйм, эшләрендә уңыш, тормышларында куаныч телим.

Ш. МАННУР.

# Әдәби мирас һәм библиография

Соңгы ун ел эчендә әдәбият кыштәләребез бермә-бер баеды. 1930 елларның урталарыннан алып исемнәре матбугат битләрендә искә алынмый башлаган атаклы һәм күренекле язучыларыбыздан Г. Ибраһимов, Ш. Усманов, К. Тинчурин, М. Галәү, Г. Газиз, Л. Гыйльми, М. Крыймов, Галим Мөхәммәтшиннарның сайланма әсәрләре басылып чыкты. Әдәбият һәм әдәби тәнкыйть өлкәсендә күп хезмәт күрсәткән Гомәр Галиев, Г. Нигъмәти, Ф. Сәйфи-Казанлы, Г. Толымбай, Ш. Әхмәдиевларның хезмәтләре фәнни әйләнешкә кертелде. Вакытында, төрле сәбәпләр аркасында, иҗатлары берьяклырак яктыртылган Ф. Әмирхан, Ш. Бабич, С. Рәмиев, Дәрдмәнд, З. Бәшири, Ш. Мөхәммәдов, З. Һади, С. Сүнчәләй кебек язучыларыбызның эшчәнлегенә объектив бәя бирелде, аларның иң яхшы әсәрләрен эченә алган җыентыклары укучыларга тәкъдим ителде. Г. Тукай, Г. Камал, Ш. Камал, К. Нәҗми, М. Гафури, М. Фәйзи, Ә. Фәйзи, Н. Исәнбәт, М. Җәлилләрнең күп томлы сайланма әсәрләре басылды һәм басылып килә. М. Гали, М. Максуд, Г. Иделле, А. Шамов, К. Әмири һәм совет татар әдәбиятын үстерүгә күп көч куйган башка язучыларыбызның берәр томлы сайланма әсәрләре, татар әдәбияты тарихында беренче мәртәбә татар һәм рус телләрендә «Татар поэзиясе антологиясе», «Татар совет әдәбияты тарихы» китаплары дөньяга чыкты.

Аерым язучыларыбызның иҗат һәм тормыш юлларын өйрәнү буенча да беренче уңышлар бар. Г. Халитның Г. Тукай турындагы фәнни тикшеренүләре, Г. Кашшаф, Р. Бикмөхәммәтов, Н. Юзиевларның Муса Җәлил турындагы хезмәтләре, М. Хәсәновның Г. Ибраһимов, Н. Гыйззәтуллинның К. Нәҗми, М. Җәләлиеваның Гомәр Бәширов, Г. Шамуковның Н. Исәнбәт, Ф. Хатиповның М. Әмир, Ә. Нигъмәтуллинның Ш. Камал, Х. Хисмәтуллинның Ф. Әмирхан, З. Мәҗитовның Ф. Кәрим турындагы монографияләре моңа дәлил булып торалар. М. Гайнуллин, Г. Халит, Х. Госман, Х. Хәйри, И. Нуруллин, Б. Гыйззәт, Р. Бикмөхәммәтов, Р. Мостафин, Н. Юзиев, Р. Башкуров һ. б. әдәбият белгечләребезнең тикшеренүләре татар әдәбияты тарихын фәнни өйрәнүгә зур өлеш керттеләр.

Соңгы ун ел эчендә татар әдәбияты өлкәсендә ирешелгән бу уңышлар Партиябезнең XX һәм XXII съездлары тудырган киң мөмкинлекләрнең җимеше. Әдәбият тарихыбызны киң өйрәнә башлау, әдипләребезнең сайланмаларын чыгаруның үсүе әдәби мирастан дөрес файдалана белү мәсьәләсен дә көн тәртибенә куйды. Тегеяки бу язучының җыентыгын чыгарганда, аның төрле чорда, төрле темаларга караган барлык хезмәтләрен дә басмага кертүнең кирәге юк, билгеле. Әмма шул ук вакытта әдипнең иң яхшы әсәрләрен бастырганда, аның тулы иҗатын укучыларга әйтми, күрсәтми үтү дә ялгышлык булыр иде.

1956—1957 елларда Г. Ибраһимовның өч томлык сайланма әсәрләре, 1960 елны «Әдәбият мәсьәләләре» дигән җыентыгы басылды. Бу басмаларга әдипнең барлыгы 14 хикәясе, 4 романы, 1 драмасы һәм 31 әдәби-тәнкыйть мәкаләләре кертелгән. Һәм менә 1964 елны Мансур Хәсәновның әдипнең тормыш һәм иҗат юлын киң планда тикшергән «Галимҗан Ибраһимов» исемле монографиясе чыкты. Монографиядә әдипнең барлык хезмәтләрен, әсәрләрен, аның турында басылган барлык материалларны эченә алган тулы библиография дә китерелгән. Библиографиядән күренгәнчә, Г. Ибраһимовның соңгы басмаларына әле биш хикәясе кертелмәгән («Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы», «Гыйшык корбаннары», «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә», «Көтүче карт», «Караңгы төннәрдә»), ә әдәби тәнкыйть, публицистик мәкаләләренең саны 31 генә түгел — 300 дән артык икән! Шул ук библиографиядән Г. Ибраһимовның әдәбият белеме, тарих, тел, сәнгать буенча 30 лап китабы басылганлыгын да күрәбез. Әгәр М. Хәсәновның хезмәтендә бу библиография китерелмәсә, әдипнең күп хезмәтләре озак елларга тагын томаланып калган булырлар иде. Н. Гыйззәтуллинның «Кави Нәҗми» дигән монографиясендәге, Нәкый Исәнбәт турындагы Г. Шамуков хезмәтендәге (Гөлсем Исәнбәт төзегән) библиографияләр турында да бары тик мактау сүзләре генә әйтергә мөмкин.

Кызганычка каршы, язучыларыбызның тормыш һәм иҗаты турындагы башка монографияләрнең авторлары библиографиягә тиешле әһәмият бирмәгәннәр. Ф. Хатипов «Мирсәй Әмир» дигән хезмәтендә (1964) әдипнең иҗаты турында басылган тәнкыйть мәкаләләренең исемлеген теркәү белән чикләнгән. Безгә билгеле булганча,

М. Әмир әсәрләре татар һәм рус телләрендә 50 тапкыр аерым китап булып басылды, аның газета-журналларда, төрле җыентыкларда йөзгә якын әдәби әсәрләре, тәнкыйть, публицистик мәкаләләре бар. М. Әмир иҗаты турында язылган мәкаләләр дә, Ф. Хатипов күрсәткән 43 исем белән генә чикләнми. Ә. Нигъмәтуллинның Шәриф Камал турындагы монографиясенә язучының төрле җыентык һәм альманахларда, газета-журналларда басылган күп мәкаләләре, аның турында матбугатта басылган материаллары күп өлеше керми калганнар. М. Җәләлиеваның «Гомәр Бәширов» турындагы хезмәтенең библиография өлеше Ф. Хатипов, Ә. Нигъмәтуллин хезмәтләре рамкасыннан чыкмаган. Х. Хисмәтуллинның Ф. Әмирхан турындагы монографиясендә библиография бөтенләй юк.

Без күренекле язучыларыбыз турындагы монография авторларын үзләре өйрәнә торган әдип иҗатын белмиләр дип уйламыйбыз һәм аларны наданлыкта гаепләргә дә җыенмыйбыз. Ә инде тупланган материалларның тулы библиографиясен хезмәттә күрсәтмәү — фәннилектән чигенү дигән сүз.

Инде теге яки бу әдип иҗаты турында беренче мәртәбә монография басыла икән, ул чын мәгънәсендә әдәбият тарихында югалмаслык хезмәт хәлендә чыгарылсын иде. Монографиянең библиографик өлешендә язучының бөтен мирасын һәм аның турында язылган бөтен материалларның исемлеген урнаштырырга кирәк. Киләчәктә шул ук әдип иҗаты буенча кемдер башка берәү эшләргә уйлый икән, ни өчен ул яңадан еллар буенча газета-журналлар, китаплар диңгезендә казынырга тиеш?..

Язучының барлык әсәрләре, хезмәтләре һәм аның турындагы мәкаләләрне тулы чагылдырган библиографияне бастыру язучыларның сайланма әсәрләрен чыгарганда да онытылмаска тиеш. Бу өлкәдә татар әдәбияты тарихында үрнәк булырлык аерым хезмәтләр юк түгел. Г. Тукайның 1955—1956 елларда чыккан 4 томлык «Әсәрләр» ендәге күренекле библиографыбыз Мәсхүдә ханым Бурнашеваның библиографик шундый хезмәтләр рәтенә керә. Билгеле булганча, бу басма — Г. Тукайның иң тулы җыентыгы. Шушыннан чыгып, кайбер кешеләр биредә библиографиянең кирәге бармы соң дип сорарга мөмкиннәр. Бу чыннан да шулаймы соң? Басмада библиография китерелмәгән булса, без Г. Тукайның кайсы әсәре ничә мәртәбә, кайсы газета, журнал, җыентыкларда басылуын, аның әсәре кайсы телләргә тәрҗемә ителүен, аның турында нинди хезмәтләр һәм мәкаләләр басылуын, Тукай образына багышлап нинди әсәрләр язылуын, аның әсәрләренең барлыгы ничә мәртәбә, нинди тираж белән басылуын, әсәрләрен башка телләргә кемнәр тәрҗемә итүен, башка күп нәрсәләрне белми үткән булыр идек.

1958 елны Г. Газизнең «Хикәяләр» җыентыгы чыкты. Җыентыкны төзүче Р. Гайнанов әдипнең җыентыкка кертелгән хикәяләре белән генә чикләнсә, укучылар язучының күпкырлы хезмәтен күрә алмаслар иде. Р. Гайнанов төзегән библиографиядә Г. Газизнең язучы гына түгел, зур әдәбият белгече, күренекле тарихчы, әсәрләре рус, татар, әзербайҗан, үзбәк телләрендә күп тапкырлар басылган зур галим булуын ачык күрәбез. Кызганычка каршы, Р. Гайнанов Г. Газиз турында чыккан тәнкыйть материалларның библиографиясен бирмәгән.

А. Әхмәтнең 1964 елны, Г. Толымбайның 1959 елны, Г. Нәгъмәтинең 1958 елны чыккан сайланма әсәрләрендә дә библиография китерелгән. Ләкин бу библиографияләр берьяклы гына. Аларда я авторның төп әсәрләре генә, я аларның иҗаты турында язылган кайбер хезмәтләр генә саналып үтелә. Шунлыктан, бу җыентыклардагы библиографияләр фәнни-информацион библиографик күрсәткечләр дәрәҗәсенә күтәрелмәгәннәр. Соңгы ун ел эчендә матбугатка чыккан монографияләр һәм сайланма әсәрләрдә китерелгән библиографик хезмәтләр шушылар белән чикләнә.

Ф. Бурнаш (1959), Ш. Әхмәдиев (1959), К. Тинчурин (1956), Дәрдмәнд (1959), С. Рәмиев (1962), З. Бәшири (1958), Ш. Бабич (1958), З. Һади (1957), Ф. Сәйфи-Казанлы (1958), Ш. Мөхәммәдов (1958), Н. Думави (1960), М. Крыймов (1961) һәм башка язучыларның сайланма җыентыкларында библиографияләр бөтенләй юк. Хәзерге көн укучысы өчен бу язучыларның иҗаты шушы сайланма әсәрләренә кергән материаллар белән генә чикләнә, ә шул ук язучыларның сайланма җыентыкларына керми калган әсәрләре турында бүгенге укучылар хәбәрсез калалар. Мисал өчен Г. Кутуйның соңгы елларда чыккан ике сайланмасын һәм 1957 елны чыккан «Публицистика» исемле җыентыгын алыйк. Бу басмаларда язучының барлыгы 50 исемдәге әдәби-тәнкыйть мәкаләләре, матур әдәбият әсәрләре, рецензияләре урнаштырылган. Ә бит Г. Кутуйның әдәби мирасы болар белән генә чикләнми. Аның татар әдәбияты, татар театрына караган мәкаләләре генә дә 100 дән артык. Ул мәкаләләрнең байтагы «Правда», «Литература и искусство» газеталарында һәм украин, белорус телләрендә басылган. «Тапшырылмаган хатлар»ы рус телендә күп тапкырлар һәм корея, кытай, албан, вьетнам h. б. телләрдә чыккан.

Хәзер Татарстан китап нәшрияты Әхмәт Фәйзи, Н. Исәнбәтнең күп томлы сайланма әсәрләрен бастырып бетерү алдында тора, башка күренекле язучыларның күп томлы сайланмаларын басуны планлаштыра. Татар әдәбиятына өлеш керткән башка язучыларның да җыентыклары чыгасы бар. (Г. Рәхим, А. Таһиров, Р. Ильяс, С. Атнагулов, М. Галәү, Мин Шабай, Ә. Айдар h. б.) Аларның сайланмаларын чыгарганда, үткәндә җибәрелгән җитешсезлекләр кабатланмасын иде. Атлаган саен һәр язучының сайланма әсәрен чыгарып булмый. Шунлыктан зур сайланма әсәрләр тулы фәнни библиографик аппарат белән тәэмин ителгән булырга тиеш.

Язучылар иҗатына багышланган монографияләрне һәм зур сайланма әсәрләрне бай фәнни-библиографик материал белән тәэмин итү татар әдәбияты өчен бигрәк тә зарури. Билгеле булганча, кыска гына ва-

кыт эчендә без ике графиканы үтеп, өченче графика нигезендә язабыз. Гарәп, латин графикасы инде онытылып бара. Ә бит безнең әдәби мирасыбызның шактый өлеше гарәп һәм латин шрифтларында басылган. Һәм ул мирасны хәзер яңа графикага күчереп бетерү мөмкин дә түгел, кирәкми дә. Шунлыктан, бигрәк тә, элекке чорларда язган әдипләребезнең сайланма әсәрләрен чыгарганда тулы фәнни библиография китерү — безнең фәнни һәм намус бурычыбыз.

Татар матбугатында революциягә хәтле һәм революциядән соң да псевдонимнар астында язу бик модада булган. Әдипләрнең псевдонимнарын тегәл белмәү аркасында, кайбер фәнни хезмәтләрдә буталчыклыклар киткәли. Сайланма әсәрләр төзүчеләр һәм монография авторлары бу мәсьәләгә дә игътибар итсеннәр иде.

Татар әдәбияты библиографиясе әле эшләнмәгән диярлек. Булган хезмәтләрнең библиографик тасвирламасында күп төрле җитешсезлекләр, хәтта гафу ителмәслек хаталар да очрый. Бу бездә библиографик грамоталыкның түбән булуын күрсәтә. Библиографик хезмәтләрнең сыйфатын үстерү, татар библиографик тасвирламасын унификацияләү үзе аерым зур мәсьәлә. Киләчәктә бу мәсьәләне дә күтәрү һәм хәл итү көн тәртибенә куелырга тиеш.

Күреп үткәнчә, әдәби мирас мәсьәләсе фәнни библиографиягә бик тыгыз бәйләнгән. Библиография фәннең ачкычы, диләр. Моңа өстәп, библиография әдәби мирасның сакчысы, аның юл күрсәткече дисәк тә ялгыш булмас кебек.

Әгәр без әдәбиятыбызны яратабыз, бай әдәби мирасыбызны ачыкларга, барларга, сакларга телибез, аны халыкка җиткерүне, киң мәйданга тулырак чыгаруны үз бурычыбыз итеп саныйбыз икән, без аның фәнни библиографиясен булдыруга, әдәбиятыбызның псевдонимнар сүзлеген төзүгә дә тиешле әһәмият бирергә тиешбез.

Ә. КӘРИМУЛЛИН.

## *Халык мәзәкләре*

### УЙЛАУ

Бер бай ялчысы белән ярминкәгә бара икән. Юлда боларга кунарга туры килә.

— Хезмәтеңне онытма! Атларны онытып бетермә, урлап китмәсеннәр, — ди бай ялчыга.

Беркадәр ятканнан соң, бай ялчыга дәшә:

— Йокламыйсыңмы?

— Юк, бай, уйлап ятам.

— Нәрсә турында уйлыйсың?

— Җир ничек су өстендә батмый йөзә ала икән. Алай-болай батып куйса, атларыбыз һәлак булмас микән, — дип уйлыйм.

Ярты төннәр җиткәч, тагын сорый бай:

— Әй син, йокламыйсыңмы?

— Юк, бай.

— Һаман уйланасыңмы?

— Уйлыйм. Менә җирне күк белән каплап куйганнар бит инде. Берниндн багана-мазар юк. Әгәр шул атлар өстенә төшә калса, харап булмаслар микән мескеннәр?

Бай тынычлап йокыга китә. Атларны караклар урлый.

— Я, хәзер нәрсә турында уйлыйсың? — дип сорый бай.

— Йөк төягән арба шактый авыр була бит инде ул, атлар булмагач, аны алмаш-тилмәш тартырбыз микән, — дип җавап биргән ялчы.

### ҮЧ

Берәүнең кызы күрше авылда кияүдә икән. Көннәрнең берендә кыз әтисе өенә кайткан да:

— Икенче самоварны эреткән өчен киявең яңагыма суга язды, — дип кычкырып елап җибәргән.

Бик ачуы килгән кебек иткән әти кеше.

— Ул минем кызны рәнҗетә икән, үчне аның хатыныннан алыйм әле, — дигән дә кызын яңакларга керешкән.

### ГОРУРЛЫК НИШЛӘТӘ

Кышкы тар юлда ике бай кара-каршы очрашканнар. Берсенең дә юл бирәсе килми, юл бирсә, дәрәҗәсе төшә, имеш... Менә байларның берсе кучеренә әмер бирә:

«Бар әле, кыйна тегеләрне, югыйсә борыныи бик күтәрә...

Ә теге бай үз кучерен боларны кыйнарга җибәрә. Кучерләр байларны һуштан яздырганчы кыйныйлар да, тату гына кул бирешеп юлларын дәвам иттерәләр...

Бераздан байларның берсе һушына килеп, кучеренә:

— Ну пешердек тегеләрне, әйе бит! — дип мактана икән.

# Яңа китаплар

**Габдрахман Әпсәләмов.**

**АК ЧӘЧӘКЛӘР.**

*Роман. Бәясе 98 тиен.*

Язучы Габдрахман Әпсәләмовның «Казан утлары» журналының узган елгы 1—5 саннарында басылган «Ак чәчәкләр» исемле яңа романын әдәбият сөючеләр яратып укыганнар иде. Роман хәзер китап булып та басылып чыкты. Үзәгендә иң кешелекле профессия вәкилләре— врачлар торган һәм мавыктыргыч сюжетка корылган бу әсәрендә автор геройларының тормышларын һәм эчке кичерешләрен тирәнтен ачарга омтыла. Медицина мәсьәләләреннән тыш, романда мәхәббәт проблемалары да кузгатылган.





**Әмирхан Еники.**

**ӨЧ ПОВЕСТЬ.**

*Бәясе 75 тиен.*

Әсәрләрендә һәрвакыт зур, мөһим проблемалар күтәрү белән беррәттән, гаҗәеп образлы телгә, үзе сурәтләгән образларның бөтен эчке дөньяларын тулы итеп ачып бирә алу осталыгына ия булган язучыларыбызның иң күренеклесе Әмирхан Еники дисәк — һич тә ялгыш булмас. Шуңа күрә дә аның әсәрләрен укучылар көтеп алалар, яратып укыйлар. Ә. Еникинең «Өч повесть» исемле бу җыентыгында «Рәхмәт, иптәшләр!», «Саз чәчәге» һәм «Рәшә» исемле повестьлары басылган.




**Атилла Расих.**

**ИКЕ БУЙДАК.**

*Роман. Бәясе 68 тиен.*

Күп санлы хикәяләре, повестьлары һәм «Язгы авазлар» исемле романы белән укучыларга таныш булган язучы Атилла Расихның «Ике буйдак» исемле яңа романы моңарчы татар язучыларының кулы бөтенләй диярлек тимәгән темага — фән кешеләренең иҗади хезмәтен, аларның уй-хисләрен, тормышларын сурәтләүгә багышланган. Әсәрнең үзәгендә ике яшь галим — Рәхим һәм Заһид образлары. Алар характерлары һәм фәнгә мөнәсәбәтләре ягыннан бер-берсеннән бик нык аерылып торалар. Рәхим һәртөрле кыенлыклардан да курыкмыйча үзенекен эшләргә тырышучы, алга, яңага омтылучы, нык характерлы, чын мәгънәсендәге галим булса, Рәхим, киресенчә, үз карьерасы өчен теләсә нинди хакыйкатьне дә ялган дип танырга әзер торган мәкерле кеше. Романның сюжеты әнә шул әлеге ике галимнең һәм эшләрендә, һәм мәхәббәт мәсьәләсендә үзара мөнәсәбәтләрен ачыклау юнәлешендә үстерелә.




**Ибраһим Салахов.**

**КҮКЧӘТАУ ДАЛАЛАРЫНДА.**

*Роман. Бәясе 62 тиен.*

Казагыстанның Күкчәтау далаларында төзелә башлаган «Алка күл» совхозына парторг итеп билгеләнгән Сәет Батталов, бу совхозга килеп төшү белән, үзенең беренче хатыны Гайшәне оч-

рата. Элек алар бергә институтта укыганнар, берберсен яратышып өйләнешкәннәр. Әмма беренче балалары туар алдыннан, 1937 елны, халык дошманы дип нахак бәла ягып, Батталовны кулга алганнар. Гайшә исә, Сәетнең әйләнеп кайтуына өмет өзеп, кияүгә чыккан һәм, «халык дошманы баласы» дип кимсетмәсеннәр өчен, кызы барлыгын яшереп йөргән.

Хәзер Гайшә — совхоз директорының хатыны, Батталов та өйләнгән. Әмма аларның яшьлек мәхәббәтләре сүрелмәгән. Нишләргә? Тирән кичерешләр һәм фаҗигаләр башлана. Менә шушы сюжет буенча үстерелә торган вакыйгалар барышында совхоз төзелеше, ул совхозны төзүче кешеләрнең характерлары һәм язмышлары сурәтләнә романда.



### Әдип Маликов.
## КЕМБРИГӘ ЮЛ САЛУЧЫЛАР.
*Очерк. Бәясе 25 тиен.*

Әдип Маликов моңарчы укучыларга шагыйрь буларак билгеле иде. Әмма соңгы ике-өч ел эчендә ул проза әсәрләре дә яза башлады. Әле күптән түгел генә аның мәктәп балаларына адресланган «Без кояшны юлда каршылыйбыз» исемле китабы басылган иде, инде «Кембригә юл салучылар» дигән китабы да дөнья күрде. Авторның Себер нефтен чыгаруда катнашучы Татарстан нефтьчеләренең эшен, тормышын сурәтләгән бу китабы шулай ук мәктәп балаларына адресланган. Ләкин ул олылар өчен дә кызыклы һәм мавыктыргыч, чөнки анда Татарстанда яшәүчеләргә таныш булмаган Себер табигате, аның халкының тормыш-көнкүреше шактый киң күрсәтелгән.




### И. Нуруллин.
## ТУКАЙ ПЕТЕРБУРГТА.
*Драма. Бәясе 18 тиен.*

Язучы, тәнкыйтьче һәм әдәбият белгече Ибраһим Нуруллинның сигез картинадан торган бу драмасы татар халык шагыйре Габдулла Тукайның 1912 елда Петербургта булган вакытта кемнәр белән очрашуын, ниләр эшләвен чагылдыра.




Драмада катнашучы егермедән артык персонаж арасында, шул замандагы Петроград байлары, интеллигентлары, журналистлары һәм эшчеләреннән тыш, ул чорда психоневрология институты студенты булган атаклы революционер Мулланур Вахитов образы да бар.

### Шамил Рәкыйпов.
## БАРЫП АЛАСЫ ХАТ.
*Повесть. Бәясе 15 тиен.*

Алар бер авылда туып, бергә үскәннәр. Авыр сугыш елларында беренче мәхәббәтләре бөреләнә башлаган. Әмма бу бөреләр ачылып китәргә өлгерә алмаганнар: яшьләрнең юллары аерылган. Егет, тормышында очраган кыенлыкларны җиңә барып, алга атлаган. Ә кыз, шәхси тормышында очраган күңелсез хәлләр алдында аптырап калып, төшенкелеккә бирелгән. Ул туган авылын ташлап киткән, язмышка, аллага ышанып яши башлаган.




Шамил Рәкыйповның «Барып аласы хат» исемле бу китабында әнә шул ике яшь кеше башыннан кичкән вакыйгалар, алар үткән юллар турында сүз бара.

### Равил Фәйзуллин.
## РӘСЕМ ЯСЫЙМ.
*Шигырьләр җыентыгы. Бәясе 17 тиен.*

Соңгы елларда әдәбиятыбыз мәйданында яшьләр авазы шактый нык ишетелә башлады. Өметле аваз бирүче шул яшьләребезнең берсе — Р. Фәйзуллин. Аның шигырьләре газета һәм журнал битләрендә әледән-әле күренгәләп тора. Инде менә яшь шагыйрьнең «Рәсем ясыйм» исемле беренче китабы дөньяга чыкты. Җыентыкта авторның мәктәпкәчә яшьтәге балаларга адресланган утызлап шигыре тупланган һәм ул әсәрләр һәркайсы балалар хәтере-

нә бик тиз сеңеп калырлык гади, җиңел тел белән язылганнар, шул ук вакытта



нәни укучыларыбызга әйләнә-тирәбездәге әйберләр, күренешләр турында шактый бай мәгълүмат та бирәләр. Җыентыктагы шигырьләргә художник И. Әхмәдиев ясаган иллюстрацияләр дә бик уңышлы чыккан.

### КҮҢЕЛЛЕ СӘХНӘ.

*Җыентык. Бәясе 46 тиен.*

Татарстан китап нәшрияты елның елында үзешчән сәнгать түгәрәкләре өчен «Күңелле сәхнә» исемле җыентык чыгарып килә. Әле күптән түгел генә «Күңелле сәхнә»нең унбишенче китабы басылып чыкты. Ю. Әминов, Ш. Рәкыйпов, Р. Батуллин, Г. Сагыйдуллин, М. Усманов, Ш. Хөсәенов, Э. Шамиль пьесалары; Г. Мөхәммәтшин, М. Рафиков, К. Фәсәхов, С. Кальметов, Э. Касыймов, Х. Гобәйдуллин, Д. Аггрей, Н. Фәттах хикәяләре; Г. Афзал, С. Баттал, Г. Шамуков, З. Нури, М. Кәримов, Ә. Баянов, Ә. Камал, Ш. Галиев, М. Саттаров, К. Фәсәхов, И. Фазлуллин һәм М. Газизовларның юмористик, сатирик шигырьләре тупланган әлеге җыентыкны укып чыккач, шундый фикер күңелгә килә: «Күңелле сәхнә»нең бу китабы башка еллардагыларына караганда кызыклырак һәм байрак эчтәлекле булып чыккан. Үзешчән сәнгать түгәрәкләренә яхшы бүләк булыр ул. Шул ук вакытта





аны әдәбият сөюче укучылар да яратып укырлар.

### Ш. Рахманкулов.
### ФАТЫЙМА КАМАЛОВА.

*Очерк. Бәясе 6 тиен.*

Үз гомеренең кырык биш елын сәхнәдә үткәргән, татар театр сәнгатен үстерүгә зур өлеш керткән, Татар-





станның атказанган һәм халык артисткасы, РСФСР-ның халык артисткасы дигән мактаулы исемнәрне яулап алган Фатыйма Камалованың тормыш һәм иҗат юлы турында сөйли бу китапчык. Китап артистка төрле рольләрне башкарган вакытта төшереп алынган фоторәсемнәр белән дә иллюстрацияләнгән.

### РАССКАЗЫ 1964 ГОДА.

*Җыентык. Бәясе 21 тиен.*

Татар язучыларының иң яхшы хикәяләрен русчага тәрҗемә иттереп, елныкын елга бер җыентыкка туплап чыгару — Татарстан китап нәшриятының әйбәт традициясенә әйләнеп китте. Бу, бер яктан, язучыларыбыз иҗаты белән тугандаш рус халкын таныштырып баруга ярдәм итсә, икенче яктан, татарча укый белмәгән татар балаларына бүгенге әдәбиятыбыз турында мәгълүмат бирү юнәлешендә дә бик файдалы эш.




Әле яңарак кына басылып чыккан «Рассказы 1964 года» исемле җыентыкны да нәк шул яктан хупларга кирәк. Уники әсәрдән торган бу китапта А. Шамов, Ә. Еники, Ф. Хөсни, Г. Галиев, А. Гыйләҗев, Ә. Ихсанова, С. Сабиров, Н. Дәүли, Г. Минский, Г. Мөхәммәтшин, Б. Камалов хикәяләре урнаштырылган.

**Бу китапларны һәм гомумән үзегез укырга теләгән барлык татар язучылары китапларын түбәндәге адрес буенча хат язып, соратып алдырырга мөмкин:**

*г. Казань, Баумана, 19, Таткниготорг, отдел «Книга — почтой».*

**Редакция укучыларга китап җибәрү белән шөгыльләнми.**

# Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары

## СЪЕЗДДАН СЪЕЗДГА

КПССның XXIII съезды барган көннәрдә Казан кинотеатрларында, культура сарайларында һәм клубларында «Советлар иле съезддан съездга» девизы астында тематик фестиваль үткәрелде. Фестиваль барышында язучы Г. Серебрякованың «Ут урлау» романы буенча эшләнгән «Гомер хәтле бер ел» исемле, киң форматлы, ике сериядән торган яңа фильм күрсәтелде. Әсәр Карл Маркс һәм Фридрих Энгельсның яшьлек елларына багышлана. Сценарий авторлары Галина Серебрякова һәм Григорий Рошаль. Режиссеры — Г. Рошаль. Рольләрне И. Кваша, А. Миронов, Р. Нифонтова, А. Алексеев, В. Ливанов, С. Столяров һәм башка артистлар башкара.

Тамашачылар шулай ук «Мосфильм» (СССР) һәм «Студио» (Польша) иҗади коллективлары эшләп чыгарган «Ленин Польшада» фильмын карадылар. Бу әсәрдә В. И. Ленин образын танылган артист М. Штраух тудырган. Бүтән рольләрдә А. Лисянская, А. Павлычева, Э. Феттинг, И. Кусьмерска, К. Кальчинский катнаша.

Репертуарда «Барысы да кешеләргә кала», «Гөнаһлы фәрештә», «Яшәгән ди карт белән карчык», «Таныш булыгыз, Балуев!», «Безнең йорт», «Палата», «Кеше исән чакта», «Председатель» кебек инде халыкка таныш булган художестволы фильмнар белән берргәттән, күп кенә документаль һәм фәнни-популяр фильмнар урын алган иде.

## В. В. НИКОЛАЕВА-ТЕРЕШКОВА һӘМ Г. К. МОСОЛОВ МАТБУГАТ ЙОРТЫНДА



Республикабыз башкаласына якташыбыз, атаклы очучы, Советлар Союзы Герое Георгий Константинович Мосолов һәм дөньяда беренче хатын-кыз космонавт Советлар Союзы Герое Валентина Владимировна Николаева-Терешкова килде. Алар Татарстан өлкә комсомол конференциясендә катнаштылар. Казан гарнизоны сугышчылары, В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты студентлары белән очраштылар һәм шәһәрне карап йөрделәр.

Кадерле кунаклар 17 март көнне журналистлар һәм язучылар янына, матбугат йортына килделәр. Язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында В. В. Николаева-Терешкова космонавтларның эше, укуы һәм тормышы турында сөйләде.

— Мин Казанда,— диде В. В. Николаева-Терешкова,— моннан 10 ел элек булган идем. Аның тарихи һәм истәлекле урыннары белән танышкан идем. Шәһәр миңа ул чагында да ошаган иде. Хәзер ул тагын да матурланган, тәзекләндерелгән.

Ахырда батыр «Чайка» сорауларга җаваплар һәм күп кенә автографлар бирде. Аннары Г. К. Мосолов кыска речь белән чыкты.

Бу очрашудан соң «Социалистик Татарстан» һәм «Советская Татария» газеталарының берләшкән редакциясендә В. В. Николаева-Терешкова Ярославль шәһәрендә танышкан дусты Тамара Петровна Сапарова белән күреште. Т. П. Сапарова 1956 елда «Красный Перекоп» текстиль комбинатында практика үткән.

Кунаклар шул ук көнне Казанның дүртенче тегү фабрикасында һәм Казан авиация институтында булдылар.

## НИКОЛАЙ ОСТРОВСКИЙ ИСЕМЕНДӘГЕ...

Бөек Октябрь социалистик революциясенең 50 еллыгына багышлап, ВЛКСМ Үзәк Комитеты, СССР язучылар союзы, ВЛКСМ Үзәк Комитетының «Яшь гвардия» нәшрияты Николай Островский исемендәге әдәби конкурс үткәрергә карар бирделәр.

Конкурсның төп темасы һәм әсәрләрнең герое безнең яшь замандашыбыз, тырыш, иҗади хезмәт иясе, хыялга бай эшче, романтик колхозчы, студент, мәктәп укучысы, интеллигент, комсомол активисты, совет сугышчысы,— коммунистик җәмгыять төзүдә актив катнашучы олы һәм гүзәл җанлы кеше булырга тиеш.

Конкурска профессиональ язучылар белән бергә башка профессия кешеләре дә катнаша ала.

Барлык жанрларда язылган әсәрләр: романнар, повестьлар, поэмалар, шигырь, хикәя һәм очерк җыентыклары кабул ителә.

Конкурс ике этапта үткәрелә: хәл ителеп бетмәгән беренче нәтиҗәләр 1966 ел азагында, ә соңгы нәтиҗәләр 1967 елның 7 ноябрендә ясала. Җиңүчеләргә 2500 әр сумлык ике беренче премия; 1200 әр сумлык ике икенче премия һәм 700 әр сумлык дүрт өченче премия билгеләнгән.

Жюри тарафыннан иң яхшы дип табылган әсәрләрнең авторларына Николай Островский исемендәге конкурс лауреаты медале һәм премия, ә яхшы дип билгеләнгән әсәрләр өчен бәяле бүләкләр бирелә.

Конкурска әсәрләр тапшыруның соңгы срогы —1966 елның 30 августы.

Жюри яхшы дип билгеләгән барлык әсәрләр «Молодая гвардия» нәшриятында басылачак.

## РОССИЯ БҮЛӘКЛӘРЕ

РСФСР Министрлар Советы әдәбият, сәнгать һәм башкару осталыгы өлкәсендә РСФСР Дәүләт премияләре комиссиясе составын раслады. Аңа Россия федерациясе әдәбияты һәм сәнгатенең күренекле эшлеклеләре кертелгән. Комиссиянең председателе В. И. Кочемасов.

Шулай ук лауреатларга бирелəчәк мактау значоклары үрнәкләре һәм аларның тасвирламалары расланды. Значокларның алгы ягында М. Горький, И. Репин, К. Станиславский, М. Глинка, бертуган Васильевлар рәсемнәре төшерелә.

Беренче тапкыр Дәүләт премияләре 1960 елның 1 январеннан 1965 елның 15 июненә кадәрге вакыт эчендә матбугатта басылып чыккан, җәмәгатьчелек каршында башкарылган һәм күрсәтелгән иң күренекле әсәрләргә бирeләчәк. Комиссия карамагына хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләүгә булышлык итә торган, социалистик реализм принципларына җавап биргән, җәмәгатьчелек тарафыннан киң танылган хезмәтләр һәм әсәрләр кабул ителә.

## КИНО БӘЙРӘМЕ

Күптән түгел Казанда «Ленфильм» студиясе эшләп чыгарган кинофильмнар фестивале үткәрелде.

Студия мастерлары Казанның «Татарстан», «Родина», «Победа», «Спутник» кинотеатрларында, В. И. Ленин исемендәге культура сараенда тамашачылар белән очраштылар. Кунак булып килгән кинематографистлар группасы җитәкчесе, «Ленфильм» студиясенең 1 нче иҗади берләшмәсе директоры Б. Гринер коллективның иҗат планнары турында сөйләде.

— Безне Казан белән,— диде ул,— дуслык җепләре бәйли. Без Казанда Ленин турындагы «Беренче Бастилия» фильмын төшердек һәм Муса Җәлил турындагы фильмны эшләүгә керешәбез.

Тамашачылар режиссерлардан М. Ершов, С. Микаэлян, Л. Быков, дүрт халыкара фестивальдә катнашкан артистка Л. Чурсина, РСФСРның атказанган артистлары В. Чекмарев һәм А. Демьяненко белән очраштылар.

## ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ПРЕМИЯ

Минзәлә районының Тукай исемендәге колхоз членнары татар халкының сөекле шагыйре Габдулла Тукай юбилее уңае белән, быелдан башлап, Тукай премиясе булдырырга карар бирделәр. Ул игенчелектә һәм терлекчелектә иң югары күрсәткечләргә ирешкән ике алдынгыга 150 шәр сум итеп бирeләчәк.

Бүләк белән бергә хезмәт алдынгысына колхозның Тукай премиясе лауреаты дигән мактаулы исем бирeләчәк һәм диплом тапшырылачак.

## ОРЕНБУРГ ТАТАР ТЕАТРЫНА —40 ЕЛ

Шушы елның 25 январенда М. Горький исемендәге рус драма театры бинасында Оренбург өлкә филармониясе каршындагы татар драма театрының 40 еллыгына багышланган кичә уздырылды. Башта С. Кайтов һәм Н. Асанбаевларның «Ана йөрәге» пьесасы буенча эшләнгән спектакль күрсәтелде. Кичәнең икенче яртысында 40 еллык иҗат эшчәнлеге белән котлап төрле өлкәләрдән килгән телеграммалар, котлаулар укылды.

## ЧУВАШ ТЕЛЕНДӘ

«Ялав» («Байрак») журналын чуваш укучылары көтеп алалар. Әдәбият сөючеләр журналның январь санын зур кызыксыну белән укыдылар. Ул татар совет әдәбиятына багышланган иде. Журналда Гомәр Бәшировның «Таң атканда» романынннан «Ямьле тугай» дигән өзек, Габдрахман Әпсәләмовның «Зәңгәр иртә», Габдрахман Минскийның «Ярату» исемле хикәяләре, Шәраф Мөдәррискең «Аврора крейсеры», Әхмәт Ерикәйнең «Иркәмә», Мөхәм-

мәт Садриның «Күзгә уйлар», Әхсән Баяновның «Киләчәк көн», Зәки Нуриның «Туган илем» шигыре һәм Кави Латыйпов шигырьләре бар. Аларны чуваш теленә Александр Калган, Николай Евстафьев, Николай Сандров, Юрий Петров, Юхма Мишши, Кави Юлдашев тәрҗемә иткән.

## «СОҢГЫ ХАТ» СПЕКТАКЛЕ

Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры драматург Хәй Вахитның «Соңгы хат» драмасын сәхнәгә куйды. Беренче спектакль 21 март көнне күрсәтелде. Рольләрне артистлардан Наил Дунаев, Асия Галиева, Әзһәр Шакиров, Гәүһәр Камалова, Фирдәвес Әхтәмова, РСФСРның һәм ТАССРның халык артисты Габдулла Шамуков, ТАССРның атказанган артисты Гали Надрюков башкарды. Спектакльләрдә шулай ук артистлардан Р. Тажетдинов, Х. Искәндәрова, Н. Гәрәева, Ә. Гобәйдуллин, Тукай премиясе лауреаты Ф. Кульбарисов, ТАССРның атказанган артисткасы М. Миңлебаева катнаша.

Әсәрне сәхнәгә режиссер М. Сәлимҗанов куйган. Декорацияне Тукай премиясе лауреаты Ә. Тумашев эшләгән. Музыкасы — композитор Х. Вәлиуллинныкы.

## ҮЗЕШЧӘН СӘНГАТЬ СМОТРЫ

РСФСР Министрлар Советының «1967 елда үзешчән сәнгатькә Бөтенроссия смотры үткәрү» турындагы карары нигезендә ТАССР Министрлар Советы республика үзешчән сәнгать көчләренә смотр игълан итә. Смотрны районнарда һәм шәһәрләрдә 1966 елның декабрена кадәр үткәрергә карар бирелде. 1967 елның февралендә Казанда йомгаклау концерты булачак.

Республика үзешчән сәнгать смотрына җитәкчелек итү өчен ТАССР Министрлар Советы председателе урынбасары Р. Ю. Ярмөхәметова җитәкчелегендәге оештыру комитеты составы расланды.

## ИҖАДИ ХЕЗМӘТ ӨЧЕН

Татарстан АССР Верховный Советы президиумы совет театр сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен һәм иҗади эшчәнлегенең илле еллыгы уңае белән РСФСРның атказанган артисткасы һәм Татарстан АССРның халык артисткасы Фатыйма Ильскаяны Почет грамотасы белән бүләкләде.

## «ЯҢА КЕШЕ ӨЧЕН КӨРӘШТӘ ОЧЕРК»

15 марттан 18 енә кадәр Көньяк Уралның индустриаль үзәге Чиләбе шәһәрендә, РСФСР язучылары союзы идарәсенең секретариат утырышы булып үтте. Партиябезнең XXIII съезды алды көннәрендә үткәрелгән бу утырышта әдәбиятның иң сугышчан жанры булган очерк проблемалары һәм аның яңа кеше тәрбияләүдәге бурычлары И. Котенко, Н. Горбачев, И. Виниченко, В. Канторович, Р. Бикмөхәммәтов докладларында; В. Чивилияни, М. Золотогов, Г. Морягин, Б. Ручьев, Е. Лушницкий, В. Туркин, Я. Вахминцев һ. б. ларның чыгышларында тирәнтен ачылды, соңгы елларда Ленинград, Себер, Идел буе, Урал, Ерак Көнчыгыш язучылары язган очеркларга анализ ясалды.

Секретариат утырышына Ленинград, Мәскәү, Калуга, Архангельск, Воронеж, Омск, Новосибирск, Якутия һ. б. шәһәрләрдән, республикалардан йөздән артык очеркист җыелган иде. Татарстаннан утырышка М. Хәмитов катнашты.

Утырыш барышында язучылар Чиләбе шәһәре предприятиеләрендә, югары уку йортларында, мәктәпләрдә чыгышлар ясадылар. Соңыннан өлкәнең Магнитогорск, Златоуст, Чибәр күл, Миасс, Кошак шәһәрләрендә һәм районнарында булдылар.

## КИТАПХАНӘ ЮБИЛЕЕ

Быел февраль аенда Чиләбе шәһәрендәге татар-башкорт китапханәсе оештырылуга 60 ел тулды. Бәйрәм тантанасына Татарстаннан язучы А. Расих барды. Ул икенче көнне әдәби түгәрәк членнары белән очрашты, Чиләбе трактор заводында булды, тимер юл эшчеләре белән әңгәмә үткәрде.

## «КАЗАН УТЛАРЫ» УКУЧЫЛАРЫ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

19 мартта Чиләбе шәһәренең татар-башкорт китапханәсе залында «Казан утлары» журналы буенча укучылар конференциясе үткәрелде. Журнал редакциясеннән килгән Малик Хәмитов конференциягә катнашучыларны журналда басылган һәм басылачак әсәрләр, аның планнары һәм үткәне белән таныштырды, бүгенге татар әдәбиятының торышы һәм аерым язучыларның иҗаты турында сөйләде.

Китапханә эшчесе Җ. Шәймәрданова С. Батталның журналда басылган «Чирмешән якларында» шигъри романын, Ш. Маннурның «Муса» романын, А. Расих әсәрләрен, Ш. Галиев, Г. Афзал шигырьләрен яратып укуы турында сөйләде. Ф. Хөснинең соңгы елларда язылган кайбер хикәяләрендә хәзерге заманның җитди тормыш күренешләренә игътибар азлыгы турында әйтте. Шулай ук эшчеләрдән Римма Хәйруллина, Роза Мөхәммәтшина, Фәрит Хәсәнов, китапханә директоры Райхәнә Газиева үзләре яратып укыган әсәрләр турында, Чиләбедә яшәүче күп санлы татар хезмәт ияләренә культура хезмәте күрсәтүне үстерү кирәклеге хакында сөйләделәр.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Казанның Ленин районындагы Пионерлар сараена Биектау районы мәктәпләреннән бер төркем укучылар әдәби кичәгә килделәр. Алар каршында шагыйрь Нәби Дәүли чыгыш ясады: үзенең язылган әсәрләре турында сөйләде, иҗат планнары белән уртаклашты.

* * *

Питрәч районының Вахитов исемендәге колхозында культура университеты эшли. Аның чираттагы җыелышы яшь авторлар иҗатына багышланган иде. Кичәдә К. Фәсәхов, М. Рафиков, А. Сәләхетдинов, Р. Әхмәтҗанов, М. Садыйков булдылар.

* * *

Яшь шагыйрь Рәдиф Гатауллин Мөслим районының Бүләк, Урәзмәт, Сикия авылы мәктәпләренә барып, әдәби кичәләр үткәрде. Аннары Уфа шәһәрендә, Башкортстанның Миякә районында булды.

* * *

Казанның Дербышки поселогындагы культура сараенда язучы Ә. Еникинең «Өч повесть» исемле китабы буенча укучылар конференциясе оештырылды. Конференциягә автор үзе дә килгән иде.

* * *

Казанның 89 нчы мәктәбе укучылары, Совет Армиясе көненә багышлап, әдәби кичә оештырдылар. Кичәгә язучылардан Ш. Бикчурин, К. Фәсәхов һәм А. Сәләхетдинов катнашты.

* * *

14 марттан 19 мартка кадәр Чувашстан АССРның Батыр районында татар һәм чуваш әдәбиятлары дуслыгы атналыгы булып үтте. Атналыкта татар язучылары Илдар Юзеев, Газиз Мөхәммәтшин, Кави Латыйпов, чуваш язучылары Георгий Ефимов, Александр Калган, Петр Львов, Юхма Мишши, Александр Галкин, Николай Терентьев, Педер Хузангай, җырчы Мефодий Денисов катнашты.

Район хезмәт ияләре, электән килгән гадәт буенча, кунакларны ипи-тоз белән каршы алдылар.

Татар һәм чуваш әдәбиятлары дуслыгы атналыгы Кызыл Чишмә авыл Советының «Ленинец» колхозында башланды.

«Герой» колхозында татар яшьләре чуваш кунакларына, ә чуваш яшьләре татар кунакларына ак сөлгеләр бүләк иттеләр. Сөлгеләрдә «Кунакларга «Герой» колхозы эшчәннәреннән» дигән сүзләр чигелгән.

Первомайск урта мәктәп укучылары Г. Мөхәммәтшин, К. Латыйпов, И. Юзеев, Г. Ефимов, А. Калган, П. Львов, Ю. Мишши, А. Галкинны почетлы пионер итеп кабул иттеләр.

Татар һәм чуваш язучылары Первомайскида чуваш халкының атаклы шагыйре Митта Васли каберенә делегацияләр исеменнән чәчәкләр куйдылар.

Первомайск урта мәктәбендә оештырылган музейда язучылар Репин шәкерте художник Кокель, Митта Васлиның тормыш һәм иҗат юллары белән таныштылар, музейның почетлы кенәгәсенә кулларын куйдылар.

Атналыкның йомгаклау кичәсе Батыр район үзәгенең культура йортында булды. КПССның Батыр район комитетының беренче секретаре В. Тимошев хезмәт ияләре арасында татар һәм чуваш әдәбиятын эшлекле пропагандалаган өчен, КПССның район комитеты һәм район советы исеменнән, язучыларга Мактау грамоталары тапшырды.

Атналык арасында республика һәм район газеталарында татар һәм чуваш язучыларының әсәрләре басылды, радиолардан яңгырады, атналык барышы телевидениедән күрсәтелде.

●

## Мәсгут Шәрифуллин

**Озакка сузылган каты авырудан соң талантлы яшь язучы, СССР әдәби фондының Татарстан бүлеге директоры Мәсгут Шәрифуллин вафат булды. Кыска гына иҗат чоры эчендә ул күп кенә хикәяләр, «Еллар үткәч» повесте һәм «Туганнар» исемле драма язды.**

**Авыр сугыш елларында колхозда эшләгән яшүсмер Мәсгут Совет Армиясендә хезмәт итеп кайтканнан соң заводта эшли, Казан художество училищесын тәмамлый, татар академия театрында художник булып эшли. Мәскәүдә, М. Горький исемендәге институтта, югары әдәбият курсларында укып кайта. Һәрвакыт тормыш эчендә кайнаган Мәсгут Шәрифуллин иҗатында үзе яхшы белгән замандашларын гәүдәләндерде. Талантының тагын да киңрәк колач белән ачыла барган, зур иҗат планнары белән канатланып яшәгән чагы иде аның. Вакытсыз үлем каләмдәшебезне язылачак яңа әсәрләре белән бергә безнең арабыздан алып китте.**

**Хуш, каләмдәш дустыбыз. Синең якты истәлегең безнең йөрәкләрдә гомергә сакла
ныр.**

**БЕР ТӨРКЕМ ИПТӘШЛӘРЕ.**

# *Укучылар игътибарына:*

«Коръән серләре»нең 2, 3 саннарда басылган өлешләрендә редакция гаебе белән кайбер хаталар киткән. Мәсәлән: «Кешеләр белән шайтаннарны гына түгел, бу эшкә фәрештәләрне дә өйрәтә **ала»** (№ 3, 85 бит). Дөресе: «Кешеләр белән шайтаннарны гына түгел, бу эшкә фәрештәләрне дә өйрәтә **алла»**.

«...**ала** сүзе булып Тәуратка кереп утыра». Дөресе: «...**алла** сүзе булып Тәуратка кереп утыра» (№ 2, 58 бит).

«Әллә очынып китеп, сычкан ясап ташлый». Дөресе: «...**Алла,** очынып китеп, сычкан ясап ташлый». «...**кяферләрнең** алтын-көмешләрен сорап торалар» (№ 2, 83 бит). Дөресе: «...**кяфирәләрнең**...»

**«Кяферләр дә**... ахмак булып чыга» (№ 2, 83 бит). Дөресе: **«...кяфирәләр дә...»**

**«Тәфсил** казый» (№ 3, 87 бит). Дөресе: **«Тәфсир** казый».

«Тәфсир сүрәсе» нәҗем (101 бит). Дөресе: «Тәфсир сурәтел нәҗем».

«...Канганнан Ханан җиренә качып барышлый...» (№ 2, 69 бит). Дөресе: «...**Харан** җиренә...»

«Луз дигән шәһәр иске китапларда булса да, дөньяда юк» (№ 2, 69 бит). Дөресе: «...**изге** китапларда булса да...»

«Дини язучылар бу аятьтән алып шундый әкият уйлап чыгарганнар» (№ 3, 86 бит). Дөресе: «...бу аятьтән **илһам** алып...»

«...Сара белән Мысыр патшасы кебек...» (№ 2, 60 бит). Дөресе: «Сара белән Мысыр патшасы **романы** кебек».

«...Мусаның шунда борылып каравы була, **ә** биһуш булып егыла». (№ 2, 74 бит). Дөресе: «...Мусаның шунда борылып каравы була, **һәм** биһуш булып егыла».

«...үзенә ышандыру өчен Мөхәммәт төрле чаралар кулланып карый». «Бу ышануның файдалы икәнен тасвирлап сүрә арты сүрә иңдерергә керешә» (№ 3, 92 бит).

Шушы ике җөмлә арасына бит ахырында бирелергә тиешле искәрмә килеп кергән. Шуларны төзәтеп укуыгызны сорыйбыз.

**РЕДАКЦИЯ.**

Җаваплы редакторы **Рафаэль Мостафин**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Ибраһим Гази, Әмирхан Еники, Гази Кашшаф, Шәйхи Маннур, Габдрахман Минский, Сибгат Хәким, Нил Юзиев**

Производствога бирелде 15/III-1966 ел. Басарга кул куелды 15/IV-1966 ел. ПФ 15001. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 36 800 экз. Заказ Н-395. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1966 ел.

Цена 10 коп.
Бәясе тиен

Индекс
73210

*Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал*

# КАЗАН УТЛАРЫ

*(Огни Казани)*

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ